ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

11.1987



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**11**

**1987**


## *Бу санда*


БӨЕК ОКТЯБРЬНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

Ш. Ә. МУСТАЕВ. Октябрьдән нур алып 3

Н. АРСЛАНОВ. Котлау. *Шигырь* 12
Н. ДӘҮЛИ. Октябрь байрагы. *Шигырь* 13
Я. ЧАНЫШЕВ. Казан Кремлен штурмлау. *Истәлек* 14
Р. ИШМОРАТ. Гомер сукмаклары. *Истәлекләр* 25

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

В. ТЕЛЬПУГОВ. Якшәмбегә каршы төндә 51
А. СИИГ. Чүплек. *Шигырь* 55
А. ПАРПАРА. Ватан турында уй. *Шигырьләр* 57
М. КАРАБАЕВ. Тулган ай. *Шигырьләр* 57
С. КУДАШ. Робагыйлар 59

Р. МИҢНУЛЛИН. Кунакка килегез. *Шигырьләр* 62
М. ХУҖИН. Урак өсте болытлары. *Повесть* 66
Ә. РӘШИТОВ. Кем җырлады? *Шигырьләр* 121

Т. ӘЙДИ. Дәртле, дәрманлы әдип. *Мәхмүт Хәсәновка 60 яшь* 125
М. ХӘСӘНОВ. Сыймас Садри. *Хикәя* 126

И. НИЗАМОВ. Бер карадым... *Парчалар* 144
Ә. ГАДЕЛ. Сөю. *Шигырьләр* 156
Ә. ЕНИКИ. Касыймга сәяхәт 158

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

А. В. ЯКОВЛЕВ. Күлләрдән — Иделгә! *(Лаеш районы)* 166

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Яшьләр бәхәсләшә. *Яшь тәнкыйтьчеләр — Р. Әхмәтҗановның «Бишташ» поэмасы турында* 169

БИБЛИОГРАФИЯ

И. ТАҺИРОВ. Бишенче елны уяндык таң белән 175



КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

Х. МӘХМҮТОВ. Көрәшкә рухландырган җырлар 178
З. ШАКИРОВ. Революция солдаты, журналист һәм галим 184

ОРЕНБУРГТА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

З. МӨХӘММӘТҖАНОВА. «Урал» газетасы басылган йорт 188
Җ. МИҢНУЛЛИН. «Урал» һәм уралчылар 189

Культура тормышы көндәлеге 190

Тышлыктагы сурәтләр 192

*Баш редактор*

**РЕНАТ ХАРИС**

*Редколлегия*

**МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ**
**ӘХӘТ ГАФФАР**
**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**
**АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ**
**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ**
**МӘДИНӘ МАЛИКОВА**
**САЛИХ МАННАПОВ**
*(җаваплы секретарь)*
**ТУФАН МИҢНУЛЛИН**
**ФЛҮН МУСИН**
**РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ**
*(баш редактор урынбасары)*
**РӘФЫЙК НӘФИКОВ**
**НУРИХАН ФӘТТАХ**
**РИЗВАН ХӘМИД**
**НИЛ ЮЗИЕВ**
**АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН**

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор —53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь —53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк —53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар —53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«К 70-летию Великого Октября». Статья Председателя Президиума Верховного Совета Татарской АССР Ш. А. МУСТАЕВА — «Свет Октября». Н. АРСЛАНОВ, Н. ДАУЛИ — стихи о Родине. Воспоминания генерал-лейтенанта в отставке Я. ЧАНЫШЕВА об октябрьских днях в Казани. «Дружба литератур — дружба народов» — рассказ В. ТЕЛЬПУГОВА, стихи А. СИИГ, А. ПАРПАРА, М. КАРАБАЕВА, С. КУДАША.
Х. МАХМУТОВ «Песни, вдохновлявшие к борьбе». З. ШАКИРОВ. «Солдат революции, журналист и ученый».
Р. ИШМУРАТ. «Тропы жизненные». Воспоминания. Повесть М. ХУЗИНА «Облака страдной поры». Рассказ М. ХАСАНОВА «Неугомонный Садри». Литературные зарисовки И. НИЗАМОВА. Стихи Р. МИННУЛЛИНА, А. РАШИТОВА, А. АДИЛЯ.
В рубрике «Татарстан — родной мой край» — статья первого секретаря Лаишевского РК КПСС А. В. ЯКОВЛЕВА.
«Литературная критика» — начинающие критики обсуждают поэму Р. АХМЕТЗЯНОВА.
«Библиография»: рецензия И. ТАГИРОВА на сборник И. Абдуллина «Боевое большевистское слово».
«Памятники татарской культуры в Оренбурге». Дом, где печаталась газета «Урал».
На первой странице обложки — картина Л. ФАТТАХОВА и Х. ЯКУПОВА «Провозглашение Советской власти в Казани»
На четвертой странице обложки — памятник С. М. Кирову в Казани.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Г. Салихҗанова, А. Садыйкова.*

Производствога бирелде 7.09.1987 ел. Басарга кул куелды 3.11.1987 ел. ПФ 05390. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 66849. Заказ М-402. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1986 ел.

**Ш. Ә. Мустаев,**
Татарстан АССР Верховный Советы
Президиумы председателе.

# ОКТЯБРЬДӘН НУР АЛЫП

Көннәрне — көннәр, елларны еллар алыштыра. Чорларны чорларга тоташтырып агучы елларның һәрберсенең үзенә хас тантаналары, бәйрәмнәре бар. Бәйрәмнәр күп. Аларның да һәрберсенең үзенә хас төсмере, үзенчәлеге була. Тик бусы — барлык бәйрәмнәребезнең нигезе, юл башы. Әгәр дә Октябрь бәйрәме булмаса, башкалары да бөтен халык бәйрәменә, азатлык алган хәр күңелле кешеләрнең эчкерсез тантанасына әверелә алмас иде.

Нәкъ менә Бөек Октябрь социалистик революциясе халыклар тормышын тамырдан үзгәртеп корды; социаль һәм милли изүдән коткарып кына калмады, хокуксызлык һәм хәерчелектән — социаль һәм милли иңарыш юлына, наданлык һәм томаналыктан — мәгърифәт үрләренә, фән һәм культура үсешенә, зәгыйфь промышленность һәм артта калган авыл хуҗалыгыннан — индустрия гигантларына, механикалаштырылган колхоз-совхоз хуҗалыгына алып чыкты.

Нәкъ менә Бөек Октябрь социалистик революциясе илебездәге йөзләрчә башка халыклар белән бергә татар халкына да киң юллар, иксез-чиксез мөмкинлекләр ачты. Моннан җитмеш ел элек кенә Казан губернасы патша Россиясенең иң изелгән һәм ачлык-хәерчелектән җәфа чиккән ярымколониаль төбәге булган. Бүгенге Татарстан АССР исә, тигез хокуклы башка республикалар арасында, үзенең алдынгы фәне һәм промышленность куәте, мул уңыш үстерүче игенчеләре, абруе ерак-еракларга таралган әдәбияты һәм сәнгате белән дан тота. Дусларыбыз да, дошманнарыбыз да моны яхшы белә. Октябрь казанышларына күз йому мөмкин түгел.

Әйе, һәрберебез диярлек республикабыз Татарстанны яхшы беләбез дип исәплибез. Бер уйласаң, бәлки, ул шулайдыр да. Чынлап та, аның революциягә кадәрге чоры, революцион үткәне, күренекле вакыйгалары һәм данлыклы кешеләре күбебезгә дәреслекләр буенча, әдәби һәм фәнни-популяр әсәрләр буенча билгеле. Ә республиканың бүгенгесе исә һәммәбезнең күз алдында. Әмма чын мәгълүмат ул чагыштырулар нигезендә генә барлыкка килә. Әйдәгез, үткәннәргә күз салыйк, бүгенгене алар яктылыгында, Октябрь революциясе балкышыннан иңгән нурлар яктылыгында барлап карыйк. Кем идек тә кем булдык? Бу сүзләр риторик эндәш кенә түгел. Нибарысы бер кеше гомеренә тиң чор республикабызга нинәрсә биргән, нинди үзгәрешләр алып килгән?! Уйласаң — уйларлыгы, соклансаң — сокланырлыгы, горурлансаң, горурланырлыгы бар!

Революциягә кадәр Казан губернасы промышленносте авыл хуҗалыгы чималын эшкәртүче 198 кустарь һәм ярымкустарь предприятиедән гыйбарәт булган. Аларда, нигездә, шәм, сабын, чыпта, кәрзин кебек әйбер-

ләр ясалган. Җан башына промышленность әйберләре җитештерү тулаем Россия күләмендәгедән дүрт тапкырга кимрәк, ә Казан эшчеләренең хезмәт хакы Үзәк Россиядәге эшчеләрнекеннән якынча 25 процентка түбәнрәк булган.

Авыл халкының хәле исә тагын да аянычрак. Гомере буе нужадан башы чыкмаган авыл агае сука белән җир ерткан, агач тырма белән җир тырмалаган. Шулай булмый хәле дә юк. Барлы-юклы имана җирендә нәрсә генә иксен дә нәрсә генә үстерсен соң ул?! Һәр өченче йортта хәтта ат та булмаган. 853 эре җир биләүче 200 мең крестьянга караганда күбрәк сөрүлек җиргә, болыннарга, урман-әрәмәлекләргә хуҗа булып торган заманда аңа алпавытларга, кулакларга бил бөгүдән башка чара калмаган да. Мәҗбүри хезмәтнең, ярым кол хезмәтенең кайчан яхшы нәтиҗәләргә китергәне бар?!

Азат хезмәткә сусаган халык, чын мәгънәсендә, могҗизалар тудырырга сәләтле. Бүгенге Совет Татарстанында җитештерелгән промышленность продукциясе иксез-чиксез илебезнең барлык төбәкләренә җибәрелә, аларны дөньяның сиксән илендә көтеп алалар. Илебездә чыгарыла торган полиэтиленның һәр дүртенче тоннасы, кино-фотопленканың һәр икенче метры бездә эшләнә. Пластмасса, сумала, шин, нефтехимия һәм вакуум җиһазлары, синтетик каучук, суыткыч җайланмалар, компрессор һәм медицина инструментлары, сәгать һәм үлчәү приборлары, тагын башка бик күп әйберләрдә «Татарстанда ясалды» дигән мөһер тора. Дөнья күгендә Казан самолетлары һәм вертолетлары да оча, чиге-кырые күренмәгән юлларда «КамАЗ» машиналары чаба. Җир асты торбалары буйлап, ил экономикасына көч һәм шифа биреп, җир мае агыла. Халыкара «Дуслык» нефть үткәргече шулай ук Татарстанда башлана. Әйтерсең лә Октябрьдә азатлык алган республикабыз шул торбалар аша тугандаш илләргә дә үзенең җан җылысын бирә, көче һәм куәте белән уртаклаша.

«Органик синтез», «Казаньрезинотехника», «Тасма», Түбән Камадагы «Нефтехим», «Шин» берләшмәләре, С. М. Киров исемендәге синтетик каучук заводы һәм башкалар синтетик каучук, шин, полиэтилен һәм кинофотопленка җитештерү буенча илдә төп предприятиеләргә әйләнделәр.

Ягулык-энергетика куәте турында аерып әйтәсе килә. 1986 елга республикабызның җир асты тирәнлекләреннән 2 миллиард 298 миллион тонна кара алтын чыгарылды. Менә ун ел инде Татарстан нефтьчеләре Көнбатыш Себер киңлекләрен үзләштерәләр. Халыклар дуслыгы, аларның эчкерсез ярдәмләшүе һәм хезмәттәшлегенең ачык чагылышы бу.

Үз вакытында илебезнең барлык халыклары Татарстанга ярдәм кулын сузган иде. Беренче бишьеллыклар чорында да шулай булды, бүген дә шулай. Кама автомобиль гигантын кору интернациональ бердәмлекнең гүзәл сәхифәсе, чын мәгънәсендә, батырлыкка тиң эпопея булып тарихка кереп калды. Аның корпусларын һәм яңа шәһәрне илебезнең җитмештән артык милләт вәкилләре иңгә-иң торып төзеште, күтәреште. Борынгы Чулман буйларында әкияттәгедәй үсеп чыккан якты кала, теләкомтылышларының изгелегенә ишарә иткәндәй актан киенгән ак шәһәр — совет кешеләренең эчкерсез бердәмлегенә һәм туганлыгына һәйкәл дә ул. Әнә шул туганлыкны без хәзер Татарстан атом станциясендә дә, Кама трактор заводы төзелеш мәйданнарында да күрәбез. Әгәр Татарстанда промышленностьның йөздән артык тармагы уңышлы эшләп килә икән, бусы да шул туганлык, хезмәттәшлек җимеше. Әйтергә генә ансат, Совет власте елларында продукция җитештерү 800 тапкырга арткан!

Әйе, халкыбыз металл кыра, нефть чыгара, машина төзи, йортлар сала, Әбугалисина хикмәтләренә тиң химик тылсым серләрен эшкә җигә... һәм, әлбәттә, ашлык үстерә. Татарстан — борын-борыннан иген игү, терлек асрау җире. Борынгы болгар бабаларыбыздан мирас булып калган изге һәм гомерлек һөнәр бу.

Күренекле инглиз язучысы, фикер иясе Джонатан Свифт үз вакытында болай дип язып калдырган: «Әгәр кем дә булса берәү элек бер башак

үскән урында ике башак, бер төп үсемлек үскән җирдә икене үстерә алса, бөтен кешелек дөньясының рәхмәтен казаныр, иленә олуг хезмәт күрсәткән булыр иде». Бүгенге игенчеләребезне, авыл эшчәннәрен без нәкъ әнә шундый кешеләр дип әйтә алабыз. Моңа тулы нигез бар. 1904—1913 елларда төбәктә бөртеклеләрнең уртача җыемы гектарыннан 6,8 центнер тәшкил иткән. Хәзер исә 35 һәм хәтта 65 центнер да гаҗәп күренеш түгел. Узган ел, мәсәлән, колхоз һәм совхоз эшчәннәре бөртеклеләрнең һәр гектарыннан — 20,9, шикәр чөгендереннән — 183, бәрәңгедән 142 центнер уңыш җыеп алдылар. Аларны дәүләткә сату планы да шул культуралар буенча 113, 105 һәм 114 процентка үтәлде, сәүдә челтәренә планда билгеләнгәннән шактый артык күләмдә яшелчә озатылды.

Татарстан агропромышленность комплексы 574 колхоз, 293 совхоз һәм 83 хуҗалыкара предприятиене берләштерә. Элек файдасыз яткан сазлык һәм ташландык җирләр киптерелә, тазартыла, яраклы хәлгә китерелә; чәчүлекләр өстендә салават күпере уйный. Халык кайчандыр хыялында гына йөрткән ясалма яңгыр яудыру елдан-ел киңрәк колач ала бара.

Республика яулаган үрләрне дәлилләү өчен, саннарга күбрәк мөрәҗәгать итәргә дә туры килә торгандыр. Ләкин шунсыз булмый. «Саннар дәүләт белән идарә итми, ләкин алар идарә итүнең яхшымы, яманмы икәнен ачык күрсәтәләр»,— дигән борынгы акыл ияләреннән бер әү. Әгәр дәүләт белән халык үзе идарә итә икән, ул үзенең ничек идарә иткәнен дә, аның нәтиҗәләрен дә ачык күреп торырга тиеш.

1986 елда Татарстан эшчәннәре дәүләткә 260,5 мең тонна ит, 784,9 миллион йомырка, 2215 тонна йон саттылар. Һәр сыердан уртача савым 2834 килограммга житте. Ә Балтач, Кукмара, Питрәч районнарының алдынгы хуҗалыкларында хәзер 3500 — 4000 килограмм сөт савалар. Узган ел терлекчелек продуктлары сату буенча да барлык планнар арттырып үтәлгән иде. Димәк, әле резервлар һәм мөмкинлекләребез байтак. Авыл эшчәннәренең тырышлыгы, иҗади эзләнүләре нәкъ шуңа — игенчелек һәм терлекчелекне кызу темплар белән үстерүгә, илебездә азык-төлек муллыгын булдыруга юнәлдерелгән.

Ә моның өчен авыл хуҗалыгының материаль-техник базасы җитәрлек. Республика колхоз-совхозларында 35,6 мең трактор, 20,9 мең бөртек суктыру комбайны, 23,5 мең йөк автомобиле һәм байтак башка төр авыл хуҗалыгы техникасы бар.

Хуҗалык итүне камилләштерү, механикалаштыру белән бергә авылларның йөзе дә танымаслык үзгәрә. Бөтен уңайлыклары булган заманча өйләр, мал-туар асрау өчен каралты-курасы, гаражы, бакчасы булган йортлардан гына төзелгән яңа авыллар үсеп чыкты.

Бөек Октябрь социалистик революциясенең житмеш еллыгы — ул кустарь предприятиеләрдән индустрия гигантларына, сукадан механикалаштырылган авыл хуҗалыгына сикерешне генә аңлатып калмый, рухи тормыштагы бөек үзгәрешләрнең дә шаһиты булып тора. Мәдрәсәләрдән академия үзәкләренә, кубыз һәм курайдан милли опера һәм балетка үсә алганбыз икән, болары да Октябрь нурларында шыткан, тамыр җәйгән үсентеләрнең мул итеп җимеш бирүе дигән сүз. Татарстан — тоташтан укый-яза белүче республика гына түгел, ә бәлки югары белемгә ия республика.

Мондый чагыштырулар үткәргәндә, еш кына татар әдәбияты классигы Фатих Әмирханның шушы гасыр башында гына язылган «Гарәфә кич төшемдә» дигән фантастик хикәясен телгә алалар. Миңа калса, урынлы искә төшерү. Хикәя каһарманы төшендә үзен ул чор өчен гадәти булмаган җир — татар клубында итеп күрә. Клубта хокук, медицина, математика, фәлсәфә һәм фәннәрнең башка тармакларында эшләүче профессорларны, әсәрләре чит илләргә дә яхшы танылган татар язучыларын очрата ул.

Әйе, моннан сиксән ел элек, ерып чыккысыз мохтаҗлык, наданлык

шартларында бу, чыннан да, төш булып, буш хыял булып тоелырга мөмкин. 1905 нче елга кадәр татар телендә вакытлы матбугат һәм профессиональ театр булмаганны, ислам дине кануннары буенча музыка һәм сынлы сәнгать белән шөгыльләнүнең тыелганлыгын искә төшерсәк, моны аңлау кыен түгел. Халыклар төрмәсе—патша Россиясендә азчылык милләт кешеләренә түбәнсетеп карау, аларга аң-белем юлын томаларга тырышуның бер чагылышы ул. Патша власте татарларга югары белем бирмәскә тырышкан. Казан губернасындагы бердәнбер гомуми китапханәгә дә алар кертелмәгән. Бөек Октябрьгә кадәрге чорда, ягъни 113 ел дәвамында, Казан университетын татарлардан бары тик санаулы кешеләр генә тәмамлый алган. Ләкин бу кимсетелүләр инде күптән артта калды. Андый вакытлар кире кайтмаячак. Монысын да без яхшы беләбез.

Әйдәгез, тагын чагыштырулар үткәрик. Хәзерге вакытта республикада 2385 гомуми белем мәктәбе һәм 129 һөнәр училищесы бар. Аларда 42 меңнән артык укытучы, тәрбияче һәм инженер-педагог эшли. Дүртенче — унынчы класс укытучыларының 99,2 проценты югары белемле. Унберенче бишьеллыкта 307 мең егет һәм кыз урта белем турында аттестат алды, эшче яшьләр мәктәпләрендә укучылардан 83 мең кеше урта белемгә ия булды. Һөнәр училищеларында яшьләр ике йөз төрле белгечлек буенча өйрәтелә. Үткән бишьеллыкта алардан республика халык хуҗалыгына 204,6 мең әзерлекле яшь эшче килде.

Югары һәм урта махсус уку йортлары тирән белемле, фәннәрнең төрле тармаклары буенча заманча әзерлек алган кадрлар әзерли. Татарстанда 13 югары уку йорты һәм илебездәге башка вузларның биш филиалы, 63 урта махсус уку йорты бар. Аларда белем серләрен өйрәнүче 135 мең егет һәм кызның яртысына якыны, ягъни 45 процenttан артыгы — татар милләтеннән. Ун мең кешегә туры килүче студентлар саны буенча Татарстан Англия, Франция, Германия Федератив Республикасы, Италия кебек нык үскән буржуаз дәүләтләрне узып китте. Ә Владимир Ильич Ленин укыган һәм революциягә беренче адымын ясаган Казан дәүләт университеты — безнең мактанычыбыз, горурлыгыбыз. Республикабыз башкаласына ямь биреп, аның яңа корпуслары күтәрелә; студентлар һәм галимнәр яшь Володя Ульянов кабызган революцион традицияләр ялкынын сүндермиләр, аңа яңа сулыш өстиләр. Илебездәге иң өлкән университетларның берсе — академик вузларның флагманы. Хәзер ул халыкара мәйданга да чыга. Аның аудиторияләре, коридорлары буйлап йөргәндә, немец яшьләрен дә, Азатлык утравыннан килгән кызлар һәм егетләрне дә, Әфганстан вәкилләрен дә, башка социалистик илләрдән килгән студентларны да очратасың. Революцион традицияләр әнә шулай интернациональ берлек белән тыгыз үрелә, бүгенге тормышка яңа рух бирә. Унҗиде яшьлек Володя Ульянов катнашында узган сходканың быел билгеләп үтеләчәк йөз еллыгы төрле илләр яшьләренең революцион үткәнгә тугрылыгына смотр да булачак.

Сүз уңаеннан шунысын да искәртик: Татарстан илебездә киң танылган гыйльми үзәкләрнең берсенә әверелде. СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалына кергән дүрт институтта, югары уку йортларында, 75 фәнни-тикшеренү һәм проект-конструкторлык оешмаларында егерме меңгә якын галим эшли. Алар арасында СССР Фәннәр Академиясе академигы Б. А. Арбузов, член-корреспондентлары В. Е. Алемасов, П. А. Кирпичников, А. Н. Пудовик, И. А. Тарчевский, Педагогия Фәннәре Академиясе академигы М. И. Мәхмүтов, член-корреспонденты А. А. Кирсанов, алты йөзгә якын фән докторы һәм алты меңләп фән кандидаты бар.

Республикада — меңнәрчә клуб, культура йорты һәм сарае, китапханә, ун музей, тугыз профессиональ театр, филармония, цирк. Совет власте елларында Татарстанда, бөтен илебездәге кебек үк, социалистик милли культураның барлык төрләре чәчәк атты.

Әле шушы гасыр башында гына сөекле шагыйребез Габдулла Тукай «... безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнарга... янадан-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә мохтаж» дип язган иде. Аның бу хыялы да тормышка ашты. Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, Ф. Кәрим, Г. Кутуй, И. Гази, К. Нәҗми, Х. Туфан, Г. Әпсәләмов, М. Әмир, Ш. Маннур һәм башка бик күп татар совет язучыларының әсәрләре күп милләтле совет халкының культура хәзинәсенә аерылгысыз өлеш булып керде. Ялкынлы шагыйрь, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең Моабит төрмәләренең калын стеналарын ватып чыккан үлемсез шигырьләре, бөтен иҗаты дөнья поэзиясенең казанышына әйләнде.

Татарстан язучылар оешмасы Россия Федерациясендә иң зурлардан санала. Яшь һәм башлап язучыларны исәпләмәгәндә, 183 кеше СССР Язучылар союзы члены булып тора. Соңгы елларда гына да алар республикабыздан бик еракларда да яхшы танылган яңа, күләмле әсәрләр иҗат иттеләр. Г. Бәшировның «Җидегән чишмә»се, Г. Ахуновның «Идел кызы», Ш. Бикчуринның «Каты токым», М. Хәсәновның «Язгы ажаган» романнары, А. Гыйләҗевның «Җомга көн кич белән» повесте һәм башкалар әнә шундыйлардан. Д. Вәлиевның «Диалоглар», «Тормыш бүләк итәм», Т. Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр», Ш. Хөсәеновның «Әни килде» пьесалары үткен социаль проблемаларны заманча югарылыкта куюлары белән игътибарны җәлеп иттеләр. С. Хәким, Н. Арсланов, З. Нури, Ш. Галиев, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Р. Харис һәм башка шагыйрьләр укучыларны күтәренке рухлы, лирик һәм тәэсирләндергеч шигырьләре, поэмалары белән сөендерделәр, публицист М. Зариповның заман сулышы белән сугарылган очерклары ил күләмендә киң яңгыраш тапты.

Республикабызда татар телендә — сигез, рус телендә дүрт журнал чыгарыла. Аларның гомуми тиражы бер миллион данәдән артып китә. Биш республика газетасы, бер шәһәр һәм житмеш тугыз район газетасы басыла. Татарстан китап нәшриятында ел саен өч йөз исемнән артык яңа китап дөнья күрә. Әдәбият сөючеләр татар әдипләре әсәрләре белән генә түгел, рус һәм күпмилләтле Ватаныбызда яшәүче башка милләт язучыларының китаплары, чит ил шагыйрьләре һәм язучылары иҗаты белән дә ана телендә таныша алалар. Соңгы өч елда, мәсәлән, илебез халыклары язучыларының кырыкка якын китабы бастырып чыгарылды. Аларның гомуми тиражы 1 миллион 237 мең данә тәшкил итте.

Театр, музыка, сынлы сәнгать өлкәсендә дә рухи һәм иҗади яңарыш, күтәрелеш күзәтелә.

Хәзерге вакытта Татарстан Художниклар союзы 93 рәссамны, скульптор һәм графикны берләштерә. Х. Якупов, Б. Урманче, К. Максимов, Л. Фәттахов, С. Ахунов һәм башка күренекле осталарның әсәрләре гомумсоюз культура мирасының алтын фондына керде. Аларның традицияләрен В. Маликов, И. Зарипов, Т. Хаҗиәхмәтов, В. Скобеев һәм башкалар дәвам иттерә. Музыка һәм башкару осталыгы турында сөйләгәндә, татар музыкасының чит ил сәхнәләрендә дә зур уңыш белән яңгыраганын әйтми мөмкин түгел. Кырлай урманнарындагы сукмаклардан чыгып, «Шүрәле»без Европа сәхнәләре буйлап сәяхәткә китте. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, дөньяның әллә ничә континентында булып, халкыбыз сәнгатенә баш идерде, алкышларга күмелеп кайтты. Республикабызның талантлы композиторлары, җырчылары, музыкантлары күп. Милли профессиональ музыка сәнгатенә нигез салучы С. Сәйдәшев, композиторлар Ф. Яруллин, М. Мозаффаров, Җ. Фәйзи, А. Ключарев, З. Хәбибуллиннарның якты истәлеге халык күңелендә яши, иҗатлары хезмәткә һәм көрәшкә рухландыра, рухи дөньябызны баетуга ярдәм итә. Заманыбызның күренекле музыканты, Социалистик Хезмәт Герое, СССРның халык артисты Н. Җиһановның күпкырлы иҗаты бөтен дөньяга танылды. СССРның халык артисты Р. Яхин исеме дә илебез музыка сөючеләренең мәхәббәтен казанган исем. М. Яруллин, Ф. Әхмәтов, Р. Еникеев, А. Луппов,

Б. Мулюков һәм башка композиторларыбыз да музыка сәнгатен үстерүдә актив эшлиләр. Юл башында СССРның халык артисты Н. Рахлин торган Татарстан дәүләт симфоник оркестры республикада гына түгел, туган илебезнең башка якларында да зур абруй казанды.

Театр сәнгате үткән юл гаять катлаулы, ул — эзләнүләр һәм ачышлар юлы. Ленин орденлы, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрын илебезнең теләсә кайсы шәһәрендә көтеп алалар, «Тагын килегез!» — дип озатып калалар икән, бу — шул ачышлар һәм табышларның халык күңеленә хуш килүе, театрның гомумсоюз мәнфәгатьләре белән яшәве, шул дәрәҗәне саклавы дигән сүз. Аның спектакльләренең Үзәк телевидение программалары буенча кат-кат күрсәтелүе дә шуны раслый. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының да, РСФСРда иң өлкән театрларның берсе булган Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы, В. Качалов исемендәге Зур Драма театрының да иҗат биографияләре гаять бай.

Татарстанда кино сәнгате уңышлы эшләп килә. Казан студиясе кинематографистлары «Киң Иделдә» киножурналының 180 санын төшерделәр инде. Чувашия, Мордовия, Мари АССРга тарала торган бу программа Идел буендагы республикалар тормышының киноелъязмасын алып бара. Бөтенсоюз экранындагы иң яхшы нәфис фильмнар шушында тәрҗемә ителә, аларның геройлары татар, башкорт, чуваш, удмурт һәм башка халыклар телендә сөйләшә башлый. Эшләү чорында барысы 375 нәфис фильмга дубляж ясалды.

Республикабыз экономикасы һәм культурасының үсешен, тарих өчен бик кыска чорда — нибарысы җитмеш елда ирешкән казанышларыбызны раслаучы дәлилләр әнә шундый. Дөрес, монда әле тагын башка бик күп мәгълүматлар һәм чагыштыруларны да китереп булыр иде. Ләкин, хикмәт аларда гына түгел. Иң мөһиме — без бу казанышларның Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңүе нәтиҗәләре икәнен, Коммунистлар партиясенең илебез халыклары бәхете турында армый-талмый кайгыртуы нәтиҗәсе икәнен, үз милли дәүләтен төзегән татар халкының һәм республикада яшәүче башка милләт вәкилләренең бердәмлеге, азат хезмәт җимеше икәнен яхшы беләбез.

«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы — эшчеләр, крестьяннар һәм интеллигенциянең, республикадагы барлык милләт хезмәт ияләренең ихтыярын һәм интересларын чагылдыручы гомумхалык социалистик дәүләте.

Халык дәүләт властен Татартсан АССРның политик нигезен тәшкил итүче халык депутатлары Советлары аркылы тормышка ашыра». Республикабызның Төп Законында халыкның дәүләт белән идарә итүгә хокукы шундый юллар белән беркетелгән.

Автономиябезне төзүдә В. И. Ленинның турыдан-туры катнашуы һәм җитәкчелек итүе аеруча горурлык уята. Октябрь революциясеннән соң ике ел ярым чамасы вакыт узуга ук, 1920 елның 27 маенда игълан ителә ул. Республика Казан, Уфа, Самара, Вятка һәм Сембер губерналарының татар халкы яши торган төбәкләрен эченә алып, ул вакытларда анда барысы 2 миллион 892 мең кеше яши. Шулардан татарлар 51,6 процент, руслар — 39,2, чувашлар — 6,4, мордвалар — 1,8, марилар — 0,6 һәм башка милләт вәкилләре 0,4 процент була. Яшь республика алдында яңа мөмкинлекләр, яңа офыклар ачыла.

Республикабыз үз карамагына бирелгән мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итә һәм РСФСР, СССР Верховный Советларындагы депутатлары аша, алар карамагына тапшырылган мәсьәләләрне хәл итүдә катнаша. Илебезнең иң югары власть органнарының Милләтләр Советында Татарстаннан унбер депутат вәкиллек итә. Вәкилләребез СССР Верховный Советының Союз Советында һәм РСФСР Верховный Советында да бар.

РСФСР Верховный Советының үткән елның декабрендә узган сессия-

сендә 1987 елда Россия Федерациясен экономик һәм социаль үстерүнең дәүләт планы каралган иде. Анда Татарстаннан сайланган депутат, Казан шәһәр Советы башкарма комитеты председателе Р. Идиатуллин чыгыш ясады һәм шәһәр хуҗалыгына җитәкчелек итүдә экономик ысулларны киңәйтү, илкүләм мөһим предприятиеләр, оешмалар белән мөнәсәбәтләрне камилләштерү турында сөйләде.

Хикмәт шунда: шәһәр хуҗалыгына тотыла торган акчаның биштән дүрт өлеше чамасы әнә шул предприятиеләрдән алына. Ә аларның саны алтмыштан артык. Элегрәк һәр предприятие нигездә үзе өчен тырыша иде: йорт сала, балалар бакчасы төзи, больница, я башка объект кора. Зур оешма булса ярый әле. Ә кеше саны азрак һәм финанс куәте кечерәк булган предприятиеләргә нәрсә кала? Менә шушы хәл Казанның социаль үсешендә төрле чатаклыкларга — диспропорциягә китерде. Шәһәр Советы башкарма комитеты моннан котылу өчен 1986 елдан бердәм норматив булдырды. Ул шәһәрдә яшәүче һәр кеше һәм предприятиедә эшләүче һәр кеше исәбеннән шәһәр төзелешенә билгеле микъдарда акча бүлеп бирүне күздә тота.

Нәтиҗә озак көттермәде. Инде 1986 елда ук илкүләм әһәмиятле, ягъни турыдан-туры СССР һәм РСФСР министрлыкларына, ведомстволарына караган оешмалардан шәһәр хуҗалыгын үстерүгә 50 миллион сумлап акча алынды. Быел исә бу өлеш тагын да зуррак булачак дип көтелә.

Халык депутатларының Казан шәһәр Советы башлангычын илнең югары власть органнары хуплады, эшләнгән нормативлар «1987—1995 елларда Казанның шәһәр хуҗалыгын үстерү чаралары турында» СССР Госпланы кабул иткән кararга (1986 ел, 24 декабрь) нигез итеп алынды. Депутатларның, республика мәнфәгатен яклап, илнең югары органнарында эш итүенең бер мисалы әнә шундый.

Татарстан АССРның РСФСР Верховный Советы Президиумында да тулы вәкаләтле вәкилләре эшли. РСФСР Конституциясе нигезендә, Президиум председателенең уналты, ягъни һәр автономияле республикадан (шул исәптән Татарстаннан да) бер урынбасары бар.

Татарстан АССР Верховный Советы һәм 922 җирле Совет органик рәвештә республикабызның һәм ССР Союзының дәүләт власте органнары бердәм системасына керәләр. Аларның һәркайсы югары властьның бер өлеше булып тора, үз вәкаләтенә кергән мәсьәләләрне хәл итеп кенә калмый, гомумдәүләт карарларын тормышка ашыручы буларак чыгыш ясый. Югары һәм җирле органнарның шушы бердәмлеге, югары властьның җирле инициативага таянып эш итүе — Советларның асылын — халык белән какшамас элемтәсен, бәйләнешен күрсәтә дә инде.

Советларның көче — партия җитәкчелегендә, ул аларның үз функцияләрен уңышлы үтәвенең политик гарантиясе. Республикадагы җирле Советлар эшчәнлегендә, кызганычка каршы, формализм, сүлпәнлек һәм кайбер башка кимчелекләр әле бетеп җитмәүгә карамастан, яхшы якка үзгәрешләр байтак. Мөстәкыйльлек, активлык арта. Бу уңайдан Казан, Түбән Кама, Әлмәт, Азнакай, Лениногорск, Чистай шәһәр һәм Баулы, Октябрь, Менделеев район Советларын уңай яктан телгә аласы килә.

Түбән Кама шәһәр Советы һәм аның башкарма комитеты, мәсәлән, халык куллануы товарлары җитештерүне эшлекле контрольгә алдылар, нинди министрлыкка буйсынуга карамастан, һәр предприятиенең шәһәрне социаль үстерүгә бердәй катнашуына ирештеләр. Унберенче бишьеллыкта биредә халык куллануы товарлары эшләп чыгару 1,8 тапкырга артты, узган ел хезмәт хакы фондының һәр сумына бер сумлыктан артык шундый әйбер эшләнде. Планнан тыш дүрт мең квадрат метр торак салынды, бу тагын 200 гаиләгә тормыш-көнкүреш шартларын яхшыртырга мөмкинлек бирде.

Халык депутатларының Баулы поселок Советы да эшчәнлеген заман таләп иткәнчә үзгәртеп кора. Поселокны экономик һәм социаль үстерү

мәсьәләләре хезмәт коллективларында, халык арасында киң тикшерелә, әйтелгән тәкъдимнәр һәм фикерләр Совет кабул иткән карарларда чагылыш таба.

Партия оешмалары җитәкчелегендә җирле Советлар кешеләрнең көндәлек ихтыяҗын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән чараларны әнә шулай кыюрак хәл итә башлады. Тизләнешнең көч җыя баруы, киңрәк колач алуы турында мондый фактлар да сөйли: 1986 елда промышленностьта җитештерү күләмнәренең һәм хезмәт җитештерүчәнлегенең үсеш темплары планда билгеләнгәннән 1,4 тапкырга югарырак булды. Үсешнең 95 процентган артыгына җитештерүчәнлекне күтәрү исәбенә ирешелде. Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү һәм продукция урнаштыру планнарын үтәмәүче предприятиеләр саны ике ярым тапкырга кимеде. Соңгы елларда беренче тапкыр буларак, узган ел торак йортлар, мәктәпләр, балалар бакчалары, клуб һәм культура йортлары, башка төр социаль һәм культура-көнкүреш объектлары, юллар, күперләр төзүнең еллык планнары арттырып үтәлде. Халык куллануы товарлары эшләп чыгару арткаlннан-арта бара.

Быелның беренче яртысы йомгаклары да алынган темпның тайпылышсызлыгы турында сөйли. Промышленностьта продукция җитештерү һәм хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү планнары арттырып тормышка ашырылды, өстәмә рәвештә 40 миллион сумлык төрле әйберләр эшләп чыгарылды, торак йортлар билгеләнгәннән 60 мең квадрат метрга күбрәк төзелде. Хезмәт ияләренең тормыш хәлен яхшыртуга юнәлдерелгән байтак чаралар гамәлгә ашырылды. Бу нәтиҗәләргә ирешүдә халык депутатларының җирле Советлары мөһим роль уйнадылар, аларның эшчәнлегендә сизелерлек үзгәрешләр бар.

Әйе, үзгәртеп кору Советлар тормышында һәм эшчәнлегендә тирән үзгәрешләр китереп чыгарды. Башкача мөмкин дә түгел, чөнки дәүләт политикасының барлык җепләре Советлар аша үтә, кешеләрнең ихтыяҗы һәм мәнфәгатьләре, көзгедәге кебек, аларда чагыла.

Җирле Советларга 21 июньдә булып узган сайлаулар һәм аларга әзерлек республиканың җирле власть органнары эшен камилләштерүгә куәтле этәргеч ясады. Халык вәкилләренең үзгәртеп коруны, социаль-культура төзелеше планнарын тормышка ашыруда җаваплылыгы артты. Депутатлыкка кандидатлар ачыктан-ачык һәм принципиаль сөйләшүләр, фикер алышулардан соң гына күрсәтелде. Формализмнан арыну җиңел түгел. Әмма, үзгәртеп коруны без шуннан башларга тиеш идек. Теләгәнебезгә ирештек дип әйтә алам. Кандидатлар күрсәтү һәм сайлаулар активлык, тирәннән кызыксыну шартларында барды, халык вәкиле булачак кешеләрнең эшлеклелек һәм әхлакый сыйфатлары һәрьяклап тикшерелде, искә алынды. Мәсәлән, барысы 55016 кандидатура каралды, ә депутатлыкка кандидат итеп 31467 кеше теркәлде. Шулардан 31243 е югары исемгә лаек булды. Буа районында исә сайлаулар, беренче тапкыр буларак, күп мандатлы система белән үткәрелгән иде. Биредә тугыз кеше сайлаучыларның яртысыннан күбрәгенең тавышын җыя алмадылар һәм депутат итеп сайланмадылар.

Яңа сайланган Советларның беренче сессияләрендә дә демократизм ачык чагылды. Әнә шулай, республика, район, шәһәр һәм авыллар тормышы белән идарә итүнең торган саен халыкка якынаюын, демократиялерәк була баруын күрәбез.

КПССның XXVII съездыннан соң беренче тапкыр узган бу сайлаулар халыкның хезмәт һәм политик активлыгын күтәрде, Бөек Октябрьнең 70 еллыгы билгеләп үтеләчәк 1987 ел планнарын һәм тулаем уникенче бишьеллыкны уңышлы үтәүгә рухландырды, көрәшкә туплады. Меңнәрчә коллективлар юбилей вахтасына басып эшли. Менделеев районы хезмәтчәннәре бу бәйрәмгә бишьеллыкның ике елы заданиесен төгәлләргә дигән башлангыч белән чыкканнар иде. Чакыру һәркайда теләктәш-

лек һәм яклау тапты. Патриотик хәрәкәтнең алдынгылары сафында КамАЗдан РСФСР Верховный Советы депутаты В. А. Ватагин житәкчелегендәге токарьлар бригадасын, агрегат заводы эшчесе, Татарстан АССР Верховный Советы депутаты Н. П. Корноуховны, «Мамадыш» совхозы сыер савучысы С. В. Гарифуллинаны, СССР Дәүләт премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое, Әлмәт шәһәр Советы депутаты Д. М. Нуретдинов житәкләгән бригаданы, КПССның XXVII съезды делегаты, район Советы депутаты, «Казанькомпрессормаш» фәнни-производство берләшмәсе токаре В. Н. Кузьминны һәм башка дисталәрчә фидакарьләрне әйтергә мөмкин.

1986 елның 23 декабрендә СССР Верховный Советы Президиумы утырышында республика Советлары эшчәнлеге тикшерелгән иде. Анда КПСС Үзәк Комитеты генеральный секретаре М. С. Горбачев чыгыш ясап, экономик һәм социаль үсешне тизләнеш юлына күчерүдә республика Советларының эшчәнлеген уңай бәяләде. Бу өлкәдә үзгәрешләр байтак, ләкин әлегә алар акрынрак бара. Советлар еш кына конкрет эш белән шөгыльләнәсе урынга төрле кәгазь язу белән мавыгалар, моңа чик куярга, социаль мәсьәләләрне хәл итүгә, сайлаучылар наказын үтәүгә игътибарны көчәйтергә кирәк. Советлар эшчәнлеген үзгәртеп кору — кешеләргә, аларның ихтыяжларына йөз белән борылу, бу эштә депутатларның, барлык совет кадрларының ролен һәм җаваплылыгын күтәрү дигән сүз ул. Республика Советларының алдагы чорга эшчәнлек программасы шушы юнәлештә билгеләнде.

Республикабызның хезмәт ритмында, аның алга омтылышлы ышанычлы адымнарында без Октябрь нурлары балкышын күрәбез. Тугандаш совет халыкларының бердәм сафында Татарстан республикасы да партия билгеләгән курс — революцион яңарыш курсы белән атлый.

## Нури Арсланов

### Котлау

Җидегәннән йолдызлар алып
Тездек Ил күкрәгенә,
Балкып, алтын йолдызланып
Ил ашты күкләренә!

Җидегәнгә әйләнде Җитмеш,
Борыла таңнар уятып,
Уяткандай тылсымлы көч
Тарих капкасын ватып:

Анда таҗлар баштан төште,
Җимерелде иске дөнья,—
Азатлык кошлары очты,
Яңадан корды оя.

Күпме йолдызлар атылды...
Кыелды күпме җаннар!
Хаклык үз дигәнен кылды,—
Тез чүктеләр дошманнар.

Җитмеш елда җитмеш җиде
Кайгы, шатлык кичердек:
Мәңгелек иттек без сине —
Абелхәят эчердек!

Ленин рухы котлый Илне
Җитмеше белән, сөеп,
Ил котлый Бөек Ленинны:
— Җитмешлең белән!— диеп.

## Нәби Дәүли

### Октябрь байрагы

1

Байракта:
Кан төсе,
Таң төсе,
Яз төсе,
Яз төсе — күзендә.
Яралу,
Яңару,
Уяну —
Октябрь сүзендә.

2

Байракта —
Гаделлек,
Тигезлек,
Намуслык.
Тормышның сафлыгы,
Азатлык,
Туган җир,
Һәм икмәк,—
Октябрь шатлыгы.

3

Байракта:
Батырлык,
Чыдамлык,
Горурлык.—
Ватанның сагында
Көрәштә
Җиңүләр,
Сагышлар
Октябрь чаңында.

4

Байракта:
Тынычлык
Һәм хезмәт,
Һәм җырлар.
Һәм чәчәк багышы.
Офыкта
Өметләр,
Юлларда
Октябрь балкышы.

5

Байракта:
Безнең ант,
Тугрылык,
Дөреслек.—
Йөрәктә янганы.
Җирдәге
Өлешкә,
Безнең хак —
Октябрь байрагы.

6

Бу якка
Күз текәп,
Сокланып
Караган
Дөньяның бар ягы:
Чакыра
Дусларны
Табынга
Октябрь байрагы.

**Якуб Чанышев**

отставкадагы генерал-лейтенант,
1917 елдан партия члены.

# КАЗАН КРЕМЛЕН ШТУРМЛАУ

*Озын гомер юлымда нинди генә җил-давыллар, сугышчан һәм революцион үзгәрешләр кичерергә туры килмәде. Барысын да үттем. Сынмадым, сыгылмадым, дошман пуляларына да, снарядлар шартлавына да бөгелмәдем. Коммунист дигән бөек исемне легендар 1917 елның мартыннан бүгенге көнгәчә намус белән алып килдем. Җитмеш ел сафта — партия стажым әнә шундый минем!*

*Җитмеш ел... Гаять күп вакыт, зур тормыш юлы ул. Бик күп нәрсәләр күрергә, башымнан кичерергә туры килде. Нинди генә гаҗәеп кешеләр белән очрашылмаган да нинди гадәттән тыш вакыйгаларда катнашырга туры килмәгән. Бездән соң яшәячәк, социализмны төзеп бетереп, коммунизм корачак яшьләргә, миллионнарча егетләргә һәм кызларга бик күп нәрсәләр турында сөйлисем килә. Истәлекләремдә мин озын гомер юлымда күргәннәремне, кичергәннәремне аларга ирештерергә булдым...*

*Отставкадагы генерал-лейтенант, Казанда Совет властен урнаштыруда актив катнашкан ленинчы-большевик Якуб ага Чанышевның «Безне яшьлек үзе чакырды» дигән истәлекләр китабына* язган кереш сүзендә әнә шундый юллар бар. Түбәндә шул китаптан Казанда октябрь көннәрен тасвирлаган бер өзек тәкъдим итәбез. Әсәр журнал битләрендә киләсе елда басылачак.*

Вакытлы хөкүмәтнең Петроград эшчеләреннән канлы үч алуы революцион рухтагы Казан эшчеләрендә кискен нәфрәт дулкыны күтәрде. Контрреволюция басымына җавап итеп, алар тагын да тыгызрак сафларга тупланды. Эшче һәм солдат депутатлары Советларында большевиклар өстенлек итә башлады. Мәсәлән, 1917 елның 7 сентябрендә Советның утыз кешедән торган солдат секциясе башкарма комитетына уналты большевик һәм ундүрт сул эсер сайланды. Башкарма комитет президиумындагы биш кешенең өчесе — Ершов, Ежов һәм Кортов — большевиклар иде. Эшчеләр секциясен Карпов, Рудов, Северов һәм Бочков җитәкләде.

Большевиклар партиясенең Казан комитеты эшче-крестьяннарның революцион активлыгына таянды, «Бөтен власть Советларга!» дигән өндәмәгә һәм шулай ук предприятиеләрдә эшчеләр контроле урнаштыруга каршы чыккан меньшевиклар һәм эсерларны изоляциядә калдыру чараларын күрде.

Бу бик вакытлы эшләнгән булып чыкты. Чөнки контрреволюционерлар тарафыннан котыртылган завод-фабрика хуҗалары эшчеләр арасында революцион хәрәкәткә комачаулык итү, предприятиеләрне пролетариатның үз кулына алу мөмкинлегенә юл куймау өчен барысын да эшләделәр, хәтта мал-мөлкәтләрен югалтуга да риза иделәр. Алар завод һәм фабрикаларны яндырдылар, цехларны һәм аерым агрегатларны җимерделәр, теләсә нинди

* Ис[illegible] әдәби эшкәртүчесе Валерий Анисимов

корткычлыкка бардылар, предприятиеләрне эшләтмәскә сылтау эзләп, чималны яшерделәр. Ләкин бернинди хәйлә һәм алдаулар да ярдәм итмәде. Эшчеләр аларның мәкерле ниятләрен фаш иттеләр.

Дары заводы эшчеләре, мәсәлән, большевиклар завкомы җитәкчелегендә эшкә алу һәм эштән чыгару, заводны һәм складларны, дары базларын саклауны, исәп-хисапны үз кулларына алды. Шәһәрнең башка предприятиеләрендә дә алар үрнәгенә иярделәр. Завод хуҗаларыннан берсе — Арсланов, чимал җитмәүне сәбәп итеп, предприятиене ябарга маташа башлагач, эшчеләр комиссия төзеп, җентекле ревизия ясадылар. Нәтиҗәдә подвалларда биш мең пот туң май, ике мең пот мамык мае, бер мең пот киндер мае, йөз мичкә силикат һәм шактый күләмдә утын табылды. Бу хәл завод эшчеләре арасында гына түгел, бөтен шәһәр предприятиеләрендә ачу һәм нәфрәт тудырды.

Дошманның теләсә нинди хәйләгә, мәкергә баруын күргән Казан пролетариаты мондый халдә битараф һәм ваемсыз кала алмый иде, әлбәттә. Көрәштә В. И. Ленинның пролетариатны коралландыру турындагы күрсәтмәсе нигез булды. Алда торган сыйнфый бәрелешләрдә бары тик шушы чара гына уңыш вәгъдә итә ала иде. Һәм Казан эшчеләре коралланырга, Кызыл гвардия отрядлары, эшче дружиналары, сугышчан формированиеләр төзергә керешә. Округтагы регуляр гаскәри подразделениеләр аларга зур ярдәм күрсәтә башлады.

Дары заводы янында гына урнашкан складлар һәм дары базларында каравыл хезмәте алып бара торган безнең 240 нчы полк бу җәһәттән бигрәк тә аерылып торды. Полкта исәпкә алынмаган корал: гранаталар, винтовкалар, карабиннар аз түгел иде. Завод комитеты үтенече белән алар барысы да эшчеләргә бирелде һәм аларны кораллы бәрелешләргә әзерләүдә хәлиткеч роль уйнады. Октябрьгә кергәндә, завод эшчеләреннән ике меңнән артык кызыл гвардияче һәм дружиначы бар иде инде. Яхшы гына коралланган бу отрядларны безнең кече офицерлар өйрәтте. Дары заводы эшчеләре һәм 240 нчы полк солдатларының килешеп эш итүе пролетариат белән армия бердәмлегенең ачык мисалы булды.

Э илдәге вакыйгалар агышы көрәшкә ачыктан-ачык күтәрелер вакыт җиткәнне тоярга мөмкинлек бирә иде. Көзгә таба Казанда һәм өязләрдә халык хуҗалыгы, экономика торгынлык хәленә килде, эшчеләр һәм ярлы крестьяннарның хәле коточкыч авырайды. Казан предприятиеләрендә забастовкалар ешайды, авыл җирендә чуалышлар башланды. Губерна комиссары Чернышев төрле якларга кораллы отрядлар җибәрде һәм озакламый «күпчелек алпавыт утарларында кораллы командалар бар, шунлыктан хәзер барысы да тәртиптә» — дигән хәбәрләр алды. Губерна комитетының чираттагы утырышында да ул шулай дип белдерде.

Ләкин «тәртип» турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Авыл ярлылары кулакларга, кеше каны эчеп баеган алпавытларга каршы тагын да кискенрәк һәм ешрак баш күтәрә. Шулай итеп, эшчеләр, крестьяннар һәм солдатлар бердәмлеге турындагы пролетариат лозунгысының дөреслеге тагын бер кат расланды. Бу бердәмлек исә көннән-көн үсә һәм ныгый бара иде.

Татар крестьяннарының көрәшен җәелдерүдә бу юлы да М. Вахитов җитәкчелегендәге Мөселман социалистлар комитеты зур эш башкарды. Большевиклар белән бергә өязләргә Мөселман социалистлар комитеты агитаторлары һәм пропагандистлары да чыкты, алар татар милләтчеләренең контрреволюциясен фаш иттеләр. Вахитов һәм аның көрәштәшләре Шәһит Әхмәдиев, Әминә Мөхетдинова, Сәйфи татар крестьяннарының Казанда үткәрелгән губерна съездында Туктаров һәм аның иярченнәренә җир мәсьәләсе буенча кискен отпор бирделәр, алпавыт җирләрен тартып алган крестьяннарны кыю якладылар. Съезд делегатларын шәһәр эшчеләре һәм солдатлар белән берләшергә, аларга икмәк һәм башка азык-төлек белән ярдәм итәргә, бергәләп алпавытларга, капиталистларга каршы көрәшкә чакырдылар.

Сентябрь башларында большевиклар партиясе Үзәк Комитеты җирле

оешмаларга «Власть турында» дигән резолюция җибәрде һәм зуррак шәһәрләргә ҮК членнарын һәм күренекле большевикларны озатты. Казанга профессиональ революционер, 1903 елдан партия члены Бубнов килде. Ялкынлы оратор, публицист эшчеләр митингларында чыгыш ясап, Вакытлы хөкүмәтнең, меньшевиклар һәм эсерларның контрреволюцион политикасын фаш итте. Округта һәм шәһәрдә башкарган эшләре, кыйммәтле киңәшләре белән ул Казан оешмасы җитәкчеләренә шактый сизелерлек ярдәм күрсәтте. Бу акцияләрдән соң большевиклар оешмасы җитәкчеләренең эшчәнлеге нык көчәйде, солдатлар һәм шәһәр эшчеләре активлашты.

Нәкъ менә җирле пролетариат таләбе белән «Рабочий» газетасы яңадан чыгарыла башлады. Ә 19 сентябрьдә большевиклар тәкъдиме белән Советның өч секциясе бергә кушылды. Аның 22 сентябрьдәге утырышында азык-төлек белән тәэмин итүдәге кыенлыкларны бетерү буенча уртак план төзелде. Эшлекле һәм бөртекләп уйланган план иде ул. Аның тормышка ашуына шәһәрдәге йөзләрчә эшчеләр дә нык ышанды.

Бу сүзләргә бераз аңлатма биреп үтү кирәктер. Актив, акыллы һәм чын-чыннан революцион эшчәнлеге нәтиҗәсендә большевиклар партиясе шулкадәр популярлык һәм абруй казанды ки, аның шәһәр комитеты меньшевиклар, эсерлар комитетлары һәм губерна комиссары Чернышев белән бергә, бер бинада — губернатор сараенда ачыктан-ачык эшләп килде. Большевикларның беренче приказлары, хәлиткеч һөҗүмгә күчү турындагы хәбәрләр дә нәкъ менә шуннан яңгырады.

Бишенче октябрьдә шәһәр кешеләрен гудок тавышлары уяты. Бистәләрдән Казанның үзәгенә, Панаев бакчасы тирәсенә эшчеләрнең оешкан сафлары куәтле дулкын булып агыла башлады. Алар дәртле тавыш белән «Марсельеза» һәм «Варшавянка»ны җырлыйлар.

Забастовкада кырык меңнән артык кеше катнашты. Ләкин бу эшнең башы гына иде әле. Советның эшчеләр секциясе, большевиклар белән килешеп, әгәр таләпләр кабул ителмәсә, гомуми забастовка булачагы турында кисәтеп куйды.

Панаев бакчасында Карпов, Шеварев, Ежов, Гладилов, Волков һәм ул вакытта киң танылган башка большевиклар, революционерлар чыгыш ясады. Хәрби округ командующие Архипов һәм губерна комиссары Чернышевның янавыннан митингта да, аннан соңгы көннәрдә дә куркучы булмады. Хәрби гарнизон солдатларының яклавын һәрдаим тоеп яшәгән Казан пролетариаты үз-үзенә нык ышанып эш итә иде.

Завод һәм фабрика хуҗалары төп шартларны кабул итәргә мәҗбүр булды. Шәһәр пролетариатының беренче зур җиңүе иде бу. Ул шулай ук Казан большевикларының да мөһим җиңүенә әйләнде, аның халыкны күтәрергә һәм илдә Совет властен яулап алу өчен көрәшкә алып барырга сәләтле икәнен күрсәтте.

Эшчеләрнең җиңүе, кем әйтмешли, аларга һәм аларның вәкилләренә юридик файда да китерде. Дәүләт думасына октябрь аенда үткән сайлауларда большевиклар — 22, ә Мөселман социалистлар комитеты вәкилләре 11 урын алды. Эшче, солдат, крестьяннарның тормышын бәхетлерәк, матуррак итүдә уртак максат белән берләшкән бу кешеләр абруйлы, йогынтылы политик көчкә әверелгән иде инде.

Октябрь урталарыннан гаскәри берләшмәләрдә дә алдынгы фикерле кешеләр өстенлек итә башлады. 240 нчы полк бигрәк тә аерылып торды. Шул вакытларда солдатлар мине беренче батальонның командиры итеп сайлап куйдылар.

Шуннан соң узган җыелышларның берсендә гарнизонның Мөселман хәрби комитеты сайланды. Аның председателе ефрейтор Әбдрәшитов, урынбасарлары Сафиуллин һәм мин, комитет членнары Биккинин, Сәйфелмөлеков, Касыйм Шамил, Шмаков һәм башка иптәшләр иде. Эшче һәм солдат таләпләрен яклап, 15 октябрьдә зур митинг үткәрү турында карар кабул ителде. Шуннан соң большевиклар хәрби оешмасы членнары һәм Советларның солдат секциясе депутатлары барысы да диярлек роталарга, батальон-

нарга, батареяларга киттеләр, безнең политиканы, митингка хәзерләнгәндә нинди максатлар күздә тотылуын аңлата башладылар.

Бу эшне бик гади, идеябезне бөтен кеше дә аңлый иде дип әйтеп булмый. Большевикларга бик күп эшләргә туры килде. 14 октярбьдә эшче-солдат депутатлары Советының берләштерелгән утырышында, мәсәлән, меньшевиклар һәм эсерлар большевиклар эшчәнлегенә котырынкы һөҗүм ясадылар: безне армияне таркатуда, солдатларны офицерларга каршы котыртуда гаепләделәр, бернинди дәлилсез-нисез большевиклар законлы властьның дәрәҗәсен төшерәләр дип белдерделәр. Һәм ахырдан, бернәрсә дә исбатлый алмыйча һәм беркемне дә ышандырмыйча ишекне шартлатып ябып чыгып китәргә мәҗбүр булдылар.

Ләкин ул вакытта аларның сүзе үтми иде инде. Меньшевиклар һәм эсерлар, политик группировка буларак, нәкъ менә митинг буласы көн алдыннан тар-мар ителделәр дип әйтергә тулы нигез бар.

Солдатларның гомуми җыелышына әзерлек исә зур җанлылык белән дәвам итте. Плакатлар, лозунглар языла, байраклар тегелә. Солдатлар корал чистарта, музыкантлар хәстәрлек күрә.

Иртә белән, билгеләнгән вакытта 240 нчы полк солдатлары плацка чыгып тезелде һәм рота, батальон командирларын көтә башлады. Ләкин... алар, имештер, моңа округ гаскәрләре командующие һәм гарнизон начальнигының рөхсәте юк дигән булып, митингка катнашудан баш тарттылар. Солдатлар да, большевик офицерлар да каушап калмады. Полкка җитәкчелек итүне полк комитеты председателе Масальский һәм мин үз өстебезгә алдык. Рота һәм батальоннарда да чая егетләр табылды.

Нәкъ иртәнге унда 240 нчы полк вокзал артындагы болынга юнәлде. Сафлар өстендә «Бөтен власть Советларга!», «Бетсен сугыш!», «Бетсен Вакытлы хөкүмәт!» дигән өндәмәләр, байраклар җилферди. Һәркемнең күңеле күтәренке һәм шул ук вакытта сугышчан да. Моны тыныч сугыш белән разведка ясау дип әйтергә мөмкин иде.

Соңрак митинг буласы урынга гарнизонның башка полклары, шулай ук 2 нче һәм 5 нче артбригадаларның артиллерия дивизионнары, 685 нче һәм 586 нчы дружиналар һәм автомобилистлар командасы да килеп җитте.

Хәрби училище юнкерлары һәм прапорщиклар мәктәбе курсантлары гына күренмәде. Аларның гомуми җыелыш җыеп, митингка бойкот игълан итәргә карар чыгарулары мәгълүм булды.

Бу уңайдан бары тик бер генә нәрсәне әйтеп була. Россиядә революцион вакыйгалар үсешенең иң хәлиткеч көннәрендә — моны Казан һәм Смольный мисалында ачык күреп була — юнкерлар иң реакцион позициягә бастылар, патша режимына тугрылык сакладылар, халык белән бергә киләчәккә атлау дәрәҗәсенә күтәрелә алмадылар.

Ә безгә килсәк, митингта нәкъ менә шул адым ясалды. Революция эше өчен беренче сугышчан бәрелешләргә таба кыю адым иде ул.

Солдатларның гадәттән тыш бу зур җыелышын большевиклар хәрби оешмасы председателе Ершов ачты.

— Иптәшләр! — диде ул.— Без монда илдәге хәлне һәм Вакытлы хөкүмәтнең политикасын тикшерергә дип җыелдык. Без бүген солдатларга һәм эшчеләргә кайсы юлдан барырга, сугышны ничек тизрәк бетерергә, властьны халык кулына — халык депутатлары Советларына тапшыру өчен ни эшләргә кирәклеген хәл итәргә җыелдык.

Бер мәлгә тын калып, ул күзен сафлар буйлап йөртеп чыкты һәм:

— Дөрес сөйлимме? — дип сорады.

Бердәм тавышлар яңгырады:

— Дөрес, дөрес!

— Алай булса мәсьәләне хәл итүгә керешик.— дип тәгалләде Ершов һәм Казан большевиклар комитеты вәкиле Грасиска сүз бирде. Грасис фронтлардагы соңгы вакыйгалар, Петроградта, Кронштадтта һәм Казанның үзендәге хәл турында сөйләде.

Башка чыгышлар да булды. Соңыннан без Ленинга, Петроград Сове-

тына. Кронштадт каһарманнарына котлау телеграммалары җибәрдек. Шуның белән митинг тәмамланды, ә политик көрәш ялкыны көчәеп кенә килә иде әле.

Большевиклар заводларда һәм фабрикаларда, профсоюз оешмаларында, гаскәри частьларда киң колач белән аңлату эшләре башлап җибәрделәр. Аларны Мөселман социалистлар һәм Мөселман хәрби комитетлары яклап чыкты. Ул гына да түгел, алар гарнизонның гомуми җыелышыннан соң 240 нчы полк плацында татар роталары өчен аерым митинг ясадылар. Барлык биш рота солдатлары гомуми митинг резолюциясен бердәм хуплап чыкты.

Бу көннәрдә яшьләрнең социалистик союзы, Панфилова, Таҗетдинова, Леонтьева җитәкчелегендәге солдаткалар союзы да эшен активлаштырып җибәрде. Кыскасы, большевиклар һәм социалистлар барлык юнәлешләрдә хәлиткеч сугышларга хәзерлек башладылар. Ләкин контрреволюционерлар да йоклап ятмады.

Капитан Калинин таләбе буенча округ командующие Архипов гарнизон частьлары командирларының ашыгыч киңәшмәсен җыйды. Анда 240 нчы полк командиры полковник Смирнов белән миңа да катнашырга туры килде.

Сандецкий сараена кем генә килмәгән. Монда меньшевиклар да, эсерлар да, Хәрби шура җитәкчеләре дә, шәһәр милициясе начальнигы, губерна комиссары һәм округ суды прокуроры да... Аларның соңгысына «югары таләпләр»: гарнизон җыелышын башлап йөрүчеләрне кулга алу һәм судка бирү таләбе куелды. Ләкин эш сүздән ары китә алмады. Кем әйтмешли, көчләре азрак, ә дөресрәге кыюлыклары җитми иде инде. Хәер, кече офицерларның күпчелеге, солдатларның исә барысы да революция ягына күчкән һәм аның өчен утка керергә әзер торган бер заманда андый кыюлык каян килсен ди.

Әйе, солдатлар сугышка керергә әзер иде. Командирларының рөхсәтеннән башка гына алар цейхгаузларны һәм корал складларын ачтылар, коралландылар. Икенче артбригада тупчылары аеруча өлгерлек күрсәтте. Тәҗрибәле большевик Шелымханов җитәкчелегендә монда көн саен митинглар уза. Дивизия комитеты председателе Андронов тупчыларның ничек коралланувы белән үзе шөгыльләнә, аңа бомбардир-разведчик Алексашин һәм солдат Хисаметдинов ярдәм итә.

Ләкин, кабатлап әйтәм, контрреволюционерлар да йоклап ятмады. Ул гына да түгел, капитан Калинин коткысына ияреп, алар алдынгы фикерле солдат, офицер һәм эшчеләргә каршы «хәлиткеч һөҗүм» башлап җибәрделәр. Хәрби шура җитәкчеләре, меньшевиклар һәм эсерлар алар ягына басты. Алардан башкасын көтеп тә булмый иде. Дөреслеккә хилафлык китерәсем килми: алдынгы карашлы сул эсерлар теге якка да, бу якка да авышырга белмичә икеләнеп тордылар, әмма соңыннан, Казанда революцион вакыйгаларның иң хәлиткеч мизгелендә большевиклар ягына бастылар.

Сандецкий сарае контрреволюция үзәгенә әйләнде. Капитан Калинин анда урталыкта тирбәлүче барлык социалистларны җыйды. Алар арасында бертуган Деникелар, Нелидов, Якобсон, Бухов, Пионтковский, Бартольд, Иванов, Алкин, Әбелханов, Токумбетовлар... Шулай итеп, контрреволюция штабы янында «Социалистик блок» оештырылды. Контрреволюция көчләре алдына Калинин куйган бурычлар мондый: большевиклар комитеты һәм полк комитетлары җитәкчеләрен кулга алырга, эшчеләр һәм солдатларның прогрессив хәрәкәтен тар-мар итәргә, Казанда һәм округта «революцион тәртип» урнаштырырга.

Әйтергә кирәк, шактый колачлы бурычлар. Ләкин ул гамәлгә ашарлык түгел. Казандагы көчләр нисбәте инде күптән аның файдасына түгел иде. Дүрт укчы полкны, ике артбригаданы большевиклар тулысынча үз якларына тарта алдылар. Моннан тыш, бу хәрби берләшмәләр белән бер сафта ике эшчеләр дружинасы һәм революцион яшьләр отрядлары бар. Контрреволюция ягында исә хәрби училище, меңгә якын юнкер, ике меңләп кеше исәпләнгән ике прапорщиклар мәктәбе, казаклар отряды, броневиклар отряды һәм бер батарея.

Әнә шул көчләр белән капитан Калинин большевикларны тар-мар итәргә җыена. Аның боерыгы белән 19 октябрьдә юнкерлар отряды һәм ике броневик Арча кырындагы артиллеристлар казармасы янына килеп туктадылар. Максатлары — беренче артдивизионны коралсызландыру. Тупчыларга алар шулай дип белдергәннәр дә.

Тупчылар исә, Калинин уйлаганча түгел, ә үзләренчә җавап бирәләр. Вакытны әрәмгә уздырып тормастан, тупларны тартып чыгаралар һәм броневикларга ут ачалар. Юнкерларга табан ялтыратудан башка чара калмый. Дөресен әйтергә кирәк, артиллеристлар сугыша беләләр иде. Броняга төренгән контрреволюцион частьлар белән беренче бәрелештә үк алар шул осталыкларын күрсәттеләр. Армия төшенчәләре буенча кечкенә исәпләнсә дә, ул чыннан да бәрелеш, революция хакына сугышу иде. Шушы кораллы бәрелеш гарнизондагы бөтен частьларны хәрәкәткә китерде, солдат һәм офицерларда ачу уятты.

Нәтиҗәдә, 22 октябрьдә барлык частьлар вәкилләренең гарнизон җыелышы уздырылып, шәһәрдәге һәм округтагы хәлләр һәръяклап тикшерелде. Ершов, Грасис, Волков һәм Шелымханов катнашында үткән бу җыелыш частьларны сугышчан хәзерлеккә китерергә, округ һәм гарнизон командованиесе боерыкларына буйсынмаска, беренче очракта да бер частьның икенче частька каршы чыгуына юл куймаска дигән карар кабул итте. Моңа өстәмә итеп, татар роталары командирлары солдатларының үз полклары составында хәрәкәт итәчәкләрен һәм Хәрби шура боерыкларына буйсынмаячакларын белдерделәр.

Икенче көнне, ягъни 23 октябрьдә Казан большевиклар комитеты һәм эшче, солдат депутатлары Советының утырышы булды. Аның эшендә большевиклар хәрби оешмасының барлык членнары да катнашты. 25 октябрьдә иртән гомуми забастовка игълан итәргә, юнкерларга каршы хәлиткеч сугыш башларга, моның өчен алдан ук гарнизон частьларын һәм Кызыл гвардияне сугышчан хәзерлеккә китерергә карар бирелде.

Кораллы восстаниегә җитәкчелек итү өчен 240 нчы полкта һәм 2 нче артбригадада революцион штаблар булдырылды. Аңа Ершов, Волков, Фролов, Олькеницкий, Грасис, Шелымханов, Карпов, Масальский, Чанышев, Израилович, Милх, Дерунов, Шубин, Шулаков кертелде. Председатель итеп Ершов сайлап куелды.

Оештыру мәсьәләләрен караганнан соң, Ершов гарнизон алдында торган бурычларга, контрреволюция кыймылдый башлаганны күтеп тормыйча, дошманга беренче ударны ясау зарурлыгына тукталды.

Кремльгә һәм Сандецкий сараена юнкерлар кереп оялаган иде. Ершов аларны камап алырга һәм тар-мар итәргә тәкъдим кертте. Елга арьягы һәм Арча кыры ягыннан бәреп, дошманны оборонага күчерергә, шуннан файдаланып Кремльне һәм Сандецкий сараен кулга төшерергә кирәк иде. Аннан соң округ командованиесен һәм «Социалистик блок»ны кулга алырга, юнкерларны коралсызландырырга, ә каршылык күрсәтүчеләрне юк итәргә! «Сугышның үз таләпләре бар», диде Ершов. Бу очракта исә сүз идеялар сугышы, эшчеләр, солдатлар һәм крестьяннарның якты киләчәге өчен сугыш турында бара. Әгәр кан коела икән, ул изелгән халыклар азатлыгы хакына коелсын!

Тәҗрибәле хәрби эшлекле, оста җитәкче һәм стратегияне тирәннән аңлаучы кеше буларак, Ершов бу мөһим сугышны алып баруның төп принципларын да аңлатып бирде. Артиллеристларны саклау һәм, кирәк булса, яклау өчен 2 нче артбригадага 154 нче, 95 нче полклардан берәр батальон һәм 5 нче артбригадага бер дружина җибәрергә тәкъдим итте. 240 нчы һәм 94 нче полклар телеграф һәм телефон станцияләрен, банкны кулга төшерергә, шуның өстенә 240 нчы полкның ике ротасы вокзалны алырга тиеш. Кулга кергән мәгълүматлар буенча, Калининның Чистайдан прапорщиклар чакырырга җыенуы билгеле. Алар килә-нитә калса, вокзалда ук безнең частьлар белән очрашачак. 240 нчы полктан тагын ике ротаны Ершов Үсиягә җибәрергә планлаштырды. Шулай итеп, дошманның

барлык килү һәм китү юллары, ничек хәрәкәт итү ихтималы, аларга каршы чаралар — барысы да искә алынды. Вакыйгалар үсеше Ершов исәпләүләренең дөреслеген күрсәтте. Сүз уңаеннан шунысын да әйтим: безнең 240 нчы полкта хөкем сөргән сәяси атмосфераны да гаҗәп яхшы тоемлаган ул. Казан өчен, Совет власте өчен барган сугышларда полк солдатлары һәм офицерлары үзләрен тирән аңлы патриотлар, чын көрәшчеләр итеп күрсәттеләр. Халыкларны капитал изүеннән, самодержавие коллыгыннан азат итү теләге белән янучы, большевистик рух белән сугарылган гаскәри берләшмә иде ул.

Хәлиткеч бәрелеш көннәрендә дә шулай булды. Октябрьнең 24 енә каршы төн... Барлык гаскәри частьларда, фабрикаларда һәм заводларда халык мөһим күтәрелешкә әзерләнә. Большевиклар идеясе, бурычлары һәм максатлары аларга мәгълүм һәм ачык аңлаешлы.

Бу төн контрреволюциянең яшерен мөмкинлекләрен барлау, безнең исә көчебезне сынап карау төненә әверелде. Дошман, Казандагы хәлне ничек тә булса үз файдасына бору өчен, соңгы тапкыр талпынып карады. Бу «талпыну» нәтиҗә бирми калмады. Мәсәлән, егерме дүртенә каршы төндә алар Грасисны кулга алдылар һәм төрмәгә утырттылар. Бу исә капитан Калинин боерыгы буенча юнкерлар тарафыннан эшләнде. Икенче артдивизионда булган Ершовны да кулга алырга маташып карадылар. Броневикларга ышыкланып, операциянең беренче өлешен шактый уңышлы башкардылар: берләшмәнең бер өлешен коралсызландыруга ирештеләр. Ләкин төп максатларын — революцион рухлы солдат һәм офицерларны җитәкчесез калдыруны тормышка ашыра алмадылар. Большевиклар яклы тупчылар ярдәмендә Ершов чолганыштан бәреп чыкты һәм Арча кырындагы икенче артбригадага килеп җитте.

24 октябрьдә иртән округ командующие һәм капитан Калинин большевик җитәкчеләрне кулга алу өчен икенче артбригадага җәза отряды җибәрде. Ләкин артиллеристлар контрреволюционерлардан өлгеррәк булып чыкты, алар Сандецкий сараена ут ачтылар. Ә бераз соңрак, 95 нче һәм 164 нче полкларның тупчыларга ярдәмгә җибәрелгән батальоннары Арча кырына үтеп керде, икенче артбригада солдатлары һәм офицерлары белән берлектә юнкерларга һөҗүм башланды.

Елга аръягындагы полклар, Кызыл гвардия отрядлары Бишбалта һәм Кәҗә бистәләре буендагы Адмиралтейство дамбасында позицияләрне кулга төшерделәр, дамба өстеннән йөреп торган броневикларга ышыкланып килүче юнкерлар белән атыш башланды. Винтовкалар, пулеметлар белән коралланган Кызыл гвардия отрядлары Ягодный бистәсенең көнчыгышында урнашты. Дары заводы эшчеләре, ике зур орудие табып, шулай ук сугышка кушылды. Алар белән янәшә Алафузов фабрикалары эшчеләре һөҗүм итә. Эшчеләр хәтта гаскәри частьларга да кыюлык, батырлык, куркусызлык үрнәкләре күрсәтеп кенә калмадылар, тактик һәм стратегик тапкырлык та күрсәттеләр. Броневикларны торак кварталларга үткәрмәс өчен, мәсәлән, Казан ярына чыгарып ташланган бүрәнәләрдән дамбада баррикада корып куйдылар.

Атыш шактый озак дәвам итте. Һәр ике якта яраланучылар бар. Сугыш дәвамында аларның әле шактый булачагы ачыклангач, Ершов бердәнбер дөрес карарга килде. Революцион штабта ул Елга аръягы ревкомына һәм 240, 94 нче полклар комитетларына командующий штабы белән сөйләшүләр өчен Сандецкий сараена делегатлар җибәрергә тәкъдим итте.

Бу тәкъдим хуплангач, дошман белән сөйләшүгә ревкомнан Дерунов белән Шулаков, 240, 95, 94 нче полклардан Фролов һәм мин, Советлардан Израилович, Малх, Гринцбург, Шелымханов җибәрелде. Делегация шактый күпсанлы һәм дәрәҗәле иде.

Контрреволюционерлар да безне шулай күпләп җыелып каршы алдылар. Араларында полковник Архипов, капитан Калинин, меньшевик лидерлары бар. Ләкин эш аларның санында түгел, ә үзләрен ничек тотуларында иде. Безне Сандецкий кабинетына алып керделәр, беренче минутларда ук янаулы һәм мәсхәрәле тон белән «һөҗүмгә» күчтеләр.

— Ә... большевиклар ярлыкау сорап килгән!

— Нәрсә... бирeләсезме?!

— Солдат әфәнделәр! Рәхим итегез, сезнең өчен төрмә камералары да, пулялар да җитәрлек бездә,— дигән тавышлар ишетелде.

Мондый каршы алуны көтмәгән идек дисәм, дөрес булмас. Делегациядәге һәр кеше үзенең нинди хәтәр эшкә тәвәккәлләгәнен яхшы белә. Безне үлем көтүе дә ихтимал. Ләкин иптәшләребезнең тормышын саклап калу хакына шушы адымны ясарга тиеш идек.

Ләкин контрреволюционерлар иң мөһимен аңлап җиткерми: без «җиңүче»дән рәхим-шәфкать сорап түгел, ә үз шартларыбызны, таләпләребезне куярга дип килдек. Шелымханов бу турыда турыдан-туры һәм аңлаешлы итеп белдерде дә.

— Без сезгә сораучы сыйфатында түгел, ә эшче, крестьян һәм солдат депутатлары Советы делегатлары, баш күтәргән,— кабатлап әйтәм, баш күтәргән! — гарнизон делегатлары буларак килдек. Безгә шәһәрдә властьны Советларга тапшыруны, юнкерларны коралсызландыруны һәм капитан Калининны округ белән командалык итү хокукыннан читләштерүне таләп итәргә вәкаләтләр бирелгән,— диде ул.

Әйткәннәренең мәгънәсе тыңлаучыларга тирәнрәк барып җитсен өчен, Шелымханов бераз тын торды һәм яңадан дәвам итте:

— Барлык полклар һәм артиллерия частьларының революциягә тугрылыгы, большевикларны яклавы һәм Советлар власте өчен җаннарын аямый сугышачакларына ышангансыздыр.

Һәм, ниһаять, ультиматумны ул мондый сүзләр белән тәмамлады:

— Уйлану һәм бер карарга килү өчен, Совет сезгә бер төн вакыт бирә. Әгәр дә иртәнгә кадәр безнең тәкъдимнәр кабул ителмәсә, һөҗүмгә күчәчәкбез һәм ут ачачакбыз!

Кырмыска оясына таяк тыгып бутадылармыни! Бердән шау-шу, гауга купты. Берсен-берсе уздырырга тырышып кычкырыша башладылар. Имеш, большевиклар барыбер сытып ташланачак, башлап йөрүчеләрне якындагы агачларга асып куячаклар, парламентерлар исә Сандецкий сараеннан исән чыкмаячак. Кем белә, кайнар кулдан бу берьяклы бәхәс нәрсә белән тәмамланган булыр иде, шул чакта полковник Архипов ташлаган бер сүз ишетелде. Округ командующие буларак, ул гаскәрләрдәге чын күренешне яхшы белә һәм үзе яклы кешеләрнең мөшкел хәлдә икәнлеген дә аңлый иде. Менә шунлыктан булса кирәк, җаен туры китереп, ул болай диде:

— Миңа калса, большевиклар тәкъдиме турында... уйлап карарга була кебек.

Меньшевиклар, эсерлар, «социалистлар» шунда ук аңа ташланды. Калинин барысыннан да уздырыбрак кычкыра:

— Ничек итеп сез... Вакытлы хөкүмәткә ант иткән офицер большевиклар белән килешүгә барасыз? — диде ул ярсынып.— Пушкаларны аларга каршы борасы, ә башлап йөрүчеләрне атасы урында?! Мин сезне аңламыйм! Сез җиңеп чыкканчыга кадәр үзебезнең законлы хөкүмәтне якларга тиешсез. Тиешсез! Бу — сезнең бурыч!

Эңгәмәнең икенче юнәлешкә кереп китүеннән файдаланып, Шелымханов үз сүзләрен кыстырды:

— Әфәнделәр, сез киңәшә торыгыз, без китә торыйк. Күрәм, әле сезнең хәл итмәгән уртак фикергә килмәгән мәсьәләләрегез байтак. Ә җавапны бирердә,— сарайда ишеткәнгә караганда эшлеклерәк төстә алу дөрес булыр.

Без Сандецкий кабинетыннан чыгып киттек һәм монда килүнең, контрреволюционерлар белән сөйләшүнең ничек тәмамланганын хәбәр итү өчен, ревкомга ашыктык.

Ершов зур игътибар белән тыңлады һәм мондый йомгак ясады:

— Сандецкий сараенда оялаган бу кешеләрдән уңай җавап ала алмабыз дип уйлыйм. Ләкин аларның көч туплаганнарын, Казандагы һәм округтагы халыкне ачыклап бетергәннәрен, Чистайдан ярдәм китергәннәрен дә көтеп

тора алмыйбыз. Тиз, кыю, революционерларча... эш йөртергә кирәк! Башкача әйткәндә, кораллы бәрелешкә әзерләнергә!

Шулай хәл иттек тә. Тагын бер сәгатьтән барлык гаскәри подразделениеләргә, фабрика-завод комитетларына большевикларның, кулга корал тотып, Советлар властен якларга, революцион халыкның тулы җиңүенә кадәр юнкерлар белән ачык көрәш алып барырга карар бирүе турында хәбәр җиткерелде.

25 октябрь көнне иртән хәлиткеч һөҗүмгә күтәрелдек. Фабрика һәм завод гудоклары гүли башлады. Эшчеләр коралга тотынды. Арча кырындагы артиллеристлар берьюлы ун батареядан Сандецкий сараена ут ачты.

240 нчы полк, дары заводы һәм алафузовчыларның Кызыл гвардия отрядлары белән берлектә Казан үзәне һәм тимер юл буенча һөҗүмгә күчте, юнкерларны Кремльгә таба кысрыклый башлады. Алар исә, камалуда калудан куркып, ашыгыч рәвештә күпергә таба чигенде. Бу операция көн уртасына кадәр дәвам итте.

Көннең икенче яртысында, броневиклардан яудырылган ут яңгырына да карамастан, алафузовчылар (алар арасында татар эшчеләре дә күп иде), 240 нчы полк ярдәменә таянып, юнкерларны Адмиралтейство дамбасыннан алып ташлады һәм Кремль стенасына китереп кысты.

95 нче һәм 164 нче полклар, Крестовниковлар заводы отрядлары исә артиллеристлар белән бергәләп, Сандецкий сараен алдылар. Чигенеп баручы юнкерлар Кремльгә омтылды. Ярдәмгә дип ашыккан бу төркемнәр үзләре җиңелүгә дучар булды. Кызыл гвардия отрядлары һәм революцион полклар Кремльне камап алды, калын крепость стеналарын үтеп, эчкә ыргылды.

...Мин күпчелек кабинетларның ничек урнашканын яхшы беләм, элек аларда шактый еш булырга туры килә иде. Шунлыктан, командующийның кабул итү бүлмәсенә барып җитәргә күп вакыт кирәк булмады. Минем арттан ышанычлы адымнар белән солдатлар килә. Кораллы восстаниенең хәлиткеч мизгеле килеп җитте. Бер адым, ике адым, тагын... Ишекне тартып ачтым һәм кабинетка атладым. Офицерларга исләрен җыярга һәм нәрсәдер хәл кылырга мөмкинлек бирмичә, наган көпшәсе белән капитан Калинин алдындагы өстәлгә күрсәтеп:

— Тавышланмавыгызны сорыйм! Коралны — өстәлгә! Барыгыз да урыннарында кала! Каршылык күрсәтү файдасыз! — дип кычкырдым.

Кая ул тавышланмау?! Капитанның өстенә кайнар су сиптеләр диярсең, сикереп торды һәм базар хатыннары шикелле чинап кычкырып җибәрде:

— Сүзләреңне ничек аңларга, прапорщик? Ничек батырчылык иттегез! Ни дигән сүз бу?!

Тынычлык сакларга тырышып җавап бирдем:

— Кремль — революцион солдатлар кулында. Шәһәрдә власть Советларга күчә.

Шул ук мизгелдә кабинетка унлап солдат килеп керде. Тавышсыз гына, каты басып, көчле кулларына винтовкаларын кысып килеп керделәр алар. Кыю һәм кискен адымнары, сугышчан кыяфәтләре сүзләремнең раслыгын исбатлагандай булды. Капитан Калининның да, иярченнәренең дә башка юлы юк иде инде. Һәм ул бу очракта мөмкин булган бердәнбер юлны сайлады — коралын мин күрсәткән урынга ташлады. Аның үрнәгенә башка офицерлар да иярде.

Властьны революцион эшче һәм солдатлар кулына тапшыруның беренче этабы шулай тәгәлләнде. Округ командованиесе вәкаләтләреннән ваз кичте. Казанда яңа власть урнаштыруның үзенчәлеге, символы булып Кремль өстендә кызыл флаг җилферди башлады. Мәйданга тантана итүче эшчеләр, солдатлар, хатын-кызлар, балалар җыелды, бу көн чын мәгънәсендә халык бәйрәменә әйләнде.

Халыкны капитал изүеннән азат итү көне иде бу. Казан яңа тормышка аяк баскан көн.

Хөррият яуланган шушы беренче көнне үк пайтәхеттән телеграмма килеп төште. Анда Вакытлы хөкүмәтнең бәреп төшерелүе, илдә бөтен

властьның эшче һәм солдат депутатлары Петроград Советына күчүе хәбәр ителгән иде.

Хәтта житмеш ел узганнан соң да дусларымның, көрәштәшләремнең, Казанда революцион вакыйгаларда, азатлык хәрәкәтендә катнашучыларның йөзләрен ачык күз алдына китерәм. Никадәр елмаю балкыган, күпме көлү, шатлыклы һәм бәхетле җырлар яңгыраган иде ул көнне. Ә лозунглар!.. «Яшәсен Советлар власте!», «Бетсен сугыш!», «Халыкка — тынычлык, крестьяннарга — җир!», «Яшәсен Ленин!»

Һәркем Ленин исемен — дөнья пролетариатының бөек юлбашчысы исемен телгә ала.

...Икенче көнне, 26 октябрь кичендә, эшче, солдат һәм крестьян дупутатлары Казан Советының киңәйтелгән утырышы булды. Казан пролетариаты һәм Казан губернасының беренче органы — революцион комитет сайланды! Бер көн элек кенә революцион солдатлар һәм эшчеләр тарафыннан төрмәдән азат ителгән Грасис бертавыштан председатель итеп күрсәтелде. Аның урынбасары Венецианов, политик секретарь Ольковицкий булды. Ершов, Масальский, Волков, Рудов, Фролов, Бочков, Милх, Карпов, Гинцбург, Кортов, Вахитов, Якубов, Чанышев һәм Израилович ревком члennары итеп сайланды.

Шушы ук утырышта Ершов Казан хәрби округы командующие итеп сайланды. Ревком шәһәрдә һәм аның тирәләрендә тынычлык һәм тәртип сакларга чакырып мөрәҗәгать итте һәм, кем әйтмешли, агымдагы мәсьәләләргә күчте. Аның җитәкчелегендә солдатлар һәм эшчеләр тәртип урнаштыра башладылар. Революцион комитет байтак кына оештыру мәсьәләләрен дә хәл итте: шәһәрдәге мөһим, җаваплы постларга — телеграф, телефон, дәүләт банкы, азык-төлек комитеты кебек җирләргә үз комиссарларын билгеләде. Революцион тәртип булдыру, иске чиновник аппаратын җимереп, гади кешеләргә якын һәм аңлаешлы демократик совет учреждениеләрен төзү алар карамагына бирелде.

Мәгълүм булганча, Ленин теләсә кайсы революциядә төп мәсьәлә власть мәсьәләсе дип алдан ук кисәтеп куйган иде. Аны алу — зур эшнең башы гына. Ә властьны пролетариат кулында саклап калу, ныгыту, какшамас һәм җиңелмәс итү — төп бурыч булды һәм шулай булып кала да. Һәм бу мәсьәләдә төп рольне Кызыл гвардия уйнарга тиеш иде.

Менә шунлыктан, ревком һәм Казан хәрби округы гаскәрләренең яңа командующие Ершов иң беренче эш итеп промышленность предприятиеләре дружиналарын ныгыттылар, кызыл гвардиячеләрне яхшылап коралландырдылар, аларга яңа кешеләр кабул итүне оештырдылар.

Шуның белән бергә, оешып килүче регуляр Кызыл Армия частьларына революцион солдатларны чакырып аңлату эшләре алып баруга да зур игътибар бирелде. 29 октябрьдә Ершов беренче приказын чыгарды, властьның солдатлар һәм эшчеләр кулына күчүе белән генә хезмәт халкын капиталистлар һәм җир биләүчеләрнең күпьеллык изүеннән азат итүнең тәгәлләнмәвен, аның әле башланып кына китүен аерып, басым ясап күрсәтте. Мондый шартларда партия белән халык бердәмлеген ныгытырга, контрреволюциягә каршы уртак көрәшкә солдатлар һәм эшчеләрне тыгызрак тупларга кирәк. Дошман йоклап ятмый, дип белдерде ул, һәм аның каршылык күрсәтүенә без әзер булып торырга тиеш.

Бу сүзләрдә командующийның зирәклеге һәм политик уяулыгы ачык чагылды. Ершов идея дошманнарыбызның казынуларын алдан күрә белде. Ә алар, чыннан да, озак көттермәде. Эсерлар һәм меньшевиклар командующийга яла яга башладылар, аны эзәрлекләргә керештеләр һәм хәтта бу посттан алуны таләп иттеләр. Үз кандидатларын күрсәтеп кенә калмыйча, алар революцион солдатлар төрмәгә япкан элеккеге командующий Архиповны һәм капитан Калининны азат итәргә кирәк дип белдерделәр.

Ревком контрреволюциянең барлык бу дәгъваларын кире какты һәм 31 октябрьдә «Знамя революции» газетасында аларның позициясен аңлатып, Казан хәрби округы солдат депутатлары Советларына мөрәҗәгать бастырып чыгарды.

Аннан ике көн алдарак эшче һәм солдат депутатлар Советының киңәйтелгән утырышы үткәрелеп, анда башкарма бюро сайланган иде. Ревком вәкаләтләрен аңа тапшырды. Башкарма бюро председателе итеп, Советларның II съездыннан килгән Ежовны сайладылар. Шейнкман эшче, солдат һәм крестьян депутатлары Казан Советы председателе постына тәкъдим ителде.

Шулай итеп, 1917 елның 4 ноябреннән Казанда һәм губернада бөтен власть Советлар кулында иде инде.

Төбәктәге революцион хәрәкәт тарихында бу — хәлиткеч борылыш чоры булды. Казан хәрби округы солдат Советларының икенче съезды да зур политик активлык белән үтте, идеологик эшкә яңа этәргеч бирде.

Съезд 16 ноябрьдә ачылды һәм аның каравына түбәндәге мәсьәләләр куелды: агымдагы момент турында партиянең Казан губерна комитеты вәкиле доклады; эшче-крестьян армиясен төзү турында; яңа округ комитеты һәм округ белән идарә итү өчен хәрби коллегия сайлау турында.

Съезд эшлекле төстә үтте. Анда иске хәрби берләшмәләр һәм артбригадалар нигезендә иректе башлангычта отрядлар, полклар төзү турында резолюция кабул ителде. Съезд шулай ук 65 кешедән хәрби округ комитеты һәм Казан хәрби округына идарә буенча хәрби коллегия төзү турында карар кабул итте. Соңгысы округка идарә итү буенча Комиссарлар Советы дип үзгәртеп корылды.

Шушы Совет составына биш кеше: большевиклар Ежов, Скачков һәм мин, сул эсерлар Котляров һәм Останин кертелде. Омскига киткән Ершов урынына Ежов билгеләнде.

Съезд тәмамланганнан соң ук Комиссарлар Советы үз алдына куелган бурычларны гамәлгә ашырырга керешге. Аерым алганда, безгә округ белән идарә итүне үзгәртеп корырга, ышанычлы кешеләрдән комиссарлар сайлап алырга һәм билгеләргә, хәрби училище һәм прапорщиклар мәктәбен бетереп, алар урынында кызыл командирлар әзерләү буенча кыска сроклы курслар ачарга, кызыл отрядлар оештырырга, акгвардиячеләр һәм бандитизм белән көрәштә округ гарнизоннарына ярдәм итәргә кирәк иде.

Минем үземә хәрби училищены ябу һәм Кызыл армия частьларын оештыруда файдалану өчен фронтовик офицерларны ачыклау бурычы йөкләнде. Хәрби шура эшчәнлегенә контроль урнаштыру да минем вазифага кертелде. Бусы да бик мөһим эш иде.

Бераз алгарак китеп булса да, шуны әйтергә тиешмен, бу соңгы мәсьәлә буенча Комиссарлар Советына мөселман солдат һәм офицерларның II Бөтенроссия хәрби съезд делегатлары — Галиев, Касыймов, Мәүлетов, Галиев гаять зур ярдәм күрсәттеләр. Чын ленинчы, какшамас рухлы шушы кыю большевиклар булышлыгы белән, ниһаять, без Хәрби шураны һәм Мөселман хәрби комитетларын тарката алдык.

Ләкин алар турында соңрак сөйләнер. Ә минем 1917 елгы ноябрь көннәрендә Казан хәрби округы комиссары постына сайлануым белән катлаулы, авыр язмышымның тагын бер чоры тәгәлләнде. Революция җиңеп чыкты. Илдә власть халык кулына күчте. Хәзер аны, кулга корал тотып, мәкерле, хәйләкәр һәм куркыныч дошманнан саклау өчен көрәшкә күтәрелергә кирәк иде.

## Риза Ишморат

# ГОМЕР СУКМАКЛАРЫ

ИСТӘЛЕКЛӘР*

* * *



Мәдрәсәдә торып укымый иде Мәүлихан шәкерт. Янбарыска якын ниндидер бер чит авылдан килеп күптәннән укый иде. Уналты-унҗиде яшьләр тирәсендәге өлкән шәкерт иде ул. Яртылаш ятим. Әтисез. Бик ярлы. Өстендә һәрвакыт ямаулы бишмәт. Аягында оек-чабата. Башында бик иске, камалы хәтфә бүрек. Исеме генә камалы бүрек, ә җисеме... Хәтфәсе дә, камасы да күптән инде кырылып, ашалып беткән. Эчендәге мамыгы да бүселеп чыгып бетә язган. Кайчандыр ул берәр бай гына кешенең башында булгандыр, мөгаен. Аннан, чүплеккә чыгарылып ташланган җирдән, Мәүлихан башына килеп утыргандыр. Шул. Ә бүрек астында ямьшәеп, майланып беткән яшькелт түбәтәй. Ул Мәүлиханның озын гына булып үскән чәчен каплап та бетерә алмый. Кулында һәрвакыт алачадан теккән иске букча. Букчада таушалып, тузып беткән китаплар — әфтияк, соббәтелгаҗизин, бәдавам һәм тагынниләрдер. Шул ук букчада бер кыерчык ипи, берничә пешкән бәрәңге, хәтта кайвакыт берәр шакмак шикәр дә була. Озын һәм чандыр буйлы, ач яңаклы Мәүлихан шәкерт бик ярлы, киемсалымы сәләмә булса да, күңеле бик күп вакыт көр аның. Авызында һәрвакыт ниндидер мәзәк, тапкыр сүз. Я нинди дә булса бер җыр, такмак. Кушаматы да аның «мәзәкче Мәүли». Ишектән кереп, чабатасын салып бетәр-бетмәс үк, бер кызыклы әйтем әйтеп куя. Гарәпчәләп ниндидер бер дога белән башлый да аннан татарча такмакка борып җибәрә. Мәсәлән, болай: «Кәлимәтен тайибәтен... әти, миңа тай җигәсең, дилбегәсен тоттырасың, үзең карап тик торасың!» Я булмаса, болай дип такмаклый: «Әссәбехе мәдәни, суктым-ектым кәҗәне. Китте кәҗә тәгәрәп, шул булды бөтен мәзәк».

Мәүлихан ишектә күренмәме, шәкертләр аны: «У-у, мәзәкче Мәүли килде»,— дип шаулашып-гөрләшеп, хуплап каршы алалар. Бары да ярата Мәүлихан шәкертне. Еш кына аның белән азык-төлекләрен дә бүлешәләр. Шуңа күрәдер, мөгаен, тамак тук, күңел көр аның. Киң табигатьле егет Мәүлихан шәкерт. Такмак та әйтә, тапкыр әйтемнәр дә, табышмаклар да әйтә.

---

РИЗА ИШМОРАТ *(1903) — драматург, публицист, тәрҗемәче. «Үлмәс җыр», «Шаулыйлар дулкыннар», «Давылга табан» — барысы кырыкка якын пьеса авторы, РСФСРның һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

* Әсәр кыскартып басыла.

Тап, тап, таптыра,
Табалмасаң — аптыра,
Йөгертә дә чаптыра,
Чит җирләргә тарттыра.
Ул нәрсә? —

ди.

Безнең ише бала-чага нәрсә диярга дә белмичә аптырап торган арада, Мәүлиханның үзе шикелле үк сүзгә оста Ясәви шәкерт бик тиз җавабын табып бирә. Алай гына да түгел әле, шул табышмакка каршы табышмак белән җавап бирә.

— Ул нәрсәме? Ул:

Көч түкмичә, бил бөкмичә
Кулга керми бу нәрсә,
Кулга керсә, тиз ычкына,
Сизелми дә бу нәрсә,—

ди.

— Белдем! — ди арадан бер шәкерт,— кулга кереп җитмәс борын үк ычкына торган булгач, А К Ч А дигән каһәр инде ул,— ди.

— Дөрес! — дип, башкалар да раслап куя аның сүзен.

Җырга да, биергә дә оста Мәүлихан. Бер җайлырак вакыт чыктымы, хәзер җырлап җибәрә.

Җырла, җырла дип әйтәсез,
Җыр чәчмәдем бакчама,
Җыр чәчмәсәм дә бакчама,
Сатып алмыйм акчага.

— Җырың бушка гына килгәч, тагын берне җырла,— диләр аңа. Ул ялындырып тормый, тагын да дәртләнебрәк җырлый:

Яңа өемнең түренә
Элеп куйдым тастымал,
Уф, йөрәгем, су сибегез,
Ут кабуы ихтимал.

Шулай да аны яратмаучы, хәтта дошман күрүче шәкертләр дә юк түгел. Аеруча үзләрен бик күп белүче дип исәпләгән пишкадәмнәр, ислам диненең саф вә мөнәззәһ булуы өчен чукынып үләргә әзер торган кадим һәм мотәгассыйп мулла, мәзин малайлары яратмыйлар мәзәкче Мәүлиханны. Яхшы постаудан яңа фасон белән тегелгән казаки һәм чалбар кигән, сәхтиян читек, резин галош белән фарчит итүче сәүдәгәр малайлары да аны чит күрә, яхшы укуы, тапкыр сүзле, зирәк акыллы, җор егетнең күпчелек тарафыннан яратылуы, хөрмәт ителүе ошамый аларга. Бигрәк тә өстенә буй-буй зәңгәр трикодан теккән казаки киеп, түш кесәсенә озын чылбырлы көмеш сәгать тагып йөрүче Габделкадыйр әфәнде яратмый аны. Яратмый гына да түгел, бөтен барлыгы белән дошман күрә. Очраганда, кылаеп карап китү генә түгел, нинди дә булса дорфа сүз, «Нихәл, ач эрвах? Өтелгән чебеш?» кебек мыскыллау сүзләре әйтеп китә. Мәүлихан шәкерт тә җавапсыз калмый, билгеле. Чәнечкеле җаваплары белән Габделкадыйрның җен ачуын чыгара.

«Нихәл, ач эрвах?»— диюгә ул, уйлап та тормыйча: «Шөкер әле, Габделкарун әфәнде»,— дип, Кадыйрның карунлыгын йөзенә бәрә. «Өтелгән күркә!»— дисә,—«Шөкер әле, симергән хинзир[1] әфәнде», дигән җавабы белән Кадыйрның авызын томалый. Боларның чәкәләшүеннән шәкертләр көлә, билгеле. Чәнечкеле сүзләр әйтеп ярышуда һәрвакыт җиңүче булып, өстен булып Мәүлихан шәкерт кала. Көннәр шулай эреле-ваклы ыгы-зыгы белән бер-бер артлы үтеп торганда, олы фаҗига белән тәмамлана язган коточкыч бер вакыйга булды.

---

[1] Хинзир — дуңгыз.

Икенде намазын гадәттә шәкертләр мәдрәсәдә генә укый. Мәгъсум хәлфә дә, мәчеткә бармыйча, икендене, аның артыннан ахшам намазын да шәкертләр белән бергә мәдрәсәдә генә укый. Имамлык вазифасын үти. Намаз тәмамланып, соңгы аят укылып, догалар кылынгач, шәкертләр, аеруча баераклары, хәлфә абзыйга хәер-садака да бирә. Хәлфәнең күңелен күреп, аңа ярау өчен Габделкадыйр кебек баераклар зуррак та өлеш чыгара. Шундый бер көнне, ишек янындагы бүлмәдән, өс-баш киемнәре, аяк киемнәре салынып куела торган җирдән, казакиен салып, тәһарәт алып йөргән арада, Габделкадыйр кесәсеннән илле тиенлек көмеш акча югалган. Биш тиенлек бакыр гына түгел, илле тиенлек көмеш! Ай-яй зур акча иде бит илле тиен ул заманнарда. Бигрәк тә шәкерт халкы өчен. Берәү булса, бу хәл өчен әллә ни кыланмас, шау-шу күтәрмәс, хәерле каза булсын дип кенә калдырыр иде. Ләкин бер тиен өчен җанын бирергә әзер торган, карунлыкның чигенә житкән Габделкадыйр тыныч кына кала аламы соң? Юк, калмый. Портмонетында илле тиен акчаның юкка чыгуын белү белән, шундый шау-шу күтәрде бу, я алла! Булса да була икән дөньяда кешеләр!

— Бәлки, пыртманитыңда булмагандыр ул илле тиенең? Башка кесәңә, я сандыгыңа-мазар салгансыңдыр? — диләр аңа.

Юк, ишетергә дә теләми.

— Кесәмә кереп алганнар, урлаганнар! — ди.— Бур эше, карак эше бу,— ди. Аны яклаучы, аның сүзен сүз итеп, күтәреп алучы бигрәк тә Габделкадыйрның үзе кебек баерак шәкертләр гөр килеп шаулаша башлады.

— Тентергә барлык кешенең дә кесәсен!

— Сандыкларын! Урын-җирен!

Шау-шуга килеп житкән Мәгъсум хәлфә дә бугаз ертып кычкыручы бай шәкертләрнең сүзен кире какмады. «Бөтен шәкерт кесәсен, урын-җирен тентеп, аларны бурлыкта гаепләү кебек хурлыклы эшне рөхсәт итә алмыйм» димәде. Тентү була калса, бөтен нәрсә актарылып, туздырылып ташланачак, мәдрәсәнең асты өскә килеп, мәхшәр көнен хәтерләтәчәк иде. Ләкин эш аңа барып житмәде. Габделкадыйр үзе үк кычкырып:

— Берәүне дә тентеп торасы юк, акчаны кем урлаганы мәгълүм, шаһитлар бар, менә алар,— дип янында торган ике малайны күрсәтте.

— Кем ул бур?

— Мәүлихан...

— Мәүлихан?!

— Булмас!

— Нахак!— дип кычкырды күп кенә шәкерт.

— Бур булмаса, намаз вакытында утын ярган булып йөрмәс иде. Бияләй эзләгән булып нигә актара ул кеше кесәсен?

Сырма кесәмнән бияләй алырга мин үзем рөхсәт иттем аңа,— диде калын гына тавышлы бер шәкерт.

— Алай булгач, нигә синең сырмага түгел, минем казаки кесәсенә керә ул?

— Бәлки ялгышып кына...

— Ялгышып?!— Күп кенә шәкерт көлеп җибәрде бу сүздән.

— Ялгышып нигә Гарәфи кесәсенә түгел, Габделкадыйрның акчалы кесәсенә кергән?

— Кем күргән? Кайда шаһитлар?

— Әйтеп бир әле, энем, күргәнеңне!

— Мин... ни...

— Әйт, әйт!.. Курыкма!

Сүзләрен ишетелер-ишетелмәс кенә башлаган малай кинәт ачылып:

— Мәүлихан абыйның акча урлаганын күрдем,— диде.

— Мин дә күрдем,— диде икенчесе, янәшәдә басып торганы.

— Ишеттегезме? Үз күзем белән күрдем ди.

— Бары да мәгълүм. Күп төпченеп торасы юк, тотарга да ярырга ул каракны! Башкаларга сабак булсын!
— Ашыкма!..
— Яру да әз аңа. Кулларын бәйләргә дә бәкегә тончыктырырга!
— Үзе кайда, үзе? Кача күрмәсен!
— Әле генә утынлыкта иде.
— Алып керәбез дә самасуд ясыйбыз...
Туган көннәреннән бирле харам ашап, мин-мин дип кукраеп, үзләрен әллә кемгә куеп үскән, укыганда да аннан-моннан гына укып, тупаслыгы, наданлыгы белән мактанучы күп кенә бай малайлары, карагруһ мулла малайларыннан да усалрак, мәкерлерәк кешеләр күп түгелдер, мөгаен, бу дөньяда.
Өсте-башы да чиста, заманага муафыйк итеп тегелгән дә була күбесенең. Чәчләре дә җиту, түбәтәе дә кыңгыр, түш кесәсендә сәгать... Һәр ике сүзнең берендә алла... дин, шәригать, рәсүл, фәрештә, ә эчендә кара елан, кирелек, усаллык, рәхимсезлек... Әнә шундый кара фикерле, карагруһлар ябырылды Мәүлихан шәкерткә. Илле тиен өчен түгел, ә Мәүлихан шәкертнең тапкыр һәм әче теле өчен.
Әнә аны тыштан өстерәп алып керү өчен ике шәкерт ишеккә ыргылды. Ыргылдылар, әмма өлгермәделәр. Нәкъ шул вакыт ишек ачылды һәм зур кочак утын күтәреп, мондагы хәлләрне әле ишетеп тә өлгермәгән, шуңадыр, мөгаен, тыныч кына кыяфәттә Мәүлихан үзе килеп керде. Ул утынын ишек янынарак урнашкан зур мич белән стена арасындагы аралыкка куеп та өлгермәде, әлеге ике шәкерт аның якасыннан тотып:
— Менә ул бур, измәсен изегез бәдбәхетнең,— ди-ди, шәкертләр янына, Габделкадыйр белән Мәгъсум хәлфәнең алдына ук китереп бастырдылар. Мәүлихан аптырап:
— Нинди бур мин, нәрсә урлаган? — дип, Габделкадыйрның кызарып бүртенгән йөзенә, зәһәр чәчеп торган күзләренә карады.
— Ач әрвах, хәерче! Хәзер үк кайтарып бир минем илле тиенне... Югыйсә...
— Илле тиен түгел, сукыр бер тиенеңә дә кагылганым юк... Кесәңә керергә каракмы әллә мин...
— Карак! Кесә карагы, мошенник!
— Хакың юк яла ябарга! Фасунлы казаки кидем, чылбырлы көмеш сәгать тактым дигәч тә әллә...
— Көмеш сәгать сиңа төс түгел шул, эсвинжә!..— диде дә аны җилкәләп китергән шәкертләрнең берсе, олы чукмардай йодрыгы белән Мәүлиханның яңагына сугып та җибәрде. Аның артыннан ук бөтен көчен җыеп Габделкадыйр сукты.
— Җанын ал каракның, башын из! — дип, кемдер котыртып торды. Йөзләрен ачу баскан олы гына шәкертләр Мәүлиханны идәнгә егып тәпәли дә башладылар.
— Үтерәләр, кәпә-көндез кеше үтерәләр! — дип кычкырды берәү.
— Үтер! Бугазын өз бурның,— дип кычкырды Габделкадыйр.
Чукмар йодрыклы егетнең йодрыгы Мәүлиханның башына кат-кат менеп төште, кемдер аягы белән дә типкәләде аны. Бик авыр хәлдә калды Мәүлихан... Ләкин ул арада булмады, сабан туйларында көрәшеп дан алган, мәдрәсәдә генә түгел, бөтен тирә-якта «Батыр Кирам» дип танылган Кирам шәкерт алга чыкты да Мәүлиханга ябырылган егетләрнең кулларыннан, я җилкәләреннән алып, төрле якка чөеп җибәрә башлады. Батыр Кирам беләгенең көчен, аның бәясе күпме торганын яхшы белә торган шәкертләр сугышны артык дәвам иттермәделәр.
— Каракны якларга хакың юк,— дип, Габделкадыйр аңа җикеренеп караса да, Кирамның үткен һәм утлы карашы белән очрашкач, кинәт юашланып калды. Шулай да бирешергә теләмәде.— минем шаһитларым бар,— диде ул әтәчләнеп. Моннан соң вакыйганың барышы бераз тыныч-

рак, шау-шусызрак төс алса да, үзенең киеренкелеге, ниндидер бер дәһшәтлелеге белән күңелгә бик авыр иде. Башта күңелләреннән Мәүлиханны яклаучылар да соңрак бераз шикләнеп, икеләнеп калдылар. Мәүлихан әллә чыннан да шундый әшәкелеккә барды микән? Әнә бит ике малай чатнатып әйтеп тора. «Үзебез күрдек»,— диләр. Караклык нинди зур әшәкелек һәм гөнаһ бит ул. Зыя абый белән минем дә уйларыбыз шундыйрак хәзер. Мәүлихан шәкертне дә чын күңелдән кызганабыз. Ләкин чын карак булып чыкса, бик яклыйсыбыз да килми. Юк, Габделкадыйр шәкертнең илле тиен акча югалтканын кызганып түгел. Кесәсеннән кайдадыр төшеп кенә югалган булса, бик яхшы, югала бирсен. Шул кирәк аңа, ике аяклы бүрегә!

Хәзер инде Мәүлихан шәкертне хөкем итү Мәгъсум хәлфә кулына күчте. Ул яңаклары, битләре каралай янган, күгәреп-шешеп чыккан, авыз, борын тирәләре канланган Мәүлихан шәкертне каршысына тезләндереп, сорау ала башлады.

— Әйт дөресен, нинди ният белән урладың ул илле тиенне?

— Мин бер тиен дә урламадым...

— Алдашма! Урлавың мәгълүм. Өйгә кергәнеңне дә, казаки кесәсенә тыгылып акча алганыңны да күрүчеләр бар.

— Өйгә керүем дөрес, Кадыйрның казакие янынарак эленгән Габделәхәт сырмасы кесәсеннән бияләй алуым да дөрес. Әмма ләкин акча алганым юк.

Габделкадыйрның ымлавы буенча әлеге тымшык борынлы, базык гәүдәле шаһит:

— Алдың, Мәүлихан абзый, алдың, үзем күрдем,— диде.

— Алдашма, энем, күрмәдең. Алмаганны күреп булмый ул,— диде Мәүлихан, малайның күзләренә туп-туры карап.

Тымшык борын күзләрен аска төшерде.

— Үзең алдашасың! — дип кычкырды Мәгъсум хәлфә.— Дөресен әйт. Урладыңмы?

— Урламадым.

— Дөресен әйтмәсәң менә... каезлыйм аркаңны,— диде янындагы пеше тал чыбыкларына күрсәтеп.

— Каезла, хәлфә абзый, мин дөресен әйттем,— диде Мәүлихан ниндидер бер әчке әче тавыш белән.

— Ят! — диде Мәгъсум хәлфә кычкырып.

Мәүлихан рәхимсез хәлфәнең күзләренә карап алды да, ике кулын ике якка ташлап, йөзтүбән ятты һәм, кыйнарга булгач рәхәтләнеп кыйнагыз инде дигәндәй, ачу белән аякларын ук сузып җибәрде. Шул секундта ук әлеге ике шәкерт Мәүлиханның бишмәтен дә, күлмәген дә күтәреп куйдылар. Хәтта берсе аның чалбарын да яртылаш тартып төшерде. Бөтенләй ялангач калган тәнгә, Мәгъсум хәлфә бөтен көче белән бер-бер артлы дүрт тапкыр сугып алды. Бу хәлне тамаша итеп торган бөтен шәкерт «аһ!» итеп йөзен җыерып куйды. Мин, Зыя абыйга елышып, аның кулына тотындым. Ул, түз, түз, дигәндәй минем кулымны кысты. Башы аска иелгән булса да, аның әче нәфрәт уты белән янган күзләре шушы кыргый күренешне күзәтә иде. Аның гына түгел, шәкертләрнең зур күпчелеге күңелендә Мәгъсум хәлфәгә карата, ике аяклы хайван Габделкадыйрга, аның үзе шикелле үк «тырыш» дусларына карата да, гомумән бу «низамлы» дини мәдрәсәнең бөтен низаматәртибенә карата да нәфрәт уты сизелә иде. Әйтерсең лә Мәгъсум хәлфә суккан тал чыбык Мәүлихан шәкерт аркасына түгел, безнең үз аркабызга, шушы кыргый тамашаны күреп, аңа чыдап торган шәкертләр аркасына төшә иде. Ләкин Мәүлихан шәкерт үзе әз генә дә ухылдамады, сызланып еламады да. Абый белән без моңа исебез китеп бер-беребезгә карашып куйдык.

— Тор, утыр тезләнеп! — дип кычкырды Мәгъсум хәлфә, тал чыбыгын бер як читкә куеп.

Мәүлихан чалбарын, аннан бишмәтен, күлмәген дә күтәреп, йөзен сызланудан да бигрәк ачу галәмәте чыгарып, тезләнеп утырды.

— Я, инде шаять, дөресен сөйләрсең,— диде хәлфә Мәүлихан шәкертнең йөзенә туры карап.

— Дөресен сөйлим, хәлфә абзый, бары дөресен генә сөйлим, хәлфә абзый...

— Шулай кирәк тә, дөресен сөйләү гөнаһыңның яртысын киметү дигән сүз ул,— дип, зур бер яңа хәбәр кәткәндәй, күзләрен тагын Мәүлиханга текәде.

— Алла шаһит, бераүнең дә бер тиен акчасын да урлаганым юк.

— Алдыйсың!— диде Мәгъсум хәлфә, йөзенә тагын да зәһәрлерәк ачу чыгарып.

— Алдаша ул, хәлфә абзый, ышанма!— дип өстәде Габделкадыйр.

— Алла исемен телгә алырга оят кирәк.

— Күңелем саф булгач, оят түгел,— диде Мәүлихан, хәлфәгә җавап кайтарып.

— Алайса коръән үбеп ант ит!

Шәкертләр Мәгъсум хәлфәнең бу сүзен ишеткәч, гөрләшеп үк куйдылар. Коръән үптереп ант иттерү. Кешеләр өстенә иң зур гаеп ташланган чагында һәм иң соңгы чиктә генә кулланыла торган дәһшәтле чара шәкертләр йөрәгенә бер шом салды. Бигрәк тә бу сүзне ишеткәч, Мәүлиханның, Мәгъсум хәлфә күзенә карап, бераз тын торуы, югалып калуы, әлегә кадәр булган тамашаны эчләреннән бик авыр кичереп килгән безнең шикелле бала яшендәге шәкертләргә тагын да көчлерәк тәэсир итте. Ни булыр? Ант итәрме Мәүлихан шәкерт, әллә...

— Ант итәм!— диде ул көр тавыш белән, кискен бер карарга килеп.

— Ант итәсең?!. Ә ялганга ант итеп, антыңа ханис булсаң, мәңге җәһәннәмдә яначагыңны беләсеңме?

— Беләм!— диде Мәүлихан шундый ук кыюлык белән.

Ул арада Габделкадыйр чуар тыстәге калын бер китапны, «Каләм Шәриф» дип хөрмәт белән исемләнеп йөртелә торган коръәнне алып килеп, Мәгъсум хәлфә кулына тоттырып та өлгерде. Хәлфә йөзенә ачу чыгарып:

— Тәһарәтең дә юктыр әле синең, хәсис. Әбуҗәһел токымы,— дип сүгенә-сүгенә коръәннең битләрен ачып карады.

— Икенде намазын укырга дип алган тәһарәтем бар,— диде Мәүлихан шәкерт, кырт кисеп.

— Алайса мә, урламадым дип, өч кәррә ант ит тә коръәнне үп!

— Сәмган вә тәгатән![1] — дип, Мәүлихан шәкерт Мәгъсум хәлфә кулыннан коръәнне алып баш өстенә күтәрде дә:— Билләһи урламадым, валлаһи газыйм, урламадым! Таллаһи урламадым!— дип, коръәнне иренә китерде һәм хөрмәт белән үпкәннән соң, яшьләр белән тулы күзләрен Мәгъсум хәлфәгә юнәлтте.

Бу хәлне зур киеренкелек белән күзәтеп торган шәкертләрнең күбесе җиңел генә сулап куйдылар. Аларның йөзендә шатлык чаткысы чагылып киткәндәй булды. Мәгъсум хәлфәнең йөзенә дә ниндидер бер канәгатьләнү тойгысы чыкты. Тик бу хәл Габделкадыйрга һәм аның дусларына гына ошамады. Ул иренен чалышайта төшеп:

— Оятсыз, Мәккә мөшриге! Ялганга ант итәргә алладан куркыр идең ичмасам,— диде.

— Гаебем булмагач, курыкмыйм,— диде Мәүлихан, аның күзләренә туп-туры карап. Бу караш Кадыйрның йөрәгенә үткен пычак булып кадалды. Ул кинәт кабынып китте, һәм йодрыкларын йомарлап, Мәүлиханга кизәнде. Тик белмим, нинди могҗиза булгандыр, бу юлы Мәгъсум хәлфә Кадыйрга ирек бирмәде, аның кулын тотты. Мәүлиханга карап:

---

[1] Ишеттем һәм буйсынам (автор искәрмәсе).

— Бар, хәзер үк чыгып кит, өеңә кайт, кирәк тапсак, хөкемне иртәгә хәзрәт алдында дәвам иттерербез,— дип бүгенгә шуның белән хөкем тәмамланганын белдерде. Шәкертләрнең йөзе кинәт яктырып киткәндәй булды. Бу күнелсез күренешнең тагын да зуррак фаҗигага әверелмичә, шулай тәмамлануына сөенеп, гөрләшеп куйдылар. Тик Мәүлихан үзе генә сөенмәде. Ул тиз генә чыгып китмичә, яшь бөртекләре тамып төшеп, хәзер инде зәһәр ачу гына сакланып калган күзләрен Габделкадыйрга юнәлтте. Нидер әйтергә теләгән иде, Мәгъсум халфә ирек бирмәде.

— Бар, бар, кайт, әйтәсе сүзләреңне иртәгә әйтерсең,— дип, аны тизрәк чыгарып җибәрү ягын карады.

Мәүлихан идәндә аунап яткан бүреген алып, әкрен генә киде дә, чыбык төшкән аркасының сызлавын бераүгә дә сиздермәскә теләп, гәүдәсен төз тотып, кызу-кызу атлап чыгып китте.

Юк, акча урлаган кесә карагына охшамый иде Мәүлихан шәкерт. Габделкадыйр, мөгаен, аңа үчләшеп кенә нахак бәла тага. Баксаң, күрәсең, илле тиен акчасын югалтмагандыр да әле. «Урлады, үзебез күрдек»,— дип әйтүче «шаһитләрне» бишәр тиен акчага сатып алу чүтмыни аңа.

Шәкертләрнең күпчелеге шулай уйлады да. Бу үзенә күрә бер күргәзмә хөкем төсен алган гыйбрәтле тамаша, Мәүлиханга никадәр газаплы минутлар китерсә дә, аны хөкем итү түгел, ә Габделкадыйрның үзен хөкем итү булып чыкты. Күпчелекнең ачу һәм нәфрәте аның үзенә каршы юнәлде. Мәгъсум халфәгә карата да ачулары көчәя төште шәкертләрнең. Күптән түгел генә Мәгъсум халфә чыбыгының тәмен татыган Зыя абый белән миңа бу күптән шулай иде, билгеле.

Икенче көнне Мәүлихан шәкертнең хәле ничегрәк икәне белән кызыксынып, аның мәктәпкә килүен көттек. Барлык шәкертләр көтте. Ләкин ул килмәде. Өченче көнне дә, дүртенче көнне дә килмәде Мәүлихан. Кемнәрдер аны, ул каты авырып, түшәктә ята икән диделәр. Кемнәрдер, мәдрәсәне дә, авылны да ташлап, халфә һәм хәзрәтләргә ләгънәт укып, каядыр еракка, шахта дип йөртелә торган җирләргә эшкә киткән диделәр. Бу арада Габделкадыйрның илле тиен акчасы да табылды. Ул аның сандыгы төбендә яткан имеш. Юри шунда үзе яшереп куйган да, Мәүлиханнан үч алу, аны кыйнату өчен, акчамны ул урлады дигән ялган хәбәр тараткан имеш диделәр. Без моның дөресен аныклый алмадык.

Биш көн үткәч, гадәттәгечә ачык йөз белән, кулына үзенең киндер букчасын тотып, ишекне киң итеп каерып ачып, Мәүлихан шәкерт килеп керде.

— Әссәламегаләйкем!— дип кычкырып сәлам бирде. Күп кенә шәкерт «Вәгаләйкем әссәлам!» дип, сәламен алып, аңа каршы килде.

— Хәлләр ничек, Мәүли дус?— диде берсе, күптән күрмәгән якын дустын каршы алгандай.

— Әйбәт! Нәкъ ат мөгезе кебек,— дип җавап кайтарды шаяракөлә Мәүлихан. Шуңа ук ялгап:

Әссәбахе бәдәни,
Суктым ектым кәзәне!
Китте кәзә тәгәрәп,
Шул булды бөтен мәзәк,

дип такмаклап та куйды.

...Янбарыс мәдрәсәсендә укыган заманда булган бу тамашага инде нәкъ җитмеш җиде ел вакыт узды. Мәүлихан шәкертне дә, Мәгъсум халфә белән Габделкадыйрны һәм башка шәкертләрне, әлбәттә инде, Заһид хәзрәтне күрмәгәнемә дә шул гомер вакыт үтте. Аларның хәзер дөньяда барлыкларын да белмим. Габделкадыйр белән Мәүлихан исемнәрен дә бик төгәл итеп язмавым мөмкин. Ләкин күз алдымнан үткән

бу авыр һәм чын вакыйга, шәкертләрнең төсе, кыяфәтләре, җырлары, такмаклары хәтеремдә нык саклана. Кайчакта шушы тамаша күз алдыма килеп йөрәгем тетрәнеп куя...

Мәдрәсәдә, билгеле, гел шундый күңелсез минутлар гына булып тормады. Уен-көлке белән үткән кичәләр дә еш кына була иде. Кулны артка куеп, «кем сукты?» уйнау. Күз бәйләш, мендәр белән бәрешеп, сугышып уйнаулар бик күңелле һәм рәхәт була иде. Кайбер шәкертнең кубызы, бер-икесенең хәтта авыз гармуны да бар иде. Зуррак шәкертләр, хәлфә абзый кичләрен кунакка, я мәчеткә, намазга киткән араларда, җыйналышып җырлыйлар, бииләр, аларга без дә, бала-чага булып исәпләнгән шәкертләр дә, кушыла идек.

Әлеге Мәүлихан шәкерт белән булган күңелсез тамаша мине уйланырга, миңа дөньяны танырга ярдәм итте. Сәхнә өчен, драматургия өчен дә бераз файдасы булмады микән әле? Булгандыр, мөгаен.

Яз җитәр-җитмәс борын ук, апрель урталарында, этиебез килеп, безне авылга — Йосыфка алып кайтып китте. Озак вакытлар күрми торган искиткеч ямьле авылыбыз, әниебез, туганнарыбыз, бергә уйнап йөргән малайлар, кыр, урман, чәчәкләр, ягымлы кояш нурлары — барысы, барысы да сагындырган иде. Шуңа күрә шатлыгыбыз эчебезгә сыймады. Бигрәк тә әнә шундый караңгы һәм күңел әрнеткеч мәдрәсәдән котылу шатландырды безне.

* * *

Кыр эшләре бетеп тә өлгермәде, безне укытыр өчен яңа мәдрәсә эзләп, эти якын-тирә авылларның байтагына барып кайтты. Аксәеттә дә, Гундырда да булды. Чокыр авылына да, Күрдемгә дә сугылды. Тик үз күңеленә ошаган, заманга лаеклы белем бирә, тәрбия итә алырлык мәктәп-мәдрәсә таба алмады. Аңа мәктәпләрнең әле бер ягы, әле икенчесе ошамады. Шулай да эти беркөнне бик дулкынланып кайтып керде. Ул без яшәгән Йосыф авылыннан яхшы ук еракта, Гәйнә иле дип йөртелә торган якларда, Сараш авылында бер-ике ел гына элек ачылган Русско-татарская школа барлыгы турында ишетеп кайткан икән. Бигрәк тә бу школаның укытучылары Казанда Татар учительләр мәктәбен тәмамлаган яхшы укытучылар — агалы-энеле Шәриф һәм Сәгыйть Сүнчәләйләр булуы ошаган этигә. Билгеле инде, ул елларда татар телендә чыккан барлык газета-журналларны укып барган эти Сәгыйть Сүнчәләйнең Габдулла Тукай, Мәҗит Гафурилар шикелле үк шагыйрь булуын яхшы белә иде. Димәк, Шәриф белән Сәгыйть Сүнчәләйләр — милләтебезнең алдынгы кешеләре.

Бу мәктәп һәм аның әнә шундый акыллы һәм зур гыйлем иясе булган укытучылары турында сөйләгәч, Зыя абый белән без шатлыгыбыздан нишләргә дә белмәдек. Этинең фикере белән бик тиз килешә торган һәм киләчәктә безнең укыган кеше, бәхетле кеше булуыбызны теләгән әниебез дә шатланды моңа. Тик Сараш авылының бик еракта, алтмыш чакрымнардан да артыграк җирдә булуы борчыды аны. Шулай да үзенең сагынуларына караганда да безнең киләчәк бәхетебез турында күбрәк кайгырткан әниебез, бу борчылуларын безгә сиздермәскә тырышты. Тырышты, тик шулай да күзләренә килгән яшь бөртекләрен бездән яшереп кала алмады...

* * *

Сентябрь ае башында инде без, Зыя абый белән икебез, Сараш авылы мәктәбендә укый башладык.

Дөресен әйтергә кирәк: Янбарыс мәдрәсәсенең җан өшеткеч тәртипләре, уку-укыту ысуллары белән якыннан танышып, бер кыш укып кайтканнан соң, Сарашка да бераз куркыбрак бардык. Нинди булып чыгар

бу мәктәп? Бигрәк тә укытучы абыйлар? Сабакны белмәгән өчен бәлки алар да чыбык белән аркага сыздыра торганнардыр? Коръән, хәдис укытмасалар, анда урысча укыталар. Хәзерге көнгә кадәр бер сүз дә урысча белмәгән башың белән ничек урысча укыйсың да ничек аңлыйсың ди аны? Шундый сораулар куркытты безне.

Ләкин куркуыбыз юкка гына булган икән. Гариф исемле кеше өенең югары катындагы зур ике бүлмәгә парталар тезелгән. Монда мәктәп. Бүлмәнең зуррагында беренче, икенче классларда укучылар, ә кечерәк бүлмәдәге парталарда өченче класс укучылары — Зыя абый белән мин, гәрчә ике ел сабакка йөреп татарча укый-яза белсәк тә, хәтта гарәп телендә язылган коръәннең кайбер сүрәләрен, шулай ук намаз-нияз шартларын яхшы ук үзләштергән булсак та, урысчаны бөтенләй белмәгәнгә күрә, учитель абзыебыз Шәриф Сүнчәләй безне беренче класска урнаштырды. Без инде моңа да бик шат. Шулай булмый, урысча укыйбыз ич без. Кыш буе укып, яз көне авылга кайткач, бергә уйнап йөри торган дус-иш малайлар Миңнемөхәммәт, Гарифҗан, Хәтмуллаларның авызын урыс сүзләре белән генә томалаячакбыз. Аннан безнең белән бергә беренче класста укучы малайлардан, шулай ук кызлардан да (монда малайлар белән кызлар бергә укыйлар) яшебез белән һич аерылмыйбыз. Миңа сигез яшь тулып килә, абыйга — тугыз. Беренче класс укучыларының күпчелеге шул яшьтәгеләр. Унбер, унике, хәтта зурраклар да бар. Ләкин андыйлар күп түгел. Безне иң шатландырганы — монда дин сабакларының булмавы. Коръән сүрәләре, төрле догалар ятлап, намазлар укытып, бераү дә сине азапламый. Монда тик, эти әйткәнчә, заманга лаеклы, дөньяда кирәкле белем. Русча да, татарча да дөрес итеп укый, яза белү. Аннан арифметика, җәгърәфия, табигать белеме, тарих. Стеналарда җәгърәфия карталары эленгән. Төрле ерткыч хайван сурәтләре — аю, бүре, төлке, куян.... Тагын без гомеребездә күрмәгән генә түгел, ишетмәгән дә ерткычлар, төрле җәнлекләр. Парталар алдында кара такта. Һәр партада карасы түгелми торган кара савытлары. Кыскасы, безнең өчен яңа дөнья, өр-яңа тәртип. Үзенең караңгылыгы, һавасының сасылыгы белән беренче күрүдә үк җаныңны биздерә торган Янбарыс мәдрәсәсе белән чагыштырганда, бу инде үзенә күрә бер хан сарае. Ә укытучылары? Шәриф абый белән Сәгыйть абый? Аларны Заһид мулла һәм Мәгъсум хәлфәләр белән янәшә куеп чагыштырып карау да зур гөнаһ булыр иде кебек. Шәриф Сүнчәләй... Ул чагында әле 25 яшендәге мәһабәт сынлы, чем-кара һәм озын гына чәчле ир-егет. Ул чәчләрен яхшылап торып уң як читеннән аерып куя да үзенең мөлаем карашы белән сихерли сине. Тирән акыллы, сабыр холыклы, үзенең бөтен укучыларына яхшы белем һәм тәрбия бирергә, аларны чын кеше итәргә тырышкан бу хөрмәтле зат беренче танышуда ук ихтирамыбызны яулап алды. Ул чакларда һәр укымышлы кешегә мулла дип хөрмәтләп дәшү гадәте булганга, без дә аңа Шәриф мулла абзый дип дәшә идек. Бераз кызурак канлы, кырысрак табигатьле булса да, шул ук хөрмәтләү сүзләрен Сәгыйть абый Сүнчәләйгә дә әйтә идек.

Беренче класстан алып дүртенче классны тәмамлаганчы, ягъни 1911 елның сентябреннән 1915 елның май урталарына кадәр укыдык без бу мәктәптә. Русча укырга, язарга, шулай ук, әлбәттә, татарчага да өйрәндек. Хисап, җәгърәфия, беркадәр тарих фәне, табигать фәне белән таныштык. Халкыбызның атаклы әдипләре, шагыйрьләре Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал һәм башкалар турында ишеттек, аларның күп кенә әсәрләрен укыдык. Рус язучылары Толстой, Тургенев, Некрасов, Гоголь, Пушкин, Лермонтов, Кольцов, шулай ук Гейне кебек дөнья классикларының да кайбер әсәрләре белән таныштык.

Шушы дүрт ел эчендә Шәриф абый ник бер генә тапкыр тән җәзасы бирсен! Хәтта тавыш күтәреп, йөзенә ачу чыгарып тиргәми дә иде ул

безне. Зыя абый белән миңа карата гына түгел, үзенең барлык укучыларына да шундый яхшы мөнәсәбәттә иде ул. Безнең бик шаярып, хәтта әйберләр дә ватып, аның ачуын китергән чакларыбыз була иде. Кайбер укучылар дәресләрен дә белми, өйрәнмичә киләләр. Андый хәлләрдә ул укучыны ашсыз-әбәтсез калдыра, һәм дәрестән соң, барлык укучылар өйләренә кайтып киткәч, аны ике сәгатьләр чамасы вакыт класста утырта, өйрәнмәгән дәресләрен өйрәнергә мәҗбүр итә. Я булмаса бу ялкау, шаян укучы янында үзе дә кала һәм өйрәтә. Монысы да укучы өчен авыр җәза. Бөтен кеше кайтып киткәч, бер ялгызың класста утырып кара әле син. Бигрәк тә ач килеш. Шуңа күрә укучылар Шәриф абыйның бу җәзасыннан бик курка һәм һәрвакыт дәресләрен белеп килергә тырыша иде. Ә Сәгыйть абыйның талканы бераз корырак. Дәрес вакытында шаярсаң, я сабагыңны белми килсәң, колагыңны борып та алгалый, шып итеп маңгайга да чиртеп куя. Кулында линейка булса, кайчакта йомшак кына итеп маңгайга да кундырып ала! Кырысрак холыклы иде Сәгыйть абый. Ә шулай да укучылар аны бик ярataлар. Чөнки ул дәрестән соң, ә атна кич махсус билгеләнгән дәрес вакытында, бөтен укучы балаларны бергә җыеп, җырларга өйрәтә һәм шул вакытта бик матур итеп, моңлы итеп скрипкада уйный. Без — укучылар аңа кушылып җырлыйбыз. Яңадан-яңа көй, яңа җыр өйрәтә безгә Сәгыйть абый. Ә безгә инде бергәләп күмәкләшеп җырларга булса, шул җиткән. Дөньябызны онытып җырлыйбыз, җыр тавышыннан Гариф абыйның өй тәрәзәләре селкенеп тора.

Күбрәк вакытта Тукай шигырьләрен җырлыйбыз без. Һәр шигырьгә аерым көй. «И бәһале, и кадерле...» дип башланган җырны «Сәлим бабай» көенә җырлыйбыз. Ә «Туган тел» шигыренең үз көе бар. «Туган тел» аеруча дәртле булып яңгырый. Туган телне яттан белмәгән һәм аның көен үзләштермәгән бер генә укучы да юк иде. Безнең белемебез, яшәвебез, бәхетебез әнә шул матур тел, туган телебезгә бәйләнгән кебек тоела иде безгә.

Кайвакытларда Сәгыйть абый үз шигырьләренә язылган үз көен дә өйрәтә иде. Мәсәлән:

> Тау биекме, син менәмсең? Мен, менәлсәң, таука мен.
> Күр яланнар, күр япаннар, күр бу дөньяның ямен.

Без бу җырны да бик яратып җырлый идек.

Ә кайчакта Сәгыйть абый укучыларга скрипкада махсус «Тәфтиләү», «Зиләйлүк», «Карурман» шикелле озын-озын көйләр дә уйный һәм без, укучылар, аларны бөтен күңелебезне биреп тыңлыйбыз. Скрипкада уйнаганда, Сәгыйть абый бөтен дөньясын оныта. Сызгычы белән бергә аның бөтен гәүдәсе хәрәкәт итә. Бигрәк тә иреннәре хәрәкәттә. Сызгыч барышына карап кыегаялар, тагын төзәяләр. Башта балалар моннан бераз көләләр дә кебек иде. Ләкин Сәгыйть абыйның усал гына итеп бер карап куюы аларны көлүдән туктата иде. Менә шулай безне сихерли иде Сәгыйть абый.

Укучыларны үзенә тарта торган аның әле тагын бер сыйфаты бар. Ул, дәрес алып барганда, кычкырып, артистларча кыланып, бик әйбәт итеп шигырьләр укый иде. Күбрәк Тукай шигырьләрен укый. Ул укыганда, без бу шигырьләрнең мәгънәсен тагын да тирәнрәк аңлый идек, матурлыгын да ныграк тоя идек.

— Сәгыйть абый, Тукайның үзен күргәнең бармы синең? — дип сорау бирде аңа беркөнне укучы малайларның берсе.

— Бар, без аның белән бик якын танышлар гына түгел, хәтта дуслар да... Үзара хатлар да алышабыз, — дип җавап бирде Сәгыйть абый... Казанга барган саен (ә ул укулар беткәч, җәй башыннан ук Казанга китеп бара торган иде), Тукай белән очрашып, сөйләшеп йөрүен, үзе язган шигырьләрен Тукайга укып күрсәтә баруын сөйләгәч, укучы балаларның аңа карата булган хөрмәтләре тагын да артып китте.

Әнә бит безнең Сәгыйть абыебыз Тукай белән хатлар алышып тора. Үзе дә шигырьләр яза. Шагыйрь укытучыбыз әнә шундый кеше булу безнең өчен зур горурлык иде. Ә безнең Шәриф абый? Сабыр холыклы, дөньядагы бөтен гыйлемне дә яхшы белә торган Шәриф абыебыз? Ул Сәгыйть абыйга да абый. Дөрес, ул шигырь язмый, ләкин бөтен шигырь язучыларны укытырлык олы белеме бар аның. Ул да Тукай белән яхшы таныш. Казандагы башка шагыйрьләр, әдипләр, галимнәр белән дә таныш, скрипканы да шундый оста уйный. Дөрес, уйнаганда, аның гәүдәсе Сәгыйть абыйныкы кебек боргаланмый, иреннәре дә чалышаймый, ләкин шулай да бик моңлы яңгырый аның кулында скрипка. Ул да безгә шигырьләр укып күрсәтә. Артык кычкырып та җибәрми, кулларын да селтәп куймый. Сәгыйть абый укыгандагы кебек озын чәчләре дә тузгаланмый. Гадәти генә укыган кебек ул. Шулай да шигырьнең мәгънәсе безнең йөрәккә ярып керә. Дулкынландыра безне. Кайчакларда күзләребез яшь белән тула. Әйе, әйе, «Көзге җил»ләрне укыганда, нәкъ шулай булды.

> Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил жылый,
> Җил жыламый, ач үлемнең куркусыннан ил жылый.

Шәриф абый укып кына калмый, Тукайның нәрсә әйтергә теләгәнен, халкыбызга, кешеләргә карата мәхәббәтен бик гади генә, без — балалар аңларлык итеп сөйли.

Аеруча Тукайның балаларны яратуы турында сөйли. Үзенең сүзләрен раслар өчен, Тукайның балаларга атап махсус язган шигырьләрен дә укып күрсәтә. Ятлап килү өчен, шагыйрьнең басылып чыккан китапларын өйгә дә биреп җибәрә. Ул Тукайны гына түгел, башка шагыйрьләрнең шигырьләрен дә укый. Мәҗит Гафури, Дәрдмәнд, Укмасый... Икенче, өченче классларга күчкәч, ул безгә рус шагыйрьләре Пушкин, Некрасов шигырьләрен дә укый, алар турында да сөйли иде. Без барын төшенеп тә бетермибез. Ә шулай да күбесен аңлыйбыз. Тукайның:

> Әйт әле, күбәләк,
> Сөйләшик бергәләп:
> Бу кадәр күп очып
> Армыйсың син ничек?..

— дигән юлларын без һәркайчан, һәр җирдә кычкырып укып йөри идек.

Беренче классны тәмамлаган чакларда без инде русча да үзебезгә күрә ярыйсы сукалый идек.

Сараш авылында укыган икенче елның көзендә Зыя абый белән минем өчен аеруча зур бәхет ачылды. Әткәй — Шәриф абый, аның әнисе Һаҗәр әби белән килешеп, билгеле, яшәү өчен, безне Шәриф абыйларга күчерде. Ул вакытта Шәриф абыйлар Галәветдин исемле бер бай гына кешенең зур гына өендә икенче катта фатирда торалар иде. Кап урталай бүленгән өй. Сул ягында зур зал, аның бер почмагында кечкенә бүлмә. Шәриф абыйның йокы бүлмәсе. Залда ашау-эчү өчен дә, язу-сызу өчен дә хезмәт итә торган зур өстәл. Савыт-саба тутырылган пыяла ишекле матур буфет янында китап шкафы, бер почмакта киң диван, урындыклар. Сәгыйть абый — хатыны Фәридә апа, улы Фәрит белән күршедә, Мәшрәф-Мәшкә ләкабе белән аталып йөртелә торган кешеләрдә яши. Гаиләсе Казанга киткәч, Шәриф абый янында — залда яши башлады. Өйнең икенче яртысында — түр бүлмәдә зур кухня. Анда аш өстәле, зур сәке. Бу бүлмәдә Һаҗәр әби яши. Ә ишекне кергәч тә әз генә бүленеп куелган һәм зур гына ян сәкесе булган бүлмәдә Зыя абый белән мин яшим. Сәке яхшы ук киң, урын-җир дә каты түгел, йомшак. Кыскасы, иркен безнең яши торган урын. Ашау-эчүне барыбызга бергәттән Һаҗәр әби әзерли. Коедан су алып керү, утын ярып керү кебек эшләргә без булышабыз. Хәер, утын яру безгә бик эләкми дә. Атна кич

сабактан кайткач,— ул көнне гадәттәгедән бераз иртәрәк кайта идек,— өелеп куйган бик яхшы чыршы һәм каен утынын Шәриф абый үзе яра иде. Ә безгә, малайларга, ярган утынны ташырга гына кала. Утынны ташып, чоланга өеп кую күңелле генә иде ул безгә. Җитмәсә әле Галәветдин бабайның кече малае Габдрәхим дә булыша иде безгә. Сәгать, сәгать ярым вакыт арасында бер атнага җитәрлек итеп ярылган утынны чоланга ташып өеп тә куябыз. Шәриф абыйның да, Һаҗәр әбинең дә рәхмәтләрен ишеткәч,— уенга! Кайларга барып, нинди генә уен уйнап бетермибез. Кышларын тау шуабыз. Сараштa «шуабыз» дип түгел, шул авылдагыча, «елабыз» дип сөйләшә идек. Сүзләребез дә, сөйләшкәндә, әнә ич, менә ич дип чыелдап түгел, әнә кый, менә кый дип кыелдап тора иде. Күп чакта шуарга авыл уртасындагы тауга барып түгел, ә ишек алдыбызда, кардан өеп үзебез ясаган тауда шуабыз. Ул тауны без кар төшү белән ясый башлыйбыз. Ә кыш урталары тирәсендә коймадан да биегрәк хәлгә җиткерә идек. Күбрәк бу тау Сәгыйть абыйның беренче улы — безне үз туган абыйлары кебек якын күргән, холкы белән дә, күз карашлары белән дә сөйкемле малай Таһир өчен эшләнә иде.

Шәриф абыйларда торган чакта иң кызыклы һәм иң истәлекле минутлар һәм сәгатьләрнең берсе җомга алды киче, атна кич була иде. Шәриф, Сәгыйть абыйларның үзләреннән бигрәк бу кичне Зыя белән мин сагынып көтеп ала идек. Иртәгәге көнгә тыңлатырга дәрес әзерлисе булмаганы өчен түгел, ул кичне иң тәмле ашлар пешерелеп, алардан безгә дә өлеш чыккан өчен дә түгел, ул кичне Шәриф абыйларда, авылның, авылның гына түгел, якын-тирәнең иң хөрмәтле һәм укымышлы кешеләре кунакка килеп, күңел ачу мәҗлесләре үткәрелүе була иде.

Күп чакта бу мәҗлестә катнашучы Шәриф һәм Сәгыйть абый, Сәүбән белән Зиннур Әхмәдиевләр, Түбән мәхәллә мәктәбендә укытучы, тәрәккый пәрвәр Нурулла хәлфә, старшина улы Фатих Мәүләтов, Каҗмакты (хәзерге Барда авылы) волосте, Каенлык авылы мәктәбе укытучысы, элекке реальное училищеда укучылар кебегрәк киенгән озын чәчле, тәбәнәк буйлы, һәм бик җитез хәрәкәтле Мостафин... Өстәл тулы ризык, Һаҗәр әби пешергән төрле-төрле камыр ашлары. Юк, Зыя абый белән миңа аларның ашап-эчеп утырулары түгел, чәй килгәнче, иң күбрәге, чәйдән соңгы хәлләр кызык иде.

Кызып-кызып төрле темаларга алып барылган бәхәс. Дөнья хәлләре, әдәбият, театр, музыка турында сүзләр. Сәгыйть абыйның яңа шигырьләрен кунакларга кычкырып укып күрсәтүе. Аларның әлеге шигырьләре турындагы фикерләрен тыңлый. Я булмаса яңа алынган «Ак юл» журналында басылган нindидер бер шагыйрьнең шигырен кычкырып укый. Тукай шигырьләрен укый, Тукайның ничек яшәве турында сөйли.

Сәгыйть абый бик оста скрипкачы, мандолинада да оста уйный. Шәриф абый да скрипканы начар сыздырмый, ләкин ул күбрәк гармун тартырга ярата. Гармун телләре аның кулында сайрап кына тора. Фатих абый мандолина уйный белә. Менә сиңа трио. Скрипка, гармун, мандолина. Озын көй дә, кыска көйләр дә уйный алар. Ләкин иң хәтергә кереп, уелып калганы — «Мәхәббәтем» көе, «Мәхәббәтем» җыры. Татарның беренче романсы. Ул Сәгыйть абыйның шәхси тормышына, аның беренче мәхәббәтенә бәйләнгән җыр.

Йолдыз нуры,  
Оҗмаг хуры —  
Син, бибкәй!  
Таҗым, даным,  
Гомерем-җаным —  
Син, бибкәй!  
Мине ник үптең?  
Үптең дә үттең;  
Ник күп сөймәдең?  
Үптең дә киттең?..

Сәгыйть абый бу көйне мондый кичәләрдә генә түгел, ялгыз калган минутларында да дулкынланып уйный һәм авыз эченнән генә моңаеп, җырлап та куя торган иде.

Бу көйне уйнаганда, авыз эченнән сүзләрен көйләгәндә, Сәгыйть абыйның ниндидер бер моңсулыкка бирелүен, күңелендә авыр сагыш кичерүен сизәм.

Ләкин Сәгыйть абыйга, бу җырның, бу көйнең ничек тууы турында берәр нәрсә сөйләгез әле дип мөрәҗәгать итә алмадым. Андый уй хәтта башыма да килмәде. Шулай да, бу җыр белән безнең бик нык мавыгуыбызны күреп, үзе дә бу көй башкарылганда артык нык дулкынлана һәм нык кичереш үткәрә торган Һаҗәр әби:

— Бу шигырьне Сәгыйть Таһирның әнисе Сәлимә үлгәч язды. Көен дә үзе чыгарды,— диде. Шуңа күрә мин озак еллар буе «Мәхәббәтем»не Сәгыйть абый үзе чыгарган көй дип йөрдем. Тик бары егерменче еллар уртасында гына аның җырчы һәм артист Фәттах Латыйпов тарафыннан язылган булу ихтималын ишеттем. Ишеттем, ләкин ышанып бетмәдем. Чөнки Сәгыйть абый Сүнчәләй үзе дә көйләр чыгаручы композитор иде.

Кичәнең без түземсезлек белән көтеп алган иң кызыклы өлеше Нурулла хәлфәнең сандугач булып сайравы була торган иде. Я ходай! Бу кадәр могҗиза булса да булыр икән кешедә. Сайрар алдыннан ул түшәмгә асылып куелган утызлы зур лампаны бераз батыра. Бүлмә бераз караңгыланып кичке эңгер-меңгер вакытын, я иртән таң сызылып килә торган чакны хәтерләтә. Бүлмәдәгеләр хәзер инде ниндидер бер тылсымлы моң көйләнә башлавын сизенеп, бары да тын кала. Шуннан соң Нурулла хәлфә ике кулын ике яңагына, дөресрәге, авызы янынарак куя да әкрен генә сызгырып сайрый башлый. И-и, дөнья! Булса да булыр икән. Гәүдәгә дә тупас, юантык, битләре дә итләч, ирennәре дә бераз калын булып турсаебрак торган кеше бит югыйсә Нурулла абзый. Ә сайрый башладымы, нәкъ сандугач. Нәфис моңы белән йөрәгеңне өзә. Үземне белә-белгәннән бирле урман, әрәмәлек кочагында яшәп, сандугач сайрауларын күп тыңлаганга күрә, аның моңы белән яхшы таныш мин. Үзе бик сак һәм бик үк сылу да булмаган кыяфәтен кешеләргә бик күрсәтәсе килмәгән нәни генә кош ул сандугач. Нәни һәм шундый нәфис тавыш. Ә Нурулла абзыйда бит нинди гәүдә! Сөйләгәндә дә тавышы гөбедән чыккан сыман гөрелдәбрәк чыга, ә сайрый башлагач, әнә нинди бит ул. Юк, сандугач үзе дә мондый оста итеп сайрый алмый. Кая аңа Нурулла абзыйга җитәргә! Нурулла абзый сандугач булып сайрап кына калмый, скрипка я гармунда уйнала торган теләсә нинди көйне дә сандугач булып көйли. Сандугач тавышы белән сайралган көйләр тагын да тәэсирлерәк булып ишетелә иде безгә. Нурулла абзыйны күпләр «Сандугач Нурулла» дип йөртәләр иде.

Үзенә күрә бер әдәби һәм музыкаль кичә сымак булып үткәрелгән бу мәҗлесләр хәтеремдә нык сакланып калдылар. Һәм, әлбәттә инде, шигырь белән музыкага карата тирән мәхәббәт тудырдылар.

Шәриф абыйларда яшәгән заманда Зыя абый белән минем күңелемә хуш килгән тагын бер нәрсә бар иде. Күп кенә газета-журналлар белән бергә, Шәриф абый балалар өчен махсус чыгарыла торган «Ак юл»ны ала иде. Җиңел тел белән төрле хикәяләр, шигырьләр басылган бу журналны без дүрт күз белән көтеп ала идек. Һәм аны шунда ук, хәтта дәрес әзерләүгә зарар китереп булса да, бик тиз укып чыга идек.

Шул елларда Сәгыйть абый Сүнчәләй Генрих Гейненең «Әлмансур» исемле пьесасын тәрҗемә итте. Һәм ул китап булып басылып та чыкты. Китапны шулкадәр яратып, бирелеп, кат-кат укыдым мин, хәтта аның яртысыннан күбрәген ятладым да. Әле дә беренче битләре исемдә. Яшьлек елларымны искә алганда, я Генрих Гейне исеме ниндидер уңай белән телгә алынса, «Әлмансур»ның беренче юллары исемә төшә.

Атна кичләр әнә шулай матур уза. Ә җомга? Бу көнне укымыйбыз,

ял көне, бәйрәм. Ул көн үзенә башка ямьле. Урамда уйныйбыз, тау шуабыз. Чанабыз булмаса, агачтан үзебез ясаган таштабаныбыз (тимер-аяк) бар. Дөрес, аның үзебез генә ишеп ясаган бавы өзелеп тә азаплый. Таудан шуганда, егылып, борынны канаткан чаклар да аз булмый. Салкынрак көннәрдә куллар да өши, бит очлары да, колаклар да туңа. Ә шулай да без сер бирмибез, туңдык дип, өйгә елап кайтып китмибез. Уеныбыз — уен, шууыбыз — шуу. Шуның өчен малайлар ла без. Ике чабата бер кием, ике дөнья бер тиен безгә. Кайткач, безне һаҗәр әби яхшы ук кыздырып та ала. Шәриф абыегызга әйтеп, колагыгызны бордырам дип куркыта. Тик аңа артык исебез китми. Шәриф абыйның колакны бормаганын беләбез лә без. Аптырагач, әтиегез килгәч, аңа әйтәм, дип карый. Ләкин беләбез, һаҗәр әби бик яхшы күңелле карчык, әтигә әләкләми ул. Куркыта гына. Әти килгәч, гел мактап кына тора безне. Малайларың бик уңганнар, йомышымны бик тыңлыйлар, дәресләрен дә тырышып укыйлар, фәлән дә фәсмәтән...

Шулай да җомга көннәрне үткәргән минутларның иң кызыклысы, иң истә калганы — Мулланурларда уйнап үткәргән минутлар.

Мулланур — безнең белән укый торган малай. Укучылар арасында үзенең бик сөйкемле чырае, иптәшләренә булган ягымлы мөнәсәбәте белән аерылып тора. Дәресләрен дә ул безнең барыбызга караганда да яхшырак белә кебек. Өйгә бирелгән дәресләрне дә бик яхшы итеп әзерләп килә. Дөрес, дәрес әзерләүгә килгәндә, абый белән мин дә начар түгел. Хәзерләмәс идек, һаҗәр әби дә, Шәриф абый үзе дә гел күзәтеп кенә тора. Ә Мулланур үзе әзерли... Хәер, аны да күзәтеп торучылар бар икән — аның бертуган абыйлары, безгә кадәр үк инде школаны тәмамлаган егетләр Сәүбән белән Зиннур... Апалары Шәмсенур белән Маһруй да дүртенче класста укыйлар. 13—15 яшьтәге кызлар... Ярым шәһәрчә киенеп йөрүче матур кызлар... Мулланурның үзенең киеме дә ярым шәһәрчә. Чөнки әтисе Гайсә бабай, дөньяның уңын, сулын аңлый торган, яңалыкны хуплап каршы ала торган крестьян һәм шуның белән бергә сәүдә дә итә. Бик үк зур булмаса да ике катлы өйләре бар, безнең өчен барыннан да яхшырагы, бик җыйнак итеп, кечкенә өйгә охшатып салынган мунчалары бар. Ишегаллары да уйнар өчен бик иркен һәм чиста. Без күп вакыт аларның әнә шул мунчаларында уйнарга яратабыз. Сукыр тәкәле дә уйныйбыз, йөгерешеп, сикерешеп тә уйныйбыз... Кайчакта, тыныч кына утырып, лото уйныйбыз. Карта уйный беләбез. Бер-беребезне дуракка калдыру кызык безгә.

Кайчакта биеп тә, җырлап та җибәрәбез. Хәтта үзебезчә театр уеннары да уйныйбыз. Кунакка килгән бабай, әби булып кыланабыз. Егет белән кызлар булып та уйныйбыз.

Ничектер бервакыт безнең кулга «Каенана өйдә булса, әшнең асты өскә килә» дигән пьеса килеп төште. Без аны бер сыйныфта укучы иптәшем Мулланурлар мунчасында кычкырып укып чыктык. Чиратлашып укыдык. Ә кайбер урыннарын артист булып кыланып уйнап та карадык.

Гомердә бер тапкыр да театр уйнаганны күргән булмыйча, бары тик Шәриф абый, Сәгыйть абыйларның сөйләвеннән генә ишетеп белгәнгә күрә генә, уеныбызның рәте-чираты булмады.

Шулай да бу үзенә күрә бер театр уены иде.

Мулланурның кызыклы бер ягы шунда: ул, каян өйрәнептер, төрле такмаклар, әйтемнәрне күп белә. Менә минем аңардан язып алган һәм ятлап хәтеремдә калган бер әйтем, такмак:

Чыптыр-чыптыр, вәлхәмдеки, тәңкирү, тәңкирү, тәңки сүли, тәңки сүли тәбләвәй, тәбләвәй. Анда көн дә юша, көн дә Тур-Тур, әзнәби, туди-суди, чәбчи-бичи, кәйдер, кәйдер француз.

Бала чакта ятлаган бик күп шигырьләр, җырлар, такмаклар оныттылды. Ләкин мәгънәсе белән берни дә сөйләми, ләкин әчке яңгырашы белән кош сайравын, сандугач җырын хәтерләтә торган менә бу такмак хәтеремдә мәңгегә сакланып калды. Сараш авылыннан, аның малайла-

рыннан откан бик күп истәлекләр арасында ни өчендер бу такмак иң кызыклы һәм кадерлеләрдән булып саклана. Бәлки ул минем яшьлек дусларым арасында үзенең мөлаем йөзе, сабыр акылы, гомумән кешелек сыйфатлары белән тирән эз калдырган Мулланур дустымнан отып алган кадерле бүләк булгангадыр.

Шушы такмакны укысам, келт итеп күңелемә Мулланур һәм Сараш авылының дус малайлары исемә төшә.

Сараш авылы. Бик зур һәм ямьле авыл ул. Бер ягында калын карурман. Чыршы, нарат урманы, аркылысы гына да аның җиде-сигез чакрым, ә буйга чуты-чамасы да юк. Йөзәр чакрымга сузыла. Ә икенче ягында — түбәләрен чыршы һәм каен агачлары каплаган бик биек тау. Аның итәгендә зур гына Тол елгасы. Тауның күп кенә урыннарында агач юк. Ялангач ул. Ташлы кызыл балчык. Читтән ул киң юл шикелле күренеп тора. Ләкин ул юл түгел. Анда арбалы ат түгел, ялгыз атлар да менә алмый. Текә, бик текә ул. Чөнки кайчакларда без малайлар барып, үрмәли-үрмәли булса да, аның башына менәргә тырышып карыйбыз. Ләкин урта бер җиренә җиткәч, борылып карыйбыз да котыбыз очып, тукталып калабыз. Аннан, тәгәри-тәгәри, кире төшеп китәбез.

Гөнаһны яшерми генә әйткәндә, минем беренче тапкыр шигырь язып каравым да шул тауга һәм Сәгыйть абыйның бер шигыренә бәйләнгән. Бик тырышып язып икенче көнне үк ертылып ташланган сигез юллык «әсәр»нең баштагы юллары менә болайрак сыман иде:

Биек тауларга менәм мин,<br>
Киң яланнар күрәм мин,<br>
Дөньяларның ямен күргәч,<br>
Кире әйләнеп төшәм мин.

Яздым да, шигыремне Сәгыйть абыйга кадәр Һаҗәр әбигә укып карарга булдым. Ул тыңлап-тыңлап торды да:

— Юк, әйбәт түгел шигырең. Бу — авыл җыры гына. Шигырь түгел. Аннан син моны Сәгыйть абыеңны үртәп язгансың кебек. Күрсәтеп торма аңа, ертып ташла,— диде.

Ә мин җыр белән шигырь арасындагы аерманы белми идем әле ул чакта. Хәер, бик күп еллар буе аларның аермасын белә алмый йөрдем. Миңа калса, һәрбер яхшы җыр, мәгънәсе ягыннан тирән, яңгырашы белән музыкаль булган җыр — шигырь һәм һәрбер яхшы шигырь җыр булып күренә иде. Әнә Сәгыйть абыйның «Мәхәббәтем» шигыре — шигырьме ул? Әллә җырмы? Минемчә, шигырь дә, шул ук вакытта җыр да. Ай, бу фикер, бу мисал шул чакта башыма килгән булса, һичшиксез, аптырашта калдырган булыр идем мин Һаҗәр әбине. Нишлисең бит, башыма килмәгән. Һаҗәр әбинең сүзенә ышандым да шул беренче язган шигыремне Сәгыйть абыйга да, Шәриф абыйга да, әлбәттә, күрсәтеп тормыйча ертып ташладым. Ул чакта шигырь язарга омтылу шуның белән тәмамланды.

Сараш авылында булган истәлекләремдә янә бер көн турында язмый китә алмыйм. 1913 елның апрель ае иде бу. Карлар эреп, елгаларда су ташыган чак. Каеннар, яңа гына яфрак ярып, яшеллеккә төренеп килә. Җирнең, табигатьнең уянган чагы, сыерчыклар һәм сабан тургайларының безнең якларга кайтып моңая, сайраша башлаган чагы.

Тиздән безгә, мәктәптә укучы балаларга да зур шатлык киләчәк. Укуларыбызны тәмамлап, җәйге каникулга, ялга таралачакбыз. Шундый кадерле минутларны көтәбез. Апрель артыннан тагын да җылырак, чәчәклерәк, хуш ислерәк җылы май ае, аннан июнь киләчәк, әнә шундый олы шатлыклар көтә безне алда.

Һәм кинәт безнең йөрәкләрне генә түгел, җирне, ай, кояш, йолдызларны да тетрәтерлек (һәрхәлдә, ул чагында безгә бу шулай тоелды) шомлы хәбәр килә. Белмим, кем китергәндер бу хәбәрне, телефонмы, телеграфмы, газеталармы? Ләкин ул шулкадәр тиз таралды, әйтерсең

бөтен дөньяны яктыртучы нурлы кояш сүнде! Көләч йөзләребезне генә түгел, бөтен табигатьне караңгылык басты. Вакыйгаларның нинди тәртип белән агышы анык хәтеремдә түгел, ләкин йөрәгебезне тетрәткәне шул булды: Шәриф абый барлык укучы балаларны бер бүлмәгә җыйды да күзләре тулы мөлдерәгән яшьләре аша әйтте:

— Балалар! Олы кайгы килде. Сез бик яратып шигырьләрен укый торган, җырлый торган, балаларны да, халкыбызны да чын күңелдән яратучы бөек шагыйребез Габдулла Тукаев вафат булды. Бу олы талант иясен безнең халкыбыз беркайчан да онытмас. Үзе үлсә дә, аның шигырьләре беркайчан да үлмәс, халкыбыз күңелендә мәңге яшәр,— диде.

Яшьле күзләрен сөртә-сөртә хөрмәтле укытучыбыз сөйләгән бу сүзләр, безнең йөрәкләргә кереп, мәңге онытылмас авыр истәлек булып калды. Шәриф абый үзе генә түгел, бу хәбәрне ишеткәч, без балалар да күз яшьләребез белән елый идек инде. Хәтерем алдамаса, без ул көнне укымадык та шикелле. Башларыбызны иеп, йөрәкләребезгә авыр хәсрәт төяп, өйләребезгә таралдык. Кайтып керсәк, өйдә тагын шом. Һаҗәр әбиебезнең күзләрендә яшь һәм куркыну.

— Балалар, барыгыз әле, тиз генә зират артына, су буена йөгерегез. Сәгыйть абыегызның хәле ничек икән?— диде.— Көнозын үкереп, өйдә җылап утырды да елга буена төшеп китте. Алай-болай онытылып суга төшә күрмәсен. Аның холкын беләсез бит...

Кая инде белмәгән! Шигырь язган чакларында да, «Әлмансур»ны я башка шагыйрьләр шигырен кычкырып укып йөргән чакларында да дөньясын оныта торган гадәте бар аның. Дәрт, моң, хис кешесе Сәгыйть абый. Һаҗәр әби авызыннан: «Балалар, аш ашарга да чакырыгыз үзен»,— дигән сүзне ишетү белән, гадәттәгечә ерактан әйләнеп түгел, каршыбыздагы иске зират аша, койма аркылы гына чыгып, су буена йөгердек. Елга, үткән елдагыча, котырынып ага бирә. Ары карыйбыз, бире карыйбыз, су буенда күренми Сәгыйть абыебыз. Әйдә өскәрәк, арырак барыйк әле, бәлки су буйлап еракка киткәндер ул дибез! Бара торгач, ишетәбез — кемдер ыңгыраша, елый кебек. Карасак, Сәгыйть абыебыз зират коймасы буендагы әле күптән түгел генә яшелләнеп чыккан чирәмгә яткан да шул чирәмле җирне тырмый-тырмый елый.

— Тукай җаным, бәхилләмине!— дип кычкырып та куя.

Без Сәгыйть абый янына якын килергә кыймыйча басып торабыз. Бик кызганабыз аны. Чөнки без Тукайның аңа якын дус та һәм шигырь язарга ярдәм иткән кеше дә икәнен, аның Тукайдан хатлар да алгалап торганын яхшы беләбез. Озак басып тордык Сәгыйть абыйга дәшәргә дә кыюлыгыбыз җитмичә. Ниһаять, үзе безгә таба әйләнеп карагач...

— Сәгыйть абый, аш ашарга кайт. Һаҗәр әби чакырды...

Ул, минем әйтеп бетергәнне дә көтмәде, кулын да, башын да берьюлы селкеп:

— Барыгыз, кайтыгыз, кайт!— диде коры гына.

Без читкәрәк китеп, кайтып китәргәме, юкмы дигән бер карарга килә алмыйча, койма буенда тагын байтак кына вакыт басып тордык. Безгә бит Сәгыйть абыйны ашарга алып кайтудан бигрәк, саклап, күзәтеп торырга кушты Һаҗәр әби. Әле бәлки тагын бик озак вакыт шулай басып та торган булыр идек, ләкин Сәгыйть абыйның яткан җиреннән кинәт кенә торып утыруы, башы, кулы белән генә ымлап, хәзер үк китәргә кушуы безне кузгалырга мәҗбүр итте.

Кире өйгә кайтып, Һаҗәр әбигә үзебезнең күргәннәребез турында сөйләгәч, ул тагын шуны әйтте:

— Казанга үткән баруында Сәгыйть абыегыз Тукай белән үпкәләшеп кайткан. Соңгы күрешүләре булган икән шул бу. Тукай белән яхшылап татулашып та, бәхилләшеп тә кала алмаганына шулай үкенә, өзгәләнә ул,— диде.

Инде бу хәлләрдән соң ярты гасырдан артык вакыт үтте. Ләкин Шәриф абыйның Тукай үлеме турындагы хәбәре, аның күзенә тулган

мөлдерәмә яшь, Сәгыйть абыйның, су буена төшеп, җирне тырный-тырный үкереп елавы, үзебез дә кичергән авыр минутлар бүгенгедәй хәтеремдә саклана.

Сараш мәктәбе, Шәриф һәм Сәгыйть Сүнчәләйләр белән якыннан аралашу, без балаларның гына түгел, әтиебезнең тормышына да зур йогынты ясады. Кыш көннәрендә азык-төлек китергән арада, әти Сараш-та, безнең янда ике-өч көн торып китә һәм Шәриф абыйларда үткәрелә торган атна кич мәҗлесләрендә катнаша иде. Дөрес, ул җырлый да белми, нинди дә булса музыка коралында да уйнамый, ләкин инде музыка тыңларга дисәң, аңа куш. Шулкадәр бирелеп, яратып тыңлый иде ул музыканы. Аеруча скрипка моңын ярата иде. Шуңа күрә Шәриф абыйларның ике-өч скрипкасының берсен сатып алды да безгә, аеруча миңа, скрипка өйрәнергә кушты. Һәм мин аз булса да Шәриф абыйдан скрипка уйнарга өйрәндем. Бу мәҗлестә сөйләшеп утырырга, дөнья хәлләренең барышы турында әңгәмә корырга, фикер алышырга дисәң, монысына инде безнең әти оста. Ул барыннан да хәбәрдар. Чөнки ул татарча басыла торган газета-журналларны җентекләп укып бара. Укый бару гына түгел, ул — һәр нәрсәдә яңалык тарафдары. Ул чын мәгънәсендә мәгърифәтче, тәрәккый пәрвәр кеше. Шуның өчен дә ул татарның яңа тип зыялылары, укымышлылары, хәзергечә әйтсәк, интеллигенциясенә чит кеше түгел. Ә әти өчен Шәриф Сүнчәләй — укытучы буларак — идеал. Ул үзенең мәктәбендә дә уку-укыту эшләрен балаларны тәрбия итүче әнә шундый тәртипкә куярга тырыша. Ул безне дә киләчәктә әнә шундый укытучылар итеп күрәсе килә. Милләткә, халыкка хезмәт, халыкның тормышын, көнкүрешен җиңеләйтү, кешеләрне югары әхлаклы, кешелекле кеше итү, иң башлап аларның белемле, культуралы булуларына бәйләнгәнен әти яхшы аңлый иде.

* * *

Җәй. Уразай авылы. 1916 ел.

Юк, үткән елгы ямьнәр әз быел авылда. Җир бүлү шау-шуы да күңелсез тәмамланды. Яңалар җиңмәде, җир бүленмәде. Искечә калды. Аеруча күңелсезе — әледән-әле фронттан килеп торган шомлы хәбәрләр. Дәһшәтле сугыш һаман дәвам итә. Герман гаскәрләре дә, безнекеләр дә көннән-көн кырылалар. Кем өчен? Ни өчен? Уразай кешеләренең дә һәлак булганнары, яраланганнары байтак хәзер.

Җитмәсә ашлык уңышы да начар. Үткән елгыларга карый Агыйдел суының ташуы аз булганга болыннар су астында калмаган һәм тиешле дымны җыя алмаган, шунлыктан печән дә уңмаган. Гадәттәге дүрт-биш кибән урынына бары тик бәләкәйрәк ике кибән сөмрәеп утыра. Чәчүдән соң нибары бер арба игенебез калды. Алты-җиде пот арыш. Ә сабан ашлыгы — нигездә, солы. Кыскасы, барын бергә җыйсаң, егерме-егерме биш пот. Шуның белән алты җан кеше туенып та торырга кирәк, малларны да ашатырга кирәк.

Зыя абый белән сизеп торабыз, быел укуларны дәвам иттерү бик авыр булачак. Никадәр өстәмә чыгым бит ул. Укыган өчен дә түләргә, фатир өчен дә, китап-дәфтәр, дәреслекләр, ашау-эчү, кием-салым, тегесе-монысы... Ким куйганда икебезгә ай саен унбиш-егермешәр сум кирәк. Ә каян килсен гади игенчегә ул акча? Бар байлык — икмәк. Мал-туар, ит, бакча җимеше. Алардан күпме акча? Юк! Уку өчен чыгым тоту турында уйларга да юк. Кызылъяр (Петропавел) шәһәрендә китап кибетендә сатучы булып эшли торган әтинең бертуган энесе Сиражетдин абзыйдан хат килде. Әгәр Риза белән Зыя монда килсәләр, аларга нинди дә булса берәр хезмәт табып булыр, диган. Кибеттә сатучы малай я берәр байда йомышчы булып эшләсәләр дә мөмкин. Казах балаларын укытулары да мөмкин. Алар бит инде үскән, укыган, гыйлем иясе егетләр хәзер, диган.

Сиражетдин абыйның хаты этине дә, мине дә канатландырып җибәрде. «Үскән егет, гыйлем иясе», димәк, инде без хезмәт итеп, мөстәкыйль рәвештә үз-үзебезне карап яши ала торган малайлар, малайлар түгел, егетләр! Хатны укыгач та мин икеләнеп тормадым:

— Китәм, Сиражетдин абый янына китәм,— дидем.

Бәлки, бу тормышымда ясаган ялгышларымның берсе һәм иң зурысы, ә бәлки киресенчәдер — бөтенләй диярлек мөстәкыйль юлга басып, үз кыйбламны үзем сайлау, үз көнемне үзем күрә башлау дөрес эш булгандыр. Иң беренчесе шул: туган көннәремнән үк бергә-бергә уйнап, бер-беребезне яратып, сөеп, кочаклашып йоклап үскән, ара-тирә кычкырышып, тукмаклашып та алган Зыя абый белән аерылуга сәбәп булды. Зыя үз юлы белән китте, мин үз юлым белән. Ул Минзәләгә — укуын дәвам иттерергә, мин Кызылъярга, үз бәхетемне эзләргә. Минем бу тәвәккәллеккә башта әни риза булмаса да, әтинең:

— Барсын, хәзер инде балалар икесе дә үскәннәр, әз-мәз укыганнар. Татарчасын да белә, русчасын да ярыйсы сукалыйлар. Ризаң яшькә яшьрәк булса да, абыена карый буйга зур, көче дә ярыйсы. Исән-сау барып җитсә, Кызылъярда Сиражетдин абзыйсы бар. Ашау-эчү яклары, аллага шөкер, мул дип яза.

Юк, әни дә алай ныклап каршы килеп тормады, күнде. Ни әйтсәң дә ул бит безне,— уллары Зыя белән Ризаны алты ел инде көзен читкә, икенче авылга озатырга, язын каршы алырга өйрәнгән ана. Йөрәктән әрнеп, елап озата, ә яз җиткәч, куанып, шатлыклы күз яшьләрен сөртеп, елмая-көлә каршы ала. Башта Янбарыс. Ул чакта әле миңа нибары җиде, Зыя абыйга сигез генә яшь иде. Алтмыш чакрым ераклыктагы авыл. Укыган җиребез, яшәгән җиребез дә әшәке, караңгы мәдрәсә. Түздек ничек тә. Әни күчтәнәчләр җибәреп, яхшы теләкләр теләп яшәде. Аннан дүрт ел Сараш, бер ел Минзәлә. Хәзер инде кая, без — үскән, акылыбызга ис кергән малайлар. Миңа ике-өч айдан унөч тула.

Шулай да, мине Кызылъярга озату өчен, нык кына әзерлек барды. Өс-башның юыласы юылды, ямаласы ямалды. Азык-төлек тә юлга җитәрлек әзерләнде. Уен түгел, мең ярым-ике мең чакрымлык юл. Кимендә дүрт-биш тәүлек барырга кирәк. Пароходта биш йөз чакрымнар Уфага кадәр, аннан Кызылъярга кадәр поездда. Чиләбедә бер поездан төшеп, икенчесенә утырырга. Сиражетдин абзый шулай дип язды. Китәр көн килеп җитте. Өйдәгеләр белән картый, энекәшләр Һади белән Нәҗиб, сеңелем Рәкыя белән саубуллаштым. Зыя абый белән саубуллашканда, озак кына бер-беребезгә карашып тордык. Уйланыштык. Һаман бергә идек. Ә хәзер юлларыбыз аерыла. Озакка булырмы бу? Кайсыбызның юлы бәхетлерәк булып чыгар? Дуслар, тату туганнар идек, шуңа күрә бары тик яхшылык теләдек бер-беребезгә.

Әти белән әни мине Әҗәкүлгә, пароходка кадәр озата килделәр. Пароход кычкыртып китеп баргач, әни дә, әти дә, кулларын болгый-болгый, берникадәр җир пароход артыннан йөгереп бардылар.

Ай бу хәтер дигәнең. Могҗиза! Җиде дистә ел вакыт үткән моңа. Ә шулай да әти белән әнинең пароход артыннан йөгерә-йөгерә барулары һаман күз алдымда. Хәтта әнинең башына бөркәнгән яшелле-зәңгәрле кәшимер яулыгы да хәтердә уелып калган.

Дүртенче класс булса да, пароход артына чыгып, Агыйделнең йомшак, саф, чиста суына карап, сокланып бару күңелле булды. Бигрәк тә Идел буенда үскән агачлар — каен, юкә, шомырт, бөдрә таллар күңелгә бер моңсулык бирде. Уйландырды. Ике көннән соң инде мин Уфада идем. Уфа — зур шәһәр, атаклы шәһәр. Губерна мәркәзе. Җирсу мәсьәләләре шушында хәл кылына. Монда зур-зур йортлар, атаклы «Галия» мәдрәсәсе, «Госмания» дә шушында. Барын да бер күрәсе иде дә бит, кая ул турыда уйлау, ничек тә исән-аман Кызылъярга барып җиту кайгысы миндә. Кечкенә сандыгымны күтәреп, пристаньнан вокзалга килдем. Җәяүләп, билгеле. Акча күбрәк булса, извозчик та

яллап буласы икән, алар үзләре үк кычкырып, чакырып торалар, ләкин минем кесә ягы сай булгач, вокзалның кайда икәнен сораштым да җәяүләп кенә сыпырдым. Кием-салым, ризык тутырган сандык, башта бик бәләкәй, җиңел кебек иде дә, бара торгач авырайды. Сабы кулны кисте, җилкәгә күтәргәч, почмаклары тәнне авырттырды. Шулай да килеп җиттем вокзалга. Сорашып-белешеп, Кызылъярга билет алдым. Ике-өч сәгатьтән товар-пассажир поезды китәчәк. Әкрен йөри, еш-еш туктап, товар бушата торган поезд. Озак та үтмәде, безнең поездның китүе турында хәбәр булды. Урыны, вагоны күрсәтелмәгән иде билетта. Кайсы вагонга утырсаң, шунысы ярый диделәр. Карап бара торгач, бер кызыл ачык вагон очрады. Ишекләре киң итеп ачылган, үзе буп-буш. Юк, буш ук түгел икән, идәненә утырган ике-өч кешесе бар.

Вагонга караганда юлдаш абыйлар әйбәт булып чыкты. Минем кем икәнемне һәм кая барганымны да сорашкач, үзләре белән чәй эчерделәр. Алай гынамы, бер разъездда тукталып торган арада, поездан төшеп, зур-зур кочак печән алып килделәр. Миңа да байтак кына өлеш чыгардылар. Коры, хуш исле печән галәмәт шәп булып куйды. Йомшак мендәрдән дә болайрак. Рәхмәт кенә төшсен, менә бит дөньяда нинди кешеләр бар. Илтифатлы, мәрхәмәтле.

Чиләбедән соң, Кызылъярга кадәр пассажир поезды туры килде. Гади вагон. Кешеләр күп булса да, өченче сәндерәдә ятып барыр җир табылды. Бәләкәй сандыкны баш очыма куйдым да, пәлтәгә охшатыбрак тегелгән сырмамны баш астыма салып, йоклап алдым. Кесәмдәге барлы-юклы акчамны урламасыннар дип куркып, йоклар-йокламас бардым. Ни әйтсәң дә ике сум илле тиен көмеш бит ул. Кызылъярда әтинең энесе Сиражетдин абзый булса да, һәрхәлдә эти дә, әни дә түгел инде ул. Үзе дә хезмәт итеп алган акчага гына яши. Ничек яшидер бит әле, тукмы, әллә ачлы-туклы гынамы.

Тәүлек ярым үттеме, юкмы, мин Сиражетдин абзый янында идем инде. Озын, чандыр гәүдәле, озынча битле ачрак яңаклы, яше инде утыз алты-утыз җиделәр чамасы булса да, әле сакал-мыек чыкмаган ир мине бик шатланып, ачык йөз күрсәтеп каршы алды.

— Әйдә, Риза энем, хуш килдең!..— дип, чын күңеленнән куанды.

Әти безнең — тәбәнәк буйлы, житез, кызу табигатьле, бераз кырысрак кеше. Ә энесе Сиражетдин абзый, киресенчә, юаш, йомшак табигатьле, әкрен, бераз ялкау, гамьсез. Бернигә дә артык исе китми, тыныч. Әти күп укый, тынгысыз, дөнья агышыннан, илдәге хәлләрдән тулысынча хәбәрдар. Үзе динсез, дәһри, муллалыгын ташлап, гади игенче булып калган кеше. Ә Сиражетдин абзый — намаз-ниязга бик исе китмәсә дә, күп чак мәчеткә тәһарәтсез баргаласа да, диндар кеше. Бисмилласыз яшәми. Күк күкрәп яшен яшьнәгәндә генә түгел, караңгыда мунчага, абзар-фәләнгә кагылса да, бисмилласын калдырмый. Шуның белән бергә, моңлы кеше. Озын көйләргә җырлап та җибәрә, скрипкада да уйный. Тавыш бик көр булмаса да, җомга намазыннан соң коръән дә укый. Шуңа күрә аңа бераз сәдака да эләгә ахры. Һәрхәлдә, шәфкатьле, мәрхәмәтле кешеләргә яхшылыктан башканы теләми.

Әйбәт кунак булдым мин Сиражетдин абзыйда. Хуҗа хатын Мөслихә апа да, ерактан килгән кунак итеп, мине бик яхшы сыйлады. Әйбәт симез аш, ит, ак күмәч, арыш ипие түгел, ак калач, рәхим ит, туйганчы аша. Моңа кадәр әллә нидә бер эләккән ак күмәч миңа бөтенләй бер оҗмах нигъмәте кебек күренде. Соң җүләр, авыз тутырып, ак калач аша әле син! Соңыннанрак белдем, бу якларда ак калач — кара ипи урынына, карасы ак урынына йөри икән. Арыш ипие күп кадерлерәк имеш. Менә могҗиза!

Сиражетдин абзыйның хуҗасы Хафиз мулла бик әйбәт кеше булып күренде. Бай мулла, сәүдәгәр мулла, кибете бар. Ләкин кибете — бакалея түгел, кәнфит, пәрәннек сатмый. Кызыл мал кибете дә түгел, китап кибете. Бик матур, җыйнак итеп, зур өе белән янәшә салынган. Пыяла

ишекләре урамга карап торган кибет. Киштәләрендә — китаплар. Дәреслекләр. Яңа басылып чыккан әдәби әсәрләр. «Коръән», «Кыйссасел әнбия»ләр белән беррәттән — «Таһир-Зөһрә», «Кыйссаи Йосыф», «Бүз егет», «Әбугалисина». Г. Тукай, С. Рәми, М. Гафури шигырьләре. Дәфтәрләр, каләм, кара, пенал һәм башка уку-язу әсбаплары. Белмим, болар белән сату итүдән Хафиз муллага күпме файда килгәндер, килсә дә, бик аз булыр, әмма шәһәр уртасында әнә шундый китап кибете эшләү урамга кечкенә генә булса да нур, ямь бирең тора кебек иде. Ул заманда үзенә күрә бер аң-белем учагы кебек иде. Кибеттә сату итүче кеше, приказчик — минем Сиражетдин абый. Китап һәм язу-сызу әйберләре алучылар әллә ни күп түгел, азык-төлек кибетләрендәге кебек өелеп тормыйлар. Шуңа күрә Сиражетдин абыйның вакыты бар. Китап укый, я тыныч кына уйланып утыра. Я килгән-киткән таныш-белешләре белән әңгәмә алып бара. Шундыйларның берсе — бик купшы гына киенеп йөри торган Гәрәй бабай. Өстенә кара жилетлы костюм киеп, ак күлмәгенә галстук бәйләп, ап-ак булып агарган булса да, бик әйбәт итеп түгәрәкләп кырылган сакал-мыегын сыйпый-сыйпый, ялтырап торган кара эшләпәсен кыңгыррак салып килеп керә дә сәлам бирә, исәнлек-саулык сораша. Киштәдәге китапларны, аңа алар күптән таныш булса да, тагын бер кат караштыра. Юк, сатып алу өчен түгел, тик эш югыннан гына. Алыр өчен булмаса да, нинди дә булса бер китап сорый, шуннан дөнья сүзләренә, шәһәрдә таралган яңа гайбәтләргә күчә. Сиражетдин абый аның сүзләрен җөпләп, тыңлап тора. Шулай тыныч кына, ялкау гына үтә Сиражетдин абзый гомере. Кибетнең бер ягында зур гына бүлмә. Анда карават, өстәл, урындыклар. Сиражетдин абзый шунда яши. Ашап-эчәргә зур өйгә керә. Бер көн яшәдем абый янында кунак булып, ике көн. Әз-мәз аның эшләренә дә булыштым. Караваты кечкенә, тар. Ә абый озын. Аның янына сыймадым. Урын-җир бик шәптән булмаса да, идәндә йокладым.

Ике көннән соң Сиражи абзыйга:

— Мине эшкә урнаштыру ягын кара әле. Югыйсә синең өстә туенып яту килешмәс,— дим.

— Бер сөйләшеп куйган урыным бар барын. Ошатсаң, әйдә, бүген үк барабыз.

— Нинди‌рәк эш, нинди‌рәк урын соң ул? Кайда? Еракмы?

— Алтынбай дигән бер казакъта, аның ике баласын укытырга.

— Балалар укытырга? Минем бит әле укытучы булырлык белемем юк.

— Һи-и, Риза энем, исең китмәсен. Син — барып чыккан гыйлем иясе. Үзебезчә дә, урысча да гыйлемең зур. Коръән, хәдис, намазнияз тирәләрен яхшы беләсең. Балаларга хәреф танытсаң, әлхәм-колһуалла укырга өйрәтсәң, бик җиткән. Кыскасы, менә дигән мулдәкә. Аннан йорт-җир тирәсендә вак-төяк йомыш. Җалунья ун сум. Алтынбай казакъ күңеленә ошап китсәң, унбишен дә бирер, егермесен дә кызганмас. Ашау-эчү байдан, үзләре белән бергә.

Карышып тормадым. Тәвәккәлләдем. Әйдә, анда баргач, сөйләшеп-танышкач, күз күрер дидем. Сиражетдин абзый кибетне япкач, тиз генә ашап-эчтек тә киттек Алтынбай казахка. Яшәгән җире шәһәр читендәге урамда булса да, артык ерак түгел икән. Бер сәгать тә үтмәгәндер, без инде Алтынбай казах янында идек. Ул Сиражетдин абзыйның күптәнге танышы икән. Кыска муенлы, юан гәүдәле, гәүдәсенә карый башы кечкенә, шулай да бите киң, кызгылт, саргылт мыек, шундый ук төстә кәҗә сакал... Күзләре, миңа сыный карап, хәйләкәр генә елмая. Һәм ул Сиражетдин абзыйга:

— Уйбай, мулдәкә дигәнең бик кечкентәй икән гуй,— ди.

— Кечкенә булса да эче тулы төш кенә гуй,— ди.— Урысчаны да, үзебезнең нугайчаны да су кебек эчкән егет,— ди мине мактап Сиражетдин абзый.

— Безнең балаларга иман өйрәтү, намаз-нияз шартларын да әз-мәз өйрәтү кирәк булады гуй...

— Дин, әлхәм, колһуалла дигәндә, минем энекәш хәлфәләрнең барын бәреп егады гуй. Я әле, энекәш, коръәннән бер-ике сүрә укып җибәр әле Алтынбай утагасына.

— Нәрсә укыйм соң? Әлхәм сүрәсенме, колһуалланымы, әллә ясинныңмы?

Ясин сүзен ишетүгә, Алтынбай агай, сискәнеп, миңа карап куйды:

— Жук, жук, жасыйн кирәкмәс, әлхәм булса, бик жарайды гуй.

Мин көр генә тавыш белән эгузе, бисмилла әйтеп, әлхәм сүрәсен укыдым. Бик моңлы итеп укый алмасам да, сүрәне һич бозмыйча, бик тыныч кына укыгач, мәгънәсен-фәләнен аңламаса да, миннән бик канәгать булды Алтынбай агай.

— Жаксы, мулдәкә, кызларымны да әлхәмне үзең кебек укырга өйрәтсәң, жаксы булады,— дип куйды һәм балаларын чакырырга кушты. Озак та үтмәде, Алтынбай янына ике зур гына малай килеп басты.

— Нимәнә бар, әкә? — диде чем-кара күзле уттай янып торган кечкенә буйлысы.

— Менә, кызларым, мулдәкә сезгә. Дөнья сабагын да, дин сабагын да укытачак ул.

Күзләрем, Алтынбай янына килеп туктаган малайларга карап, шар булды. Малайларча киенгән кызлар да миңа карап аптырап калды. Буе да булмаган яшь малай нинди мулдәкә янәсе.

— Бу кара кыз, чия ирен, шомырт күз — Гөлҗәмилә, ә монысы, өлкәне — Җомабикә,— диде зур буйлы, юан гәүдәле, табак битле пәһлеван егет-кызны күрсәтеп. Зәңгәрсу күзләрендә ниндидер бер нәзакәтлек, шәфкатьлелек күрсәтеп Җомабикә миңа күз сирпеп карап, елмаеп куйды. Башта Алтынбайның үзен, аннан кызларын күреп шүрләп калган идем. Юк, Алтынбай да, кызлар да мине кире какмады. Чын-чыннан мулдәкә итеп кабул иттеләр. Мин дә аларны кире кагып, укытырга алынмыйм, димәдем. Мулдәкә — укытучы дигән зур, җаваплы вазифаны өстемә йөкләп, Алтынбайда эшләргә калдым. Сиражетдин абзый ашауэчү үзләре белән бергә булыр, хезмәт хакы ун сум булыр дигән иде. Хуҗа юмартрак икән, миңа унике сум билгеләде. Сөйләшүләрдән соң аш-су, кымыз белән сыйлангач, мин Сиражетдин абзый янына кайтып, кайбер әйберләремне алып килдем. Мулдәкә-укытучы булсам да, яшәү өчен аерым бүлмәм булмады, билгеле. Укучы «балаларым» белән бер бүлмәдә яши башладык. Сәкебез зур, билгеле. Кызлар гына түгел, Гөлҗәмиләнең энисе Гайшә апа да безнең белән бер бүлмәдә йоклый. Бик ягымлы, сабыр холыклы хатын Гайшә апа. Ул Алтынбайның карт хатыны — Җомабикәнең энисе белән дә тату яши, яшь хатыны Сылубикә белән дә тату. Ә Гөлҗәмилә белән Җомабикә тату туганнар гына түгел, якын дуслар да. Мине дә алар үзләренең мулдәкәләре итеп түгел, туганнары, дуслары итеп якын күрәләр. Шулай булмыйча, барыбыз да яшьтәшләр диярлек. Миңа унөч яшь тулып килә, Гөлҗәмиләгә дә шулай ук. Тик Җомабикә генә бездән яшь ярымга олырак. Дөнья сабагы өчен, укырга, язарга өйрәнү өчен, безнең әле хәзергә китабыбыз да юк. Ә динне, әлхәм, колһуалла, тагын вак-төяк коръән сүрәләрен өйрәнер өчен, хәзергә китапларның кирәге дә юк. Мин аларны яттан беләм.

Өч-дүрт көн эчендә Җомабикә белән Гөлҗәмилә, миңа ияреп ятлый торгач, әлхәм сүрәсен дә, колһуалланы да белә башладылар. Кайбер тәшдитләрен, басымнарын, аваз әйтелешләрен җиренә җиткереп бетермәсәләр дә, нигездә дөрес укыйлар. Дөрес укыйлармы алар, хаталымы, аны якын-тирәдә белүче дә юк. Кызларының тырышлыгына, зирәклегенә Алтынбай агай да бик канәгать. Кызларны мактый, алар белән бергә, рәхмәт, бала-мулдәкә, дип, мине дә мактый.

Сиражетдин абзый янына барып, үземнең хәл-әхвалне сөйләп, аңар-

дан кәгазь, карандаш, каләм алып кайттым. Башлангыч сыйныфлар өчен әлифба. Татарчасы белән бергә русчасы да табылды.

Ләкин «балаларым» Гөлҗәмилә дә, Җома да язу-сызуга, әлифба укуга ялкау булып чыктылар. Аларны күз я кыш кергәч укырбыз, ә хәзер ашык уйныйк диләр. Ә ашык уйнарга дисәң, шундый осталар. Ашыкларны бер-бер артлы очырып кына торалар. Ялгышмыйлар, кулларыннан һич төшереп җибәрмиләр. Мине өйрәтеп карыйлар да соң, юк кына бит, булдыра алмыйм. Кулымнан ашык сөякләре төшеп китәргә генә тора. Ә кызлар көлә. Булдыра алмыйсың, мулдәкә, диләр. Ашык тәгәрәтүне генә түгел, алар үзара сугышкан булып, көрмәкләшеп уйнарга да яраталар. Уенга мине дә катыштырырга тырышалар. Кулымнан тарталар, аягымнан, беләкләремнән... тырпаеп торган күкрәкләре белән өстемә килеп егылалар. Ай бу дәртле балалык, юк, балалык кына түгел, балалыктан чыгып бара торган кызларның дәрте мулдәкәләренекеннән алдарак өлгереп җиткән. Ачык һавада, яланда уйнау тагын да кызыграк, күңеллерәк аларга. Беркөнне шәһәр читенә чыктык. Еракка, дүрт-биш чакрым җир китеп, күл буена килеп туктадык. Көн эссе, кояш кыздыра. Тирләдек.

— Әйдә, мулдәкә, су коеныйк,— ди кызлар.

Минем бик коенасым килсә дә, уңайсызланам, кызлардан тартынам.

— Ярый, коенабыз, мин читкәрәк китәм,— дидем кызларга.

— Юк, син монда коен, мулдәкә, читкәрәк без бараек,— ди Гөлҗәмилә.

Ерак китмәделәр, чишенеп бастылар. Мин дә чишендем. Тыныч кына суга кердем, йөзеп, эчкәрәк үттем. Артыма борылып карасам, харап эш, Гөлҗәмилә килгән дә минем киемнәремне күтәреп алып китеп бара. Кычкырам — туктамый. «Мулдәкә булсаң, мулдәкә бул, куып тот та ал», ди. Шәрә килеш ничек судан чыгасың да ничек куасың ди? Үзе дә шәрә килеш йөгергән кыз баланы! Аларга уенкөлке, ә миңа?..

Озак тордым су эчендә. Туңа башладым. Җомабикә, үскән, акыл утыртканрак кыз, аңлады минем хәлне. Үзе тиз-тиз генә киенде дә, киемнәремне Гөлҗәмиләдән алып, су буена китереп куйды.

— Мә, мулдәкә, ачуланма, без шаярып кына! — дигән була.

Беләм, шаярып кына. Судан чыктым, киендем. Кызларга каш җыерып, ачуланып та карыйм. Ләкин «балалар» аңлыймыни синең ачуланганыңны. «Син, мулдәкә, юкка каш җыерма, мин бит сине яратып кына шулай»,— диде дә Гөлҗәмилә, муеныма сарылып, кочаклап үбеп тә алды битемнән. Тәннәрем эсселе-суыклы булып китте. Үләм дип торам. Җитмәсә, Җома шаркылдап көлә. «Мулдәкә! Син Гөлҗәмиләнең үзен үп, кочаклап»,— ди. «Кызыл иреннәреннән»,— ди. Менә җен кызлар, иблис токымнары!.. Мин сабак укытасы урынга үзләре укыта миңа сабакны. Ничек кенә укыта әле! Ә мин яшь, яшел. Аңламыйм. Алар әнә симез ит, гомер-гомергә кымыз эчеп яшәгән кызлар миңа караганда күбрәк аңлый. Гөлҗәмиләнең мине кочаклап үбүен ошатмадым. Шулай да ачуым килмәде аңа. Хәтта бу шатранбай, шайтан кызый, тагын кочаклап үпсә икән дип куйган чакларым да булгалады. Көннәр уза бара, ашыкны һаман уйныйбыз. Көләбез, шаярабыз. Кымыз эчәбез, әче корт ашыйбыз. Ит, май, шулпа — кыскасы, ашау-эчү мул. Ләкин эч поша. «Балаларым» уйный, көлә, шаяра. Ә укырга теләмиләр. Хәтта беренче көннәрне бик яратып укыган әлхәм, колһуалланы да оныттылар.

— Мулдәкә, айналаен, син ачуланма, без кыш җиткәч укырбыз. Дөнья сабагын да, ахирәт сабагын да,— ди Гөлҗәмилә.

«Юк, болай булмый»,— дим үз эчемнән. Бу шайтан кызлар, беркайчан да ихлас куеп, сабак укымаячаклар. Боларга сабак укытыр өчен, инде буй җитеп, ажгырып торган, усал мулдәкә-хәлфә абзый кирәк. Яхшы чакта миңа ничек тә таярга кирәк моннан дим. Укыткан булып «балалар» белән шаярып йөрү килешми миңа.

* * *

1917 елның февраль ае бетеп килә. Аннан март, апрель. Язның, язның гына түгел, елның иң матур айлары. Карлар эреп, гөрләвекләр ага башлаган чак. Кояш нурлары, беренче чәчәкләр. Умырзая, баллыкай, башкалар. Кояш та инде әнә көннән-көн сөйкемлерәк карый. Тик фронттан яңадан-яңа шомлы хәбәрләр килеп тора. Нindидер чуалышлар, баш күтәрүләр. Пайтәхеттә, патшаның үзе яши торган Петербург шәһәрендә дә, имештер, тыныч түгел. Кемнәрдер, имеш, патшаның үзенә бәйләнәләр...

Кызылъяр шәһәренең Авыл хуҗалыгы складында курьер булып эшләп йөрим. Беркөнне шулай секретаребез Ольга Сергеевна мине телеграфка җибәрде. Бардым. Бик авырлык белән генә йомышымны үтәдем. Ә анда ыгы-зыгы, шау-шу. Солдатлар, офицерлар, нindидер кара тужуркалы агайлар. Ирек! Ирек! Патша төшкән. Патша үзе теләп тәхетеннән ваз кичкән дип кычкыралар. Аптырап ук киттем. Патша кадәр патша үзе теләп патшалыгыннан ваз кичсен дә тәхетеннән төшсен имеш. Юк, бу — акылга сыймый торган хәл. Шуны ишеткәнем бар иде минем: халыкның авыр тормышының сәбәбе патша аркасында, аның министрлары, генераллары аркасында, аңа якын торган байлар, завод хуҗалары һәм җир хуҗалары — алпавытлар аркасында, ә халык — крестьяннар, эшчеләрнең күбесе патшаны яратмый, аңа каршылар. Димәк, халык, фронтта сугышучы солдатлар кыскан, кысрыклаган патшаны, һәм ул тәхетеннән ваз кичәргә мәҗбүр булган. Димәк, инде патшасыз яңа дөнья, ирекле дөнья башланачак, әлеге сүзләрне ишетү белән, башымда әнә шундый уйлар бөтерелде. Күңелем күтәрелеп китте. Авылыбызда җир өчен барган дау, низаглар күз алдымнан узды. Болай булгач, «искеләр» җиңеләчәк, «яңалар» җиңәчәк. Җир җан башыннан бүләшенәчәк. Ирләргә генә түгел, хатын-кызларга да тиячәк җир. Күтәренке күңел белән сикергәли-сикергәли, өйгә кайтып бара башлаган гына идем, искерәк кара тужурка кигән бер абзый дәшә миңа:

— И, малай, браток, кая ашыгасың? — ди.

— Кайтып барам,— дим, абзыйның йөзенә һәм кулындагы алсу зур кәгазьләргә карап.

— Кайтырга өлгерерсең, әниең аш пешереп көтмидер әле.

— Әни түгел, мине эшләгән җиремдә көтәләр. Курьер мин.

— У-у, курьер. Алайса бигрәк тә шәп. Кайтырга өлгерерсең. Хәзер ирек — свобода! Аңлыйсыңмы? Менә күрәсеңме? Телеграмм, патша төшкән, төшергәннәр. Сат шушы телеграмманы. Барысы ун данә. Өчәр тиеннән сат. Кычкыра-кычкыра сат. «Ирек, хөррият, свобода. Патша төшкән»,— дип кычкыр. «Телеграмма, ирек!» — дип кычкыр. Сатып бетергәч, акчасын үземә китереп бирерсең. Мин шушы тирәдә булам. Күрәсеңме, әнә типография, шуның капкасы төбендә булырмын. Революция! Халыкка ирек! Шатлык бу!.. Бар, бар, белсен халык! Ишетсен халык! Тизрәк. Тик син кычкыр, ныграк кычкыр!

Абзый тиз-тиз генә кулындагы телеграммаларның ун данәсен миңа санап бирде дә үзе, кызу-кызу атлап, типографиягә кереп китте. Мин, кычкыра-кычкыра, телеграмма сата башладым.

— Телеграмма! Телеграмма! Ирек! Хөррият! Свобода! Патша төшкән, патша! — дим. Үтеп баручылар, мине туктатып, телеграмма алалар. Бу кызыклы, яңа хәбәр һәркемне кызыксындыра. Өч тиен урынына хәтта бишәр тиен биреп китә кайберсе. Кычкыра-кычкыра, алдагы урамнарның берсенә барып чыксам, каршыма городовой килеп басты. Таза гәүдәле, озын кара мыеклы.

— Туктале, малай, син нигә тузга язмаган сүзләр кычкырасың? Какой такой ирек ул сиңа?.. Патшага тел тидерәсең? Кил әле, кил! — дип чакырып алды мине үз янына. Кулымдагы телеграммаларны да тартып алды. Укыды. Күзләре шар булды городовойның. Телсез калды.— Ке-ем, кем бирде сиңа боларны? — дип сорый тотлыга-тотлыга. Ул курыкты, ә мин, киресенчә, кыюланып, батыраеп киттем.

— Биленә револьвер таккан бер абый, зур начальник булса кирәк! — дим.

Городовой телеграммаларны миңа кире бирде дә:

— Бар, бар, только син бу тирәдә түгел, арырак барып сат, арырак барып кычкыр! — ди.

Кинәт кызганып куйдым мин бу городовойны. Бүген иртән генә әле кукыраеп, мин кем дип йөргән городовой, патша хәзрәтләренең ышанычлы сакчысы, телеграммадагы хәбәрне укыгач, өтелгән тавык шикелле, ләпшерәп калды. Ярты сәгать вакыт та үтмәгәндер мин кычкыра-кычкыра, хәзер инде тагын да катырак тавыш белән, «Ирек! Хөррият! Свобода! Патша төшкән! Патшаны төшергәннәр!» дия-дия, телеграммаларны сатып бетердем дә, типография капкасы янына барып, тужуркалы абыйны бик тиз таптым. Аңа утыз тиен акчаны тапшырдым да, патша төшү шатлыгын уртаклашу өчен, тиз-тиз атлап өйгә, конторага килеп кердем. Билгеле инде, бер данә телеграмманы үземә калдырган идем. Барысы да патша төшкәнне ишетеп, бик шатланыр, ирекле тормыш килде дип сөенеп кул чабып каршы алыр дип уйлаган идем дә, алай булып чыкмады. Артык сөенмәделәр дә, көенмәделәр дә. Ольга Сергеевнага мин алып кайтып биргән телеграмма барына караганда да ныграк тәэсир итте кебек. Ул аны аптырап та, гаҗәпләнеп тә, бераз борчылып та башта ялгызы укып чыкты, аннары башкалар өчен кычкырып укыды, аннан телеграмма зур бүлмәгә күчеп, кулдан-кулга китте. Телеграмманың тәэсир көче аз булмады, бу хәбәр барысын да дулкынландырды. Эшләрен дә калдырып, шау-гөр килеп, үзара сөйләшеп алдылар. Бераз тын торгач, тагын сөйләштеләр. Яңадан-яңа хәбәрләр көттеләр. Ә яңа хәбәрләр озак көттермәде. Телеграммалар һәр сәгать диярлек яңа хәбәр алып килә торды. Типография капкасы янына тужуркалы абыйны эзләп, тагын бардым. Ләкин аны тапмадым, башка абыйларны күрдем. Кешеләр яңа телеграммаларны төркем-төркем җыйналып укыйлар, сөйләшәләр.

— Революция башланды! Яшәсен хөррият! Төрмәләр ишеген ачыгыз хәзер. Ачмасалар, ватабыз. Яшәсен революция! — ди берәү.

Үзеннән-үзе туган җыелыш. Митинг. Урамда солдатлар, атлы казаклар. Городовойлар: «Таралыгыз! Таралыгыз!» — дип кычкырып йөриләр. Халык тарала, мин дә йөгерәм.

Бу безнең Туган илебезне Бөек Октябрьгә алып килгән революциянең беренче баскычы, Февраль революциясе көннәре иде.

Өч-дүрт көн үткәч, хәл белешергә дип, Сиражетдин абзый янына килдем. Аның янында Гәрәй бабай, үзенең купшы итеп кырылган сакал, мыекларын сыйпый-сыйпый, кызып-кызып сөйли:

— Син Сиражетдин энем, юк-бар сүз сөйләмә. Патша — патша инде ул. Патшасыз дөнья — тәртипсез дөнья ул. Патшасыз ничек яшәмәк кирәк? Иген чәчәргә җирне кем бирер дә, налукларны кем җыяр?

— Икмәге булса, налог җыючысы табылыр...

— Шул шул энә, җире булмаса, каян килә ул икмәк? Эрәчәй тулы җилкуар, караклар, исерек башлар, ә кем яба аларны төрмәгә?

— Төрмәгә ябарга гына эш калса, патшадан башка да ябучылар табылыр, син менә хаксызга төрмәгә ябылучыларны кем чыгара, шулар турында борчыл, Гәрәй абзый,— диде Сиражи обзый.

— Хәзер инде ирек, хөррият! Хаксызга төрмәгә ябылганнар чыгарылачак,— дидем мин, алар сүзенә кушылып.

Гәрәй бабай миңа кашларын җыерып карап:

— Кем чыгарыр икән аларны патша рөхсәтеннән башка? — диде.

Патшаны алласыннан да югары куеп, аның олтырагы булырга да әзер торган бу ак сакаллы дивана картка (бу минутта ул миңа шулай булып күренде) кырт кына кисеп әйттем:

— Солдатлар чыгарыр, эшчеләр. Төрмә ишекләрен рөхсәтсез генә үзләре ачып. Ачкычлары булмаса, ишекләрне ватып.

Гәрәй бабайның җен ачуын чыгарган, Сиражетдин абзыйның да исен китәргән бу сүзләр, минем үз сүзләрем түгел, урамда төрле кешеләрдән, шул ук солдатлар, эшчеләрдән ишеткән сүзләр иде.

Февраль революциясе әле халкыбыз тормышын нигездән үзгәрткән революция түгел иде. Шулай да ул күпләр тормышына зур яңалык кертте. Шул исәптән, мәсәлән, күп еллар буе читтә төрле эшләрдә эшләп, зимагур булып йөргән Сиражетдин абзый: «Болай хур булып йөрүләр җитәр, туган-үскән авылыма кайтам да иген игеп көн күрә башлыйм»,— дигән уйга килде. Яз җитүен дә көтмичә, Хафиз мулла белән тату гына араны өзеп, бәхилләшеп, Уразайга кайтып китте. Аны озату күңелсез булды миңа. Ерак шәһәрдә туган-тумачасыз ялгызым гына калдым. Шулай да артык күңел төшенкелегенә бирелмәдем. Бердән, мин инде үз көнемне үзем күрә ала торган малай. Эшем бар, ашым бар. Шәһәрдә якын танышларым, дусларым бар. Аннан, язлар җитеп, җәйләр башлангач, үзем дә Уразайга кайтып китәчәкмен.

Әтидән хат килде. Озын хат, ялкынлы хат. Патшаның төшүе, илгә хөррият, азатлык килүе шатландырган әтине. Канатландырган. Аның башында якты уйлар, яңа планнар. Үзеннән бигрәк, без балалары хакында иде аның уйлары. Шунысын да әйтим: Сиражетдин абзый да әтинең киңәше — «Үз дөньяңны кор, үз көнеңне үзең күреп яшә, байлар табанын ялап йөрүең җитәр, аякка басарга үзем ярдәм итәрмен, кайт»,— дигән хаты буенча илгә кузгалды бит.

Беренче май. Ольга Сергеевнадан һәм безнең кәнсәдә эшләүче башка кешеләрдән дә ишетүемчә, бу көнне зур бәйрәм тантанасы булачак имеш. Хөррият бәйрәме, хезмәт ияләре бәйрәме. Бу турыда миңа Хафиз мулла абзый улы Габдулла да әйткән иде: «Син, Риза, безгә кил, бәйрәмне бергә уздырырбыз»,— дигән иде. Габдулла — шәһәрдә миңа якын булган бердәнбер дус. Сиражетдин абзый аларда яшәгәндә, без гел-гел очраша идек. Уйный-көлә, шаяра идек. Китап кибетенең Сиражетдин абый яшәгән ягы, безнең өчен уен-көлке булмәсе, төрле темаларга әңгәмә куерту, укыган китапларыбызның эчтәлеген бер-беребезгә сөйләп, алар турында фикер алышу булмәсе иде. Хәзер инде кибеттә күбрәк ул була, китапны ул сата. Әйбәт малай иде Габдулла. Шуңа күрә 1 май көнне иртүк торып ашап-эчтем дә, өс-башымның мөмкин кадәр яхшыракларын киеп, үземә күрә әйбәт кенә төзәтенеп, Габдуллаларга китеп бардым.

Урамда зур бәйрәм һәм тантанага әзерлек сизелеп тора. Гадәттәгедән чистарак һәм затлырак киенгән кешеләр каядыр ашыгалар. Кайбер өйләрдә зур гына кызыл флаглар эленгән. Капка түбәләренең баганаларына тартылып куелган зур кызыл киндергә симез кара хәрефләр белән: «Яшәсен халыкара хезмәт ияләре бәйрәме 1 Май!» дип язылган лозунг та күренә. Кайбер капкаларга «Яшәсен, Хөррият!» дип язылган лозунглар беркетелгән.

Мин Садовая урамы буйлап алар өенә килеп җиткәндә, Габдулла, Хасиб һәм миңа таныш булмаган бер малай урамда мине көтеп торалар иде. Мине зур бәйрәм белән, хөррият бәйрәме, хезмәт ияләре бәйрәме белән котлап каршы алгач, Габдулла безне китап кибетенең алгы ягына, элек Сиражетдин абзый яшәгән бүлмәгә алып керде. Өстәлгә табын әзерләнгән. Чынаяклар куелган. Пешкән коймак, балга катырган чәкчәкләр, шикәр, конфет. Бу Габдулланың әнисе, дөресрәге, сеңелләре безгә — Габдулланың иптәш малайларына дип әзерләгән бәйрәм чәе. Берәр чынаяк чәй эчеп тә өлгермәдек, ул безгә ал кәгазьләргә татарча басылган җыр тәкъдим итте. Менә укыгыз, бүген шушы җырны җырлаячакбыз диде.

Атты нурлы таң илебездә,
Хөррият кояшы балкыды.
Яңа бәйрәм көне килде безгә,
Яңа шатлыклы дөнья туды.

Мин урамда сатып йөргән телеграмма шикелле үк ал кәгазьгә шул үк форматта басылган. Җырның бер нөсхәсен кулыннан тартып алдым да әнә шул юлларны кычкырып укыдым.

Җыр миңа искиткеч көчле тәэсир итте. Хөррият җыры. Яңа дөнья, шатлыклы дөнья тууы турында сөйли торган җыр.

Габдулла:

— Аның көе әле сүзләреннән дә әйбәтрәк!— дигәч, без өч малай аңа ышаныр-ышанмас карадык. Яле, җырлап күрсәт!

— Яхшылап белмим шул. Кичә Кәшфеләсрар хәлфә абзый әкрен генә җырлап күрсәткән иде дә, отып кала алмадым.

Минем күз алдыма кинәт Сираҗетдин абзый янына килеп, бик озак кына китаплар карый торган мәһабәт буйлы, бик пөхтә киенеп, башындагы кызыл фәсне кыңгыррак салып йөри торган куе кара мыеклы, кызыл чырайлы кеше килеп басты. Күзләре ут яна иде, кай яклары беләндер серле, мут кеше кебек иде. Әллә югыйсә ул да патшага каршы котыртып торучыларның берсе — революционер булдымы икән?

Без «Марсельеза»ны кат-кат укып чыктык. Көен Габдулла авыз эченнән генә көйләп караса да, хәтеренә төшерә алмады. Аның каравы без җырны кат-кат укып ятларга, үзләштерергә тырышкан арада, урамнан бер төркем кеше көйне җырлап узды.

— Әнә ул көй, тыңлагыз!— дип, Габдулла кычкырып җибәрде.

Без урамга ташландык, ләкин төркем ерак киткән иде инде. Колак төбендә, яңгырап, утлы моңы гына калды. Кешеләр инде күбесе урамга чыккан, төркем-төркем булып шәһәрнең үзәгенә таба узалар. Озакламый Хафиз мулла мәдрәсәсенең югары сыйныфларда укучы шәкертләре, хәлфәләре килеп җитәргә тиеш. Аларга кушылып, мөселманнарга хас ай сурәте төшерелгән яшел әләмнәр һәм хөррият-азатлык символы булган ак-кызыл флаглар күтәреп, хөррият-азатлык дәрте белән канатланган Хафиз мулла үзе дә инде мәдрәсәдән киткән шәкертләре һәм мәхәлләнең могтәбәр кешеләре белән берлектә урамга демонстрациягә чыгарга, халык белән, мөэмин мөселманнар белән берлектә хөрриятне котларга җыена. Без, Габдулла һәм аның янына килгән бүтән малайлар, тиз-тиз генә кибет ишеген бикләдек тә мәктәпкә юнәлдек.

— Их, Кәшфи абзый булса, яңа җыр «Марсельеза»ны җырлар идек,— дип куйды Габдулла.

Ул бу сүзләрен әйтеп тә бетермәде, каяндыр килеп безнең төркемгә кушылган өч-дүрт яшь егет:

— Әйдәгез, егетләр, яңа җыр башлыйбыз,— дип, кулларындагы ал кәгазьләрне бирделәр. Бу безнең куллардагы шикелле «Марсельеза» иде. Бирделәр һәм, безгә кушылып җырлагыз дип, үзләре җырлый да башладылар.

Атты таң, нурлы таң илебездә,
Хөррият кояшы балкыды;
Якты бәйрәм көне килде безгә,
Яңа шатлыклы дөнья туды...

Әлегә кадәр ишетелмәгән көй булса да, яңа моң, яңа аһәң, әйтерсең, колак элпәләребезне ярып үтте дә йөрәгебезгә кереп урнашты. Сүзләрен дә, көйне дә бик тиз үзләштереп алды шәкертләр. Ун-унбиш минут үтүгә, «Марсельеза»ны бергәләшеп бик көчле җырлый идек инде. Соңрак белдем: бу ялкынлы җырны татарчалаштыручы шагыйрь минем хөрмәтле укытучым Сәгыйть Сүнчәләй булган икән.

## Виктор Тельпугов

# ЯКШӘМБЕГӘ КАРШЫ ТӨНДӘ

хикәя



Төнге сәгать унике. Бер. Ике. Өченче.

Владимир Ильич кайчан кайтыр икән соң? Ульяновлар гаиләсендә йорт эшләрен башкаручы Сысоева-ны Ленинның бик тә аз йоклавы, юньләп ял итмәве пошаманга сала иде. Бу хакта ул җайлап кына «төн җене кагылган»ның үзенә дә әйтте. Владимир Ильич Александра Михайловнаны бик тә игътибар белән тыңлады, моннан соң да болай дәвам итү һич тә мөмкин түгеллеге белән килеште «һичсүзсез» төзәлергә сүз бирде, әмма барысы да үзгәрешсез калды. Җитмәсә әле, мөгаен, тагын да начарлангандыр.

Менә бүген дә инде өченче ярты узып китте. Чәй ун тапкыр яңартылып, ун тапкыр суынды. Александра Михайловна белә: чәй салкын булган очракта да Владимир Ильич ризасызлык белдермәячәк, игътибар өчен барыбер мактаячак. Әмма ул үзе кышкы төн үткәнче диярлек арып-талып эшләгән кешенең бераз тамак ялгамыйча ятуын уена да китерә алмый. Ул эмальләнгән чәйнекне плита өстенә кат-кат куйды. Әанысы исә, бүген дә нык соңарган хуҗаны тизрәк кайтырга өндәгән сыман, чуен рәшәткә өстендә түземсез калтырана иде.

Александра Михайловна сәгатькә еш күз сала. Сәгать теле үзенең җиз тәлинкәсендә аксыл-соры, әйтерсең лә бәсләнгән биек түшәмнән асылынып торган бердәнбер лампочканың тонык чагылышын тибрәтә. Владимир Ильич белән бер-бер хәл булмагае тагын?!

Өч тулгандарак Сысоева тынгысыз йокымсырау аша сискәнеп китте, артында таныш адымнар ишетелгән ишек янына килде. Әмма нәрсә бу? Адым тавышлары ишетелде дә... тынып калды. Ялгыш ишеттеме соң әллә? Юк, ялгыш түгел, Ильичның тиз-тиз һәм еш адымын башкаларныкы белән бутау мөмкин түгел. Эшендә берәр нәрсәсен онытып, кире киттеме әллә? Ул колагын ишек ярыгына куйды һәм ирексездән ике кешенең акрын гына, әмма бик әйбәт ишетелерлек сөйләшүенең шаһиты булды:

Берсе сорый, икенчесе җавап бирә:

— Сезгә, мөгаен, бик салкындыр, иптәш?

— Түзеп була әле, Владимир Ильич.

— Димәк, мин хаклы, салкын. Әйдәгез, болай эшлик. Мин хәзер ишекне ачам да, икәүләп миңа кереп, берәр стакан кайнар чәй эчеп җылынабыз.

— Булдыра алмыйм, Владимир Ильич, ярамый.

— Соң бит үзегез әйттегез, туңдым, дип. Ул-бу килеп чыкса, тиешле кешесенә минем рөхсәт белән, дип аңлатырбыз. Аңларлар безне, бернинди дә күңелсезлек булмас, ышандырам сезне.

— Постны ташларга хакым юк, Владимир Ильич.

— Анысын хәтта мин, штатский кеше дә, аңлыйм, әмма сүз бит фәкать ниндидер минутлар турында гына бара.

— Бер секундка да аерыла алмыйм, Владимир Ильич. Хезмәттә мин.

— Шулай да бәлки кагыйдәдән кечкенә генә чигенеш ясарбыз, ә? Ахыр чиктә мине җәзаларлар. Гауптвахтага җибәрмәсләр ич?

— Сезне җибәрмәсләр, Владимир Ильич. Ә мин хәтта сезнең белән сөйләшмәскә дә тиеш...

Мондый сүзләрдән соң тыныч гәп өзелде. Сысоева ишек янышнан китәргә чак өлгереп калды, йозак тишегендә ачкыч әйләнә башлады.

Бераздан инде Александра Михайловна Ленинга пальтосын салырга булыша иде. Ә Ильич кыенсынып кына аның ярдәменнән баш тартты:

— Соңаруым өчен мең-мең гафу үтенәм, кадерле Александра Михайловна. Мең-мең гафу! Үзем дә йокламыйм, башкаларга да комачаулыйм. Ә сез һаман мәшәкатьләнәсезме?

— Нинди мәшәкать булсын, Владимир Ильич? Менә яраткан чәегезне кайнаттым азрак.

Владимир Ильич арыган, әмма игътибарлы күз карашын чәйнеккә юнәлтте:

— Бүген сыйдан баш тартмаячакмын.

— Хәзер үк ясыйммы? — дип сорады Сысоева.— Әллә...

— Хәзер үк,— дип, гадәтенә каршы килеп, аның сүзен бүлдерде Ильич.— Хәзер үк һәм, әгәр мөмкин булса, ике стакан, Александра Михайловна. Һәм катырак итеп, зинһар!

Александра Михайловна гаҗәпләнеп сорап куйды:

— Берьюлы икене? Сез берсен эчкәнче, аның икенчесе суынып бит.

Икенче стаканның кемгә икәнен Сысоева бик яхшы белә, тик Ленинның коридорда кем белән һәм нәрсә турында сөйләшкәнен ишетеп торуын сиздерәсе килми иде. Ә тегесе йомшак, әмма кискен төстә кабатлады:

— Берьюлы икене, кадерле Александра Михайловна, берьюлы икене. Миңа һәм часовойга. Ул туңган, ә постыннан хәтта минем рөхсәт белән дә китә алмый. Берничек тә күндереп булмый. Сез моңа ни әйтерсез?

— Күндереп булмас та, Владимир Ильич. Мин ул егетне яхшы беләм.

— Беләсез? — дип гаҗәпләнде Ленин.— Ә минем, дөресен әйткәндә, аны беренче тапкыр күрүем.

— Дөрес, ул яңа кеше әле, әмма холкын күрсәтеп өлгерде инде.

— Холкын, дисезме? Кызык бит бу! Холыклы кешеләрне яратам. Ә шулай да, һичнигә карамастан, бер стакан чәй илтеп бирегез әле үзенә, бик тә үтенеп сорыйм сездән, Александра Михайловна. Әллә югыйсә, сезгә уңайсыз булса, үзем илтеп, янындагы тумбочкага куйыйммы? Үзегез теләгәнен сайлагыз.

— Юк, нишләп, миңа кыен түгел, Владимир Ильич.

— Алайса, бик яхшы, Александра Михайловна. Кеше туңган, «уставта каралмаган» бер стакан чәй өчен аны беркем дә битәрләмәс дип ышанам.

Сысоева ике стакан чәй ясады. Ленин, күзен кысып, башта берсен, аннары икенчесен яктылыкта тотып карады:

— Менә монысы аңа. Бусы катырак кебек.

— Шулай тоела гына ул, Владимир Ильич. Икесе дә бертигез каты, сез яратканча. Икесе дә бер куелыкта.

— Әйе, әйе, әлбәттә, Александра Михайловна, икесе дә бер куелыкта.

Ленин стаканнарны тагын бер кат яктылыкта тотып карады һәм ярым шаяртып, ярым җитди төстә әйтте:

— Аеруча менә монысы. Суынганчы, шунысын илтегез, Александра Михайловна.

Сысоева тыңлаучан кыяфәттә тиз адымнар белән часовой янына китте һәм тулы стаканын тотып, шулай ук тиз-тиз кире керде.

— Алмадымыни? — дип сорады Ленин.

— Алмады, Владимир Ильич.

— Ичмасам, берәр сүз әйттеме соң? Ни диде?

— Берни дә әйтмәде, Владимир Ильич. Дәшми генә кире борды, менә шул.

Ленин уйга калды. Стаканнан бер-ике йотым чәй эчте. Бераз дәшми торгач, Сысоевадан:

— Бу мөнәсәбәттән сез ни әйтер идегез, хөрмәтле Александра Михайловна? — дип сорады.— Сезнең фикерегез нинди? Тик дөресен әйтегез?

Сысоева икеләнүсез диярлек җавап бирде:

— Минемчә, сез икегез дә үзегезчә хаклы. Сез тәкъдим ясап яхшы иттегез, Владимир Ильич. Ул баш тартып яхшы эшләде. Чынлап та, каравыл хезмәте уставы кушмый бит. Әтием хәрби кеше иде, шуңа боларның бөтенесен беләм. Ә иң мөһиме — эш уставта түгел, ә егеттә. Уставны кайчак теләсә ничек борып була, миңа монысы да билгеле.

Савыт-сабаны җыештырып куяр өчен. Ленинның чәй эчеп бетерүен көтеп, Сысоева дәшми генә утырды. Әмма Ленин башка эчмәде. Ул үз уйларына чумып, дәшми-тынмый гына кашыгы белән чәен болгатып һәм өстә әйләнгән чәй бөртекләренә карап озак утырды.

Шактый паузадан соң беренче булып Сысоева сүз башлады:

— Бер сорау бирсәм ярыймы, Владимир Ильич?

Ленин стаканындагы чәй бөртекләре әкренрәк әйләнә башлады.

— Әлбәттә, Александра Михайловна, әлбәттә.— Ул арыган күзләре белән кызыксынып Сысоевага карады.

— Кызык, ә ул егет турында сез ни уйлыйсыз, Владимир Ильич? Хәзер бит уйларыгыз аның турында шикелле?

— Нәкъ шулай, Александра Михайловна! Аның турында. Торган саен бер фикергә килә әле мин: яңа тормышны, кадерле Александра Михайловна, нәкъ менә шундый кешеләр белән генә төзергә мөмкин дә инде. Нәкъ менә шундыйлар белән генә! Бик тә мөмкин! Ачлык, салкын, җимереклек шартларында алар үз хезмәтләрен намус белән һәм ахырынача башкаралар. Я, искиткеч түгелмени бу?

Стакандагы чәй бөртекләре түгәрәге яңадан кызурак бөтерелә башлады.

— Мин хаклы түгелме әллә? — дип сорады Ильич.

— Һәрвакыттагыча, тулысынча хаклы, Владимир Ильич,— диде Сысоева. Ленин тонына кушылып.— Һәрвакыттагыча...

Икесе дә сүзсез калды. Һәркайсы үз уйларына чумды. Һәркайсының үз мәшәкатьләре һәм бурычы, үз эшләре бар иде. Тынлыкны беренче булып Ленин бозды:

— Зинһар, Александра Михайловна, минем ул егет белән очрашуымны оештырыгыз әле. Миңа һичшиксез аның белән сөйләшергә кирәк. Һичшиксез! Бәлкем, чыннан да без аның белән берәр стакан чәй эчәрбез? Моның өчен бик аз гына вакыт булса да табарга тырышачакмын.

Сысоева дәшми генә баш какты. Һәм шул арада иске сәгатькә карап алды.

— Аңладым сезне, кадерле Александра Михайловна. Керәм һәм йоклап китәргә тырышам. Озакламый торырга кирәк булачак. Шулаймы? Сез шуны әйтмәкче идегезме? Менә бит нинди заман килеп җитте! Иң әһәмиятлесен эшләргә өлгерми калабыз. Иң кирәкле кеше белән сөйләшергә вакыт юк...

Бүлмәгә кереп китәр алдыннан Ильич тагын бер тапкыр Сысоевага мөрәҗәгать итте.

— Дөресен әйткәндә, аның белән яңадан кайчан очрашачагыбызны белмим. Мин йоклаган арада ул, мөгаен, алышынадыр инде. Ә аннары минем «смена» башлана... Сездән шуны үтенәм, Александра Михайловна. Кем дә булса часовойга күз-колак булып торсын да, дежурствосын бетергәч, аны монда, шушы өстәл янына утыртып, чәй белән сыйласын. Кем эшли ала моны?

— Кем булсын, үзем эшләрмен, Владимир Ильич. Мин һәрвакыт үз урынымда.

Ильич рәхмәт әйтте дә бүлмәсенә таба атлады. Ишек янында ул артына таба борылып:

— Бу һич тә безнең очрашу сүтелә дигән сүз түгел, Александра Михайловна. Бу очрашуны чын күңелдән сөйләшерлек итеп һәм, мөмкин булса, шушы атнада ук оештыруыгызны үтенеп сорыйм. Ярыймы?

— Бу атна бетте инде, Владимир Ильич. Хәзер якшәмбе дип исәплэгез.

— Сез тагын хаклы, Александра Михайловна. Әйтергә мөмкин, соңгы секундына кадәр исәпләнгән якшәмбе. Алайса, бәлкем, дүшәмбе яки сишәмбедер? Язып куегыз һәм секретарема чын күңелдән үтенүемне җиткерегез. Нәкъ менә шундый часовойлар бик тә кирәк хәзер Совет властена. Бик тә кирәк, кадерле Александра Михайловна!

— Әлбәттә, Владимир Ильич, әлбәттә, бөтенесен җиткерермен, борчылмагыз.

Зур ак ишекне сак кына ябып, Ленин кереп китте.

Үзе ишеткән, шаһиты булган нәрсәләр турында уйланып, Сысоева эшлисе эшләренә тотынды.

Өйдә тынлык урнашты. Озакламый үз бурычларын үти башлаячак якшәмбе таңы атачак иде.

Ярты сәгать үтмәгәндер, зур ак ишек тавыш-тынсыз гына яңадан ачылды. Аннан әле һаман да «йокларга тырышып» карамаган Ильич килеп чык-

ты. Александра Михайловнага карады да, галстук төенен аз гына бушатып, болай диде:

— Александра Михайловна, сез бәлкем гаҗәпләнерсез. Әмма мин бер мөһим фикерне ачыклау өчен чыктым әле.

Сысоева Владимир Ильичка гаҗәпләнгән күзләре белән карады. Ильич аңа якынлашты һәм аның шәл бөркәлгән җилкәсенә сак кына кагылып:

— Часовойлар турында әйткәндә, мине туры мәгънәдә генә аңламагансыздыр, дип ышанам? Мин бит күз алдымда аларны гына тотмадым, Александра Михайловна. Һич кенә дә аларны гына түгел — гомумән, барыбызны да. Хәзер революциягә барлык постларда, зурларында да, кечкенәләрендә дә, нинди кешеләр кирәклеге аңлашыламы сезгә?

— Сезне дөрес аңладым дип уйлыйм, Владимир Ильич. Монда беренче көнемне генә эшләмим, күп нәрсәгә өйрәндем бу вакыт эчендә.

— Монысы искиткеч, Александра Михайловна! Эшкә бирелгән кешеләр күбрәк булган саен, безнең алда торган максат та якынрак һәм реальрәк. Килешәсезме?

— Әлбәттә, килешәм, Владимир Ильич.

Сысоева сүзсез калды. Ильичка тагын бер тапкыр, бу юлы инде сокланып карады. Әмма шулай да чак кына шелтә катыш сорады:

— Шуның өчен әлегә кадәр йокларга ятмадыгызмы? Махсус кире чыктыгызмы?

— Шуның өчен,— диде Ильич.— Әмма эш, үзегез аңлаганча, Александра Михайловна, үтә дә җитди. Бәлкем, хәзерге мизгел өчен иң җитдиедер.

— Монысы белән дә бәхәсләшмим, Владимир Ильич.

— Нишләп соң алайса миңа шундый кырыс итеп карыйсыз? Нәрсәне дә булса дөрес әйтмәдемме әллә? Ялгыш әйттемме?

— Барысы да дөрес, барысы да шулай, Владимир Ильич. Тик уйлаганнарыгызның барысын да үтәр өчен, сез аз гына булса да сәламәтлегегезне сакларга тиеш. Тамчы гына булса да...

Сысоева, авыр сулап, теле рәхимсез төстә төннең соңгы минутларын санаган сәгатькә карады.

**Миргалим ХАРИСОВ** тәрҗемәсе.

## Арви Сийг,

эстон шагыйре

### Чүплек

Шартлатылган Европаның
хәрабәсе гүя чүплек.
Тракторлар. Ком. Тутык ләгән. Табаныннан мәхрүм итек.
Алабута арасында —
циклон күзе —
ак унитаз.
Эчәгесе актарылган карт солдат күк —
иске матрац.
Күзләремне ала алмыйм
чәрдәкләнгән бер вазадан —
Нигә сыкрап иске төште
тере Вася,
тере Юхан?
Кызганудан җан дусларны ник кысыла шулай йөрәк?—
Кешеләргә караганда
әйберләр шул хәтерлерәк!
Үзләрен бит тутык баса,
алабута үсә өстә —
Үзләренең хәтерләре
тутыгуны белми һич тә.
...Хыялланды яшь бер егет
бер бәләкәй бүлмә, диеп,
Булмаса да артык иркен,
булмаса да артык биек,
Эшләнмәсә дә тәрәзнең
яңаклары
бизәп-сырлап,
Сыйсын гына аңа
өстәл,
пар урындык,
бер карават!
Бу куышта булмас иде беркайчан да тимер йозак —
Яши бирсен
Нух пәйгамбәр йолып калган
һәр тере зат!
Кызыкмады
Людовикча
нәфис, көяз, зат яткка —
Кызыкты ул
гади, җылы, ныклы тимер караватка.
Тимер ятак эзләп китте
бар булганын чутлап кат-кат:
Пружинасы сынатмаса
ярар безгә
тимер ятак!

Тыңламады киңәшләрне —
барды,
сатып алып кайтты
Сафо софасын түгел,
ә спартаннарга хас ятакны.
Аның ялгыз хыялларын белде бары ялгыз мендәр...
Изольдасыз гына үтте күпме ялгыз, уйлы төннәр!
Тристанның да ут кылычы
кирәк түгел иде аңар...
Һәм караватт белде:
әгәр
өстә бәйрәм башласалар —
Аякларын сындырмыйча
туктамаслар караватның!—
Бу яуга да әзер иде
һәр тимере карт солдатның.
Килде сәгать! Сукты сәгать!—
ныклы ятак — әйлән-бәйлән!—
Күпме төннәр дәвам итте
караватта ярсу бәйрәм!
Ыңгырашып, сыкранып гел
пружиналар җырлады җыр —
Бу җыр —
кеше дигән затның
яшим диеп җырлавыдыр.
Яңгырады яңа аваз...
Кеше килде бу дөньяга
Алсу тәпиләре белән
тибә-тибә пружинага.
Нәкъ шушы җан аңлатмасмы
мәгънәсен зур Яшәешнең,
Җирдә кылган һәр гамәлнең,
дөньядагы һәрбер эшнең?
Спартаннарча кырыс ятак!
Рәхмәт сиңа,
мең-мең рәхмәт!
Синдә гомер башладык без,
җылыттың син, булдың рәхәт.
Тик...
тарайдың...
чүплеккә дә
бик вакыттыр инде сиңа.
Ял ит хәзер
алабута һәм әремнәр арасында.
Лафетларга салып сине
китерәсе иде монда —
Олы юлардан талкынып чыккан карт бер солдат сыман...
Озатасы иде сине
байракларны түбән иеп.
Ә без
кайтып киттек менә
зур чүплеккә сине... түгеп.
Лаек идең курганнарга!
Сыктавына хатын-кызның!—
Өсләреңә кунды карга.
Әче әрем сабак сузды.
Шартлатылган Европаның
хәрабәсе гүя чүплек.
Тракторлар.
Ком.
Тутык ләгән.
Юллар йөреп тузган итек...

**ЗӨЛФӘТ** тәрҗемәсе.

# Анатолий Парпара,

рус шагыйре

## Ватан турында уй

Гаҗәеп төн! Тыныч, серле юлдан
Үрләр аша узып барышым.
Чирәмлектә туктап калам кинәт
Ишетәм дә кошлар тавышын.

Бик якында, урман ешлыгында,
Тамакларын чыкка чылатып,
Сайрый сандугачлар — җан сердәшен
Иркәләпме, әллә елатып...

Ишетәмен: төнге үләннәргә
Тупыр-тупыр алма коела.
Бакча-дәрья, шуның дулкыннары
Җирне капшый кебек тоела...

Җирем минем! Күпме гарасаттан
Исән-аман чыга белгәнсең.
Яшәр өчен безгә — үлмәс хәтер,
Үткер хыял, иман биргәнсең.

Азмы анда синең курпыларны
Җилләр кискән, ялкын ялмаган.
Ә үләннәр, халык рухы сыман,
Күтәрелеп чыккан яңадан.

Исеңдәдер ул яралы көннәр,
Тик беркайчан үчле түгелсең...
Чәчәк ат син, Рәсәй, шатландырып
Җирнең барлык, барлык кешесен!

## Җиңү миләше

Кемнәргәдер тоелырга мөмкин
Сәер исем булып, ят исем,—
Килә минем күзге миләшләрне
Кызыл салют диеп атыйсым!

Ни дисәм дә, чагыштыруларым
Хакыйкатьтән мәхрүм түгелдер:
Учлам-учлам кызыл миләш дәрли —
Кар өстендә гүя кызыл җыр.

Кызыл сурәт — йөрәк хәтерем ул,
Балачакның төсе югалмас:
Смоленск җирендәге канны
Һәм янгынны еллар юалмас.

Гашыйк булдык Җиңү салютына!
Безнең теләк, өмет аркылы
Кар өстендә миләш тәлгәшләре
Кызыл шартлау булып балкыды.

Авыр көннәр искә төшкән саен
Йөрәгемне кинәт моң сара.
Утлы сүз һәм кызыл күлмәкле кыз.
Кызыл мәйдан — кызыл манзара.

Зәңгәр күкнең кызыл балкышлары
Йөзеп килә балачагымнан.
Күрәсезме: көзнең миләшләре
Кызыл салют булып кабынган!

Рәшат **НИЗАМИЕВ** тәрҗемәләре.

# Марат Карабаев,

каракалпак шагыйре

## Тулган ай

...Очтык, очтык, аста калды болытлар,
Арал диңгезе дә күптән күмелде.
Мотор моңы, заман моңын искәреп,
Җилкәндереп күңелләргә түгелде.

Ак тигезлек безнең аста — ак болыт,
Их, чабасы шуннан чая малайдай.
Урталай киселгән бөтен икмәк күк,
Изге юллар теләп безгә кала ай.

Җырлар багышласы килә аңарга
Җирдәгедәй якын күреп, үз күреп.
Әнә бит ул безне сынап озата.
Ярты йөзе пәрәнҗәле кыз кебек.

Күңел сизә, бер-береңә талпынсаң,
Үпкәләмә, ярты җаным, дигәнгә.
Мин дә менә синең кебек идем бит
Ярты җаным калгач туган илләрдә.

Бер сөйләшик әле, дустым, ярты ай,
Бу җиһанда һәрни беткән бәйләнеп —
Йөзик әле шушы гүзәл киңлектә
Ике ярты — бер бөтенгә әйләнеп.

...Кайтып барам... Бер гүзәлне хәтерләп,
Кавын кебек бөтен булып мең яшә!
Җирдә күпме төнге гашыйк адәмнәр
Исәнме!— дип, тулган айга эндәшә.

Кайтып барам. Әле ничә көн элек
Ярты җаным күтәрелде биеккә:
Колач җәеп каршылады киң Идел,
Ярты идем... чөйде мине зенитка.

Ярты аем, якты аем, синең күк
Безнең язмыш бер үк төрле ахрысы:
Дусларымда булыр, туганнарымда
Калган булса әгәр җанның яртысы.

Ә син миңа ярдәм кулы сузасың,
Мин моңаймыйм, ташый куанычларым.
Тулган ай күк кайтып барам: үзем күк
Мул хисле дип каршылаган дусларым.

## Кеше һәм бәхет

Мин язмышка сорау бирдем:
«Миңа бәхет чәчәрсеңме?»
Ул сорады: «Ә син үзең
Кеше булып яшәрсеңме?
Рәхәткә коенмассыңмы,
Тынлыкка сыенмассыңмы?»

Саллы язмыш сындыргалап
Сынады мине төрлечә.
Сукмак салдым юлымдагы
Чытырманны кисә-кисә,
Елгаларда колач җәйдем
Чоңгылларны кичә-кичә.

Әле үзе алып бәрә,
Әле өскә килеп менә —
Бәхет булып күтәреләм.
Саклап кала өмет кенә.

Хезмәт диган чая атым
Мине әйдәп җилде генә...
Мин бәхетне эзләмәдем,
Үзе эзләп килде миңа.

Кеше булып туганмын да
Хезмәт итәм —
Башка бәхет табылмады.
Югалтмаска, пычратмаска
Байрак итеп йөртәм аны.

## Мизгел

Мизгел бит ул сәгать түгел,
Мизгел бары мизгел генә...
Ә бит түрдән урын ала
Кереп кеше гомеренә.

Мизгел — йөрәк яра ала,
Мамык кебек оча ала,
Ана сыман үз баласын
Мәңгелеккә коча ала.

Күп яклы ул, күп канатлы,
Еллар, айлар тора аннан —
Бер мизгеллек күз карашы
Гомерлеген яулап алган.

Бәлки бәхет нигезе дә
Бер мизгелдә салынадыр.
Ә калганы — гомерең буе
Шуны саклап барудадыр.

**Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ** тәрҗемәләре.

## Сәйфи Кудаш,

Башкортстанның халык шагыйре

# РОБАГЫЙЛАР

❁

Кем йөретә илнең авыр йөген
Гомер буе йөкләп иңендә —
Эзе кала бары шул кешенең
Югалмыйча туган җирендә.

❁

Эшсез торсам әгәр, эчем поша,
Күкрәк кыса, тормыш тарлана.
Үлсәң иде тәртә арасында,
Ил арбасын тартып барганда.

❁

Кайбер кеше зур уңышка саный
Тәнкыйтькә эләкми торганын.
Уйламый ул: кайбер эшләренең
Тәнкыйтьтән дә түбән булганын.

❁

Таң каласың, очкан кошны күреп —
Канатларын кагып болытка,
Күпме генә очмасын ул биек,
Җирдән очканлыгын онытма!..

❁

Куркаклар бозган эшләрне
Батырлар төзәтер.
Алар төзәтә алмаганны
Акыллар төзәтер.

❁

Кыяларда очар шоңкарлар,
Далаларда җилер тулпарлар.
Шоңкар булсаң, күктә йөзеп кал.
Тулпар булсаң, кырда җилеп кал.

❁

Киң кырларга сыймый, тибешеп
Аксасалар бәйге атлары,
Сабан туйларында ярышта
Алга чыгар... ишәк затлары.

Дошманлашып аерылышканчы беркөн,
Ике арага кара пәрдә тартып,
Дуслашмый һәм дошманлашмый гына,
Тату гына шулай торган артык.

❁

Егылырга елан сызгырганга
Без түгелбез камыш затыннан.
Егылмассың, юкка җиң сызганма,
Безнең токым ныктан, катыдан.

❁

Һәрвакыт омтыл син алга,
Нишләсәң дә алга бар.
Барып егыл максатыңның
Капкасына булса да.

❁

Сөюләрең сөелеп бетмәс борын
Өзелсәләр әгәр гомерләр,
Мәхәббәтнең изге учагында
Дөрләп кала икән күмерләр...

❁

Җилләремнең узганын да сизәмен,
Җилкәнемнең тузганын да күрәмен.
Тик шулай да өмет җебен өзмимен,
Җил чакырып сызгырамын, түзмимен.

❁

Сынсалар, шартлап сыналар,
Баш имиләр иманнәр,
Иман затыннан булмыйлар
Башны түбән игәннәр.

❁

Кайберәүләр хөрмәт юллый торгач,
Табанына сөял чыгара.
Шул арада аның барлы-юклы
Хөрмәт кисәге дә югала.

❁

«Сукыр күздән яшь чыкмый»— дигәнне
Әйтмәгәннәрдер чын сукырлар:
Сукыр күз төбендә ята икән
Яшь чишмәсе чыккан чокырлар...

Кайсы берәү эш эшли дә
Бер төймә чаклы гына,
Бастыра дөядәй итеп
Җиде юл чатлыгына.

❁

Әгәр керсәң начар уй белән син
Чәчкәгә бик бай бер бакчага,
Төшмәс күзең... уталмый калган
Зәгыйфь чүп затыннан башкага.

❁

Гамьсезлек — аяк астында
Күм-күк боз көзге кебек.
Әгәр дә басса шул бозга,
Таеп егылыр егет.

❁

Теләкләргә ирешү авыр түгел,
Өмет булса әгәр юлдашың.
Ялгыз булса булсын юлчы күңел,
Тик өметсез генә булмасын.

## Роберт Миңнуллин

### Кунакка килегез!

Җирнең иң матур җирендә —
Татарстанда торам мин.
Малайлар һәм кызлар! Сезне
Кунакка чакырам мин.

Йөртербез сезне утыртып
Я КамАЗга, я атка.
Ашыксагыз — үзебездә
Ясалган самолетка.

Сезне үзебез үстергән
Ипи белән сыйларбыз.
Сыйга өстәп, Тукай, Җәлил
Шигырьләрен сөйләрбез.

Ни телисез, бар да булыр —
Көньяк та үзебездә.
Кирәк икән, котыбы да
Киләчәк үзе безгә.

Тундрасын да, джунглиен да,
Даласын да табарбыз.
Әгәр тайга кирәк булса,
Анысын да карарбыз.

Безнең якның көзе дә бар,
Кышы, язы, җәе дә.
Бездә иген кырлары да
Диңгез булып җәелә.

Таудан да биек өелә
Ашлык көшелләре дә.
Чөнки эшчән, тырыш безнең
Якның кешеләре дә!

Безнең өстә — якты кояш
Һәм зәп-зәңгәр төсле күк.
Гомумән, бездә бик матур,
Нәкъ сездәге төсле күк.

---

РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН *(1948) — шагыйрь. «Бәхетле булыгыз», «Сөенсеннәр әле каеннар», «Мәңгелек сәфәр» һ. б. шигырь китаплары авторы. Татарстан комсомолының М. Җәлил премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Тагын ниме? Безгә килгәч,
Үзегез дә күрерсез.
Бездә Идел буйларында
Булмас сезгә күңелсез.

Безнең якларны күрсәгез,
Сез шаккатыр идегез.
Дусларыгыз көтә сезне —
Татарстанга килегез!

## Йөгерә чебиләр урамнан

Көзге җил җилферди урамда,
Ул минем чабуга ябыша.
Җил белән ярыша-ярыша
Сап-сары чебиләр чабыша.

Йөгерә чебиләр урамнан,
Йөгерә берни дә күрмичә.
Кинәттән бер чеби чак калды
Машина астына кермичә.

Туктап ук калды ул куркудан.
Йөрәгем жу итте минем дә.
Ул сары яфракка әйләнде,
Мин аны тотмакчы идем дә!

## Мин көрәшергә тиеш!

Безгә якты дөнья кирәк!
Якты дөнья — тынычлык.
Дөнья тыныч булсын өчен
Кирәк әле тырышлык.

Тынычлык өчен бар дөнья
Көрәшкәндә — бер минме
Калырга тиеш бер читтә?
Мин шуны да белмимме?!

Тынычлыкны яклашуым
Кирәк булмас иде дә,
Кара җанлы ракеталар
Үтермәкче мине дә!

Җимермәкче ракеталар
Авылымны, өемне.
Үтермәкче сеңелемне,
Әниемне, әнемне.

Хәтта җирне үтерергә
Теләүчеләр бар алар.
Телевизор экранында —
Яраланган балалар.

Алар бомба ярчыгыннан
Гарипләнгән, имгәнгән.
Алар карый миңа Ливан,
Чили кебек илләрдән.

Үземнең шул яшьтәшләрем
Тора гел күз алдымда.
Ракеталар эзәрлекли
Аларны һәр адымда.

Ул ракеталар миңа да
Һаман төбәлгән килеш.
Менә шуңа ТЫНЫЧЛЫКНЫ
Мин яклашырга тиеш!

Көрәшче булган бабамнар,
Көрәшче мин үзем дә.
Ә минем кебек малайлар
Меңләгән — Җир йөзендә!

## Кызымның җыры

Кызым бер җыр
Уйлап тапкан,
Шул җыр килә
Төрле яктан:
— Мин әнине яратам!
Мин әтине яратам!

Җырлый кызым
Көн дә безгә,
Җыр яңгырый
Бүлмәбездә:
— Мин калачны яратам!
Мин кояшны яратам!

Кызым җырлый,
Җыры тынмый,
Бөтен дөнья
Җырын тыңлый:
— Мин өемне яратам!
Мин илемне яратам!

## Яңгырда яланөс бик оза-а-ак торганнан соң язылган шигырь

Яңгыр ява.
И-и-их, ява!

Яңгыр ява.
Ә-ә-әх, ява!

Яңгыр ява.
У-у-у, ява!

Яңгыр ява.
Ну-у-у, ява!

Яңгыр ява.
Бр-р-р...
Бер-р-раз гына
Яумый тор-р-р...

## Самолет иллюминаторыннан җиргә карап барганда язылган шигырь

Акрын гына, салмак кына
Аста Идел агып бара.
Ул иңенә баржаларын
Һәм салларын салып бара.

Кара әле, кара, кара:
Бер олы юл китеп бара,
Машиналарын тезгән дә
Казанга ук җитеп бара.

Поездларын төягән дә,
Тимер юл да китеп бара,
Боргалана-боргалана
Елан кебек итеп бара.

Бер сукмак та барган була,
Башкалардан, ахры, күреп.
Бер малайны ияртән дә,
Чаба гына терек-терек...

## Әгәр...

Әгәр бер эш төбәсәң,
Әгәр бик нык теләсәң,
Бик-бик, бик-бик теләсәң,
Әгәр бик нык тырышсаң,
Тырышканда үзеңә
Бик ныгытып булышсаң,
Күп тапкырлар тырышсаң,
Һәм тырышсаң тагы бер,
Теләгеңә бер көнне
Ирешәсең барыбер!

## «Фәнни ачыш»

Идел суы — зәңгәрсу,
Гап-гади бер су инде.

Диңгез суы — тозлы су,
Ул ачы су шул инде.

Идел туңса, шунда ук
Әвереләчәк бозга.

Диңгез туңса әгәр дә,
Әвереләчәк т о з г а!

## Оча торган чәчәк

Чәчәкләрне бик яратам,
Белмим, әллә нигә мин.

Чәчәкләрнең матурларын
Җыеп кайттым өйгә мин.

Хуш ис белән тулды бүлмә!
Ләкин шунда, кем күрсен!..—

Кагынды да очып китте
Чәчәкләремнең берсе!

Әллә бер гөл, чәчәк түгел,
Күбәләк аткан микән?

Юк ла, болыннан күбәләк
Ияреп кайткан икән!

## Күкнең тарту көче

Җирнең тарту көче бар!
Җир бик ярата безне —
Шуңа күрә үзенә
Көчлерәк тарта безне!

Ләкин кеше барыбер
Тартыла өскә таба —
Очарга көч тә таба
Иң биек төшкә таба!

Кешене галәм тарта,
Тартылу һаман арта!

Оча ул йолдызларга!
Димәк, анда эше бар.
Гел күккә омтылабыз —
Күкнең тарту көче бар!

## Мәгъсум Хуҗин

# УРАК ӨСТЕ БОЛЫТЛАРЫ

ПОВЕСТЬ

*Әти истәлегенә*

### I

**1985 ел, сабан туе җитәр көннәрнең берсе, иртәнге як**



Борынгылар Кылык авылын уңайлы урынга хасиятләп утыртканнар: аның өч ягыннан өч елга ага, сыртлар булып ике биек тау сузыла. Авылга исемне дә хезмәткә бәйләп кушканнар.

Кылык кешеләре Мишә буендагы уентыкны аеруча кадерлиләр, элек-электән җыеннар һәм сабан туйлары урыны бу. Уентыкны язгы ташу басса да, су йортларга күтәрелми, кар күп явып, ташу тоташ купкан елларда гына инеш ярларындагы киртәләр күмелеп торгалый торуын. Әмма монысына гына түзәрлек, су ташкыннарының авылга зыянбәла китермәве хәерле.

Туган нигезенә тугры кешеләр Кылык турында начар сүз әйтмиләр һәм әйттермиләр, авылны мактаганда, аңа гына хас үзенчәлеген таба беләләр. Мисалга, авылның өлкәннәреннән берсе Газизҗан карт:

— Безнең Кылык тирәсендә җәйнең аяз иртәсе аерата колачлы була, бу җәһәттән аңа тиң юк,— дип тасвир итә. Моны исә Кылык табигатен күңел биреп, үз итеп күзәткән һәм тыңлаган Газизҗан кебекләр генә тоя ала...

Гаҗәбрәк,— дип үзалдына әйтеп куйды Гаян Сәйфулов һәм, озын күперне чыгуга, «Уазик» машинасын дамба читенә туктатты.

Кылык авылы табигатенең серенә төшенмәкче булып, атап килүе иде аның. Югыйсә, моннан ничәмә тапкырлар узды, ләкин су буендагы сигез гектарлап уентык җирнең әрәм ятуы сәбәбен белми иде әле район авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы. Бу турыда Сәйфулов колхоз җитәкчеләреннән сораштырып карады, тик аңлаешлы төгәл җавап ишетмәде. Район үзәгеннән Кылыкка уникe чакрым, шуңа күрә ул шоферын гаражны караштырырга калдырды. Якын арага төзек машинада җилдереп барып кайту аның үзенә дә ял гына булачак иде.

— Гаҗәбрәк кенә түгел, хәтта гаҗәп!

---

МӘГЪСУМ ХУҖИН *(1930) — прозаик. «Авылым урамнары», «Урманлы үр», «Өч каен ышыгы» һ. б. китаплар авторы. Татарстан АССРның атказанган культура хезмәткәре. Казанда яши.*

Сәйфулов уентыкларны җәяүләп карап чыгасы итте. Башта авылның Сул инеше тамагындагы мәйданга төште.

Ташу калдырган ләм шакмакланып ярыла, кояш кыздырудан гына түгел инде бу, үләннәр баш төртүе дә сиздерә. Атна чамасы терлектән таптатмасаң, монда үлән котырып үсәчәк, кабат килеп караганда, үз күзеңә үзең ышанмассың. Язын су баса торган сугарулы болынның ни тамашага сәләтле икәнен Гаян әйбәт белә. Малай чакта, бер җәй башында, кармак сала-сала, елга буйлап шактый төшкән иде ул. Бер тугайдан икенчесенә кистереп чыкканда, карасуланып торган ләмгә карап хәйран калды, ялан тәпиләрен дым салкыны кымыржыта, ләмгә табан эзләре аермачык булып уела иде. Ә былтыр бу төшләрдә печән бил тиңентен иде, тугайдан тугайга турылаганда, кармак җебен чуалтып бетерде. Быел тап-такыр, печән үсмәячәк икән монда.

Июнь урталарында тагын шушында килде Гаян һәм, күзләрем ялгыш күрә бугай, дип хәйранга калды. Печән былтыргыдан да котырыбрак уңган иде. Һәм, институтта имтихан тапшырганда, сугарулы җирләр турында сорау эләккәч, малай чагындагы үзенең шушы күзәтүен дә мисалга китерде.

Кылыктагы уентыкларны беренче тапкыр күргәч тә Сәйфулов шушы вакыйганы исенә төшерде.

Әрәм ята җирләр, шушыннан акча ясау, байлыкны арттыру берәүнең дә уена кермәгән, күрәсең. Юк инде, агайнеләр, Сәйфулов абыегыз мондый хуҗасызлыкка юл куймас, җаен-әмәлен табар, табышны тәгаен санарга да үзе килер. Иренмәс. Бәлки, быел ук та берәр нәрсә чәчеп булыр, әйтик, шалкан чәчү вакыты узмаган, июнь уртасы. Ат кузгалаклары тырпаешып утырмас монда быел, үги ана яфраклары да каплап алмас. Боерган булса. Юк, боеруын инде үзебез боерырбыз. Ялвармыйбыз.

— Кырк-кырк!

Ямьсез тавыш Сәйфуловны сискәндерде. Инеш тамагының вак ташлы читендә иләмсез зур карга, Гаянга башын борып, горур гына басып тора иде. Сәйфулов җирдән ыргытырга әйбер алгандай итеп иелде.

— Карр-р-р! — дип зәһәрен чәчте кара карга һәм, ава-түнә адымлагач, кушаяклап елгага таба сикергәләде дә очып китте. Аргы ярдагы юан талның очына менеп кунаклагач, тагын да катырак каркылдады.

Гаян кирегә борылды һәм тагын сискәнеп куйды. Ничек сизмичә калгандыр, артында ук ала бозау аның чалбар балагына үрелеп маташа иде. Бозау сикереп читкә тайпылды да, Сәйфуловтан ризык өмет иткәндәй, тагын башын сузды.

— Бозау арканлау өчен сөрмичә тоталар икән моны,— диде Сәйфулов, нәтиҗә ясап.— Уентык эченә табан үлән әйбәт шул. Ничәү сез, мүкләкләр? Алтау гына. Азрак. Теге яктагыларыгызны санап карыйк. Крестьян агаең үз җаен каерырга гына тора, бармагы гомергә үзенә кәкре. Соңгы елларда исә крестьянны узындырып җибәрдек. Абзары тулы терлек, кош-корты исәпсез. Колхозда эшләргә вакыты да калмый аның. Үз хуҗалыгында аруы ашкан кешедән ничек житештерүчән хезмәт көтмәк кирәк? Бар, әлбәттә, арада алдынгыларыбыз да, тырыш колхозчыларыбыз да бар. Шулар тарта авыл хуҗалыгын. Йөкләп чәлдермәсәләр дә, кыеграк ятканны култык астына кыстырырга чамалаучылар күбәйде.

Гаян Сәйфулов бу мәсьәләләр турында еш уйлана иде. Быел февральдә идарә начальнигы булып килгәч, яңа җирдәге кимчелекләр аңа ачыграк күренде. Шулардан бер фикере ныгый барды:

— Крестьян үз хуҗалыгына ябышып ята, хәтта житәкчеләр арасында да очрый андыйлар. Соң, шулай булмаса, меңләгән күз алдында сигез-тугыз гектарлап җир буш ятмас иде. Бу инде, сөргәндә кыйпыл-

чыкланып, чи калган урын гына түгел. Монысы, әйтәм ич, күз алдында, ә олы юллардан еракта, басу түрләрендә файдасыз яткан җирләр бик күп җыйналадыр.— Сәйфулов, башына бүтән уй килеп, сүзеннән тукталып торды.— Баш агрономны селкетергә кирәк, бер атнада барлык колхоз-совхозларның җирен тикшертсен. Бөтен районда күпмегә җыела икән мондый уентык-муентыклар, белик без моны. Чыгыш ясаганда, иң саллы мисал булыр бу.

Институтта Гаян Сәйфулов имтиханнарга үзалдына сөйләнеп әзерләнергә өйрәнгән иде. Болай эшләү аңа фәннәрне төплерәк үзләштерергә ярдәм итте. Шушы гадәтен совхозга агроном булып баргач та, аннары совхоз директоры булып күтәрелгәч тә ташламады. Хәзер, идарә начальнигы итеп күчерелгәч, әйтәсе фикерен кат-кат уйлау кирәклеген тагын да ныграк аңлады. Уентык карап йөргәндә үзалдына сөйләнүе аның урып-җыюга хәзерлек тикшереләчәк киңәшмәдә сөйләргә тиешле докладын эзгә салуы иде.

— Санап карыйк,— диде ул, машинасы турыннан күтәрелеп,— бу якта ничә бозау арканлаганнарын санап карыйк.

Әмма уң уентыкта бозаулар юк һәм монысында үләннәр шәбәебрәк үскән иде. Уентыкка менмәкче казларны ян-ягына пар ак тасмалар тегелгән спорт чалбарлы кыз бала юкә пумала белән елгага таба кире куалап йөри иде.

— И-и, җыклар, монда менмәскә куштым ла мин сезгә, ә-ә-нә, болынга чыгыгыз,— дип аңлатырга тырышты кыз казларга.— Тагын бер атнадан гына ярый әле сезгә монда менәргә, дидем ич. Тиргәтмәгез миннән, ату белермен үзегезне нишләтергә, ямегез.

— Нигә хәзер ярамый? — дип сорады Сәйфулов. Ул кыз янына якынлашып килә һәм аның сүзләрен ишетеп алган иде.

— Ярамаганга ярамый!

Кыз Гаянны күреп торган, шуңа күрә таныш түгел кешенең эндәшүеннән куркып төшмәде.

— Ай-яй, усал икәнсең. Пумалаң белән мине дә куып җибәрә күрмә, яме,— дип шаяртты Сәйфулов.

— Пумаласыз да куармын.— Кыз, җитди күренергә тырышып, юка кашларын җыерып алды.— Әнә бу мәйданны таптасагыз.

— Мин... мин яр читләтеп кенә килдем бит,— дип акланып кулларын җәйде Сәйфулов, кызның олылар кушкан эшне башкаруын абайлап алды. Әмма башкалар боерганны үзгәртергә дәрәҗәсеннән килүен бала алдында сиздертәсе итте: — Мин кусаң да китмим.

— Китәрсез! — диде кыз сузыбрак. Хакимият мәсьәләсендә ул үзен идарә начальнигыннан өстенрәк тота кебек тоелды.— Нибуч! Казлар да кертмибез ич монда, чиратлашып саклыйбыз. Быел сабан туе монда була. Былтыр Сул Тамакта булган иде. Белдегезме инде? Каздан таптатмаганны... сездән... Олы кеше үзе үк таптамаска тиеш.

— Алаймыни әле ул, син каравыл торасыңмыни,— дип, кыз катынарак килеп чүгәләде Сәйфулов.

— Шулай шул.

— Исемең ничек соң синең?

— Җәүһәрия.

— Сезнең дә казлар бармы соң монда? Аларын кумыйсыңдыр әле,— дип астыртын гына әйтте Сәйфулов.— Юктыр үзегезнекеләр.

— Нишләп булмасын?! Әле генә куып төшердем ич әнә. Бер ата, ике ана, унтугыз бәбкә. Мин аларга камыр алып төшеп ашата идем. Шуңа ияләнеп калдылар да үскәч тә яныма кабаланып киләләр. Үрдәкләребез дә ике оя безнең. Ә-әнә, инеш төбен актаралар. Аларына су булса — шул җиткән, кич якта өйгә алып кайта башласам, судан чыгара алмыйча аптырап бетәм.

Сәйфулов Җәүһәрия күрсәткән үрдәкләрне саный алмады, алар ерактарак та һәм бәбкәләр арлы-бирле йөзеп буталышалар иде. Ишле

оялар, ишле, санамыйча да чамалап була. Гаян, кыз тирәсеннән китмичә, азык көтеп торучы казларга карады. Көр үсә каз бәбкәләре. Күкрәген киереп, муенын арткарак каерып баскан ата каз бер генә тапкыр горур итеп каңгылдады, аннары, урыныннан кузгалмыйча гына, башын җиргә уелдырып ысылдады.

— Ә кем кызы соң син?

— Әти белән әни кызы, бабай белән әби кызы,— диде Җәүһәрия, Сәйфуловның баласытып сөйләшүен ошатып житкерми иде ул.

Кыз, күпер төбеннән мәйданга менеп килүче бер оя казны йөгереп барып суга куып төшергәч, Гаян янына әйләнеп килде.

— Ә сез кем? Теге машинаның шоферымы?

— Минме?

— Сез, дим ич инде.

— Идарә начальнигы мин.

— Ә-ә, белдем инде алайса! Сәйфулов дигән кеше. Аңлашылмый торган кеше.

— Ничек? — Сәйфулов кулындагы вак ташларны суга чәчеп жибәрде.

— Әти әйткән иде әнигә, аңлашылмый торган кеше, юк, адәм, диде, идарәнең яңа начальнигы, диде, аңлый алмыйм әлегә, дигән иде.

— Кемнәр соң синең әти-әниең?

— Әти — председатель, әни китапханәдә эшли.

— Кайсы председатель, авыл советындамы?

— Юк, колхоз председателе минем әти.— Сәйфулов ни әйтергә белмичә торган арада Җәүһәрия тезеп тә китте: — Әти өйдә хәзер, энемне дә карый, кичен яшелчәләргә сибәргә инештән су да ташый, өлгерсәм, карлыганнарны күтәртермен, диде. И-и, өйдә эш бетәме соң? Әни районга семинарга киткән көнне мәйданны саклау сәгатьләре безгә туры килде бит менә. Тагын егерме... егерме биш минуттан безнең чират уза инде,— дип масаеп алды Җәүһәрия, кулындагы сәгатькә карап.— Энемне уйнатырга үзем урамга алып чыгам аннары. Өйдә бабай да бар безнең, ул авырып тора шул, энем аның белән генә дә калгалый иде. Бабай тиз савыга ла минем, аның сырхавының сәбәбе бәләкәй. Аннары без аның белән бөтен йортны карап торабыз. Рәхәтләнеп эшләсеннәр әти белән әни үз эшләрендә. Әти өйдә, дим ич, барыгыз безгә. Әнә безнең өй. Сул Тамак урамыннан менгәч, авылның урта төшендә зу-ур тупыл күрәсезме, безнең капка төбендәге тупыл ул.

Сәйфулов, торып басып, тез асларын сыпырды. Ул кыска жиңле соргылт күлмәктән иде, беләкләре су жиле бәреп кымыржыды, аларны алмаш-тилмәш ышкыды.

— Бүгенгә бармыйм сезгә,— диде Гаян һәм, машинасына таба бераз жир киткәч борылып, кулын күтәрде: — Исән булып тор, Җәүһәрия.

— Районнан килгән начальниклар безнең әтине күрмичә китмиләр иде ич.

Күр син бу кызыйны, сүзгә беткән, ни әйтсәң дә чәтелдәтеп жавап кайтара.

— Мин китәм менә.

— Китсәгез соң. Ялынмыйм.

Җәүһәриянең үз ише белән сөйләшкәндәй тартынмавы сәбәбе председатель кызы булып иркәләнүдән түгел, ә аның ачык күңелле булуыннан икәнлеген аңлады Гаян һәм кызга, үз итәргә тырышып, тагын кул изәде.

Машинасын кабызуга ук кузгатты да, кырт борылып, күпер чыкканда ярамаса да, тизлекне алыштырып, килгән юлыннан элдертте. Әмма ерак китә алмады, арткы уң тәгәрмәченең сөйрәлгән кебек баруын гәүдәсе белән тойды. Моторны сүндермичә генә артка чыгып карады.

— Атасына сәлам әйткере! — дип сүгенде Сәйфулов.— Тәгәрмәч алыштырып ят инде хәзер, начальник иптәш. Ачу ташып кайнаганда! Бүтән чараң да юк. Авылда булсаң, берәр шофердан алыштыртыр идең дә, хәзер үзеңә кала, агайне.

Ул, чиста күлмәген салып, алгы утыргычка куйды, арткы утыргычка ябылган калын келәм өстеннән кара сатин халат алып киде.

— Чепуха! Тәгәрмәч алыштырмаган кеше түгел без. Кирәк икән, моторының эченә кереп актарынабыз.

Кылыкка килергә чыгар алдыннан Гаян Сәйфулов колхозга шалтыраткан иде. Председатель Әмир Хәкимовны туры китерә алмады. Өенә кайтып китте, диделәр, ә председательнең өендә телефон юк икән. Хәйләкәр күренә Хәкимов дигән егеткәй, дип уйлаган иде Гаян, өенә телефон керттермәгән, карлыган агачларын күтәрткәндә, бүлдермәсеннәр ягъни. Әмир Хәкимовка биргән бәясе әлегә шушы иде аның, председатель исә аның үзенә, әнә, кәттәрәк бәя тапкан: аңлашылмый торган адәм. Ә бит шулай кирәк, иптәш Хәкимов, эчендәге тышыннан күренеп тормасын, ягъни мәсәлән.

— Гади колхозчыны тыясы урында,— дип район киңәшмәсендә ясаячак докладына әзерләнүен дәвам итте идарә начальнигы,— кайбер житәкчеләр үз хуҗалыкларын баетуда аларга үрнәк күрсәтәләр. Әйтергә кирәк, җитәкчеләрнең мондый үрнәкләре кайчакта чикне-чаманы сикереп кенә үтә. Нәтиҗәдә посттагы агайларыбыз үз хуҗалыкларында камыр-башак болгатудан, карлыган яфрагыннан тelә чүпләүдән арына алмыйлар. Мисаллар кирәкме? Рәхим итегез. Кылык колхозы председателе хөрмәтле Әмир иптәш Хәкимов көннең күп вакытын үз хуҗалыгында әвәрә килеп уздыра. Телефоннан шалтыратасың, өендә, диләр, колхозына барып чыксаң, иптәш Хәкимов үзенең җимеш бакчасында кайнаша.— Сәйфулов яңа куйган тәгәрмәчкә үкчәсе белән тибеп карады, машина җиңел генә чайкалды.— Ярап бетмәс, бала сүзенә ышанып, район киңәшмәсендә Хәкимовка гаеп ташлау ярамас. Колхозы әйбәтләрдән санала. Соң, Җәүһәрия, эти карлыган бакчасында, диде ләбаса, моны мин үз күзләрем белән күрә аламмы? Алам!

Гаян «Уазик»ны авылга борды, колхоз председателенең йортын белә ул хәзер, зу-ур тупыл моннан ук күренеп тора.

Күпергә җиткәнче, уентыкларны тагын күздән кичерде Сәйфулов. Шәп җирләр, әйтәсе дә юк. Яшелчә үстерү өчен бигрәк тә. Күп табыш алып булачак бу җирләрдән. Әйе, уңдырышлы уентыкларны сабан туе мәйданы һәм бозау арканлау урыны итеп кенә карап та була. Җәүһәрия, колхоз председателе кызы, мине, аңлашылмый торган кеше, дип атаган кеше... адәм кызы, шулай бәяли. Бала акылы, әтисе әйткәнне кабатлый. Сабан туе мәйданын каз-үрдәктән саклаучы кыз кадим карашлы әтисе сүзләрен кабатлый, әлбәттә. Мине дә куып җибәрмәкче, әй. Районның җир хуҗасын, мине...

Идарә начальнигы, авыл белән күперне тоташтырган дамба беткән төштә уентык өсләтеп, таллар рәтеннән Сул Тамак урамына таба салынган бормалы юлга керде. Анда машиналар йөрүдән ике ызан сизелерлек тирәнәйгән иде.

— Карачы,— дип тагын үзалдына әйтте Гаян,— бу пар ызаннар арасы каш сыман икән ич! Дамба бүлгән уентык ике күз икән дә ярлар өстеннән кыйгач кашлар сузылган икән. Әкәмәт... Авылның күзләре...

Сул Тамак урамының зур тупыллы йортын узарак туктады Сәйфулов, машинасын капка турына ук куярга иде исәбе башта, әмма астына җәйпәк ак ташлар кыстырылган юан бүрәнәдә утыручы картны күргәч, каршыдагы бакча киртәсе буена елышты. Машинасының ишеген ачык калдырып, карт янына килде.

— Исәнмесез!

— Шөкер. Иминлек әлегә.

— Сез Әмир Хәкимовның әтиседер, мөгаен.
— Газизҗан карт.
— Мин идарә начальнигы Гаян Сәйфулов булам.
— Беләм. Күргәнем бар сине.
— Сезгә турылап килүем.
— Монда туктагач, шулай, әлбәттә. Тик мин түргә чакырганчы, машинаңның ишеген ябып куй.
— Торсын ачык! Көн бик тә бөркү булыр. Кабинага да сулыш алу кирәк ләбаса.
— Ишек — ачылыр өчен генә түгел,ябу өчен дә.
— Торсын,— дип артка кул селтәде Сәйфулов.— Зыян юк.
— Кош-корт кереп кунакламагае.
— Тавыкның мие машина эченә үк алып керерлек эшләмәс.
— Нишләп хәзерге тавыкның мие эшләмәсен икән? Инкубаторда чыккан чебешкә техника тумыштан ук таныш. Бик теләсә, руленә кунып, машинаңны да җилдертер замана чебеше.— Газизҗан, каш астыннан гына карап, Сәйфуловны бөтен буена сөзеп чыкты.— Утыр, монда тупыл күләгәсе, җиләс.

Төксе йөз белән каршылавын яшерми Газизҗан. Ләкин Сәйфулов җебеп төшә торганнардан түгел, үзенең хаклыгына аермачык инанган чакта олысына-яшенә турыдан бәрергә тарсынмый. Шулай да бу очракта картның кәефен бөтенләй үк бозасы итмәде. Колхоз председателенең әтисенә ярау нияте юк иде аның үендә, Җәүһәрия сүзләре исенә төште дә сырхау Газизҗан белән әңгәмәне үзенчә төпле юнәлешкә җибәрергә булды. Бүрәнәнең карт күрсәткән төшен, утырганчы, учы белән сыпырды. Ярылмый торган әйләнмә карама агачы икән шул капка төбе бүрәнәсе; дип искәрде, бүтәнгә ярамаганга күрә монда сузып салганнар. Югыйсә, хуҗалыкта башка кирәген тапкан булырлар иде, мал кадерен белүче агай күренә Газизҗан карт, председатель Әмир Хәкимовның әтисе.
— Кәефегез ничек соң, Газизҗан бабай? — дип сүзне яңартты Гаян.

Картның ашыгып җавап кайтармасын абайлап, читләрен кара төкләр басып тарайткан маңгаен учлары белән алмаш-тилмәш сыпырды. Маңгаена һәм хәтта күз төпләренә төкләр үсеп аптырата аны. Эскәк белән йолкып та карый, ләкин барыбер бетерә алмый. Студент чагында университетта астрономлыкка укучы берәүнең бөтен йөзен кырып йөрүе турында ишеткәне бар иде аның. Әллә Гаянның да йөзе төккә төренүенә — кыргый зат сыман! — ишарәләп сөйләделәр инде бу мәзәкне. Шуннан соң ул да маңгаен кырмакчы булган иде. Нидер тыеп калды аны шушы юләр уеннан, шул чакта бөтен йөзен бер тапкыр кырса, йөрер иде хәзер адәм гыйбрәте булып. Житәкче эшкә күтәрелү түгел, кеше күзенә күренергә дә хурланыр иде. Әле кырып гадәтләндермәгән килеш тә төкләрне йолкып бетерә алмыйча алҗый.

Газизҗан кымшанды, Сәйфуловның соравына җавап кайтарырга җыена ахрысы. Түгел икән. Карт, ак күлмәгенең изүеннән чеметеп тотып, күкрәген җилләтте. Тирән галошларын ышкып кына салды да аякларын чирәмгә сузды. Шуннан соң гына:
— Шөкер, дидем ләбаса,— дип Гаянның соравына төксе җавабын кайтарды.
— Авырып тора, дип ишеткән идем.
— Җәүһәрия сүзе.
— Әйе. Аны мин күпер төбендәге уентыкта очраткан идем.
— Анысын кайтып керүгә үк миңа ирештерде. Әле, энесен житәкләп, уйнарга чыгып йөгерде. Килен китап укырга өйрәтә торган семинардан баш тубаллапдыргыч киңәшләр төяп кайтырга тиеш. Энеләренә булышасы иттеләр бугай, киңәшмәдән алган йөге ялгызына авырга килмәгәе, дип. Каршыларга киткәннәрдер. Тик энеләре төшләр үзмыйча кайтмас.

— Җәүһәрия башлы бала күренә, андый ярдәмгә ашыгуы бик тә мөмкин,— дип көлемсерәде Гаян.— Тик ул сезнең авыруга гына дәва-шифа таба алмый икән. Бабайның сырхавы әби кайтуга ук бетәчәк, ди. Сәер шунысы...

— Син, Сәйфулов иптәш, кеше җанын аңлый торган начальникмы соң? Әллә түгелме?

Газизҗан, Гаянның күзләренә текәлеп, шактый озак карап торды. Берсен-берсе өйрәнеп алдылар алар. Элгәре Сәйфулов карашын картның йөзе буйлап йөртә башлады. Төскә-биткә чибәрләр рәтенә бастырып булмый Газизҗанны, җәенке курнос борын, иреннәренең тупас калынлыгын сакал-мыегы да яшерә алмый, ә битенең тиресе шома, өлгереп житкән егетнекедәй, ялтырап тора. Юк, беренче боз кебек шома. Боз кебек салкындыр. Бу абзыкайның йөзен бүгенге чиллә дә җылыта алмыйдыр, дип уйлады Сәйфулов. Бетмәс салкынлык бар йөзендә, тимер салкынлыгы, диимме, салкынлык кына да түгел, ә ниндидер... ныклык, тимер катылыгы. Усал кешесеңдер син, Газизҗан карт, кем әйтмешли, усаллыгың йөзеңә чыккан. Әллә усал гына да түгел, ә явыз бәндәме син, Газизҗан иптәш? Нечкә күңеллелек сиңа бөтенләй ят сыйфатмы? Кеше җанын аңлау турында сөйләнәсең шулай да...

— Нигә җавап кайтармыйсың? Мин синнән кыеш-мыешсыз сорыйм лабаса: кеше җанын аңлыйсыңмы син? Әллә, ит-сөт һәм бүтәнне күбрәк булдыру өчен, мал-туарны кешедән алгарак чыгарасыңмы? — дип, мәйданда билгә сөлге салырга җыенган кебек итеп кулларын түгәрәкләп алга сузды Газизҗан.— Әйт. Юкса, синең белән сүз боткасы куертырга ният итмим.

— Кинәт чоңгылга чумасың, Газизҗан бабай! Чирканчык алу кирәктер элгәре,— дип башын чайкады Сәйфулов.— Дусларча әңгәмә кору хәерлерәк.

— Шулай да, үзең әйтмәгәч, соравыма җавапны табарга тиеш булам. Кешеләр белән сөйләшүең гел дусларча булса, бик шәп тә канә. Белмим шул, алай ук микән?!

— Төрлечә булгалый инде, эшем җаваплы, әрләгән чаклар да бар, мине дә ачуланалар.

Капка астыннан ап-ак тавык чыкты. Кабарынып, түшенә кунган тузанны какты да, көдерәеп кенә атлап, Газизҗан янына узды һәм аның янәшәсенә менеп кунаклады. Карт аны йомшак кына сыйпады, ак тавык, шушы иркәләү өчен рәхмәт әйткәндәй, Газизҗанның кул аркасына томшыгын тидереп алды һәм, җиргә сикереп төште дә, шулай ук эре кыяфәт белән читкә китеп барды.

— Кулга ияләшкән икән ич бу тавык. Сәер.

— Иркә җан. Һәм чытлык та.— Газизҗан кулларын тез башларына куйды.— Әйе, сәер хәлләр бар дөньяда. Беренче карашка. Ә төптән уйласаң, сәер дигәнебез дә гап-гади аңлаешлы нәрсә икән. Менә син минем авыруның карчык кайтуга ук бетәсен ишеткәнсең. Ниткән сәер сырхау икән, дисең инде син.— Газизҗан башын салмак кына чайкады да: — Сәерлек юк монда,— дип өздереп әйтте.— Кеше күңелен аңлый белсәң әгәр.

— Бәлки, аңлап җиткермимдер, ә...

— Бәлки, бу киресенә беткән картка ачылып бетәсем килми, шуңа күрә аңлавымны сиздермәскә тырышам, дисеңме?

— Бәлки,— дип кырт кисте Сәйфулов та.

— Бәлки генә түгел, чыны шулай. Ә беләсең килсә,— дип Гаянга таба кинәт борылды карт,— карчыкны сагынудан авыруга сабышам мин! Әмма замана карчыкларының исе киткән ди мондый сәерлеккә! Син сагынудан үлеп барасың, ә ул әнә гүләнҗәдә! Кичә иртүк киткән иде күрше авылга. Минем анда ике сеңлем кияүдә. Шулар янына. Кайтмый һаман.

— Мине төксе каршылавыгызның сәбәбе менә нәрсәдә икән...

— Әйтәм ич, сагынуыңнан үл хет! Һәм авызыңа су салучы да юк.

— О-о, арттырып җибәрдегез, Газизҗан бабай!

— Нигә? Шулай түгелме әллә? Малайның колхоз эшеннән башы чыкмый, килен китап укырга өйрәнә, Җәүһәриясе энесе Җиһангирны иртәгә шыпырт кына чыгып шылды, карчык кунактан кунакка чаба. Икесе дә болын хәтле кара-каршы өй вә каралты-кура Газизҗанга гына кирәк. Һе, тавык белән сөйләшергә дә өйрәнерсең! Өйрәнмичә! Синең дә рәтле сүзең юк, ичмасам.

Сәйфуловның ни йомыш белән килүен онытырды Газизҗан карт, әңгәмәне үзе теләгәнчә алып барды, монда үзенең хуҗа икәнлеген әле капканы кергәнче үк сиздерде.

Гаян учлары белән шома караманы сыпыргалады. Китеп барырга кыенсынды ул, чөнки болай эшләү ким дигәндә дорфалык булыр иде, ә Газизҗан моны гафу итмәячәк. Килүе максатын турыдан-туры әйтергә дә кыюлыгы җитмәде. Соң, Сәйфуловның председатель Әмир Хәкимовның хуҗалыгын күрергә теләве тикшерү, хәтта тентүгә керү кебегрәк булып чыга бит, аның исә моңа хокукы юк. Дөрес, эш дәрәҗәсе зур, авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы, партия райкомы бюросы члены ул, әмма тентүгә прокурор гына вәкаләт бирә, әле дә шунысы исенә вакытында төште.

— Улыгызны өйдә дигәннәр иде бит,— диде начальник, бүтән сүз таба алмыйча.

— Өйдә! Чыгып качканына биш былтыр. Карлыганнар җиргә иелеп төшкән, күтәртергә кирәк. Хәзер гадәткә кереп бара бит: бер эшне башлыйбыз да, аны ташлап, икенчесенә тотынабыз и тәк дәли. Ярты-йорты эшләүгә күнектек. Минем малай да шул якка каера. Әнә ич, бер төбен дә күтәртеп бетермәгән.

Картның сүзләре үз хуҗалыгын алга чыгару булып тоелды Сәйфуловка. Әмма ул эш яшеннән күптән чыккан Газизҗанны үгетләп торуны кирәк санамады. Әйе шул, басу юлына үз кирәгендә генә чыгучы бабайдан хәзер күмәк хуҗалыкка ни файда, шуңа күрә авыл агаеның тырпайган сырт йоннарын уңайга сыпырасы итте Сәйфулов.

— Начар председатель исәпләнми улыгыз, йорт-җир карарга вакыты җитмидер.

— Һе, начар эшләсен тагын! Ни хакы бар аның килделе-киттеле эшләргә?! Һе, җитмәгән ди сиңа вакыты! Кая киткән ди аның вакыты? Үзең теләп җәһәннәмгә олактырсаң, әлбит, булмас вакыт, булмас. Тукып тормасаң, аркылыны буйга да алып салмас иде синең председателең!

— Минем председатель...

— Кемнеке соң?

— Сез, барлык колхозчыларыгыз, сайлап куйган бит аны башлык итеп.

— Районнан кушмасалар, без башка берәүне сайлаган булыр идек, бәлки. Әйтик, этисе сүзен тыңлый торган егетне. Бәлки...— Газизҗан иреннәрен кыса төшеп тукталып калды. Тешләре шыгырдаганы ишетелде.— Нигә мине председатель итеп калдырмаска тиешләр иде ди әле?!.

Сәйфулов, көтелмәгән сүзләрдән сискәнеп, урыныннан торды, картка текәлде. Шаяртмаган сыман иде Газизҗан, идарә начальнигына серен чишүе дә түгел иде аның бу теләге... бу юләр хыялы. Әйе, Газизҗан бабай, синең җанны аңлавы ай-һай кыендыр, карчыгың да шуңа күрә, синең бәйләнүләреңнән котылып тору өчен, ягъни ялгызыңны калдырып, кунакка бару сылтавы белән чыгып сызадыр яныңнан.

Гаянга Газизҗан аның ни-нәрсә аңлавын сизеп торадыр кебек тоелды, әңгәмәдә дилбегәнең карт кулында икәнлеге шиксез иде. Әмма Сәйфулов та сүзен аста калдырмас өчен көчен кызгана торганнардан түгел. Бигрәк тә соңгы вакытта үз сүзен сүз итәргә гадәтләнде ул. Газизҗанның тел төбенә нинди фикер яшеренүен аңлауны кирәк сана-

мады. Йомшак сөйләшүне тупаслыкка кырт әйләндерә алу гадәте өстен чыкты.

— Хәзерге заманда председатель булуны уенга санызсыз икән. Карт инде сез колхозга житәкчелек итү өчен, бик карт.

Газизҗан эндәшмәде, аның күзләрендә астыртын елмаю чагылды, ачуы кубуы күренмәде. Сәйфулов, җирне сытарга теләгәндәй каты басып, карама бүрәнә буенда йөренде. Ләкин карт мондый түрәлек йөрешенә гамьсез иде. Начальникның горурлыгын каты чеметте авыл агаеның бу битараф кыяфәте.

— Җитәкче булу өчен белем кирәк хәзерге заманда,— дип ачуын тыймады Сәйфулов.— Һаман председатель буласыгыз килә, ә. Малаегыз...

— Улым...

— Хуҗа булуы гына җитмиме? Соң, сезнең кайчандыр алган белемегез дә коелып беткән лабаса. Әле укыган булсагыз. Карт инде сез. Тормыш һәрчак яшьләргә йөз тоткан. Картайгансыз, Газизҗан бабай.

— Яшь түгел. Беләмен. Еш кабатламасаң да. Сиксәннән өстә. Туксанга өмет бар. Йөзенә дә.

— Ә йөрәк яшь, ә? Җитәкчелеккә менәргә исәп. Юк инде, сездән җитәкче чыга алмый. Хәзерге заманга исә, социалистик авыл хуҗалыгына ягъни, түрәләр кирәкми.— Сәйфулов, башын селкеп, йорт-җиргә ишарәләде.— Сез шул, менә, үз байлыгыгызны ишәйтегез. Көчегез җитеп.

Карт куллары белән этенеп торып басты. Җәһәт иде аның хәрәкәте.

— Һәм ишәйтәбез! Көч җитә. Шөкер.

Газизҗан кечкенә капка келәсенә басты да икенче кулының бармак очлары белән генә уртадагы түгәрәк бизәккә төртте. Бәләкәй капка йомшак кына ачылган уңайга теге яктагы сихри... серле дөнья киңәя барды. Сәйфуловның күзләре челт-челт йомылгалап ачылды, тик эчке яктагы бер нәрсәне дә ап-аермачык күреп җиткерә алмады. Чынлап торып күзе уйный иде аның.

— Уз... ишегалдына,— дип кулын сузып күрсәтте Газизҗан. Баганаы төргән яшел тактага таянгач, учына кытыршы нәрсә тиде, һәм буяу төерчеген җәйпәк тырнагы очы белән куптарды.— Кер,— дип кабатлады ул, кинәт сүзсез калган Сәйфуловка баш кагып.— Сизеп торам лабаса, председатель йортын күрәсең бик тә килә. Йөзеңә ат башыдай хәрефләр белән язылган. Председательнең байлыгын тикшерәсең килә. Машинаңны пыранлатып безгә турылавың шуңа иң.

Начальникка морадын яшерергә урын калдырмады хуҗа карт.

— Минем тентү ниятем юк.— Сәйфулов бу кискен сүзләр белән, акланудан бигрәк, үзенең кызыксынуын урынлы санавын исбатларга тырышты.

— Ха!— диде Газизҗан, башын мыскыллы тайчандырып. Моңарчы аның картларча тигез ишетелгән тавышы шушы ярым-йорты сүздә генә тупас калынаеп алды.— Кем тентүгә кертсен ди сине? Прокурордан рөхсәтең юк лабаса. Ә прокурор андый рөхсәт бирмәячәк. Ни өченме? Чөнки минем байлыгым хәләл икәнлеген белә ул. Байлыгым инде, агайниш, чынлап та бар!

Сәйфуловның өнен алды белемсез авыл карты. Газизҗанга карап сүзсез тора бирде Гаян, картның карашын тота алмады, ә хуҗа, читкә караса да, начальникны үтәли күрәдер кебек иде.

— Кер! Юлыңа арата салмаган лабаса. Тукталып калырга. Теләгеңне бик тә чирак хәл кылмакчы идең, әй. Газизҗанның акылын тайдырмакчы идең хәтта ки.

— Астыртын кеше икәнсез, Газизҗан бабай.

— Минме?! Менә син, ә! Әллә татарча аңламыйсыңмы соң син? Астыртын адәм — ул син. Колхоз башлыгының байлыгын син астыртын гына тикшермәкче идең бит, астыртын эш итмәкче идең, әлбит. Мин, агайниш, гомерем буена астыртын булмадым. Һәм синең белән саф-

сата сатканда да. Әйтәм ич, карчыгымның кунактан кайтуын сагынып көтәм мин. Аңладыңмы? Сагынып!

— Аңладым.

— Аңладың пычагым! Бүтәннәр күңелен күрә белгән кешенең чырае якты була аның. Ә синең йөзеңдә явызлык дүрт япьле сәнәк белән кыеш-мыеш итеп язылган килеш һаман юылмыйча тора.

— Мин ачулана да алам бит.

— Куркытты!..

— Һәм сез уйлаганча мескеннәрдән дә түгелмен.

— Өректем!..— Газизҗан, куган кебек итеп, кулы белән ишарәләде.— Җитте. Озакка китте сүз боткасы. Син, Сәйфулов, минем белән кирәкле әңгәмә кыласың килсә, үзеңне алланың кашка тәкәсенә тиңләмә. Һәм мине бер үк сүзләрне кабатлаттырмакчы булма. Югыйсә, минем кабатларга теләмәвем бар бит. Кер, дидемме?

— Соң бит...— дип мәгънәсез аклана башлады Сәйфулов. Аяклары алга да атламый, кире борылып кул селтәргә дә көче җитми, тәмам бөтереп алган иде аны сиксәннән узган егәрсез дигән карт, әйтерсең, бармакларына җеп асып, курчак итеп уйната иде Газизҗанның. Һәм ишегалдына атлатты ул авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигын.

— Шулай булгач, нигә тераләп каттың? Тентү тагын син җибәргән явыздан. Тентү дигәнең әбсәлүт орына алмый миңа. Заманында бер тапкыр тентеп карадылар, бик житкәнгә саналыр шунысы да, агайниш.

Ишегалды зур һәм чирәмле икән, аркылы-торкылы ташланган әйбер-сәйбер юк монда. Өйалды баскычыннан урам капкасына, лапаска һәм каршыдагы алма бакчасы эчендәге коега таба таштан җәелгән сукмакларны еш себереп торалардыр хуҗалар, тыгыз тезелгән ташлар чиста, юылган кебек ак.

Лапас авызындагы оясы яныннан Сарбай торып басты, сузылып киерелде, Сәйфуловны куркытып балагына кагылып үтте дә йорт нигезенә гамьсез генә тераләп ятты. Чит кешеләр кереп йөрүенә күнеккән, күрәсең, өрмәде. Хәтта ырламады да дәү эт. Юаш булса да байлык сакларга асрыйлардыр, дип уйлады начальник.

— Тими ул,— диде Газизҗан, өйалды ишеген ачып җибәреп.— Ачуын китереп котыртмасаң һәм ихатадагы әйбергә кагылмасаң.

Сәйфулов бүрәнәдән һәм нарат тактадан салынган абзар-курага карап тора иде. Сарысы да уңмаган әле аларның.

— Былтыр гына яңарттык,— диде хуҗа, начальникның кызыксынуын аңлап.— Бик искергәннәр иде, җылы абзарның аскы нигәләре череп беткән булган, утынга да ярамады. Авылдашлар, Газизҗан карт абзаркурасын музей әйберсе итмәкче икән, дип мәзәк чыгарганнар иде. Тотынырга нигәдер кул җитми иде шул. Башлагач, тиз тоттык тагын, ике малай белән өчәүләп бер җәйдә тергезеп бетердек. Акча булмаудан түгел, акчабыз җитәрлек. Бер йорттан алты җанның дүртесенә акча килеп тора бит. Әле,— Газизҗан Гаянны, өйгә керергә ишарәләп, алга уздырды,— бер айда минем пенсияне, икенчесендә карчыкның пенсия акчасын Тынычлык фонды кесәсенә салып барабыз. Нигә алмашлапмы? Карчыкның да өлешсез каласы килми чөнки. Шулай. Монысы бердән. Икенчедән ки, сугыш булмасын, дибез. Җиңүнең кырык еллыгын гөрләтеп бәйрәм иттек. Нигә зурдан куптыкмы? Дөньяны таң калдырырга Ватаныбыз лаеклы чөнки. Димәк, мин дә лаеклы моңа, Гаян туганкай. Алай да бәйрәм сугыш бәйрәме булды, хезмәт бәйрәме түгел, сабан туе түгел ягъни. Сугыш... Һай, иптәшкәй, бик саллы тондырды соңгы сугыш безгә! Афәттән соң кырык ел узса да, югалту-зыяннарны хәзергәчә санап бетерә алмыйм. Мин санап бетерә алмыйм! Аңлыйсыңмы син шуны?!

Газизҗанның бу хәбәрләре Гаянны тагын аптыратты. Алар болдырда аяк киемнәрен салдылар.

— Аңлыйм,— диде Гаян, урам башы өйнең бусагасына җиткәч кенә.— Аңлыйм.

Гәрчә хуҗа картның сүзләре аның аңына сеңмәгән иде. Газизҗан исә Гаянның бу халәтен сизде, аңлаудан ерак икәнсең әле син, агайниш, дип уйлады, фикерен тәфсиллисе итмәде, егылганны тәпәләү аның гадәте түгел.

Бүлмә тактасы буендагы озынча өстәлдә җиз самавыр утыра. Дәү түгәрәк подноста, самавыр борыны төбендә үк, пар чынаяклар әчендә шакмаклы тастымал чокыраеп төшкән. Өйдә җиһаз күп түгел, телевизор да күренми, анысы каршы як өйдәдер, мөгаен. Монда исә күзгә иң бәрелгәннәре — түрдәге ак кашага да тәрәзәләрнең һәр ике ягы саен эленгән кижеле озын сөлгеләр иде.

— Сүрелгән бу бөтенләй дә,— диде Газизҗан һәм, самавырны мич алдына куеп, ут яңартасы итте.— Кайтып җитми бит һаман, карчыкны әйтәм. Хатын-кызның ялгызын гына кунакка җибәрсәң, дөньясын оныта инде. Син, начальник иптәш, газеталар актара тор, югыйсә, вакытың калмыйдыр очеркылар укырга. Әбине әйтәм, кайтмыймы икән, чыгып карыйм әле. Түбән оч ягыннан кайтырга тиеш. Коймалар буйлап менсә, моннан күрмичә дә калырсың. Әбине әйтәм, урам уртасыннан йөрми хәзер, ә кыз чагында, әле килен булгач та, урамның читенә чыгуны бар дип тә белми иде.

Әмма Газизҗанга чыгып китәргә туры килмәде. Гаянның газеталар арасыннан идәнгә очып төшкән хатка үрелүен күрде ул.

— Хат та бар икән монда, Газизҗан бабай,— диде Гаян иелүдән кысылган тавышы белән.

— Җәүһәриягәдер, аңарга көн саен чит илләрдән хатлар килә.

— Юк, оныгыгызга түгел. Нәкъ сезгә атап язылган. Хәкимҗан Газизҗанына, диелгән.— Гаян, урыныннан торып, хатны Газизҗанга сузды.

— Әбине көтеп, почтаны актарып карарга да онытылган. Кемнән икән соң? Яшьлек заманындагы кызлардан була алмый, чөнки Сәхәрия әбиеңнән бүтән берәүне дә яратмадым,— дип шаяртты Газизҗан. Хатны кулына алгач, аны ераграк тотып, кемнән икәнлеген укымакчы булды. Ләкин конверт тышында кире адрес юк иде. Адресатын чынлап та сәер язганнар: район һәм авыл исемнәреннән соң, татарчалап «Хәкимҗан Газизҗанына» диелгән.

Газизҗан конвертны ябыштырылган төшеннән куптарып ачты, түрдәге урта тәрәзә янына барып, кына гөл чүлмәге төбеннән күзлеген алып киде. Туры сызыклы дәфтәр битенә эре һәм калтыравык хәрефләр белән язылган беренче сүзләрне укуга ук, агач чөйгә эленгән кижеле сөлгене тарттырып, тәрәзәнең уң ягына сөялде. Гаян аның хатны дикъкать белән укуын, йөзендә канәгатьләнү яки ачу кубу чаткыларының еш алмашынуын эндәшми генә күзәтеп утырды. Әйе, хатка битараф түгел иде Газизҗан карт.

— Мә, укы,— диде йорт хуҗасы, хатны Гаян Сәйфулов алдына өстәлгә куеп.— Идарә начальнигы буларак, син дә җавап язарсың. Уйланырга шәбрәк булыр үзеңә. Югыйсә, колхозлашуның асылын онытКалап җибәрә хәзерге җитәкчеләр. Кайберләре. Тутырып әйткәндә, күбесе оныта. Сине кайсылары исәбенә кертергәдер — хәзергә белмим. Миңа ярдәмең кирәк булган өчен укырга кушуым түгел. Моңарчы мондый хатка җавап язганым булмаса да, табармын... белермен нәрсә язарга. Анлык башым эшләми түгел. Түгел! Бу хатка җавап яза алмасам, яшәвемнең мәгънәсе югалыр иде. Ә мәгънәсезлеккә бу яшемдә аерата бара алмыйм. Хәер, ярдәмең дә кирәк булуы ихтимал. Укы һәм уйлап бак: хәзер колхозда эленке-салынкы эшләүче агай безнең сыйнфый дошманыбыз буламы яки ул нибарысы ата ялкаумы? Без ярым надан килеш чын күңелдән инанып күмәкләшкән замандагы кулактан нәрсә белән аерыла соң бүгенге хөрәсән? Әйтә аласыңмы?

— Мин хатның эчтәлеген белмим ич. Сорауларыгызның хикмәтенә төшенмим.

— Шуңа күрә укы, дим бит.

— Әмма...

— Шулаймы? Танымыйсыңмы...

Сәхәрия карчык күрше авылдан һаман кайтып житмәде.

Самавыр яңарды. Газизжан ике чынаякка чәй ясады. Алар чәйне сөйләшмичә генә эчтеләр. Карт уйга чумган иде, Гаян Сәйфуловны чакырып кертүен онытты ахрысы ул.

Идарә начальнигы саубуллашты, ләкин йорт хуҗасы моңа колак салмады. Хәкимжан Газизжаны көтелмәгән хатка жавап язарга утырган иде инде. Тимер кызган икән, димәк, вакытында чүкергә кирәк аны.

Колхозлашу елларында районнан бер йөз кырык кулак хуҗалыгы сөрелде.

Кылык авылыннан сөргенгә җибәрелгән бер генә гаилә булды, ә гаилә башлыгы Арысланбәк үзе — сәүдәгәр һәм революциягә чаклы жир биләүче, хуҗалыгын алып баруда һаман да бүтәннәр хезмәтеннән файдалануы, ягъни изүче сыйныф вәкиле булуы өчен, нәптан соң хөкемгә тартылып, тиешле җәзасын алган иде. Өч кулак, бөтен гаиләләре белән, берсенең тәпи баскан гына игезәк малайлары да бар иде, куылуларын көтмичә, караңгы төндә чыгып качты. Жигүле пар атларын тимер юл станциясе янында тугарылган килеш чирәм ашап йөргәндә таптылар. Аларның атлары һәм калдырып киткән башка мөлкәтләре колхозның бүленмәс фондына алынды. Бу өч кулак авылдан чыгып качкан төндә Әлгый Фәсәхетдине исемлесенең — игезәк малайлар анықылар иде — ике катлы йорты, абзар-курасы янып көлгә әйләнде. Авыл кешеләре артыннан эзли чыкмасыннар, янгын сүндерү белән мәшгуль булсыннар өчен ут төртеп киткәннәр, дип фараз кылынды. Куып жибәрелүче гаилә кешеләре дә, чыгып качканнары да хәзергәчә бернинди хәбәр бирмәделәр. Аларның язмышы билгесез.

## 2

### 1984 ел, иртә көз

Урман янәшәсендә — олы юл. Анда көз боткасы чыйрый. Урманга сыенып тар сукмак сузыла. Аңа яфраклар төшәлә.

Яфраклар коела. Ашыгып коелалар. Ашыкмыйча ярамый. Жир күкрәгенә жәйләп ятмаса, холыксыз жил яфракны тәгәрәтә-очырта әллә-ә кайларга алып китәчәк тә, бәрелгәләүдән чәрдәкләнәчәк ул. Жилсез чакта һәм көн яктысында үз агачың төбенә төшеп түшәлүең хәер, үз агачың тирәсен бизәү бәхет.

Әллә соң яфраклар Каюмны әйдәп бөтереләләр дә аның барыр сукмагына йомшак палас булып түшәлү өчен ашыгалармы икән...

Сукмак буенда усак ботагы ята. Кайчан сынды икән сабыйкай? Жил көз хәбәрен салганчы инде, чөнки яфраклары хәзер дә коелмый, алар, бөрешеп, кара чуклар булып катып калган. Шулай шул, сынган ботакның яфраклары карая. Тирән жыерчыклы бу яфракларның төсе котсыз кара — кинәт килгән кайгы сыман...

Имән, әнә, яфрак коярга атлыкмый, бөреләрен кышын салкын тиюдән саклаячак аның яфраклары. Үзе каты булгангамы инде, каты суыклардан бик курка ул. Ботагын тиз сындырмый имән, желеге нык аның. Тормыш-табигать серләрен төпченеп өйрәнә имән — акыл иясе кебек...

Каюмның жилкәсенә юка яфрагы кунды. Һәм төшми дә төшми. Шушы ямь юкәнекеме икән бу яфрак? Йомшак агач юкә, үзенчә сылу. Жан

жылысын һичкайчан кызганмыйча сиңа кызуланып бирә юкә — мәрхәмәт иясе шикелле...

Кайгы...

Акыл...

Мәрхәмәт...

Әллә соң боларның гел дә киресеме һәм санау тәртибе бүтәнме:

Ахмаклык...

Шатлык...

Явызлык...

Яфракны җилкәсеннән алып куен дәфтәре арасына кыстырды Каюм. Күз башы хозурына сокланып, арттан машина килүен дә сизмәде ул, машина аның турысына туктап кычкырткач кына юл ягына борылып карады. Яшел «Жигули» хуҗасы ишекне ачып:

— Утырыгыз,— дип Каюмны чакырды, тукталган уңайдан шакмаклы кызгылт калын косынкасын рәтләп бәйләде.

«Хатын-кызның иң матур хәрәкәте — яулыгын бәйләве. Яулык бәйләгәндә шөкәтсез хатыннар да сөйкемле күренә»,— дигән уй килде Каюмның башына. Әмма ул, кинәт купкан бу уйны вакытсыз һәм кирәксез санап, аны җәһәт онытты һәм, кулын күкрәгенә куеп:

— Рәхмәт,— диде.— Җәяү генә, минем сәфәрем ашыгыч түгел.

— Ихтыярыгыз.

Машина пычрак боткасын ипләп кенә ерып кузгалды. Аның артыннан сузылган эзләр теләр-теләмәс кенә йомыла бардылар. Ерагайган саен машина кызулады. Хәзер инде сыеграк пычрактагы янәшә эзләр дә кабаланып күмеләләр иде.

— Олы юл һәм тар сукмак,— дип сөйләнеп куйды Каюм.— Абыйлы-энеле кебек. Әллә апалы-сеңелле кебекме? Әллә абыйлы-сеңеллеме? Әллә апалы-энелеме соң юл белән сукмак? Әллә... акыллы белән тиле кебекме... Һәрхәлдә игезәкләр дә түгел алар...

Бу уйларын да кирәксезгә чыгарды Каюм һәм аларны күңеленнән шулай ук җәһәт куды. Баш катырмыйча да була лабаса — күзнең кечке як табигатенә сокланып, шушы йомшак сукмактан салмаклап атлауга ни җитәр соң?! Күңелсез уйларга бирелер вакытлары алда әле, йомышы җиңелдән һәм кызыклыдан түгел. Ә бәлки...

Йомышының уңасын-уңмасын фараз итәргә өлгермәде ул,— бая узып киткән «Жигули»ның юл уртасында көчәнеп пычрак боткасы туглавын күрде. Каюм апарага әйләнгән юл читенә килеп туктаганда, машина хуҗасы:

— Начар шофер булдың ла син, Рәсиха,— дип үзен әрли иде.— Их, уңмаган Рәсиха...— Ул машина бүксәсе тигән төшне тагын да иелебрәк казырга кереште.

— Рәсиха исемле икәнсез,— диде Каюм һәм, сүзне җайсыз башладым, дип уйлады.

— Ә-ә, сезме, куып җиттегезме.

Рәсиха башын чөерде, һәм кыска чәчләре артка сирпелеп ятты. Аның йөзенә кызыллык йөгергән һәм яшьлеге җуелмаган бу түгәрәк йөзне елтыр-якты күзләре матурлый иде. Чибәрлекнең сере, мәгънәсе, галәмәте шул күзләрдә иде. Тормышка гашыйклык яктысы иде бу күзләрдә. Машина астын кабат казырга тотынгач, шома чәчләре, алга төшеп, Рәсиханың йөзен йәнә каплады. Ул, машинадан косынкасын алып, аларны нык кысып бәйләде.

— Ничек булышырга икән соң сезгә? Минем ботинкаларны пычрак килештермәс,— дип шаяртмакчы булды Каюм, әмма сүзләренә үзе үк аптырады: ир җаны була торып, ничек ярдәм итәргә кирәклеген белмә инде, йә. Нигә соң башта кирделе-чыктылы уйлар тулгана да, авыздан мәгънәгә туймаган сүзләр үк кебек атыла?..

— Теләк булса, җае табылыр. Монда хәйран казыйсы икән — Рәсиха күрәгән ачык ишеккә сөяде.— Портфелегезне бирегез, кабинага куйыйм. Ә ботинкаларыгызны менә бу резин итекләргә алыштырырсыз.

Машинаны чыгарганчы кичке имәзә житте. Инде сукмакка яфраклар төшәлми, олы юл боткасын әнгер-меңгер салкыны куерта башлаган иде.

— Утырып барырга теләмәгән идегез дә, барыбер сезнеңчә булмады. Рәхмәтегезне юл баткагына әйтегез.

Каюм моны шаярту дип аңлады һәм калын кашларын аз гына кымшатып елмайды да:

— Урман буеннан йөрү бик сирәк эләгә миңа, шуңа күрә табигатькә хозурланып җәяүлисе иткән идем,— диде.— Инде яңадан кереп батмыйк.

— Урманда төнгә калудан куркасызмы әллә?

— Белмим. Урманда төн кунганым юк. Мин урман тирәсендә үсмәдем. Ә сез куркасызмы соң?

— Юк. Мин бернидән дә курыкмыйм.

— Батыр ханым икәнсез. Мин кайбер нәрсәдән куркам менә.

— Нәрсәдән?

— Бакадан.

— Чиркану анысы,— дип елмайды Рәсиха, аңа бу уен ошый китте.— Тагын нәрсәкәйдән?

— Еланнан. Иң курыкканым монысы.

— Алайса котыгыз очмасын. Мин елан түгел.

Олы юл, кырт борылып, урманны кисеп керде. Монда ике чакрым чамасы урман юлы биегрәк күтәртелгән һәм әйбәтрәк каралган иде.

Урманны чыккач, Каюм куен дәфтәре эчендәге яфракны алды.

— Рәсиха ханым,— диде ул, яфракны сабагыннан тотып бармаклары арасында бөтереп торгач,— бүләгем булсын сезгә. Ә рәхмәтем, сез әйткәнчә, баткаклы иңкешкә. Юкә яфрагы, шәфкатьле агач яфрагы.

Рәсиха, машинасын акрынайта төшеп, артка борылып карап алды да, уң кулын арка терәгеч өстенә күтәрде. Каюм яфракны аның учына куйды.

— Көз бүләгеме? — Аның тавышы йомшарган иде.

— Көзе мин буламдыр.

Машина, акрыная барып, юл кырыена туктады. Рәсиха тагын артка борылды, Каюмга сынап-өйрәнеп карады. Нидер таныш кебек булды бу тәвәккәллек һәм гайрәт ташып торган йөздә. «Ә күзләрендә төпсез моңсулык үзенең»,— дип уйлады Рәсиха. Тик бу тәэсирләрне Каюмга әйтмәде, тел очына бүтән сүзләр килде:

— Минем сезне күргәнем бар түгелме икән...

— Юктыр. Хәер, дөнья киң, дибез дә, әмма ул да таныш йөзләр белән тулы.

Рәсиха яфракны алгы тәрәзә төбенә, резин кыршау арасына иплап кыстырды.

— Моңарчы миңа берәүнең дә чәчәк бүләк иткәне булмады.— Ул, моны әле генә белгәндәй, гаҗәпләнеп башын чайкады.— Кыз һәм малай таптым, яшем кырыкка якыная — вакыты да, сәбәбе дә булгандыр бүләккә чәчәк алырга. Инде көзем киләдер, ашыгып киләдер, күрәсең.

— Чәчәк түгел, яфрак ич.

— Минем өчен чәчәккә тиң бүләк ул.

— Ә бит,— дип көлемсерәде Каюм,— минем дә берәүгә дә чәчәк бүләк иткәнем юк икән. Чәчәккә балачактан күңел сеңмәгәнгә күрә шулайдыр. Үсмер чакта ашарга ярый торган үләннәрне генә белеп калынган... Шулай да кыр чәчәкләреннән таҗ үргәнем булды бер тапкыр.

— Тәкыядыр.

— Таҗ.

— Һәм хатыныгызны таҗдар иттегез, әйеме?

— Икенче хатынымны.

— Күпмени алар сезнең?

— Беренчесе белән аерылыштык, икенчесе белән торам. Килешеп яшибез.

— Шөкер, мин бердәнбер ирем белән бәхетле.

Гаилә мәсьәләсендә тиз ачылып сөйләшми торган иде Каюм, ә хәзер таныш булмаган ханымга уйламыйча да артыгын сөйләп салды. Рәсиханың йөзендәге мәрхәмәт, аның кешеләргә игелек эшләргә теләвен сиземләү ачты Каюмның телен. Югыйсә, ул бүтәннәрнең ярдәменә үзен мохтаҗ санамый, ташкынны үзе ерып чыгарга күнеккән иде. Һәм башкаларга игелек кылуда Каюм үзе дә ахыргы исәптә йөрми. Хәзер әнә Рәсиха аның серләрен җиңел генә ачтырды. Бу ханым, теләгән очракта, һәркемне һәрчак буйсындыра ала, кемне дә сындырыр ул, бәлки, шундый көче булганга күрә бернәрсәдән дә курыкмыйдыр, дип нәтиҗә ясады Каюм.

— Агачларны балачактан ук яратам. Алар миңа гел тансык бүләк булды. Анысы, агачларны, урманны яратмаган кеше юктыр да,— дип, тукталып торган әңгәмәне яңартты Каюм.— Урман буеннан җәяүләвем дә көзге агачларга сокланудан иде. Мәктәптә укыганда, көзен төрле яфраклар җыя идем дә китап битләре арасына сала идем. Китапны ачкан саен агач үзе күз алдына килә... Ул чакта минем урман күргәнем юк иде. Гаҗәп, китап арасына бүтән нәрсә кыстырсаң, укытучылар ачуланыр иде, ә яфрак өчен әрләмәделәр. Башлангыч классларда әни укытты мине.

— Урманчымы әллә сез?

— Ю-ук! Хезмәтем... Һөнәрем бөтенләй башка. Сәфәрем — Кылыкка.

— Күптән булганыгыз юк ахры безнең якларда.

— Күптән. Бик күптән. Тумышым белән Кылыктан үзем.

— Әйтәм ич, минем сезне күргәнем булырга тиеш. Безнең авыл кешесе икәнсез ич.

— Бәлки, башка җирдә күргәнсездер. Әмма Кылыкта түгел! Минем киткәнгә йөз былтыр, әле сез туганчы ук. Гомумән, Кылыкта мине берәү дә белә алмый. Басу капкасы төбендә туктатырсыз, мин төшеп калырмын.

— Нигә? Мин сезне кушкан җирегезгә илтеп куя алам. Ә басу капкалары юк бит хәзер.

— Алайса, күпер чыкканчы төшерерсез.

Рәсиха машинасын күпергә шактый кала туктатты да кинәт тагын алдырып китте. Үзе артка борылып карады. Каюм төшәргә әзер иде.

— Авылның күзе күп. Әни әйткәндәй. Ни өчен әле сез, таныш булмаган ир кешене утыртып, урам буйлап йөрергә тиеш ди? Кирәкмәс. Утыртып кайтуыгыз өчен рәхмәт сезгә, төнгә үк каласы икәнмен. Ары таба мин үзем барырмын.

— Куркуыгыз бака белән еланнан гына түгел икән ич. Гайбәттән дә куркасыз. Минем өчен булса борчылмагыз. Ирем шушы Кылыкта колхоз председателе минем. Шулай булгач, тормышыбыз авыл күзе алдында гына түгел, район күзе алдында. Ирем исә хыянәткә бармаячагыма ышана. Шуңа курыкмыйм.

— Туктатыгыз.

— Куркам, Каюм абый, мин дә бер нәрсәдән куркам. Алдашудан.

— Бу очракта курыкмагыз, мин сезгә бернәрсә дә алдамадым. Инде ачыктан-ачык сөйләшкәч, шуны да өстәп әйтим, мин дә колхоз председателе булам. Моннан ерактагы колхозда. Әгәр очраша калсак, сүз бирәм, шулай ук алдамам. Вәгъдәмдә тора беләм мин. Ләкин без кабат очрашмабыздыр, беркайчан да.

Каюм машинадан чыккач, Рәсиха, ачык ишеккә борылып:

— Рәхмәт сезгә, Каюм абый, бүләгегез өчен рәхмәт,— диде.

Машина ишеге, Рәсиха эчке яктан тартса да, Каюм тыштан этсә дә, ябылып җитәр алдыннан бер мәлгә тукталып торгандай булды.

Гәрчә мондый хәл мөмкин саналмый. Әмма шулай булды. Танышу табышмаклар калдырганга күрә шулай булды.

Ләкин машина ишегенең ябылыр-ябылмас торуы да, Каюм белән Рәсиханың көзге очрашуы да теләп вә көтеп алынган хәлләр түгел иде. Кирәкмәс тә иде бу очрашу. Хәер, дөнья дигәнең очрашулар белән тулы ич. Аның үз кануннары, үзенчә гөман кыла ул.

— 1929 елда мин авыл советы рәисе булып эшләдем. Ноябрьнең егерме бишендә волость киңәшмәсе булды. Шуннан кайткач, авыл ярлыларын җыйнап сөйләштек. Колхозга керергә теләүчеләр исемлегенең башына үземне һәм гаиләмнең барлык әгъзаларын язып куйдым. Бу кичне колхозга керергә тагын дүрт гаилә язылды. Колхозга керергә берәүне дә мәҗбүр итмәдек. Күрше-тирә авылларда колхозга бирмәс нияттән атларын суючылар хөкемгә — штрафка тартылды. Безнең Кылыкта мондый хәлләр булмады.— «Революция» колхозы оешуга илле ел тулган көнне Газизҗан Хәкимҗанов авыл җыенында шулай дип сөйләгән иде.

## 3

## 1985 ел, җәйге каникул башы

*Җәүһәрия көндәлегеннән*

«Безнең ял, ял! Җәйге ял безнең!

...Ай-й аллам икән!

Бу сүзне Сәхәрия әбием еш кабатлый, аңардан оттым мин аны.

Ай-й аллам икән! Калын дәфтәремне җәйге каникул җитүдән түгел, бөтенләй бүтән нәрсә язып башларга уйлаган идем лә.

...Көндәлек язып барырга кем кушуын хәтерләмим. Мин аны өченче ел — дүртенчедә укыганда ук яза башладым. Быелга, менә бу калын дәфтәргә яза башлаганчы, унике битле җиде дәфтәрне тутырганмын.

Кечкенә дәфтәрләрнең тышлары тиз төшә, аларны җыеп йөртүе дә уңайсыз. Шуңа күрә барысын көрән күн тышлы, шакмаклы калын дәфтәргә күчерәм дә куям, бер уңайдан өстәштереп тә язармын. Монысы тулгач, яңасын башлыйм.

Аннары, вак дәфтәрләрдә, әни әйткәндәй, язганымның һич кенә дә элә-танагы юк. Хәзер яңачарак итеп, бабай кушканча, тасвирлап язармын, юкса, бабай әйтә, кызыклы итеп язмыйсың, ди. Менә бу калын көндәлекне укып карасын әле ул, мине мактап бетерә алмас. Матур итеп язмаска ни, дүртенче класста түгел, алтынчыны укып чыккан дәү кыз ич мин.

Беренче дәфтәрем болай башланган:

Бүген — октябрьнең соңгы көне. Биш дәрес укыдык. Ахыргысы физкультура иде. Укытучы абый мәктәп стадионына алып чыкмады.

— Көннең ничек котырганын күреп торасыз,— диде.— Мондый чакта чыланып кына калмыйсың, өстәвенә уен мәйданын да изәсең. Аннары аны тиз генә юньгә кертеп булмый. Ә тәзүче абыйларыгыз-апаларыгыз яңа спорт залын бәйрәм алдына гына өлгертәчәкләр әле.

Без быел укуны яңа мәктәптә башладык. Элеккесе, авылның өч мәчетен кушып салынганы, бик тузган иде. Яңа мәктәпне ак кирпечтән, өч катлы итеп салдылар. Монда бөтенесе дә әйбәт. Тик мәктәпнең арткы ягына кушып салынган спорт залын гына һаман өлгертмиләр. Шуңа күрә укытучы абый безгә класста гына дәрес буена спорт ярышлары турында сөйләде. Безнең авылда электән үк җәен йөгерешләр, кышын чаңгыда узышлар оештырганнар икән. Чаңгы ярышында минем Газизҗан бабай баш килә торган булган.

Мәктәптән кайткач, уйнарга чыкмадым. Һаман елак кар ява. Көнозын туктый белмәде шул. Телевизордан йөзү ярышлары күрсәттеләр.

Безнең мәктәпнең дә бассейны булачак. Әти әйтә, яслегә дә бассейн ясатабыз, ди.

Юк, мин йөзүче булмыйм. Мин... мин велосипедчы булам!..

Әби белән әни табын әзерләп йөргәндә, әти кайтты. Өсте-башы чыланган, резин итеге кунычына тиңентен пычранган, аны, өйалдында ук салып, кунычларыннан чеметеп кенә күтәреп керде. Мин итекләрен шулай пычратканы өчен әтине и-и каты итеп ачуландым да ләгәндәге суда мунчала белән ышкып юдым. Әти әрләгән өчен мине мактамады. Бүтән чакта минем ачуланып тәртипкә өйрәтүемне — әбидән йокты инде миңа бу гадәт — ярата иде ул. Кәефе кырылган аның бүген. Бабайның көндәгечә:

— Ничек? — дип соравына да башта:

— Әйе, шәп икән,— дип киреле-морылы гына җавап кайтарды.

Фермада булган әти. Сыер-таналарны ябарга урын җитми, иткә җибәрергә тиешлеләрен һаман алмыйлар, ит комбинаты өлгерми, ди. Симерткән үгезләр мондый көндә лапас астында тотып кына күпме ашатсаң да ябыгачак, колхоз зыян күрәчәк икән.

И-и авыр да, мәшәкатьле дә безнең әтинең эше, колхоз председателе бит ул.

Юк, мин колхоз председателе булмыйм. Мин... мин кирпечтән сыер абзарлары салучы булам да әтинең эш хәсрәтен бетерәм! Юкса, утыра бит әнә тезләренә егылып. Әни әйткәндәй, ни ал юк, ни ял юк үзенә.

Безнең әби әти кайтуына алма турап чәй ясап куя. Әти шул чәйне эчәргә дип дәү чокырны кулына алуы гына булды, чыгырына тотынып ишекле-түрле йөргән энем Җиһангир чатый-чотый атлап әтигә таба китте дә барды! Калды чыгыры мич казнасына «дырк» тәрәлеп! Җиһангирның тәпи атлап китүенә и-и сөенештек инде, барыбыз да — бабай да, әби дә, әти дә, әни дә, мин дә сөендек. Җиһангир үзе дә бик сөенде, әти янына житкәч, тагын йөреп күрсәтмәкче булып борылган иде дә, әти аны җәһәт күтәреп алып сөйде.

— Миннән дә бәхетле кеше юк бу дөньяда! — дип кабатлый-кабатлый әти Җиһангирны ишек катына күтәреп илтеп бастырды да, үзе түргә барып чүгәләп колачын җәйде. Минем бердәнбер Җиһангир энем авызын ерып шаркылдый-шаркылдый, ава-түнә әтинең кочагына башы белән барып чумды. Әти Җиһангирның тәпи йөреп китүенә барыбыздан да күбрәк сөенгән инде әллә, шулайдыр да шул, үгезләрне иткә алмау хәсрәтен дә оныткан иде бугай ул.

...Шәп икән!

Монысы инде миңа әтидән йокты. Ул «шәп икән»не әбинең «ай-й аллам икән» дип кабатлавыннан да ешрак әйтә.

Шәп икән!

Көндәлекнең башына ук нәсел агачыбызны язып куярга оныткач, кире мәгънәдә әйткәндә генә шәп икән шул.

— Нәсел агачын онытырга ярамый, аны кимендә җиде буынга тикле һәркем төгәл белергә тиеш,— дип бик күп тукыган иде ич миңа Газизҗан бабай.— Әгәр шуны белмәсәң,— дип тә кисәткән иде,— нәсел агачын ширантай итәсең.

Ширантай — корыган, әмма әлегә төбендә утырып тора торган агач икән. Бабай бу сүзне, мин аңламый торгач, шулай дип аңлатты.

— Ә корган агачны давыл кыеп сындырырга йә төбе-тамыры белән куптарып ташларга да күп сорап тормый,— диде бабай.— Аннары череп юк була инде башта төз утырган, соңрак ширантайга әйләнгән агачың.

— Нәсел җебе нык эрләнгән булырга тиеш, Җәүһәрия кызым,— дип өйрәтә мине Сәхәрия әбием. Ул агач дими, җеп ди.

Әй-й, бабай да, әби дә дөрес әйтәләр инде: колакка нәсел агачы да, нәсел җебе дә бик матур ишетелә. Мин генә нәселебез турында көндәлек башына язып куярга онытканмын.

Ә-ә, мин аны дәфтәрнең тышлыгы эченә язам да куям, дәфтәрне ачуга ук күренеп торсын. Монда нәсел агачының төп кәүсәсен терким дә, ә тармакларын-ботакларын кендәлеккә рәсем итеп ясармын.

Мин — Җәүһәрия
Безнең әти — Әмир
Әтинең әтисе —
безнең бабай — Газизҗан
Энем — Җиһангир
Безнең әни — Рәсиха
Әтинең әнисе —
безнең әби — Сәхәрия
Газизҗан бабайның әтисе — Хәкимҗан
Хәкимҗан бабайның әтисе — Хуҗиәхмәт
Хуҗиәхмәт бабайның әтисе — Мостафа
Мостафа бабайның әтисе — Габделкаһир
Габделкаһир бабайның әтисе — Габделкәрим
Габделкәрим бабайның әтисе — Габделнасыйр
Габделнасыйр бабайның әтисе — Габделкадыйр
Габделкадыйр бабайның әтисе — Габделкәбир

Нәсел агачыбызны язучы
Әмир кызы Җәүһәрия.
1985 елның июне.

Газизҗан бабай шуннан арысын исемләп белми.

— Безнең ерак бабабыз Габделкәбирнең борынгы бабасы,— дип сөйли ул,— тагын алты кеше белән бергәләп, Казан тирәсендәге Кылыклы авылыннан монда килеп нигез корган. Күчеп килүчеләрнең башлыгы Шәрипъелга исемле булган, диелә бабайлар сөйләгән тарихта. Авылыбызның исеме дә электә шул кеше исеме белән Шәрипъелга дип йөртелгән. Ул чакта бу тирәләр карурман булган. Безнең бакча башындагы инешнең теге ягын Арыслан тавы дибезме, анда арысланнар күп булган өчен шулай атаганнар аны. Безнең йорт-җиребез Габделкәбир бабайның борынгы бабасы корган нигез булырга кирәк. Ә Шәрипъелга бабайның нигезе авылның уртасында, хәзерге клуб урынында булган булырга тиеш. Боларын ук төгәл кистереп атавы кыен, борынгы заман хәлләрен язып бармаганнар бит. Нәсел агачыбызның минем әтигә — Хәкимҗан бабабызга килеп ирешкән хәтлесе шушыннан да ерагракка китми.

...Ай-й аллам икән! Мин иске көндәлекләрне күчерә идем ич, әй. Борынгы тарихка кереп киткәнмен.

Әйе шул менә, тарихны белмичә ярамый да әле. Безнең бабай әйтә, тарихыңны күпмегә ераграк белсәң, алга барыр юлың шуның хәтлегә анык була, ди. Чагыштырып та күрсәтә: артка борылганда йөз чакрымны күрсәң, алга карагач, төп-төгәл йөз чакрым синең алдыңда ялтырап ята, ди.

Әлек язганнарымны күчерәм. Кай төшләрен кыскарткалыйм, җөмләләрен дә үзгәрткәлим»

## 4

### 1984 ел, октябрь уртасы, ә төп вакыйга, нигездә, 1926—1927 еллар кышыннан

Мишәнең ике ягында да сөзәк үрләргә тәралгән болыннар бар. Авыл халкы, район җитәкчеләреннән болыннарны сөрергә күрсәтмәләр явып торса да, аларны бетермәде. Хәер, җитәкчеләр арасында туган як табигатен саклау кирәклеген аңлаучылар да булгандыр. Югыйсә,

авыл халкының карышуына колак салып тормаслар иде, болыннарны сөрдереп, туфрагын язгы ташуда күптән Мишәгә тутырта алырлар иде. Авыл кешеләренең онытылмас балачагы яши Чәчәкле Болыннарда!

Кылыкның Арыслан тавы итәгеннән Мишәгә хәтле төшендә эрәмәлек бар. Кечерәйми эрәмәлек, хәзер дә авылның өлкәннәреннән берсе Хәкимҗан Газизҗаны малай чакта ук белгән чиктә ул. Авыл кешеләренең кайнар яшьлеге яши Моңсу Эрәмәлектә!

Эрәмәлектә күл-кое бар. Зур түгел, гадәти авыл йорты урыны хәтле генә үзе. Әмма тирән, бик тирән, хәтта төпсез, диләр аны. Гөнаһ кылган кешеләрне кайчандыр шушы күлгә таш бәйләп салганнар. Авыл кешеләренең табигатьнең пәһлеван көченә аңлы буйсынуы яши хәвефле Күл-коеда!

Арыслан тавында һәм аңа каршы яктагы Таң тавында чишмәләр бар. Авылның ике ягыннан аккан мул инешләрне шул чишмәләр туендыра. Авыл кешеләренең матур өметләре яши Җырлы Чишмәләрдә!

Таң тавы белән Миша тугае арасында сазлык бар. Шүрәле Сазлыгы, диләр аны. Йөгереп чыныгыр өчен такыр сукмаклар гына аз авыл балаларына, тормышның яшерен көчкә ия баткакларын читләтеп үтәргә өйрәнер өчен түмгәкле сазлык та кирәк аларга. Авыл кешеләренең түмгәктән түмгәккә сикереп шикләнүле имтихан тотулары яши Миһербансыз Сазлыкта!

...Кылык авылының табигый тасвирлары болар һәм баштарак әйтелгәннәр белән генә бетми. Бу байлыкларның барысы турында да язып бетерү мөмкин түгел, Туган як бит ул! Моны алдарак сурәтләргә тырышырмын, әлбәттә. Хәзергә үземне мөнә нәрсәләргә басым ясап әйтергә бурычлы саныйм. Кылыкта, иске китаплардагыча әйтсәк, ләүхелмәхфузның (язмышның, тәкъдирнең) тискәре ягында чуалгалап беткән кайгының күзенә туры караучы, бәлки, шуңа күрәдер, кырысрак, хәтта кырыс-кире холыклы, әмма, төп сыйфатны алга чыгарсак, э ш р ә т е н б е л ү ч е к е ш е л ә р яши.

Балачагымның күп көннәре Кылыкта узды минем. Шушында мин икмәк тәмен белә төштем, хәреф ятладым. Суда йөзәргә, шара-кәшәкә уйнарга, чаңгыда шуарга, ат чабыштырырга һәм атны җиңел тартырлык итеп җигәргә, каз оясы үрергә талчыбык җыярга — кыскасы, тормышның беренчел серләренә Кылык авылында аңыша башладым. Кылыкның Болын буе басуында ерак туганыбыз Шәрифулла абзыйның (хикәяләүгә ул бүтән кермәячәк, гәрчә мин аның кешеләргә матурлык бүләк итә белүе хакында озын да яза алыр идем, әмма ул безне — малайларны — эш рәтенә өйрәтсә дә, матурлыкны тәфсилләп аңлатуда үтә аз сүзле иде, димәк, хикәяләү дә бу урында аның холкынча) чөмәләкәй тубалын күтәреп, як-якка салмак авыша-борыла, бер көйгә атлап, иң куанычлысы — бәхетле елмаеп, язгы туфракка бодай чәчкәнен күргәнем бар. Чәчү чәчәргә мине дә Шәрифулла абзый өйрәткән иде. Тормышның дәвамлы икәнен чәчү чәчәргә өйрәнгәндә аңлый башладым.

Шигъриятле табигатен, күп төрле язмышлы кешеләрен балачактан ук яраттым мин Кылыкның. Бәхетле мин — балачагымны күңелемә сеңдерде Кылык. Мин аннан беркайчан да аерыла алмаячакмын.

Йомышларым төшеп һәм сагынып, еш кайтам мин Кылыкка. Ә хыялымда кайтуларым исә — бихисап!

Менә бу юлы озаграк торырга исәпләп кайттым. Максатым — хәзерге күмәк хуҗалык авылы кешеләре турында һәм авылның сугыш дәверендәге пәһлеван малайлары, мәрхәмәтле кызлары турында материаллар туплау иде.

Һәм бу әсәрне нигездә анда яздым.

УРАК ӨСТЕ БОЛЫТЛАРЫ дип уртак исем куелган хикәятләремә соңарган кереш шушы булсын.

...Мин Газизҗан бабайларда торам. Әле сугышка чаклы ук без гаиләбез белән аларның эчкәрге өендә торган идек. Шул замандагы тату-

лык хакына һәм Кылыкны яратуым өчен үз итәләр Газизҗан бабайлар мине. Урамга караган өйнең олы ягы минем карамакта. Эш өчен уңайлы, бирәү дә комачауламый, хуҗалар, кирәге чыкса, өйнең кече як ишегеннән йөриләр, хәтта бәләкәй Җиһангир да олы якка кереп эштән бүлдерми.

Кичке аштан соң гына минем янга Газизҗан бабай керә һәм, күлмәгенең сызганган җиңен сыпыра-сыпыра төшерә, бүгенгә эш бетте, дигәндәй, диванга килеп утыра.

— Кешегә иркенләп сөйләшеп утыру да кирәк,— дип сүз башлый ул.— Борынгылар әңгәмә корып акылларын баетканнар. Бер-береңә киңәш-кораш бирү, ай-яй, мәслихәт тә соң вакыты белән. Гыйбрәт булырдай хәлләр дә ишетәсең.

Хәкимҗан Газизҗанының ил тормышындагы күркәм эшләрдә үз өлеше бар, кырт борылышларның, сикәлтә-салуларның шаһиты ул. Аның егет чакта ук җибәргән мыегы инде кара төсен җуйган, битләре иткә саеккан. Хәзер сакал да йөртә. Авыл мәшәкатьләренә күнеккән кулларын йодрыклап куйса, йодрыклары чәнти бармаклары ягыннан кыйгачланып, өчпочмакка охшабрак тора.

Ул йомры башын диван аркасына салып, куллары белән йомшакка таянып, үткәндәге берәр хәлне иң элек хәтерендә барлый, аннары, тирән төбәтәен маңгаенарак төшереп, сүзгә керешә. Сөйләү — Газизҗан бабайның бер һөнәре, ул сөйләмичә булдыра алмый, чөнки авылның һәм тирә-якның тарихын күңел китабында саклый. Хәтере нык аның, вакыйганың кайчан булуын көне-сәгате белән әйтеп бирә ала.

Бераздан, аш-су тирәсендә җыештырып бетеренгәч, Сәхәрия әби дә безнең әңгәмәгә кушыла. Карчыгы ишектән күренүгә, Газизҗан бабай кытыршы учы белән Сәхәрия әби утырасы урынны йомшарта, карчыгы туктылып яулыгын төзәтеп бәйләгән арада диван өстендәге япманы тигезли. Бу һәр кичтә шулай кабатлана, һәм Сәхәрия әби картының хөрмәтен тиешле кабул итә. Өйләнешкәнче Газизҗан атлы егетең Сәхәрия чибәренә, өрмәгән җиргә утыртмам, дип вәгъдә биргәндер, шәт. Шул вәгъдәсенә тугрылык мәхәббәттә гомер буена сыналгандыр кебек. Хәер, ачуланышырга сәбәпчел авыр чаклар булгандыр, бигрәк тә балалар үстергәндә бер-береңне иркәләүләр онытылып торгандыр. Үзара игътибарга аларның хәзер вакытлары иркен, хәзер тормышлары житкелекле, балалары, шөкер, игелекле булып үстеләр дә үз юлларын таптылар. Әмма Газизҗан бабай белән Сәхәрия әби озын гомер юлында идәнгә төшеп ватылган чокыр тәтәйләре өстенә аш тәлинкәсен дә тотып томырмыйча яши белгәннәр.

— Көне буена ялгызың хыялланып утырасың,— диде бүген Газизҗан бабай миңа.— Армыйсыңмы соң. Анысы, хыял итү кирәк. Хыял, беләсең килсә, кешенең бәрәкәтле байлыгы ул. Хыял эшкә өйрәтә, тормыш җаен таптыра. Әллә син, Сәхәрия каракаш Газизҗанга хыял итмичә генә эләккән, дисеңме?! Һей, күп егетләр күз атты аңа, чиләкләрен җырлатып чишмәгә суга төшүен күпләр күзәтте. Әмма ки Газизҗанга булды Сәхәрия! Ничекме? Хыял итә белде Газизҗан йомры баш чөнки!

Бабай, карчыгына карап, шулай бит, әнисе, шәп яшәдек бит, дигәндәй, йомшак кына ым какты. Әби дә күзләрен тутырып картына карый, канәгатьлек җавабы шул аның, ә үзенең йөзенә көлемсерәү йөгерде. Һәм сүзне һич тә үпкәләү-ачу салмыйча, бәлки, назланырга һаман хакым һәм дә чамам бар, диган кебек, иплән кенә әйтеп куйды.

— Урладың ич...

— Һей, карчык, законлы урлау булды ул, бабай үзе сине минем кулга тоттырып җибәрде. Соң, Газизҗан, киявем бул син, дип ялынырга тиеш түгел иде лә инде ул. Башы эшләсә, егет үзе чамалар, дигәндер.

Кызыл Армиядә хезмәтне тутырып кайткан чак минем. Хуҗалыгыбыз бөтен, җиткелекле, әмма бүселеп баюга да бармыйбыз. Иген игәбез, терлек асрыйбыз. Җир кешеләренчә. Эш күплектән зарланып

булмый, ел әйләнәсенә иркен вакыт күп җыйнала. Өч хуҗалык берләшеп, бәләкәй ширкәт оештырып, уртакка атлы урак машинасы һәм сугу машинасы алып җибәргәч, хезмәт тә җиңеләйде.

Көзге-кышкы кичләрдә Совет өенә җыелырга гадәтләндек, шунда газет-журналлар укыйбыз. Әле бу чакта авылда китапханә ачмаган идек. Күбесенчә мин кычкырып укыйм, революциягә тикле мәдрәсәдә ук җәһәт уку буенча алдыра идем. Хатын-кыз безнең бу укуларга йөрми. Алар, авылда китапханә ачкач та, бусагадан атлап керергә шикләнделәр. Шуңа күрә аннары атнаның ике көнендә китапханәне алар карамагына гына бирергә мәҗбүр булдык.

Авылда хәбәр давыл җиленнән дә тизрәк тарала бит. Сәхәрия чишмә юлында бераүсенең аркасын көянтә белән каезлаган, имеш. Теге егетең Сәхәриянең чиләген тартып алган булган икән. Гарасат җилләре искән ди егетеңнән. Ничек сүз кушмак кирәк шуннан соң Сәхәриягә, минем ипи шүрлегенә менеп төшәргә дә күп сорап тормас кызыкай. Ә күңел дигәнең һаман саен аңа тартыла. Куера гыйшык.

Яз җиткәч, Әрәмәлек буенда «Наза»лы уйнаганда, чакырдым бит мин Сәхәрияне! Уртадан очып кына биеп чыктык. Тик шунда ук мине тагын так калдырдылар. Сәхәриягә күз атучылар биниһая күп иде, дим бит. Газизҗан да җебегән үк түгел, тагын чакырдым Сәхәрияне! Теге егет белән эленке-салынкы гына биегән иде, минем белән аягы җиргә тимичә бөтерелә Сәхәриян!

— Монысын күперттең лә,— дип бүлдерде Сәхәрия әби.— Гомеремә рәтле бии белмәдем лә мин.

— Юк, карчык, син үзең сизмәгәнсең, минем белән шәп биедең син шул кичтә. Һай шәп биедең мәгәр!

Ярар, кыш җитте. Әйткәнемчә, авылда кызлар аулак өйгә йөрсәләр дә, Совет өенә китап укырга килмиләр. Күрәсе килә Сәхәрияне, әмма көндезләрен сукмакларыбыз сирәк очраша. Күзен сирпеп бер исәнләшеп китсә, миңа ике-өч көнгә юанып йөрергә шунысы да җитә җитүен. Әмма дә ләкин гомер буена урам аркылы сәламләшеп йөрмәссең бит. Әллә, дип хыял итәм, Сәхәрияне кәләшлеккә сорап карааргамы? Тәвәккәлләдем дә ди, егылып бил сынмасмы, дип тә шикләндем. Миңа бабай буласы Басарый абзыйның да холкы ара-тирә кырт бормалы, ризалык бирмәве бик тә ихтимал. Инде ике яучыны, сезгә кызганыч, юлыгыз уңмады, дип, елмаеп кына капкага хәтле озаткан, диләр. Газизҗан җибәргән яучыны капкадан ук кертмәскә булдырыр Басарый абзаң!

Йөрим үземә үзем киңәш биреп. Тузга язмаган хыялларга кереп чумам. Ниһаять, шул хыял дигәнең Сәхәрияне минеке итте дә куйды. Вә ләкин барысы да законлы тәртиптә булды! Сәхәрия әбиең, урладың ич дип, үзе күпертеп җибәрә.

Басарый абзый, бабай ягъни, почта йөртә иде. Сәхәрияне дә волостька алып баргалый, үз эшенә өйрәтә икән. Китүләрен күреп калам боларның, кайтуларын читтән генә күзәтеп көтәм. Ут алыр чактарак кайталар.

Беркөнне, төшке аштан соң, үзебезнең Бурлы Кашканы җиктем дә, өйдәгеләргә:

— Волостьта ширкәт эше белән йомышым төште, кичкә әйләнеп кайтырмын,— дип чыгып та очтым. Чана башына юныш балтасын кыстырдым.

Үзең беләсең, элеккеге волость, хәзерге район үзәге белән безнең авыл арасы уникe чакрым, аның ике чакрымын урман аша чыгасы. Басарый абзыйларның кайтыр вакытлары җиткәнче, өч чыршыны балта белән чабып, юлга аркылы-торкылы егып та салдым. Куәтле идем ул чакта. Ат белән үтәрлек түгел, урман юлы таррак иде ул чакта. Ботаклы агачлар юлны бөтенләй каплады. Читтән дә үтеп булмый — куелык. Атымны борылышта калдырган идем. Басарый абзыйлар күренгәч кенә каршыларына юыртып кузгалдым. Егылган агачлар янына башта алар килеп җитте.

— Бу ни хикмәт тагын? Юлны кисәргә кайсы тилесенең башына килде икән?— Басарый абзый толыбын салып чанага атты.— Берәр хәвеф куптканмы әллә?

— Белмим шул.

— Газизҗан, балтаң юкмы? Ботакларын чапкаласак, чыгарга булыр иде дә моннан.

— Юк шул.— Балтам чыршы төбенә чапкан килеш калган икән, шөкер, ялтырап күренми.

— Һе, диген. Кая барышың соң?

— Тиз генә волостьтан урап кайтасы идем. Булмады инде, борылам!

Сәхәрияне утыртып алып кайтыйм, дип өстәп җибәрергә дә исәплим, тик хәйлә бозылудан куркам. Басарый абзый үзе әйтмәсме, дип көттем. Атны бора башладым.

— Һе, алайса,— диде Басарый абзый сузып кына. Кабаланучан кеше түгел иде ул.— Сәхәрия, бар, Газизҗан атына утырып кайта тор. Газизҗан энем, йөкне дә сиңа күчерик, минем атка юыртырга җиңелрәк булыр. Күрше авылдан ук әйләнергә туры килә. Әйберләрне Сәхәрия алып калыр да аера торыр.

Сон, ходай, миңа шул гына кирәк ләбаса! Йөкне җәһәт кенә күчереп төя, Сәхәрияне толыпка төреп чана уртасына утырт та, әй-дә!

Урманны яңгыратып сызгырып җибәрдем Бурлы Кашкага — баскан урыныннан ук җилдәй очып китте малкай! Килен алып кайтуын сизенде бугай.

Тиз кайттык, атны менә шушы капка төбенә — элек тә шунда ук иде безнең капка — борып туктаттым, тәртә башы, капкага «дыңк» бәрелеп, өйгә хәбәр салды.

Монда хәтле кайттык, ә хәзер нишләргә соң? Сәхәрия безгә кайтуын сизми бугай, баштанаяк төренеп утыргач, берни күрмидер. Инде караңгы эленгән иде. Болдырдан көянтә алып чыктым да аны Сәхәриягә суздым.

— Мә,— мин әйтәм,— әгәр минем сыртны каезларга карар итсәң, көянтәбез нык, сынмас. Инде мине үзеңә тиң күрсәң, шушы көянтә белән чишмәгә суга йөрерсең, көянтәбез кисмәк хәтле чиләкләр асссаң да сынмас, һәм без мәңге бергә булырбыз.

Көянтәне алмый гына Сәхәриям!

Җебемә, чүбеккә әверелмә, дип батырайтам үземне, җитәклә Сәхәрияне, юк, күтәреп алып кер өеңә Сәхәрияңне, дим!

Һәм күтәреп алып кердем. Карышмады Сәхәрия каракаш.

Һич ялгансыз, менә Сәхәрия җиңгәң үзе. Гомеремдә мин өч мәртәбә алдадым, шуның белән минем гомергә каралган алдашу лимиты бетте.

Өч алдашуым да шул көнне булды. Беренчесе — агачларны аударуымны Басарый абзыйга танмадым. Икенчесе — аңа балта бирмәдем. Ә өченчесе Сәхәрияне өйгә алып кергәч булды.

Гаиләбез өстәл әйләнәсенә түгәрәкләнеп утырган, әти коштабакка ит турый, әни тәлинкәләргә аш бүлә иде.

— Әти, әни,— дидем,— өйләндем мин. Менә киленегез Сәхәрия.

Безнең әни эшенә дә уңган, сүзен дә җайлый белә иде. Өйдә аның сүзеннән чыгучы булмады, бәлки, ул этинең карарын безгә ирештергән генәдер, соңгы боерыкны әти чыгаргандыр, чөнки әни әйткәнгә әти беркайчан да эсәреп калмады.

Хәзер нәрсә дияр әни? Күзенә генә карап торам. Юк, ачуланмады. Хәер, малаен килене каршында хур итәме соң әни кеше!

— Исәнме, саумы, Сәхәрия балакаем! Әйдә, түкле аягың белән уз!— дип Сәхәриянең шәлен-бишмәтен ук салдыра башлады.— Кара син, нәрсә аптыраштыгыз? Бар әле, син бер тәлинкә алып кил. Кая әле, кызлар, сез өстәлнең бу ягына күчеп утырыгыз, ул урыннар абыегыз белән җиңгәгезгә булыр. Рәхмәт төшкерләре, ризык бүлгән чакка туры килде кайтуыгыз, гомерегез туклыкта узар.

Соң, киленен шулай каршылыйсың белдем бит әнинең! Минем әни бит ул!

Әти үтә аз сүзле кеше иде безнең.

— Басарый кодалар белдеме соң?— дип кенә сорады ул.

— Сәхәрияне бабай үзе риза булып бирде!

— Хәерлегә. Бәхетегез үзегез белән.— Әтинең дә хөкеме шулай кыска булды.

Бабай кызын миңа риза булып бирде, дип бу кечтә өченче тапкыр алдавым өчен, Сәхәриядән миңа яман эләкте. Әгәр тагын кайчан да булса чеметем генә дә алдашсаң, Сәхәрияңне мәңгегә онытырсың, диде. Әкәмәт хәл, шуннан соң миңа түмгәкле җирне тигез итеп күрсәтер өчен ялган корырга кирәкмәде.

Шулай. Мин кәләшле булдым, йорт яшь киленле булды. Инде бабай белән әбине килештерергә кирәк иде. Монысын да кызуында сугып калу мәслихәт!

Басарый бабайларның да йорт-җире Сул Тамак урамында, безнең рәттә, тик югары очта ук. Хәзер урыннары пуҗум, бабай белән әбидән соң кеше калмады, кайнишләрнең икесе дә сугыштан кайтмады. Сүз уңаеннан бу искәрмәбез. Хәер, үзең дә беләсең Сәхәрия җиңгәңнең энеләре сугышта калуын. Бабайларның йорт урыннарын да беләсең.

Шулай. Мендек бабайларга Сәхәрия белән икәүләп. Бурлы Кашканы туармаган идем бит, аннары, яшь киленне җәяү йөртмәссең ич, өстәвенә почта әйберләре дә чанада туңып яталар иде.

Тәрәзәләренең пәрдәләре тартылган, ләкин пәрдә өстендәге ачыклыктан бабайның башы күренә, ишекле-түрле йөри бу. Буйлы да, таза да кеше иде, мәрхүмкәй. Көч сынашка, тукмашуга китсә, миңа ирешмәве бик ихтимал. Шулай да үз бабаңнан куркып торып булмый ич инде. Кияү кеше бабайга һәрчак якын була.

Күтәрдем өйалды ишегенең келәсен, ачтым каерып ишекне. Өйалдында фонарь яна, кысып куелган, күтәрдем пилтәсен. Өйдән очып кына чыгасы булса, монда кармаланырга туры килмәсен, янәсе. Ә Сәхәриягә нәрсә, поскан ул минем артка, беләккә ябышып кына йөри, көянтә белән егетләр сыртын каезлаган чакларын оныткан, бахыр!

Ачтым өй ишеген дә каерып, хәтта тоткасы кулдан ычкынып китә язды. Тупсаны атлап кердем, Сәхәрия һаман минем беләктән җибәрми. Катып торам. Тирән каккан казыктай. Сәхәрия аркамнан сөйгән кебек булды, сыгылып төшмә, дип аңлатуы инде үзенчә, көч бирә миңа, ягъни.

— Бабай,— дидем,— Сәхәрияне миңа үз кулың белән биреп җибәрдең, безнең тормыш корып җибәрүебезгә каршы төшмә хәзер. Син дә, әби. Фатихаларыгызны бирегез.

Басарый абзаң идән уртасына аякларын киң җәеп баскан, кулларын биленә таянган, күлмәк изүе чишелгән, муенында кан тамырлары ташу суы ярдан чыгарга талпынгандай күперенгәләп ала. Әби яулык почмагы белән авызын каплаган, тора бүлмә тактасына сөялеп, баскан төшенә береккәндәй, аңлыйм аның хәлен, үзем дә шундый хәләттә ләбаса. Каршыда хыял итүдә җиңелгән Басарый абзаң күзләреннән өермә чәчеп карап торганда, керер тишек эзләгәнгәме әллә Сәхәрия беләктән кысып тотып тынычландыргангамы, мин шул чактагы дөньяны җентекләп күзәткәнмен. Шуңа күрә тамчы да ялган катыштырмыйча сөйлим боларны.

Йа ходай, шөкер, бабай карашын мич казнасы буена күчерде.

Йа ходай, бетте баш, ята ла мич казнасы буенда минем юныш балтасы... Түтәсендәге карлар эреп аккан, ак карның суы кызыл бугай ла, әллә буялган идәндә генә шулай күренәме соң...

— Их, Газизҗан, Газизҗан...

Акрын гына, теш арасыннан изеп-сытып чыгарып кына әйтте моны бабай. Ә тавышында хыял итү көрәшендә батырны тану йомшаклыгы да бар иде бугай. Миңа калса.

— Бабай, Сәхәрияне туры үзебезгә алып кайтмаган булсам, егет саналаммы инде мин?! Син үзең дә, бабай, холкың-гадәтең белән егет кеше, егетнеке егеттә калмас, кызны рәнҗетмәм. Егет сүзе!

— Менә сиңа Газизҗан...— Бабай сәкегә утырды да тезләренә йодрыклары белән сукты.— Балтаңны оныткансың. Мин ботакларны чабып атны бу якка чыгарганчы, җилдертеп өлгердең. Бурлы Кашкаң җилле икән. Минем Күк юртак та хәтәр җилле анысы, ләкин, әйтәм ич, мин атны чыгарганчы, күздән югалып өлгердегез. Җиткән булсам әгәр куып...

Өйдә ыгы-зыгы, әйтер идем, чын революцион хәрәкәт купты. Бабай белән кара-каршы утырып мин сөйләшәм, сүз җитмәс төштә кулларны бутап алабыз. Сәхәрия, юньле кияүгә чыгуына сөенеп, очынып йөри. Әбине әйтәм, олы як белән кече як арасында җил-җил килә, өйалдына чыгып нәрсәләрдер күтәреп керә. Моңарчы күзгә чалынмаган ике кайниш куышып ук уйный башладылар, ачуланучы юк үзләрен...

Шуннан соң мин бабай белән әбигә һәм бөтен Кылык халкына «Кияү Газизҗан» булып киттем.

Бурлы Кашка җигүле, капка төбендә безне көтә. Алып төштек бабай белән әбине үзебезгә һәм дә ике кайнишне. Томырылып юыртты Бурлы Кашка, шатлыкны ул да аңлый булыр.

Килештеләр кода-кодагыйлар.

Шулай Газизҗан бабаң хыял җигеп башлаган туй бездә ике көн, бабайларда ике көн дәвам итте. Сыйлар мул булды. Аннары, энекәем, ике йортның да кече якларында сәке түренә кунаклаган бал мичкәләренең бөкеләре бәреп атыр чагы җиткән булган икән...

Газизҗан бабай сөйләвеннән туктады, диван аркасына тагын башын салды. Өйләнүе хикәясен күз алдыннан кабат кичерә кебек тоелды ул миңа. Картының истәлеген бүлдермичә тыңлап утырган Сәхәрия әби:

— Балта турында әйтеп бетермисең мени?— дип сорады.— Белмидер ич ул аны.

— Әйе, балта һаман исән. Теге чакта бабай аны миңа кире бирмәгән иде, шушыннан да истәлекле кияү бүләгең булмастыр миңа, дигән иде. Юнышка гына тотты ул Ижау балтасын, йөзен чыгарырга вак сырлы Ижау игәве дә юнәткән иде. Өйнең бакчага караганын, монысына каршыга, сугышка чаклы җиткергән идек. Сез килеп фатирга урнашканчы. Бүрәнә чабарга шул балта белән булышты бабай. Вафаты алдыннан миңа бирде. Балта кайнишләрнең берсенә булыр иде дә, калдылар сугышта кайнишләр...

— Төп нигезебез дә бетте шулайтеп,— Сәхәрия әби тирән сулап алды.— Югыйсә бит, төпчек энем төп йортта калыр иде дә олысы, башка чыгып, авылны зурайтасы иде. Үзебезнең Кәшафетдиннең өч кызыннан соң туган беренче малае Фәрахетдин язга өйләнер ниятә, безнең нигезгә күчеп утырырга каршы түгел үзе. Тик һаман күңеле очынкы, нигез корырга тәвәккәлләп бетерә алмый. Шул баланың күңелен Әмирҗан абыйсы да аңламый ичмасам. Газизҗан бабаң, Фәрахетдингә йорт салганда үзем дә бүрәнә чабам шул балта белән, дип хыяллана. Ай-й аллам икән... Гомерен бирсен...— Сәхәрия әби Кылык хатын-кызларына хас базымлылык белән өстәде:— Бабасы Басарый нәселен Газизҗан үз иткән икән, нигә соң әле аның оныгы бу нәселне чит итәргә тиеш ди?! Минем дә оныгым ул, минем дә каным бар аңарда. Барыр безнең нигезгә, торгызыр нигезне Фәрахетдин!

...Авылларда йортларны һәм пуҗумнарны саныйлар икән. Тик бармак бөгеп санау өлкән яшьтәгеләрнең генә шөгыленә калып бара түгелме икән?..

## 5
### 1985 ел, хикәяләү башланган көн, өйлә алды

Хәкимҗан улы Газизҗан Хәкимҗановка атап килгән хат гарәп хәрефләре белән язылган иде. Элгәрәк заманның шактый ук укымышлы кешесе язган булуы беренче җөмләләреннән үк сизелеп тора, хәреф хаталары юк, хәрефләре сикерешсә дә, язуы матур. Хатны хәзерге әлифбага әйләндерик.

«Кем син миңа? Иптәш түгел. Һәм моннан соң да булмассың. Энем, дип шулай ук эндәшә алмыйм. Синең кебек эне миңа хәзер дә, соңгы түшәккә ятыр алдыннан да, кирәкми. Гәрчә мин синнән алты яшькә өлкән. Санап торма, хәтерем нык, алты яшькә кече син.

Хәкимҗан Газизҗанын, сине, синең безгә кылган әшәкелегеңне беркайчан да онытырлык түгел! Утызынчы елны гына исеңә төшер. Кем идек без, кем иттең син безне, бөтен авылга ямь биреп торган йортыбыздан мәхрүм иттең, йорт-җирсез иттең.

Хатны кем язуын төшендеңме?

Тәүфирә мин, Әлгый Фәсәхетдине җәмәгате.

Өзә-төтә язам. Кулларым тиз тала. Туксанны уздым. Картайдым, электәге җегәр тәнне ташлады. Күңелнең эреп агар чагы җиткән. Әмма сиңа ачу һич кимеми. Чөнки мин кичергән михнәтләргә син генә гаепле, власть түгел.

Властьны күптән таныдык без. Аңа хәтта авылдан чыгып киткәнче үк каршы түгел идек. Нэп чорында тагын баеп алдыкмы? Баедык. Продразверстка-продналогларда күргән зыяннарыбызны капладык. Без гаепле түгел моңа, чөнки нэпны Ленин үзе чыгарды. Электәге һәм нэп заманында тупланган байлыгыбыз колач киереп яшәргә җитте, һәрхәлдә, минем гомеремә җитте.

Без югалып калмадык. Үзебез кебекләр җыелып, далада авыл булып утырдык. Син, бәлки, Себердә черегәннәрдер, дип сөенгәнсеңдер. Башта балаларга сабак биреп, мөгаллимәлек иттем мин. Гаҗәпме? Түгел булыр. Чөнки мин Бишбалта гимназиясендә мәгълүмат ала башлаган кеше иче. Тәмам кылмасам да. Монысының үз сәбәбе. Монда укыта башлаганчы, мөгаллимәлеккә курслар уздым, мәктәпне үзем башлап йөреп оештырдым.

Онытылмыйсың, Кияү Газизҗан!

Синең кебек мәдрәсә сабагын дүрт кыштан ташлап качкан надан түгелмен. Тәүбә! Шөкерана кылам: ярый ла сиңа ары укырга язмаган! Гыйлемең байлыгы ташыса, син галәмне кочаклап алачак кешесеңдер. Булгансың. Җитәр-җитмәс дүрт кышлык мәдрәсә сабагың белән дә син безгә көчле дошман идең. Әгәр авыл башында синнән бүтән берәү торган булса, без андыйларны, ирем Фәсәхетдин еш кабатлар иде, алдыбызда бил бөктерә белер идек.

— Җанын тәненнән аерып газраилгә үзем тоттырыр идем... Ләкин аның җанын учка йомарлап бетереп булмый! Ә сыймастай булгач, учтан барыбер шуып исән калачак бу җан һәм көчен арттырачак кына, аны вакыт үзе дә тиз хәл кыла алмас,— дип үкенгән иде Фәсәхетдин, без авылдан чыгып китәргә төенәлеп беткәч.

Синең хакта иде бахырның сүзләре.

Фәсәхетдиннең сиңа бәясенә мин ышандым. Шуңа күрә хатымны да синең исән икәнлегеңә ышанып язам. Шулай да былтыр көз, авылдан без китеп илле биш ел узгач, синең исәнлегеңне беренче тапкыр белештергән идем. Исән генә түгел, нык сәламәт тә икәнсең.

Ә минем Фәсәхетдинем сугыштан орден-медальләр алып, шуларга алмашка кулын калдырып кайтты. Сызлануы соңгы көненәчә чамасыз булды. Фәсәхетдинне җир куенына былтыр көз куйдык. Аның вафатыннан соң гына мин синең хакта белештердем. Ирем исән чагында барыбер рөхсәт итмәс иде, чөнки ул исемеңне ялгышып та искә алмады. Малаем Каюм кайтып килде Кылыкка.

Каюм улым советча кеше булып үсте. Институт тыйлемле. Үзебез салган авылда, үзебез үк оештырган колхозда рәислек итә. Хәер, шактый соңлап оештырдык без аны. Колхозыбыз бай. Элекке кулаклар бит, байлыкка күнеккән кешеләр, эш майтара белүчеләр. Авылыбыз хәзер шәһәргә тиң. Йортны шәхсән үзебез монда да ике катлы итеп салдык.

...Ә без теге чакта атларны чаптырып урманга кергәндә, безнең ике катлы йортның ялкыны колач-колач учма очкыннарны күккә чәчрәтеп сибә иде. Мин, игезәкләремә шул куәтле янгынны күрсәтмәкче булдым, йөзләрен ачтым. Тик тәпи баскан гына күкрәк балалары ни аңласыннар соң инде...

Утны Фәсәхетдин үзе төртте. Абзар-курада мал-туар һәм кош-корт калмады. Аларны сата килгән идек, якын тиешлеләргә дә биргәләдек. Яндырмадык гөнаһсыз җан ияләрен... Көндездән үк чыгып киткән кара мәчебезне генә тапмадык. Мәче утта янмас, яңа хуҗа тапкандыр.

Нигезебездә күмелгән байлык юк. Эзләп барыбер куана алмассыз. Алтын-көмешләрне Фәсәхетдин бу якларга алдан китереп урнаштырган иде. Бетте инде алтын-көмешләребез, яңа урындагы пулатларны шул элекке байлыктан җиткердек.

Көзге төндә Кылыктан безнең белән чыгып китүчеләр сезгә моңарчы шулай ук хәбәр салмадылар. Мин дә алар хакында язмыйм. Кирәк санасалар, үзләре каләм тота беләләр. Әмма — ай-һай! Гәрчә Кылыкны алар туган җирләре булган өчен онытмаслардыр. Ә минем өчен сезнең өч мәхәлләле авылыгыз торган җир генә, чөнки мин үзем, Фәсәхетдингә кияүгә чыкканчы, кала мәхдүмәсе идем.

Шулай да хатны мин язам. Чөнки мондагы тормышны корганда, минем сүзем үтемле саналды. Һәр эшне мин башлап йөрдем. Югыйсә, тормышны үзгәртеп кормасаң, үсеш булмаячагын, яшәү юклыгын мин ныграк аңлый идем.

Максатым бер.

Уйлап кара, димен. Әгәр сез, иң башлап син, безне — байларны — кумаган булсагыз, байлык туплауда, хәзергечә әйтсәк, авыл хуҗалыгын күтәреп икмәккә туенуда, безнең белән — эшне кора белүчеләр һәм сиңа караганда укымышлырак кешеләр белән — бергәләп һәм киңәшеп эшләү җиңелрәккә һәм тизрәккә туры килер иде ләбаса! Синең һәм синең кебекләрнең шуңа гакылы җитмәде. Һәм чиләндегез. Бездән битәр чиләндегез.

Чынлыкта, илгә без күбрәк файда иттек. Чөнки файдаланылмаган байлыкны ил табынына башлап без — кулак булып куылганнар — бирдек. Җәһәннәм читендәге җирләрне үзләштерергә кулаклар көче кирәк иде. Ул чакта моны бары тик алар гына эшләргә сәләтле иде.

Әйе, ил табынына. Хәзерге газета-журналларны да укып барабыз без, туган телне җуймадык.

Авылыбыз зур. Безнең авылда төрле-төрле милләт кешеләре яши. Әйбәт кешеләр.

Зираты да зурая авылның. Шунда китеп барырга әзерләнү...

Хатны язды кала мәхдүмәсе, гимназистка, бай бичәсе, кулак хатыны, дала авылында мәктәп оештыручы һәм аның беренче мөгаллимәсе, ундүрт милләт кешесе яшәүче шушы авылда колхоз оештыручыларның берсе, шул колхозның беренче рәисе, инде шактый еллар атап бирелгән пенсиядә яшәүче, бүгенгесе көндә түшәк хастасына әйләнеп баручы, Әлгый Фәсәхетдиненең тол хатыны

Тәүфирә атлы кеше.

Язылды 1985 елның май аеның 25—30 көннәрендә».

Хат шунда бетә. Ләкин Тәүфирә карчык, соңгы юллар астындагы кысынкы урынга болай дип тә өстәгән:

Туган як урманнарының язгы матур көннәрендә.

Үзе искәрткәнчә, кулының хәле беткәндер, бу юллардагы хәрефләр бик калтыравык, хәтта монысын хат авторы үзе өстәмәгәндер кебек.

Газизҗан, хатны тәрәзә янагына сөялеп укыганда, җавабын кыска тотмакчы иде. Бүре баласын бүреккә салсаң да... яки ана сөте белән... һәм бетте шуның белән. Озынга сузсаң, аклану кебек булып тоелыр да, тормыш максатына хыянәт итүең ихтимал дип уйлады ул. Газизҗанга исә акланырга кирәкми, чөнки максатына һәрвакыт тугры ул. Булгандыр, булды ялгышлары, әмма алар явыз ният белән, әшәкелектән түгел. Түшәк өстенә менгән хаста карчыкка тормышның асыл мәгънәсен аңлатырга тырышу үзе үк мәгънәсезлектер, ул моңа хәзер инде барыбер төшенмәс. Һәм хатын-кызны, бигрәк тә хаста карчыкны тәпәләү егетлек түгел. Димәк, җавап кыска язылырга тиеш.

Ләкин идарә начальнигы Гаян Сәйфулов, Кылык гадәтен хөрмәтләмичә, сыңар чынаяк чәйдән соң ук машинасын кабызып китеп баргач, Газизҗан әлгәрге фикерен үзгәртте. Авыл хуҗалыгының куәтен бүгенгесе көндә тиз арттыруда өйрәтергә генә яратучы һәм нәрсәгә өйрәтүен үзе дә төшенеп җитмичә акыл сатучы шушындый түрәләрне дә гаепли иде колхоз агае.

— Әйе, колхозларны аякка бастыру өчен, өлкән һәм урта буын кешеләре күп чиләнде,— дип үзалдына сөйләнде Газизҗан, әле һаман да җавап хатын нәрсәдән алып китәргә белмичә.— Әмма ки колхозның, совхозның да, шулай аякта нык басып торуы гына хәзерге заман өчен аз. Аның йөгереп китүе кирәк. Вә ки хәзер чиләнмичә йөгерербез, кем... Тәүфирә карчык. Шуңа күрә юл күрсәтүче начальниклардан беренче чиратта тирән акыл белән эшләүләрен таләп итәбез дә... Соң, боларны җавап хатына язып куйсаң да була лабаса!

Һәм үзалдына сөйләнгән сүзләрен кәгазьгә төшергәч, болай дип дәвам итте:

«Тәүфирә-пенсионер, колхоз төзүең белән мактанырга ашыкмыйча тор. Илдә яшәргә теләгән кеше, шәһәргә күченмәсә, кумәкләшергә мәҗбүр булды, колхозның өстенлеген күрде ул. Шәһәргә күчүчеләрнең саны шактыйга җитте, авыл шул чакта күз ачып йомганчы кечерәеп калды. Соңарган аерым хуҗалыкларга колхозга керү өчен чын мәгънәсендә үтенеп сорарга туры килде. Һәм сез дә, кулаклар да, колхозлашырга мәҗбүр булдыгыз. Сезгә дә хөкүмәт ярдәм итте. Иң башлап, сезгә миһербанлы каравы өчен, хөкүмәткә рәхмәт укы. Шөкерана кыл. Җинаятьләрегез өчен конвой белән озатмау — безнең ялгыш!

Башлы хатын син, иреңне дә бөтерә идең, гәрчә аның үз явызлыгы да җитәрлек иде. Син, җилнең кайсы якка искәнен тиз сизенеп, колхозга тотынгансың. Вә ки син күмәк хуҗалыклар оештыруның илебез социализмга барганда зарури икәнлеген, хаҗәт икәнлеген үз мәнфәгатеңә кайтарып боргансың.

Ягъни, алга таба мин дә, син дә бер үк юлдан сәфәр тоткан кебек. Ләкин мин олы һәм туры юлдан барсам, син яшерен борылышлары бихисап тар сукмактан атлагансың. Һәм колхозыңны аякка бастыргач, син шул сукмактан, борылышларына да кермичә, кирегә туп-туры сыпыртырга күп сорап торасы кеше түгелсең икән. Синең кебекләр кызганадыр, бәлки — әмма яңа тормыш кирегә әлдертү сукмагыгызны кисте, колхозлар һәр җирдә дә, аякка баскач, йөгереп китәрлек көчтә.

Сез, башкалар хезмәте җимешен — без дә газета телән беләбез — татып яшәүчеләр, миннән ни өчен игелек көтәргә тиеш идегез икән! Шулай да Әлгый Фәсәхетдиненә һәм аның астыртын бичәсе Тәүфирәгә кылган әшәкелекләремне үземнең санау ниятем юк. Яшәү рәвешен үзгәрткәндә кылган ялгышлар булды. Мине дә бит йомшак уч белән гел аркамнан сөеп кенә тормадылар, чукмардай йодрык белән сиздермәстән арка чокырына күп тондырдылар. Шулай да миңа эшләнгән әшәкелекләрне санамастан, мин сезгә эшләнгәннәрен искә төшерик.

Егерме жиденче елда, өч гаилә берләшеп, атлы урак машинасы алдык. Шушы кечкенә ширкәткә мин башлык идем. Һәркайсыбызның арышын берәр көндә урып бетердек. Уру жиңеләйде безнең! Әмма бу машинага уру кырының зуррагы кирәк иде. Безнең машина өчен аеры жирләр кыйпылчык кына! Киләсе елга арышны, язын сабан ашлыгын, жирләребезне күршеләр белән алыштырып, бер төшкә чәчтек. Уруы чагыштыргысыз жиңел булды.

Кызыктылар безнең машинага. Синең Фәсәхетдинең дә күзен ялтыратты! Үзе, акчасы юк, янәсе, машина сатып алмаган иде. Әйе, акчасы юк, имеш! Килеп сорады Фәсәхетдин абзаң миннән машинаны, арыш коелып бетә, акча юнәтеп ничек тә түләрмен, ди. Хәер, элгәре синең белән киңәшкәндер яки үзең үк киңәш иткәнсеңдер, әйтәм ич, яңалыкны үз ягыңа каерырга хәйләкәр бичә идең син. Бирдек сезгә машинаны. Түләвен үзебезгә алмаска булдык.

Безнең авылда Мөбарәк Гафифәсеннән тиз уручы кеше юк иде. Ул, сезгә ялланып, көненә өчәр чүмәлә куйган. Һәм көненә егерме тиен түләү алган. Болар революциягә чаклы булган. Гафифә апа авыру иде инде, егерме сигезенче елда ире Мөбарәк абый вафат иде.

Синең Фәсәхетдинеңнән, безнең урак машинасыннан файдаланганы өчен, тиешле хакны сезгә урак урып чиләнгән Гафифә апага үз күз алдымда бирдерттем. Нигә аңамы? Үземнең сезнең кулдан акча алып пычранасым килмәде, ә Гафифә апага сезнең исәпләнмәгән бурычыгыз күп иде. Хәтерлә, Тәүфирә бичә, акчаны, бирмәс өчен, кулыңда шытырдатып кысканыңны онытма. Әмма ки түләргә мәжбүр булдың. Бу вакытта, егерме сигезенче ел урак өстендә, мин авыл советы рәисе булып сайланган идем инде.

Сез — кулак гаиләсенә кылган әшәкелегемнең берсе шушы — Әлгый Фәсәхетдиненә урак машинасы биреп тору, машинадан файдаланган өчен хакны аның бичәсе Тәүфирәдән түләтү. Әйе, акчаны син саный идең, Фәсәхетдин түгел.

Миңа жибәргән хатыңдагы фикерләреңнең барысын да юкка чыгара алам. Тик файдасын күрмим. Ә хәбәр салу максатың турындагы сүзләреңне жавапсыз калдырырга тиеш түгелмен.

Кулак белән ярлы крестьян күмәкләшә ала иде, дисең. Мөмкин хәл түгел. Бай белән ярлы беркайчан да бер казаннан ашамаган. Ленин әсәрләрен укымагансың, надан калу мөгаллимәгә килешми. Күмәкләшү чорында, кешеләр хосусый милекчелектән аерыла башлаганда, кулак агай, төсен-йөзен генә үзгәртеп, крестьянга иш булырга төрлечә кыланып карады. Бу хакта синең сүзләрең яңалык түгел. Кулакларга колхоз капкасын ачсаң, сез безнең арба тәгәрмәченә таяк тыгу өчен жай гына эзләячәк идегез. Авылда социализм төзү өчен кулакны сыйныф булу ягыннан бетерү — мәжбүри шартларның берсе иде.

Кулакларны куарга тиеш идек без. Һәм кудык! Дөрес эшләдек! Ә далада колхозларны сез безнең үрнәктә төзергә мәжбүр булдыгыз. Чиләндермичә акылга утырмаячак идегез сез.

Жирләр колхозларга мәңгелеккә файдаланырга бирелгәч тә, кулак калдыклары эшләгән корткычлыклар жан тетрәткеч булды. Кайтып йөрмәдек, дисең. Ай-һай ла! Кулак кылганнарны газеталардан укып булса да белергә тиешсең. Әйтик, Кылыктагы Түбәкуак хәлләрен. Күп шаулады халык бу хакта, газеталарда да яздылар. Һе, өйләренә ут төрткәнче жан иярен — күзге чебешләренә кадәр — тыныч жиргә урнаштырганнар, имеш! Әгәр бөтен авылга ут капкан булса?!

Без күмәкләшүгә каршы түгел идек, дисең. Монафикъ булу һичкайчан бизәми адәми затны, ахыр килеп, түшәк өстенә калгач булса да онытырга кирәк иде икейөзлелекне.

Һе, жиргә сеңгән өйле ярлы крестьян белән ике катлы дәү йорт хужасы күмәкләшү хакында гомере буена хыялланып яшәгән икән лә ич! Хәкимжан Газизжаны шуны да аңламаган, ә?

Әйе, хатында бер хаклык бар. Совет властеның беренче елларында белем бирүне оештыруда мөмкинлекләр чамалы иде. Мәктәпне без егерме алтынчы елда ук салдык. Безнең Кылыкта салынган беренче совет мәктәбе иде ул. Ике генә класслы иде. Аны миңа чаклы авыл советы рәисе булып эшләгән Саттаров Хәниф абый салдыртты. Боларны онытмагансыңдыр. Утыз беренче елда инде мәктәпне җиде класс бүлмәле итеп өлгерттек. Ә хәзерге мәктәп өч катлы, барлык кирәкле бүлмәләре белән, Мишә суы тутырылган бассейнында балалар кышын да чумып йөзәләр. Фән сарае безнең хәзерге мәктәп!

Әйе, күбәүләргә, һәм миңа да, махсус уку йортына кереп белем алу тәтемәде. Гыйлемлекне, тормышның бүтән мәшәкатьле шөгыльләре белән бәйләп, үзлегемнән баетам. Мактанаммы? Мактанам бераз, чөнки гыйлемем безнең тормышның асылын ялангач итеп күрүче мөгаллимә гыйлемлегеннән баерак икәнен белдем. Хатынны укыгач.

Җитәр.

Авылда күмәкләшү өчен көрәштә минем җиңүем бәхәссез. Илдә җәмәгать милке, иҗтимагый байлык булдыруда, бик беләсең килсә, авыл үзенең күмәкләшүе белән хәтта эшче сыйныфка, интеллигентка билгеле дәрәҗәдә үрнәк күрсәтте. Минем фикер бу, һәм мин аның дөреслегенә ышанам.

Ә сезнең тарафлардан, нәкъ синнән, димим, көч сынашырга чакырып хәбәр салуыгызны көткән идем мин.

Хатны язды чыгышы буенча революциягә чаклы батрак малае, революциядән соң җирле крестьян, урта хәлле крестьян һәм кызылармеец, Кылыкта 1928—1929 елларда авыл советы рәисе, Кылыкта колхозга керергә беренче булып язылучы һәм аның беренче рәисе, сугыштан, орден-медальләренә өстәп, тәнендә мина кыйпылчыклары да алып кайтучы, өлкәнәя төшкәч булса да экстерн тәртиптә имтихан тотып җиде класс белемле, инде шактыйдан персональ пенсиясенең яртысын Тынычлык фондына күчереп баручы, Кылыкның басу-кырларында, болыннарында йөрүдән туймаучы, бүгенгесе көндә сәламәтлегеннән зарланмаучы, коммунист Хәкимҗан Газизҗаны.

Язылды 1985 елның печән өсте җитәр чакта, июнь аеның Сабан туен якынайтучы бер көненең төш уңаенда».

Гаян Сәйфулов, идарәгә туры бармыйча, юл уңаеннан фатирына кереп чыгасы итте. Кичен эштә тоткарланырга туры киләчәк. Авылдагы бүгенге эшләр турында идарә белгечләрен чакыртып шелтәләмәкче иде ул. Газизҗан картның бер чынаяк чәенең җегәре озакка бармады. Шуңа күрә өендә коры-сары булса да капкалап алырга кирәк иде. Гаян, машинасын туктатып моторын сүндерүгә, көтелмәгән хәлдән сискәнеп китте: ак тавык, алгы ике утыргыч арасыннан гәүдәсен яртылаш чыгарды да, тизлек тоткасының эчендә чәчәк бизәкләре калдырып койган йомрысын чукып карагач, кытаклап җибәрде.

Менә оят: тавыкны берәрсе күреп китсә, идарә начальнигы колхоздан үзенә тере хайван ташый, яңа суйган мал ите генә ашый икән яңа начальник, дип гайбәт таратырга да күп сорамас. Дәрәҗәңә сукты диген ул чакта, шушы ак тавык. Әллә муенын борып ыргытыргамы соң? Бер тавык бәясен түләр иде әле. Түләмәсә тагын, бер тавыкка калмаган Хәкимовлар, бай күренәләр. Әмма гомерендә бер тавык суймаган килеш, ни кодрәтең җитеп аның башын борып ташлыйсың...

Гаян, капканы ашыгып барып ачты, машинасын ишегалдына кертте. Тавык чыгып качмасын өчен ишекне томалап ябып, телефонга йөгерде.

— Алло! Кылыкны тоташтырыгыз! Председатель Хәкимовны хет җәһәннәмнән табыгыз! Алло, алло! Кылыкмы? Хәкимов, синме?!

— Мин.

— Сезнең колхоздан кайттым гына әле.

— Күрмәдем.
— Кайда идең?
— Эштә.
— Канцеляриядә юк идең.
— Басуларны әйләнеп, игеннәрне карап йөрдем. Силос салырга әзерлекне тикшердем.
— Начальник киләсен белеп торырга кирәк.
— Алдан әйтергә иде. Йомыш белән йөри идегезме соң?
— Ничек?!
— Колхозга килеп, аның председателен дә күрмәгәч, димәк, эшсез йөргәнгез булган.
— Да, авыз зур ачыла икән синең... Ярар, бүтән чакта тел шомартырсың. Ә хәзер уракка әзерлек турында докладывай!
— Ремонтлыйбыз. Тик запчастьләр житми.
— Тап. Син шуның өчен куелган.
— Мин сайланган кеше, постка куелган кеше сез ул.
— Да-а, кирегезгә беткән кешеләр икәнсез, этиең дә, син дә.
Начальник трубканы каплап сүгенде. Гадәтенә кергән бу шөгыленнән аны Кылык колхозы председателенең иркен тавышы колагын тырнап бүлдерде:
— Иптәш Сәйфулов, миңа ни йомыш белән шалтыратуыгыз соң әле? Комбайннар ремонты турында белергә теләсәгез, сез моны сводкадан карый аласыз. Бүгенге көнгә мәгълүматларны кичә кичтән генә идарәгә тапшырдык. Алдашмадык, дөрес мәгълүматлар. Инде запчастьләрне үзебез табарга кушып шалтыратуыгыз һәм безгә килеп-китүегез дә шуның өчен генә булса, миңа моны әйтеп тә тормагыз. Идарәнең тәэминат белән чынлап торып шөгыльләнмәячәгенә иманым камил. Давай ашлык, давай сөт, дип оран кычкыруны житәкчелек итүгә саныйсыз.
— Слушай, Хәкимов, партияне тәнкыйтьләвеңне төшенәсеңме син?
— Нишләп партияне?! Мин иптәш Сәйфулов эшеннән, ягъни сез начальник булган авыл хуҗалыгы идарәсе эшеннән канәгать түгеллегемне әйтәм.
Гаян беркадәр ара җавапсыз торды.
— Карале, Әмир Газизович, мин сезнең өегездә булдым.
— Бик әйбәт. Чәй эчертергә эти өйдә иде.
— Эчтем. Бер чынаяк.
— Нигә берне генә? Кимендә икәү тиеш. Татар гадәте буенча. Әни шуны белсә, сезне өйгә бүтән кертмәячәк бит.
— Сездә кабат булырга теләгем зур түгел.
— Кыстамыйм.
— Әмир Газизович, сезнең ак тавык минем машинада кайткан.
Трубкадан шаркылдап көлгән тавыш яңгырады.
— Нәрсәсе көлке моның?
— Көлке булмыйча соң! Тавыкның ерак сәфәре — әрәмәлек, диләр иде, ә безнең тавык, әрәмәлекне узып, район үзәгенә барып житкән!
— Шоферыңны җибәр әле, алып китсен тавыгыгызны.
— Нигә мин машина җибәрергә тиеш ди?! Машинаны кем хисабына куыйм, иптәш начальник? Алып киткәнсез, китереп бирегез. Китермәсәгез — шулай ук сезнең эш.
Сәйфулов трубканы шап итеп куйды.
Авылның урта турына, мастерскойлар һәм техника паркы янына, бакчалар башына чыгарып ак кирпечтән ике катлы итеп салынган идарә йортының колхоз председателе бүлмәсендә шаркылдап көлү кабат яңгырады. Әмир Газизов ачык тәрәзә янына килеп басты. Аның карашы, беренче булып, тыкрыкларда һәм бәрәңге бакчаларында актарынып-чүпләнеп йөрүче ак тавыкларга төште. Кычкырып көлүеннән туктады, тын алгач, кеткелдәүдән шулай да тыела алмады.

Ишек шакыдылар.

— Керегез.

— Кәефләр шәпме, Әмир абый.

— Күреп торасың лабаса — шәп бит! Көлүдән туктый алмыйм. Нинди җинел заманалар житте бит, ә, Фәрах энем, көлеп кенә эшлибез!

Председатель, ачык тәрәзәгә үрелеп, нәрсәгәдер сагайды, аннары башын чыгарып, комбайннар тезелеп торган уңайга кулын изәде. Кемгәдер нәрсәдер тыеп боеруы булды бу аның, әмма тел белән әйтеп аңлатмады. Кулъяулыгын алып, тирләгән йөзен каты ышкып сөртте. Һәм болай да алсу табак бите кызарып ук чыкты. Әмир өстәле артына бармады, стена буйлап тезелгән урындыклар арасыннан икесен идән уртасына җилтерәтеп кара-каршы куйды да түр яктагысына үзе утырды, аның гәүдәсе авырлыгыннан урындык сыкрангандай шыгырдады.

— Утыр, Фәрах агайне. Ни йомышың төште?— Егет ишек катыннан килеп җиткәнче, калын кашларын уйнатып, чәнчеп алды:— Сездән безгә ни кирәк?

— Әй, Әмир абый, иплән кенә сөйләшикче! Төртке сүзләргә минем үземнең дә осталык тулып ашкан. Бертуган абыеңның төпчегеннән бер елга элек туган малае ла мин. Анысы, Фәрахтан сезгә кирәк нәрсәләр дә булуы мөмкин. Нигә булмаска ди!

— Алайса, бездән сезгәниләр кирәк?

— Күп кирәкми, Әмир абый. Син мине үз эшемә кире ал. Шул гына.

— Шул гынамы?

— Шул гына, дим ич инде.

— Чамасыз күп сорыйсыз. Гозереңне үтәп булмый. Инде болай дисәң: Әмир абый, мин синең белән саубуллашырга кердем, бүген үк калага китәм, район үзәгенә автобуска хәтле...

— Тотынды тезәргә!

— ...автобуска хәтле җәяү барырга горурлыгым ирек бирми, колхоз «Волга»сы белән озаттырчы, дисәң, ике куллап риза. Нәкъ йомыш та төшеп тора иде, райүзәктән тавык алып кайтасы бар.

Фәрах, зур күзләрен уйнатып, ялтыравык кара түфлиләрен бер-берсенә каккалап, джинсы чалбарының бот буена салынган кесәсенә баш бармагын кертеп, бүтән бармаклары белән гармонь телләренә баскан кебек итеп, председательне тыңламагандай утыра. Әмма Әмирнең сүзләрен ишетә икән.

— Суйган тавыкмы?— дип сорады ул һәм почмактагы телевизорга беренче күргәндәй чекерәеп карады.

— Тересен!

— Соң, бер тавык өчен генә райүзәккә машина кума. Үзегездә тавык аз икән, бездән алып төш. Култык астыңа кыстыр да тәпи-тәпи генә...

— Минме?

— Син булмыйча. Миңа тавык кирәк түгел ич.

— Сиңа берни дә кирәкми.

— Сиңа күп кирәк. Әнә, телевизор алдырып, кабинетыңны бизәгәнсең бит. Төслесе, әй. «Фотон» дигәнеме соң, әллә «Горизонт»мы?

— «Лазурь».

— Колхоз акчасына инде, кәнишне.

— Ни өчен мин аны үз акчама алырга тиеш ди әле?— Әмир урыныннан җәһәт торды да телевизорны кушып җибәрде.

— Ни өчен алмаска тиешсең? Аны син үзең генә рәхәтләнеп карыйсың бит.

— Син дә кара! — Председатель, телевизор жылынып сурәт күрсәтә башлаганчы, аны сүндереп тә куйды.

— Карыйм ич. Шәп күрсәтә...— дип көлде Фәрах.— Әмир абый, зәһәрең кайчан бетә?

— Иртәгә!

— Сөйләшүне иртәгә калдырырга микәнни соң инде. Бүген хәл итәсе иде бит. Әти борчыла, кичә аракы эчте.

— Әчмәгәе! Әчкән кеше ерак китә алмый, хәзер закон каты!

— Алай ярамый инде, Әмир абый. Минем әти синең бертуган абыең бит.

— Шуннан?

— Шуннан болай: мин сине, Фәрахетдин пеләмәш, диген, эшкә алам, диген. Минем братанга хәсрәт чиктереп йөрмә, Фәрах энем, ну... малай актыгы, дип тә өсти аласың. Анысын әйтмәсәң дә була, әлбәттә, чөнки минем дә серкә су күтәрми. Аннары да килеп, Фәрах атлы асыл егет тишек төпле ләгәнне барабан итеп кагып уйный торган тиле түгел.

— Шыр тиле син!

— Шыр акыллы!

Фәрах урыныннан торды, чалбар-күлмәген сыпыргалап төзәтенде.

— Каян килде соң әле сиңа мондый көязлек?— дип гаҗәпләнде Әмир, янына Фәрах килә башлагач, өстәле артына узып.

— Каян түгел, кемнән, диген. Синнән өйрәндем.

Әмир, шаркылдап көлеп, әйләнмә кәнәфиенең таянсаларына шапылдатып сукты.

— Миннән?— дип тавышын йомшартып сорады ул.

Фәрах, җавап кайтармыйча, мотоцикл ачкычының чылбырын бармагына киертеп әйләндерүен белә иде.

— Әмма мотоцикл ачкычын зыр әйләндерергә минем осталыгым җитми.

— Аның каравы, син кешеләрнең башын әйләндерергә оста.

— Нервыларымны тәмам кыздырасың бит син!— Әмир башын чайкап куйды.— Үзең беләсеңме хет шуны?

— Мин бик изге эш башкарам, Әмирҗан абыкай,— диде Фәрах, председательгә акрын-акрын якынаеп.

— Нинди?

— Мин синең нервыларыңны бозмыйм, ә кузгалган нервыларыңны тынычландырам.

— Һе!

— Хак дөресе. Көлгән тавышың ишетелгәч, мин синең кәефең шәп дип уйлаган идем. Ә син райүзәктән «Волга»га тавык кунаклатып алып кайту турында хыялланып утырасың икән. Инде кече башымны неп кергәч, мәсьәләне хәл итмичә чыгып та китә алмыйм. Син дә үз сүзеңә беткән, мин дә сиңа иш. Кайсыбыздыр юл куярга тиеш. Иначе — орыш, кырыш, сугыш. Бу очракта Әмирҗан абый пләмәше Фәрахетдингә юл бирергә тиешле.

— Мин?

— Син. Тагын бер мәртәбә сорыйм: мине эшкә аласыңмы?

Председатель, өстәлгә җәелеп таянып, башын аска иде. Аның баш түбәсе такырая башлавын күргәч, Фәрах, иртә пеләшләнә председатель, безнең әтинең, аңардан, тәк, унсигез яшькә өлкәнрәк булса да, чәчләре агармый да, коелмый да, дип уйлады. Әмир башын салмак кына күтәрде, Фәрахка озак карап торгач:

— Син, Фәрахетдин братулла, колхозны керделе-чыктылы...— ул, күзләрен кыса төшеп, нәкъ кирәкле сүз эзләде,— керделе-чыктылы хуҗалык дип саныйсыңмы әллә? Колхоздан чыгаруны сорап гариза яздыңмы? Яздың. Үтенечең канәгатьләндерелде. Хәзер кабат эшкә алыгыз, дип тинтерәтәсең. Алдык та ди, бераздан тагын, җибәрегез, дип, гаризаңны җилфердәтеп йөрерсеңме? Аннары тагын кайтырсың да тагын китәрсеңме? Җир кешесе юл тиресләми ул, җирдә ябышып ятып эшли. Ә син колхозны, җир хуҗасын мыскыл итмәкче буласың. Ю-ук, Газизов Фәрах иптәш, моңа колхоз да, җир хуҗалары да юл куя алмый. Күмәк хуҗалыкның максаты һәм асылы бай яшәү генә түгел, ә бәлки хокукый тигезлектә матур итеп яшәү. Мин шуларны хаклыйм.

һәм боларны бозу ямьсезлек чоңгылына батыра. Син исә, Фәрахетдин, тигезлекне һәм матурлыкны санга сукмыйсың, байлык ягын гына кайгыртасың. Ничек килеп чыга инде: без, туганнар булсак та, бер-беребезгә дошманнар икәнбез. Уйладыңмы шул хакта?

Фәрах, чигәсен кашый-кашый, озын өстәл буеннан урындык тартып утырды.

— Тирәнгә кереп киттең лә син, Әмир абый. Бүтән китмим, дим бит инде. Өйләнмим дә! Ник чәнчелеп китми шунда... Хәер, бернәрсә дә чәнчелмәсен.— Фәрах тынычлыгын җуя башлады, шаянлыгы сыпырып алгандай югалды, җилкәләрен сикерткәләде.— Дошман түгел мин сиңа, Әмирҗан абый, энең мин синең! Әти сөйләшеп караса да, үз кирелне тукырсың инде син, хәтта Газизҗан бабай сүзен дә тыңламассың. Валлаһидыр, синнән дә үҗәт кеше юк безнең нәселдә. Сиңа Рәсиха җиңги ничек түзеп яшидер, ходай ярдәмен бирсен үзенә!

— Соң, алла колы Фәрахетдин,— дип пеләмәшенең көенә салды әңгәмәне Әмир,— соңгы тапкыр сорасаң да, минем сине эшкә алырга хакым юк. Башта син колхозга член булып керергә тиешсең, ә моны бары тик гомуми җыелыш кына хәл итә.

Әмир абыйсының холкын Фәрах әйбәт белә, аны мәсьәләдән сиздермичәрәк читкә сөйрәштермәсәң, җаена китерүе кыен. Ләкин хәзергә председательне бөтенләй буташтыра алган кеше юк. Шулай да тырышып карарга кирәк, белмәссең, дип өметләнгәннәр бабайлар мондый чакларда. Һәм егет председательнең сүзләрен ишетмәмешкә салынды, үзалдына сөйләнеп утыра бирде. Әмир абыйсы әңгәмәне тәмамларга ашыкмый бит, димәк, кырт кисмәгән.

— Авыл белән шәһәр арасындагы аерманың йогын да калдырмыйбыз, дибез. Мактанырга кирәк булса, колхозлар төзүебез белән авылны шәһәргә якынайттык, хәзер аерма юк дәрәҗәсендә, дип тә җиффәрәбез. Булмаган ди! Мине шәһәргә теләп тә пропискага кертмиләр. Фәрзанәне авылга прописать итеп була, әмма үзе теләми. Каршылык түгелме инде бу? Антагонистик каршылык! Шулай булгач, мине хәзерге көндә шәһәргә пропискага биш кулларына ун каләм тотып язсалар да, авылда торачакмын, ягъни Фәрзанәне онытып, антагонистик каршылыкның тамырына балта чабачакмын. Авылда яшәүне философ Фейербах та яклаган.

— Әйе, философ Фәрах-Фейербах, син шәһәрдә ни майтара аласың соң? Шәһәрнең үз хөрәсәннәре дә җиткән. Шәһәр мәйданында комбайн белән урак урдырып булмый. Синең урының менә шушында, колхоз жирендә иде. Гәүдәң генә түгел, җаның да очкалак синең. Колхоз җире тиз сагындырды Фәрахетдинне, ә! Шәһәрдә син, иң күбе, трамвай юлы чистартып, тротуар пычратып йөрер идең, ялгыз тамагыңны туйдыра алмас идең. Ә колхозда почет Фәрах Газизовка, комбайн бункерын тутырып акчасын ала! Былтыр уракта, айга күчереп исәпләгәндә, дүрт йөз алтмыш өч сум акча алдың син. Шәп саныйм мин, председатель башымны уйлатып саныйм. Әле колхозның механизаторга һәм терлекчегә, гомумән, һәр колхозчыга, бүтән өстенлекләрен ходай ярдәме итеп исәплибез. Фәрах кебекләр шулай исәпли. Син бит, әти әйткәндәй, агайниш, акча колына әйләндең. Булган акчаңны ике арада киләп сарып туздырып бетердең. Әгәр хәзер кулыңа житешле акча тоттырсаң, шул акча сиңа хуҗа булып ала һәм син секунды-минуты белән авылдан чыгып йөгерәсең. «Волга» белән озаттырганны көтмисең. Янәсе, үз көче белән урак өстендә колхозда эшләп, күп акча каера да тагын китеп бара. Эшкә алуны сорарга акчаң юклыгы гына мәҗбүр итә. Димәк, колхозны син акча сыгу чыганагы итеп исәпли башлагансың. Акча эшләргә бүтән җаең булса, җилкә аша гына тәкерәчәксең син колхозга. Мин шуны да аңламаслык аңгыра түгел, агайниш. Бигайбә.

Колхоз председателе белән колхоздан гариза биреп чыккан механизаторның бәхәсендә олысы үзенең хаклыгына таянса, кечесе, моны таныса да, иҗтимагый ялгыш ясамавына инанып, үз фикерен туглый.

Ара-тирә чәнечкеле сүзләр әйтешеп шаяртуга күчсәләр дә, бәхәснең асылы тирәндә икәнен аңлыйлар алар. Колхозларга үз жиренә тамырны нык беректергән кешеләр кирәк, димәк, ахыр килеп, коммунизм җилбәзәк-очкалаклар җәмгыяте түгел — председатель хаклы. Шәхси тормышның аерым мәсьәләләрен, атап әйткәндә, мәхәббәт газапларын социализм чишә алмады, коммунизм үзе дә моны хәл итмәс, мәхәббәт гомер-гомергә үзенчә булган һәм мәңгегә үзенчә булып калыр. Мәхәббәтнең җәмгыять кануннарына сыешмавы гел булыр — заман крестьян-механизаторы шулай ук хаклы. Капма-каршы хаклыклар үзара сыешырга тиеш тә, без роботларга әйләнербезме? Юк, без — кешеләр, һәм кешеләр булып калырбыз.

Бәхәс куертучыларның икесе дә матур әхлакый якларны үзәктә тотарга онытмыйлар кебек югыйсә. Председатель Әмир турыдан бәрсә, механизатор Фәрах читтәнрәк суктыра.

— Философларча тирәнтен уйласаң,— дип дәвам итте Фәрах, ишекле-түрле адымнарын сузыбрак атлап йөренергә тотынган Әмиргә кырын күз генә төшереп,— минем колхоздан чыгарга гариза язуыма колхоз идарәсе гаепле.

Инде председатель бу сүзләрне ишетмәгәнгә салышты.

— Һәм иң башлап аның председателе гаепле.

Әмир монысына да илтифат итмәгәндәй булды, пеләмәшенең бәхәсләшү ысулын кабул итте.

— Уракта комбайнчылар ярышы шартларын председатель житәкчелегендәге идарә эшләде. Минем барыбер жиңеп чыгасымны белә торып, беренче урынны алучыга туристик путевка куйдылар. Шулай итеп, түмәр генә буйлы булу сәбәпле армиягә дә алынмаган һәм туган авылыннан кендеге дә өзелмәгән Фәрахетдин исемле алтын куллы егетне Балтик буе республикаларына сәяхәт кылырга мәҗбүр иттеләр. Гәрчә җинаять эшләмәгән кешегә карата мәҗбүри рәвештә көчләү кулланыла алмауның социализм казанышы икәнлеген идарә әһелләре һәм аның башында торучысы белергә тиешләр иде. Алар, ярыш шартларын эшләгәндә үк, урак батыры чандыр Фәрахның Рига шәһәренең нәкъ уртасында чибәр кыз Фәрзанәне яратачагы, ягъни үлеп гашыйк булачагы турында анык акыл белән уйларга бурычлылар иде. Шулай итеп, колхозның кайбер житәкчеләре, үзләренең акыл сәламәтлеге какшавын социализмнан коммунизмга бару чорыннан яшереп, явызлыкның чигенә житәләр, ягъни изге байлык белән тулы ике яшь йөрәкне... мәхәббәт газабына бәйләп салалар.

— Сураеп йөргән егетләрне мәхәббәт газабы чиктереп, житәкчеләр бик дөрес эшлиләр,— дип ялгап китте Әмир, йөрүеннән туктамыйча.— Беренчедән,— ул уң кулын Фәрах ягына сузып чәнти бармагын бөкте,— кайбер егет затлары, сазаулык бусагасын атлап керергә жыенулары белән, нәселне югалтуга таба баралар. Икенчедән,— атсыз бармак та бөгелде,— өйләнү өчен шәһәргә таярга, диелмәгән философларның хезмәтләрендә. Электә сала кешесе, гомумән, калага китмәгән, ә туган туфрагында яшәгән. Киресенчә, шәһәр агайларының авылга кайтып төпләнү очраклары аз булмаган. Әйтик, философ Людвиг Фейербах авылга кайтып, беркая да китмичә диярлек, егерме биш ел яшәгән һәм эшләгән. Ә хәзерге заманның үз дәрәҗәсен өреп кабартучы, җил тегермәне коручы, теле белән, әлбәттә, философы Фәрах Кәшшафи, урак өсләрендә генә авылга кайтып күп акча эшләп, елның калган вакытларында сөеклесе Фәрзанәне Рига урамнарында читтән генә күзәтеп яшәмәкче була. Моңа саллы дәлил — Фәрах Кәшшафиның Фәрзанәгә булган кайнар гыйшкыннан ваз кичәргә җыенуы.

— Шулай итеп, Әмир Хәкимовның үзен генә яратуы чире табылды. Кызганыч хәл. Чөнки эгоизм дигән чир бик йогышлы авырулардан санала. Председательнең бу чире июнь ае кояшы жир кешеләрен чиксез сөендергән бүгенге көндә читтән узып азды. Моның ярылып ята торган чагылышы түбәндәгеләрдән гыйбарәт. Беренчедән, Әмир Хәкимов бер-

туган абыйсы Кәшшафетдиннең озак көтеп алып туган малае Фәрахетдинне яраткан эшенә кире алса, колхозчылар каршында җавап тотудан курка, үзе турында гына уйлый, ягъни мәсәлән, бары тик үзен генә ярата, димәк. Икенчедән, социалистик ярышта күп тапкырлар җиңеп чыккан комбайнчы Фәрах Әмир абыйсының хәзергесе сәгатьтә теңкәсен корытса да, аның, өенә кайтып көләч Рәсиха җиңгине күргә һәм малае Җиһангирны йомшак җиреннән сөюгә үк, нервылары тагын корычка әвереләчәк, ә Фәрах җебегән мондый мөмкинлектән мәхрүм — уңган егетнең хатыны юк, хатыны булмагач, малае юк та юк.

— Фәрахның үзен этисе кайчандыр йомшак җирен сөеп шатлана иде. Ләкин хәзер моны эшләп булмый. Бүгенгесе кояшлы көндә очкалак егетнең йомшак җирен тукмап кына этисе Кәшшафетдин үзен бераз тынычландырырга мөмкин. Һәм ул моны бертуган энесе Әмир Газизов алдында берничә минуттан бик теләп эшләр дип чын күңелдән ышаныйк. Әнә, Кәшшаф абый үзе монда кереп килә.

— Ә-ә?! — Фәрах атылып тәрәзә янына барды һәм болайга таба килүче этисен күрде.— Чын, әй!

Кәшшаф гәүдәсен алга чайкалдырып, сүлпән атлый иде. Адымыннан ук талчыгу сизелеп тора, әйтерсең, гәүдәсен аяклары йөртми, ә бу аяклар таккан кебек кенә иде. Салмаклык тәбәнәк гәүдәле кайберәүләрне буйга үстереп җибәргән кебек итеп күрсәтә, горур кыяфәт кертә. Ләкин Кылыкта Җәһәт кушаматын лаеклы булып алган Кәшшафетдингә бүгенге салмаклыгы бөтенләй дә килешми иде.

— Әмир абый, дус,— дип чигенә башлады Фәрах,— эти монда керәсе булгач, мин хисапчылар бүлмәсенә чыгып торыйм. Син аны көйләп-җайлап һәм тиз генә өйгә кайтарып җибәр инде. Безнең югары дәрәҗәдәге әңгәмәбезне, мәгълүм җитди сәбәпләр аркасында, вакытлыча бүлеп торырга мәҗбүрмен. Сөйләшүләр туганнарча эчкерсезлек һәм агайниләрчә аңлашу шартларында барды. Шөһрәт казанган колхоз председателе һәм потомственный комбайнчы арасындагы моннан соңгы әңгәмә дә, ә без аны эти китүгә үк возобновим, вполне прилично дәвам итәр, дип ышанам.

— Авыл белән шәһәр арасындагы каршылыкларны бетерү буенча изге эшкә тотынып юл тиресли торгач, телегезне шактый шомарткансыз сез, философ Фәрах Кәшшафи...

## 6

### 1930 ел, февральнең ике киче, урта төштә 1929 елның декабрь башына кайтып

Газизҗан волкомда һәм волбашкармада йомышларын бетергәндә, кич якынлаша иде. Моңсу булыр сыман бүгенге кич. Төнлә җиргә чатнама суык җәелеп кунаклыйсы хәбәрен сөенеп ирештергән кырыс кичләр февральдә еш була. Мондый чакта һаваның үзалдына тыгызланып, биткә ышкылуын тик басып торганда да тоясың. Бүген һава, мамык кар бөртекләре очкалагангамы, йомшак. Кояш баеды, ә аның турысындагы җете яктысы качкан төшен белдереп тора. Газизҗанның Кылыклысы әнә шул турыда, аның авылында кояш иртәрәк байый. Кояш чыгышында караңгылык куерып күтәрелә, аның карасы да җете. Җир дигәнең чынлап торып түгәрәк, әй, менә хикмәт.

Бурлы Кашка хуҗасының килүен күрде, башына элгән буш солы капчыгын селкеде.

— Ашап бетерденме,— дип ат янында сөйләнде Газизҗан.— Шунысына туеп торырга туры килә, җәйне житкерергә шактый әле.— Ул ат өстенә япкан толыпны селкеп чана башына салды. Аркалыкны күтәреп, тезгенне тартып бәйләде.— Әйдә, хайванкай, бик соңламыйк.

һәм танышларына кереп чәйләп торасы итмәде. Ерак юл түгел, түзәр, бүре-фәлән төнге ауга чыкканчы, урманны кичү хәер. Бурлы Кашка арттан куган бүрене җиткермәс җиткерүен, дуамалланып чабар чаклары узып барса да, әле көче җитәрлек, әмма ки бүренең юл кисеп ташлануы ихтимал, ул да үзенә җайлыны кыла, башы эшли ерткычның.

Авыл чыккандагы чишмә буенда юлаучылар өчен куелган, яртылаш боз каткан кыска тагаракка бер чиләк су салып, атын эчерде. Гаҗәп тә акыллы соң бу ат дигән хайван, ләкин ашарга-эчәргә сорарга теле юк, картая, ләкин чәче-ялы ялтырап агармый. Бурлы Кашка, уң аягын гына янга алып, тагаракның авыш башындагы суны чыжлатып чөмереп бетерде, хуҗасына борылып карады.

— Туймадыңмы. Эчеп бетерердәй булсаң гына тагын салам бит. Ярты чиләк тә җитәр. Урманны юыртып чыгасы бар.

Аты, суны тагын эчеп бетергәч, тагарак буйлап авызын йөртте дә башын күтәрде.

Советлар йортына кызу якканнар иде. Өстәвенә кояш булды, ул да тәрәзәләрне сыйпап җылысын сиздерә хәзер. Волкомның һәм волбашкарманың тынчу бүлмәләрендә утырып тирләткән иде, салкынны тәне тиз сизде Газизҗанның. Шулай да ул толыбын кимәде, бүрегенең колакчыннарын төшереп батырып киде, билбавын кысып бәйләде, тезләре астына бишмәт чабуларын кыстырып чана уртасына тезләнде. Хуҗасының юлга әзер икәнлеген дилбегә тартудан тоеп, Бурлы Кашка алгы аякларына сикереп куйды да урыныннан ук юыртып китте.

Яңа оешкан колхоз председателе Газизҗан Хәкимҗанов волость җитәкчеләренә нигезләп тә сөйләп карады, үтенеп тә сорады, ләкин бер йомышын да ахыргача хәл итә алмады. Бу көннәрдә колхозга кергәндә биргән гаризаларын кире сорап килүчеләр ишәйде. Нишлисең, Газизҗанның һәм башка җитәкчеләрнең үгетләүләренә колак салмыйлар.

— Колхозга керү дә, чыгу да ирекле, бир гаризамны! Керү взносымны кире бир!

Бирергә туры килә. Берәүне дә көчләп яздырмаган булсалар да, колхозга тоташтан алып ялгышынган, күрәсең. Иртә булган болай эшләргә, уңышлардан баш әйләнгән. Революциядән соң гына атка тиенгән һәм үз җирендә иген игү бәхетен татыган кешеләр арасында да, хосусый милекчелеккә караганда, күмәк хуҗалык милекчелегенең тормышны яхшыртуга тизрәк китерәчәген аңламаучылар бар иде. Аларга ялгышуларын ничек аңлатырга соң? Моны волкомда да анык әйтүче булмады.

— Бәлки, колхоздан чыгучыларның да, безнең дә ялгышуларны төзәтүдерү өчен колхозга үзегез килерсез яки вәкилегезне җибәрерсез?— диде ахыр чиктә «Революция» колхозының беренче председателе.— Кем мин аларга? Кияү Газизҗан, дип тә саныйлар бит әле менә авылда. Үзебезнең генә көч җитмидер.

Кылыкка барып, колхоз төзелешенең иң авыр сынавында катнашырга теләүчеләр шулай ук булмады.

Язга әзерләнгәндә, колхозны таратабыз, дип уйлады Газизҗан. Атын, чәчү орлыгын кире бирергә кирәк. Атлы хуҗалыклар колхоздан чыгып бетсә, язгы чәчүне ничек үткәрербез соң? Их, хет бер генә тракторыбыз булса! Тиз генә булмас шул. Тракторлар эшләп чыгару өчен Татарстан буенча бер миллион дүрт йөз мең сум акча җыелды, күп түгел — бүгенге газетада шулай язганнар иде. Гыйнварда язылa башлаган идек трактор заемына, бер заемы — илле сум. Мал-туарын, чәчү орлыгын кире бирдең дә, ди, яз чыгуга җирне бүләргә кирәк була бит. Димәк, кайсы сабан ашлыгын кайда күпме чәчәргә дип ниятләнүләребез бушка китә. Республикада авылда яшәүче һәр хуҗалыкка уртача җиде гектар җир туры килә. Безнең Кылыкта да шулай. Колхоз таралып бетсә, сиңа да җиде гектар өлеш чыга, Газизҗан. Җитәр дә бу җир сиңа, юлыңа хәзер бүре чыгып буып ташласа, өч аршыны да җитеп ашыр. Әмма нигә син, Хәкимҗан Газизҗаны, колхозны йөзе килеп

пешкән итле бәлеш итеп күз алдына китерергә тиеш тә, аны табынның уртасына, нәкъ синең каршыңа, утыртып сыйлауларын көтәргә тиешсең?! Бәлешне пешергәндә — минем катнашым юк, инде пешеп чыккач — кашыгым кулымда, шулай булып чыгамы? Шулай, хәтта өстәмә сыйлары белән. Һәм бәлеш төбен кисәргә дә сиңа, Кияү Газизҗанга, кушарлар әле. Тот...

Юк инде, колхозны таратырга ирек куймабыз! Сизеп торам, бу көннәрдә кулак куллары оста уйный, сүзләренең йогынтысы көчәергә уңайлы чак. Әлгый Фәсәхетдине колачын тагын җәя башлады. Революциягә чаклы җир биләүче һәм арендатор, сәүдәгәр булган кеше, байлыкның җирдә икәнлеген белә Фәсәхетдин абзаң. Әле былтырга хәтле, колхоз төзи башлаганчы, дүрт хуҗалыкның җирләрен арендага дигән сылтау белән алып тотты. Тегеләре колхозга кергәч, үз өлеше генә калды Фәсәхетдинеңә. Һәм колхозга керергә гаризасын бирде Фәсәхетдинең. Әйе, сузмаска иде, моңарчы куарга иде кулакларны, барысын да сөрергә иде! Авылдашлар, янәсе, алар да җир кешеләре, алла бәндәләрен туган-үскән җирләреннән аерырга ничек җөрьәт итмәк кирәк, кызганыйк үзләрен... Алар кызганып торырмы икән соң хәзер? Көт! Ярлы крестьяннарның, үз көчләре белән иген игә алмаучы хуҗалыкларның җирләрен кабат тартып алырга кулакларга җай калдырганбыз. Колхозны тиз төзибез дә, социализмны юыртып кына узып, коммунизмга тиз генә барып җитәбез, имеш. Имеш, шул менә...

Соңгарак калынды. Ичмасам, бер йомышың үтәлсә дә ярыйсы булыр иде. Юк бит. Сәхәрия үпкәләгән сыман әйтеп калган иде. Волостька еш йөри башладың, ди. Әллә көнчелеге купмакчы инде, әй, атлаган саен волость белән авыл арасын таптыйсың, телефон суздыртыгыз авылга, ди. Бик суздыртасы да, волость җитәкчеләрен килештереп булмый. Быел, күрше-тирә волостьларны бер итеп, безнең якта да район оештырылачак, диләр. Район оешкач, зур итеп Советлар йорты саласы бар, киләсе елсыз авылларга телефон сузуны башларга мөмкинчелек юк, диләр. Алар да хаклыдыр, кирәкнең чиге ерак, каян чыганак тапмак кирәк. Элгәре колхозлар төзеп байыйсы иде, тарткалау-йолыккалауга калса, әллә ни майтара алмыйсың инде, агайниш.

Бушка вакыт әрәм ителде, волбашкармага кереп тә торасы түгел иде миңа. Телефон кирәк булган Газизҗанга, әй, Сәхәриясе көнләшмәсен өчен. Тоттырдылар телефонның төребкәсен! Республикадагы алтмыш эре колхозга радио кертелгән инде. Безнең дә колхоз кечкенә исәпләнми югыйсә. Ә радиосын да, телефонын да төштә генә күрәбез. Син Кылыкның дәрәҗәсен тота, данын күтәрә белмисең, шуңа күрә сине волостьта санга сукмыйлар. Колхоз да синең җебегәнлегең аркасында таркалып бара.

Әйдә, малкай, кызула! Урман чыгып барабыз. Сәхәрия җиңгәң бәлеш пешерәсе иде. Минем кайтуны Кәшшафетдин ишек тупсасыннан төшмичә көтәдер, салкын эләктермәгәе тагын, бирешеп куймагае, болай да бик чандыр, әбигә тартым, Сәхәриянең әнисенә. Сау-сәламәт үсәр, шәт, Кәшшафетдин улым. Тик менә эти белән әни оныкларын күрә алмыйча китеп бардылар. Бер-бер артлы. Инде әтинең вафатына да икенче ел, әнинең кырыгы узганчы гына яшәде, мәрхүм.

Күп авырлык Сәхәрия җилкәсенә төшә хәзер. Мал карау бөтенләе белән дигәндәй аның кулында, бала үстерү мәшәкатьләре дә аңа. Сеңелләрне озатканчы узасы гомер шактый...

Газизҗан толыпны аягына япты. Шуны алганда, кулы кистәнгә тиде, аның элмәген табып беләгенә киде. Уйланып барып онытылган, югыйсә, караңгыда урман чыкканда, кистәнен гел әзер тота иде. Ышанып булмый бүре дигән ерткычка, әмма аң булсын иде ул. Газизҗан кулындагы бу кистән аның үз язмышын хәл итәчәк, шуны белмәсә генә юлга аркылы төшсен.

Бурлы Кашка, ул да бүреләрдән шикләнәдерме, колакларын шомартып, бар көченә юырта. Ара-тирә колакларын торгызып ала, урманда

ботак-сатак сынуы бетеп тормый, шул шылт иткән тавышка сискәнүе малкайның. Бүрене ат ерактан ук сизә, диләр. Бурлы Кашка тыныч, шулай булгач, бүреләрдән куркырга сәбәп юк, инде урман чыгарга да ерак калмады.

Малае Кәшшафетдин тагын исенә төште.

...Их, хәзер малайны куенга кысып сөйсәң икән! Нәсел дәвамын! Тунар иде микән, әй? Туңмас иде, чыдам булачак Кәшшафетдин, кайгы тирәсеннән житез-йөгерек кенә узып китәчәк, хәсрәт дигәнең чабуыннан эләктерергә өлгермәячәк. Безнең балаларга михнәт чигәргә туры килмәс, шәт. Яңа тормышны нык нигезле итеп төзеп бирербез үзләренә. Рәхәтләнеп яшәсеннәр. Нигә алар гына ди?! Тигез матур тормышта үзебез дә яшәргә өлгерербез. Ашыгуларыбыз да шуның өчен.

Бурлы Кашка мылтык тавышыннан кинәт читкә сикерде. Газизжан берни аңышырга өлгермәде, терәлеп барган төшеннән атылып каршы үрәчәгә капланды. Ат юлга кире менеп куш аяклап чаба башлагач та, чана бер табанында һәм үрәчә очында шуып шактый ара барды.

Моннан өч ай гына элек оешкан «Революция» колхозының председателе Газизжан Хәкимжанов кételмәгән хәлләрне күп кичергән урманның кышкы тар юлы читеннән сөйрәлә иде.

Толып, шуып төшеп калып, кара түмгәк булып чүмәште.

Мылтык тавышы кабат яңгырамады.

Бүреләр өерснең урман кичкәндә башлап Бурлы Кашкага ташлануыннан курыккан Газизжанның караңгыда үзен ике аяклы бүре сагалап торган икән.

Бурлы Кашка авылга кергәч тә капка төбенәчә чабып кайтты. Капка баганасына тәртә башы бәрелеп, чана «дырк» чигенеп алгач кына, Газизжан аңын җыйды. Үрәчәнең челтәрләп бәйләгән бавыннан кулын ычкындыра алмыйча беравык азапланды, бармаклары бөгелеп каткан иде. Уң кулыннан кистән эләмәген чыгарып, бияләен салып, берегеп каткан бармакларын язырга булышты. Торып аягына басканда, кечкенә капка ачылды.

— Исән-сау кайттыңмы? — дип кабул ителгән гадәттәгечә каршылады Сәхәрия.

— Шәп! Сине бабай кулыннан алып кайткандагы кебек чапты Бурлы Кашка!

Үлем тырнагыннан котылган мәлдә үк бу сүзләрне әйтергә күп көч кирәк булгандыр Газизжанга. Ә бит алдашмады, чыннан да, исәнимин кайтты, бу катлаулы заманда чат саен диярлек сагалап торган бер хәлне әйтмичә калдыра икән, монысы гөнаһ түгел, хатын-кызның кайбер ваклыкларны... хәтта эре ваклыкларны белмәве хәер. Югыйсә, борчыла торган халык алар, аның Сәхәриясе бигрәк тә өзгәләнүчән.

Тидерә алмаган дошман, соңгарак калып, аскарак алып атты бугай. Бәлки, Бурлы Кашка мылтык көпшәсе төбәлүен күреп читкә тайпылганга тидерә алмагандыр. Ат караңгыда да әйбәт күрә бит.

— Кая, толыбыңны ала керим.

— Толып... Төшеп калган икән толып, әнисе.

Алдамады, толып чыннан да төшеп калган иде бит, аны Газизжан үзе атып бәрмәде ич. Бәлки шул толып коткаргандыр Газизжанны, дошман аның үзен мәтәлеп төшеп калды дип уйлагандыр.

— Аның өчен кире барып йөрмәссең. Караңгы төндә. Атың да манма су булган.

— Әрәм ич инде...

— И-и, әтисе, юл йөргәндә югалганы да, табылганы да булыр. Яңасын тектерербез. Көз житеп маллар чалгач, толыплык тиребез жыелыр. Әлегә жылыга кияреңә бар, әткәйдән калган кыска тун киеп туздыргысыз.

Хәвеф булып узганын Сәхәрия сизенгән булса кирәк. Хатыннардан сер яшерермен димә инде, чакрымнан тышыңны күрсәләр, йөзеңә карамыйча да күңелеңдәген күрәләр...

— Сәхәрия, әллә соң Бурлы Кашканы колхоз абзарына төшереп йөрмимме икән?

— Үзеңә кара. Колхоз аты ич ул хәзер.

Сәхәрия, атның юеш сыртыннан сыпырды да, калын шәле астына кулларын кушырды.

— Озаклама, өйгә кайтып җиткәч тә, дим. Бәлеш суынып, Кәшшафетдин көтә-көтә көтек булды.

Ай-й соң бу хатын-кызның тел тегермәне, көйләнеп тарта башласа, онга көрпәне бөтенләй дә катнаштырып чыгармый. Урман вакыйгасыннан соң дуамалланып холыксызланырга иренә җай калдырмады Сәхәрия, алдан искәреп, юмалап өлгерде. Газизҗанның кызу кан белән хатынын ачуланып ташлавы да мөмкин иде. Бет ачуын туннан ала, дигәндәй. Әле хәтта... Юк, анысы булмас, Газизҗан Сәхәриягә кул күтәрмәс.

— Шулай итим әле, илтмим Бурлы Кашканы. Аягына су төшмәсенгә, туарып йөртеп килим дә, җылы абзарга кертеп ябармын. Сыерны сарыклар янына күчер син. Төнлә чыккалап карамыйча ярамый малкайны. Каты чапты, тай чагында да болай ук элдерткәне юк иде...

Иртәгесен толыпның янып бөгәрләнгән кыйпылчыкларын урман юлында күреп кайтучылар булды. Бу хәбәрне Сәхәрия дә ишеткәндер, әмма ул иреннән толыпның яну сәбәбен кызыксынмады. Толыпның яндырылуын Газизҗан да ишетеп кенә белде. Кесәсендә шырпы йөртсә дә, тәмәке тартмый ул, һәм, урман чыкканда, бүре өерен куркытырга учак якмады. Белгәнегезчә, толыпның януында Газизҗанның катнашы юк. Толып чанадан карга шуып төшеп калды, ә кар, гомумән, үзеннән-үзе ут булып кабынмый. Белгәнегезчә.

Толып хәбәре Кылыкта көндезен таралды. Кемнең толыбы януын тәгаен берәү дә белмәде. Газизҗанның сеңелләре дә үз толыплары югалгандыр дип башларына да китермәделәр.

Димәк, минем үлгәнме-юкмы икәнне тикшереп караган, толыпны күргәч, минем чанадан егылып төшеп калмавыма ачуы килеп, толыпка ут төрткән, яралы булсам, маңгаема ук терәп атасы икән мылтыклы бәндә, дип уйланды Газизҗан. Алданган мылтык атучы агай... әллә энекәшме? Минем бәхеттән! Утлы көпшәгә кистән белән каршы торып булмас иде.

Сәхәрия әйткәндәй, толыпның яңасы булыр. Баш исәнлеге кадерле! Ә минем баш дошман өчен дә бәһале икән, монысын төшенеп җиткермәгәнмен. Дошманга баш кистермәбез, боерган булса, саклarбыз башны!.. Ничек сакларга? Дошманың белән күзгә-күз очрашкач, саклануның ысулын таба алмыйча, коелып төшүең мөмкин, ул чакта инде сиңа ысул сайлап торырга вакыт юк. Чөнки дошманың алдан уйлап килгәнчә хәрәкәт кыла, син салкын яки утлы коралмы, әллә үтемле сүзме сайларга тиешлегеңне белмисең. Ә белергә кирәк, шушы чуалчык заманда моны белү бигрәк тә кирәк...

Кичен Газизҗанны бүтән хәвеф, кичәге урман юлындагысыннан бөтенләй үзгә хәвеф көтә иде. Бу юлы аңа дошманы белән күзгә-күз очрашырга туры килде.

...Колхозның канцеляриясен былтыр декабрь башында нэптан соң хөкем ителгән сәүдәгәр һәм җир биләүче Арысланбәк йортында ачтылар. Тәртиптә тотылган бу йорт-җир Урта мәчет каршында, авылның гадәти кешеләреннән өч хуҗалык утырган чамасы урынны били иде. Сәүдәгәрнең хатыны Фәрзия һәм балалары, колхозның яралгысы оешып, атна чамасы узуга, кулак буларак, сөргенгә җибәрелде. Халык җыенының карары шундый булды, хатын-кыз дип кызганмадылар, чөнки болар Кылык кешеләренә гомер буена җәфа чиктереп яшәгән нәселләрнең берсе иде. Фәрзия бичә үзе дә миһербан сорамады. Ул бер генә нәрсә үтенде.

— Безнең нәселдән берәүгә дә тырнак белән чиертүче дә булмады,

шуңа күрә сез дә безгә тән ярасы ясый күрмәгез,— диде Фәрзия бичә.

— Сукмыйча-ормыйча җелекне суырдыгыз!

Сәүдәгәр хатыны моңа туры җавап кайтармады.

— Без үзебез җыенып китәбез. Монда безгә барыбер тынгылык булмас. Каныга башларсыз да хакыйкать бозылыр. Сезгә хәзер хакыйкатьне, хөрриятне бозмыйча саклый белергә кирәк. Булдыра алсагыз,— дип авылдашлары хөкемендә соңгы сүзләрен әйтте Фәрзия.— Ике малаем белән күпме күтәрә алырбыз, шул әйберләр җитәр. Җитеп торыр. Ач булмабыз. Малайлар кечкенәрәк, берсенә унбиш, икенчесенә унике яшь кенә. Ирем, елын тутырып, исән калса да, Кылыкка кайтмаячак. Безнең беребез дә кайтып йөрмәячәк монда, балаларымның балалары да, хәтта аларның оныклары да. Бездән калган мөлкәт сезгә, ярлыларга. Теләгегез, бүлешәсезме, колхозныкы итәсезме — сезнең эш. Ут төртә алмыйм бит инде мин мөлкәтемә! Дәгъвам... юк. Өчебез күтәрә алганнан калганына. Яшерелгән байлыгыбыз юк, кайтасы булмагач, яшерү файдасыз. Хәзер үк тентү кертегез. Нинди мал-мөлкәт калдыруым теркәлсен. Кайчан да булса кулак гаиләсе байлыгын искә төшерергә теләвегез мөмкин иң. Кирәге чыгуы ихтимал. Әйберләрнең исемлеген үзем язып түр өйдәге өстәлгә куярмын. Гафу сорамыйм, тез чүкмим.— Хатын җыенда утырган Әлгый Фәсәхетдиненә төбәп өстәде:— Тормыш синең белән очраштырмаса иде. Башта авыл советына кереп оялап, үзенә тиешле салымнарны да алдап-йолдап безгә бүлә идең син. Авылда син дә озак яшәмәссең. Җир йотсын сине, хәшәп хәшәрәт! Таш астыннан шуышып чыккан елан!

Җыен халкы, киң күңеллелек күрсәтеп, сәүдәгәр хатынының үтенеченә каршы төшмәде, ире тиешле җәзасын алды, тормышның агымы үзгәрүен, бәлки, аңлагандыр, сүзләре дә хактыр, дип фикерләштеләр. Байлыгын шыпырт кына сакламакчыдыр, дип шикләнүчеләр дә булды.

Сәүдәгәр хатыны Фәрзия, төш җитәрәк, кеше күз алдында, ике малаен ияртеп, авылдан җәяүләп чыгып китте.

Капка төпләрендәге апайларның кайсыдыр акрын гына:

— Исән-сау яшәгез,— дигән иде, юл алучылар моны ишетмәделәр ахрысы, хушлашу җавабы булмады.

Фәрзиянең кулында ак төенчек, малайларының аркасында биштәрләр, кечкенәсе талчыбык кармак сабын да тоткан иде. Авыл башындагы биек күпер уртасына җиткәч, кече малай кадерле кармак сабын Мишә бозына сөңге итеп кадап ыргытмакчы итте, уеннан кире кайтып, кармак сабын җилкәсенә салып, авыл ягына борылып та карамаган әнисе һәм абыйсы артыннан ашыкты.

Хикмәт, әй, китүчеләрнең дә, калучыларның да — берсенең дә күзләреннән яшь чыкмады. Миңа калса, китүчеләр, яшь күрсәтмәс өчен, соңгы көчләрен җыеп чыдаганнар, ә күреп калучылар аларны бөртек тә кызганмаганнардыр.

Әйе, колхоз канцеляриясе авылдан горур чыгып китүчеләрнең унике аршынга сигез аршынлы итеп гел бер иш нарат бүрәнәләрдән салынган, зур тәрәзәле, калай түбәле, кояшка караган урам башы өенә урнашты. Моңарчы элеккеге мәдрәсәнең бер бүлемендә торып торган авыл советы сәүдәгәрнең эчке өенә күчте.

Колхоз председателе Газизҗан Хәкимҗанов, авыл советы председателе һәм комсомол ячейкасы секретаре кичләрен канцеляриянең берсендә — кайсы председатель алданрак килүенә карап — төнгәчә киңәшеп утырырга гадәтләнделәр. Көндезен җыйналырга вакыт тими, колхозның төзелеп килә торган каралтыларында да, өйдә дә эш җитәрлек, колхозга керүчеләр барысын да тигез эшлиләр, җитәкче булу өстәмә вазифа кебек кенә хәзергә.

Бүген Газизҗан алданрак килде, күбесенчә шулай була да, чөнки ул якынракта яши.

Алар колхоз канцеляриясендә утыралар. Йомышы төшеп яки гел дә сөйләшеп кенә утырырга керүче юк әлегә, иртәрәк.

Газизҗан урта матчага элгән унлы лампаның пилтәсен күтәрде, өй эче яктырып китте.

Кинәт ишек тартылды. Бүрегенең алдын артка әйләндереп кигән кемдер, танытмас өчен тавышын да калынайтып, ишек ярыгыннан кычкырды:

— Киләләр! Монда киләләр!

Авыл җитәкчеләре бернәрсә дә аңышмыйча карашып алдылар.

Ишек тагын тартылды. Шул ук тавыш үкергәндәй ишетелде:

— Әлгыйләрнең ак мунчасында җыйналып киңәштеләр! Сезне... Монда менәргә чыктылар! Тагын кешеләр җыялар!

Ишек шап итеп ябылды.

Җитәкчеләр сүзсез аптырашып тордылар. Берәрсе шаяртадыр, дисәң, тавышы борчулы һәм калтыравык иде. Әмма ни өчен үзен белгертмәскә тырыша соң ишектән кычкыручы? Ирештергән хәбәре дөрес булып та, соңыннан кулакларның үч алуыннан куркамы?

Менә син ә, авыл кешесен таныма инде, әй! Газизҗан калайлы түгәрәк мич кырыеннан фонарьга ут кабызды, ишек катындагы чөйдән колакчыннары артка бәйләнгән бүреген алып башына киде, ишегалдын һәм урамны карап керәсе итте. Ике өй арасындагы киң өйалдына чыккач, фонарен югары күтәреп, як-ягына каранды. Кеше юк иде. Ишегалдында һәм капка төбендә кеше йөргәне шулай ук сизелмәде. Тынлык. Болытлы. Төн дөм караңгысын төшереп өлгергән инде. Җирне тигез каплаган кар да, фонарь яктысы төшкән җирдән кала, каралып күренә.

— Юк беркем дә,— диде Газизҗан, канцеляриягә кергәч.

Ул сәүдәгәрдән калган түгәрәк өстәл янына таянсалы агач кәнәфине күчереп куйды. Учы белән таянып, өстәлне селкетеп карады. Какшауны белми дә иде имән өстәл. Кәнәфине ишеккә турылап тартты, әмма утырмады.

— Әйбәт эшләгәннәр, нык та, матур да,— диде Газизҗан сәүдәгәрдән калган әйберләргә ишарәләп.— Һаман бер нәрсәнең серенә төшенә алмыйм. Бу йорт-җирне, әйберләрне колхозга каршылыксыз һәм хәтта үз теләкләре белән калдырып китүнең әкәмәтен уйланып та таба алмыйм. Әллә чынлап та колхозга игелек эшлиселәре килде, әллә авыл халкы алдында гөнаһ-гаепләрен шуның белән юарга теләделәр тагын. Тормышның үзләре генә дилбегә тоткан чагы кайтыр дип өметләнмәгәннәрдер бит инде. Монысы беркайчан да булмаячак, әлбәттә, колхоз төзелү моңа кеlә төшереп кенә калмаячак, ә йозакны ачылмый торган итәчәк. Шулай да кулаклар варис иткән милекне бәрде-сукты тотарга ярамый. Түгел, хуҗалары кире кайтып алар алдында җавап тотудан куркып түгел. Әйтәм ич, колхоз тормышны кирегә бору юлын бикли. Төзибез колхозны! Сак тотарга кирәклек — ихтыяҗ безнең. Чөнки без моңарчы «минеке» булганын гына әрәм итмәү турында уйлый идек. «Безнеке» булуга күнекмәгән идек. Безнең күмәкләп корган әйберләребез күпер дә басу капкалары гына иде. Революция булып, ничә еллар узгач та, күмәклек дигән нәрсә бик күпләрнең күңеленә ятмый. Хикмәтле нәрсә шунысы...

Урам яктан буталчык тавышлар ишетелде. Канцеляриядәге җитәкчеләр сискәнеп аягүрә бастылар. Кичәге мылтык тавышы Газизҗанның колагын бер мәлгә кабат томалап торды. Ул, каты бәрелүдән аңына килгәндәгедәй, башын селкеде. Нәрсә дә булса эшләргә белештермичә, ишеккә таба атлады. Тоткага тотынырга өлгермәде, ишекне тыштан төбенәчә каерып ачтылар. Ишектән, кысылышып, кешеләр керә башлады. Газизҗан, чигенеп, түгәрәк мичкә терәлде. Инде өй тула, ә ишек төбендә һаман этешәләр. Әлгый Фәсәхетдине күренгәч, керүчеләр, читкә тайпылып, аңа узарга аралык ясадылар. Әлгый Фәсәхетдиненең йөзе ачуы кайнаудан кызарып бүртенгән иде. Изүе ачык, аны төймәләргә бүрәнәдәй муены ирек бирмәгәндер кебек. Ул, кулларын кыска туны кесә-

ләреннән чыгармыйча гына, вәкарь кыяфәт белән түргә узганда, Газизжанның әчена, башкаларга сиздермәскә тырышып, ышкылып кына киткәндәй итеп, каты бәрелде, авыз эченнән генә кыска үкереп алды. Эчен кинәт кысуга Газизжан бөгелә төште, әмма саклану өчен каршы хәрәкәтләр ясарга соң иде инде.

Әлгый Фәсәхетдине алдына кемдер кәнәфине тартты. Бу куштанның кем булуын абайламады Газизжан, бу адәмнең артка чөелдергән бүреге, кәнәфине жайлаганда, идәнгә төшеп, такыр башы ялтыравы гына күзенә чалынды.

— Йә, нигә әтәчләнмисең? Нигә кикриген шәлперәеп төште?

Әлгый Фәсәхетдине бу сүзләрне председатель Газизжанга кырын карап кына әйтте. Ул каеры тунын, салып, түгәрәк өстәлгә ташлады, кара буй сызыклы ак күлмәгенең жиңнәрен өскә таба сыпыргалады, сары каймалы кәзәкиенең итәкләрен тартып куйды. Аннары гына кәнәфигә киерелеп утырды, бүре тиресеннән тегелгән күперенке бүреген башыннан салмады.

Газизжан жавап кайтармады.

— Колхозны тиз генә төзисең дә тиз генә дәү түрә булып алмакчы идең, ә. Барып чыкмас, Газизжан энекәш!

— Колхозны төзедек инде без. Димәк, эшебез барып чыкты.— Газизжанның аркасын мич артык жылытып жибәрде, ул алгарак тайпылып басты.— Хәзер ныгытачакбыз колхозны!

— Ныгытачаксыз? Хәкимжан Газизжаны колхозны үстерә, менә шушы ике иярчене белән ныгыта.— Әлгый Фәсәхетдине өстәлдә яткан тунны читкә этәрде һәм, чалбар кесәсеннән кәгазь алып, аны өстәлгә жәеп салды.— Менә минем гаризам, чыгам мин колхозыгыздан!

— Синең чыгуыңа каршы төшмибез! — дип тынычлыгын сакларга тырышты Газизжан.— Сине алмаска да тиеш идек без. Хатабыз монысы. Син бит жир биләүче, арендатор. Хәтта колхозга кергәндә дә синең егерме биш гектар жирең бар иде.

— Арттырма! Жиде гектар иде жирем, башкалардан артыгы юк иде.

— Атсыз хужалыкларның жирен кем эшкәртте?

— Алар үзләре миннән ярдәм сорадылар, уңышы уртакка булды. Син монда казына алмыйсың, барсы да законча эшләнде. Минем кулымда аларның үзләре биргән ризалык язулары бар. Кирәкмәс төштә казынма! Упкынга таруың бик-бик ихтимал!

— Хәзер артыңнан жыеп йөрүеңә шикләнмим. Изүче сыйныф һәрчак хаклы саналганда гына, син артыңа карап тормагансың. Революциядән соң гына яраклашу хәйләсен оста табасың. Хәер, син патша заманында да үзеңнән баеракларга ярый белгәнсең.

— Казынма, диләр түгелме сиңа! — Әлгый Фәсәхетдине Газизжанның каршына торып басты.— Үз ялгышың өчен жавабыңны тот!

— Әйттем, хатам шунда — сине колхозга алуга риза булуымда. Авылдашны кулак итеп күрергә ярамый, имеш. Авыл советының беренче секретаре булган, Совет властен таныган Әлгый Фәсәхетдине, дип уйлап ялгышканмын.

— Булдым шул, авыл советын мин оештырдым.

— Син анда кереп оялагансың. Һәм ки, контрибуцияләрне үзең ким түләп, башкалар өстенә өеп салгансың.

Әлгый Фәсәхетдине кеткелдәде.

— Һәркемгә байлыгына карап. Мин — авылның зур бае түгел, урта хәлле кешесе.

— Мин урта хәллесе, Фәсәхетдин абзый, син — авылның корткычы! Авыл советы секретаре булуың белән канатланма, беренчедән, сине гыйлемлерәк кеше дип куйганнар. Авылда иң күп гәзит-журнал Әлгый Фәсәхетдиненә килә, ди иде минем Басарый бабай. Икенчедән, бик тиз секретарьлыктан чөеп тә аттылар.

— Их, нигә синең белән сүз озайтып торам соң мин?!

Әлгый Фәсәхетдине, Газизҗанның каршына ук килеп, аның бугазына беләгән терәде. Колхоз рәисе тагын мичкә сөяләргә мәҗбүр булды, башы күтәрелеп калды. Әлгый Фәсәхетдине аның бугазын акрынлап кыса иде. Таза иде Әлгый Фәсәхетдине, бу акайган күзләр белән текәлеп караса, явызлыкны күп кылган карт бүре дә тез чүгәр иде, бүреләрне өере белән буып ташларга да көче җитәдер моның. Газизҗан да йомшак җил өрүеннән генә бөгелеп төшә торганнардан түгел, Әлгый Фәсәхетдинен бөгәрләп сала да алыр иде, бәлки, әмма аның тарафыннан кул көче куллану хәзер һич тә акланмаячак.

— Җибәр!

— Җибәрермен! Ләкин башта, мин сезне колхозга көчләп яздырдым, дип халык алдында әйт.

— Мин...

— Әйт! Колхоздан чыгарга сезгә ирек, диген! Моннан соң колхозга керергә берәүне дә әгитләмәм, диген!

— Мин берәүне дә...

— Мине көчләп яздырдың колхозга! Чыгар мине колхоздан! Мин властька каршы кеше түгел, власть үзе колхозга көчләп кертелүчеләрне яклый. Мә гаризаны!

Әлгый Фәсәхетдине, өстәлдәге гаризасын алып, Газизҗанның битенә бәргәләп җилфердәтте.

— Чыгарабыз сине колхоздан! Һәм бик теләп,— диде Газизҗан, бугаз төенен ычкып торгач.— Һәм кулак буларак авылдан да сөрәчәкбез.

— Сөрә алмассың! Чөнки колхозың юк синең! Һәркем ирекле! Көчләүләр бетте! Укыдыңмы Сталин ни язганын?!.

Колхоз рәисе өй эченә тулган кешеләргә күз йөртеп чыкты. Барысы да таныш кешеләр, әмма берсе дә аны якларга исәп итми, кайсыларының йөзләрендә сөмсезлек ярылып ята, икенчеләре башларын аска игән яки читкә карый иде. Авыл советы рәисе һәм комсомол ячейкасы секретаре Газизҗанның күзенә чалынмады. Әллә күзләрем күрмәскә әйләнде инде, дип уйлап алды колхоз рәисе.

— Кемнәр Әлгый Фәсәхетдинен һәм аның гаиләсен колхоздан чыгару яклы — шулар кулларын күтәрсен.

— Алар үзләре дә колхоздан чыгарга килделәр,— дип зәһәр мыскыллап елмайды Әлгый Фәсәхетдине.— Нигә терәлеп каттыгыз? Гаризаларыгыз кайда?

Күпмедер тынлыктан соң, чыш-пышлар кузгалып алды. Ниһаять, берсе җөрьәт итте, аңа баштарак көттереп кушылдылар, аннары бербереен бүлдерергә үк тотындылар.

— Без үзебез колхоздан чыгып торасы иттек...

— Мин дә...

— Колхозда тигезлек була, дип аңлаттың син, Газизҗан авылдаш. Әмма алай булып чыкмады бит. Син Бурлы Кашканны үзең җиңелгә җигеп йөрисең дә үзеңнең җылы абзарыңа кайтарып төн кундырасың. Ә минем Җирән белән көн буе урман тарттыралар, лашман аты иткәләр тәмам. Мин бу агач аягым белән урман чыгара алмыйм, шуңа күрә атымны кем тели, шул җигә. Җирәнне ябыктырып бетерделәр, коры сөяккә калып бара, шунысы җанны кыя.

Монысын авылда балта остасы һәм төзү-коруда бер өмәдән дә калмаучы Мөсәвир әйтте. Газизҗан аны кешеләргә ярдәмчел булуы өчен ихтирам итә иде.

— Бүрәнәләрне колхоз каралтылары өчен ташыйбыз бит,— дип аңлатмакчы булды ул Мөсәвиргә, әмма бу сүзләр колхоз рәисенең аклануы сыман булып чыкты, чөнки Җирән ат хуҗасының дәлиле тагын булган икән.

— Колхоз каралтылары барыбызга да кирәктер бит, миңа гына

түгел. Урман ташырга синең Бурлы Кашкаң тазарак, ә минем Җирәнне волостька йөрергә үзең җигәргә иде.

Моңа җавабы булмады Газизҗанның. Колхоздан чыгарга теләүчеләрне үгетләүдән хәер бөтенләй дә юк иде хәзер. Шулай да кисәтмичә кала алмады.

— Керереңнән элгәре чыгарыңны уйла, дигән борынгылар,— дип кыюланды Газизҗан. Җебеп төшәргә һич тә ярамый иде хәзер.— Бу очракта, ягъни, чыгарыңнан элек керереңне уйла.

— Сайра әйдә,— дип чәпчеде Әлгый Фәсәхетдине.

— Сайрыйм, Фәсәхетдин абзый, киләчәктә матуррак та сайрармын.

— Күрербез. Ишетербез... елак тавышыңны!

— Күрмәссез! Ишетмәссез! Әйе,— диде ул, халыкка карап,— әйтәм ич, сез чыгардан элек керерегезне уйлагыз. Киләчәктә колхозга бик җентекләп тикшереп алачакбыз бит. Кайберләрегезне алмабыз да, шәт.

— Өркетмә!

— Алланың кашка тәкәсе булган, әй! Мөгезенә элеп кенә чөймәкче!

— Куркытмыйм да, берәүне дә аяк чалып егарга да җыенмыйм. Ләкин кисәтәм: колхозга кабат керүе бик кыен булачак! Кабаттан керүе.

— Һе, киттек-бардык калага! Алмасагыз, сезгә ялынганнар ди бик!

— Ирек хәзер!

— Ә син көчләп колхозга язасың!

— Киткәнгә — ак юл. Тик туган җирне...— Газизҗан ашыгуыннан тыелып туктап торды,— ташлап китүе җиңел булмастыр. Иманым камил: авылның киләчәге колхоз кулында, безнең кулда! Әйе. Мин берегезне дә көчләп гариза яздырмадым. Колхозга керергә өндәдем, булдыра алганча аңлаттым. Булдымы бер?! Колхозга без башта өчәү кердек, өчебез дә кул күтәрдек. Аннары колхозның һәр яңа әгъзасын, барыбыз җыелып, кул күтәреп алдык. Икенчедән, булды монысы. Димәк, инде өченчедән, колхоздан чыгучылардан һәркайсының гаризасын тавышка куябыз. Кем дә кем, кулак Әлгый Фәсәхетдинен һәм аның гаиләсен колхоздан чыгарырга ди, шулар кул күтәрсен. Кабат куела бу тәкъдим тавышка... Бердәм чыгарылдың колхоздан, Фәсәхетдин абзый. Теләгең үтәлде, китә аласың.

— Китмим әле.

— Утыр соң. Әвереп чыгарырга хакым бар да бит, көч куллана-сым килми.— Газизҗан тагын халыкка эндәште: — Гаризалы кешеләр бармы? Бар. Кем дә кем... Бертавыштан. Кем дә кем...

— Мал-мөлкәтне кайчан кире алабыз? — дип сорады Җирән ат хуҗасы Мөсәвир.

— Иртәгә,— диде Газизҗан.

— Шулай дөрес. Сузмаска кирәк. Югыйсә, ни мул ашатып та, Җирәннең сабан сукасына көрәеп җитмәве бар бит.

— Иртәгә бирәбез,— дип сузып кына кабатлады Газизҗан.— Иртүк,— дип өстәде. Биек маңгаен бармак очлары белән ышкып торгач, кызуланып сөйләп китте: — Яктыруга ук монда җыелыгыз. Башта малларны, аннары чәчү орлыкларын бүләрбез. Ләкин орлык сез биргәндәгедән кимрәк чыгар, чөнки суырылган, чүбеннән аерылган.— Ачуы ташый иде аның, әмма кызарга ярамый. Һәм ул, максатына кулак коткысы балта чапса да, үзен тыныч тотарга тырышты.— Ә син юкка хафаланасың, Мөсәвир кордаш, Җирәнең бетәшмәгән, хет бүген сукага җик. Минем Бурлы Кашкага килсәк инде, кичә ул җенең дә эшли алмастайны эшләде... Манма су иде, шуңа күрә җылы абзарда кундырдым. Ярты төнгәчә җитәкләп йөрткәч. Аягына су төшмәсенгә. Бурлы Кашкага ни өчен җилдән житез чабарга туры килгәнен мин үзем генә беләм. Бәлки, моны белүчеләрдән тагын берәү генә бардыр монда... Җитәр бүгенгә, таралыгыз.

...Канцеляриядә Газизҗан белән Әлгый Фәсәхетдине генә калды. Авыл советы рәисе һәм комсомол ячейкасы секретаре да төркемгә ияреп

шылганнар иде. Җебегән җаннар икән, икесе дә минем күләгәгә ышыклanмакчы булып йөргәннәр, ә күләгәгә яшеренеп булмый, дип уйлады Газизҗан.

— Йә, Кияү Газизҗан,— дип уйларыннан бүлдерде аны Әлгый Фәсәхетдине.— Төзеденме колхозыңны? Шулай ул тормыш дигәнең, буең җитмәстәйгә үрелмәскә куша. Энекәш! Ялгызың торып калдың, юк колхозың! Кем җиндә? Без! Әлгыйләр!

— Синең заман арбасыннан төшеп калмавыңа бик ышанасым килгән иде минем, Фәсәхетдин абзый. Ә син безнең арбага утырырга да теләмәгән булгансың икән. Хәзер үк чыгып кит син моннан, югыйсә икебезнең дә каннар кызышкан, ботарлашуыбыз бик ихтимал. Кит, өеңә кайт, бар. Хәерле чакта.

— Чәпчемә!

— Ләкин мин башлап кул пычратмыйм. Көтмә моны. Сабырлыгым җитәрлек.

— Сабырлык сиңа тимер рәшәткә эчендә бик тә кирәк булыр.

— Тимер рәшәткә артына кемне ябарлар бит әле!

— Сине! Син партия һәм хөкүмәт күрсәтмәсен боздың! Өстәвенә, колхозга кергәндә без биргән чәчү орлыгын урлаган булсаң...

— Мин урлаганмы?!

— Кызма, кызма, сабырлыгыңны сакла. Фәсәхетдин абзаң беркайчан да буш сүз сөйләмәде, шуны онытма!

— Көйгән йон исе аңкый синнән, Әлгый Фәсәхетдине! Төлке толып йоны исе. Кеше янына бик якын барып сөйләшмә, сизәрләр.

— Сизмәсләр! Җәвит итсәң дә, шаһитың да, дәлилең дә юк, Хәкимҗан углы Кияү Газизҗан!..

Әглый Фәсәхетдине ишекне тыштан селтәнеп япты. Ишек каты бәрелеп кире ачылды. Ул эчке яктан да кара күнгә тышланган иде, шундагы ак кадак башлары лампа яктысында җемелдәшеп өлгерде.

Газизҗан фонарен алмады, канцеляриянең болдыр ишегенә йозак элә алмыйча бераз маташты. Йозакны, бикләгәч, тартып карады.

Төн уртасы якынлашадыр, караңгылык үтә куерган иде.

Өенә кайтып җиткәндә, кар шыгырдаган тавышлар ишетелгәндәй булды. Газизҗан сискәнеп тукталды, як-ягына каранды, ул-бу күренми иде. Капкага сагаеп, акрын гына якынайды.

Әй, курыкканга — куш, дигәндәй, кем сагалап торсын соң аны, кемнең үче булыр, Әлгый Фәсәхетдине теләгенә иреште, чыкты колхоздан, ачулы кеше бүтән юктыр аңа. Әйе, колхозны тараттык. Юк, бер төнгә сүздә генә таралып торыр колхоз, иртәгесен мал-мөлкәт дәгъвалап килмәүчеләр дә булырга тиеш. Тиеш!

Сәхәриясе ишек ачып керткәч, Газизҗан иркенләп сулыш алды. Күзләрен йомып ятса да, якты беленгәнче, черем итмәде.

Кем белә бит. Әглый Фәсәхетдине йортыңа кызыл әтәч җибәрергә дә күп сорамас... Гаҗәп икән шомлы төн дигәнең. Йокламый ул, каты тавышланмаса да, черт-черт итеп авазын биреп тора икән...

Иртәгесен колхозның мал-мөлкәтен бүлделәр. Шулай да колхоз таралып бетмәде, анда җиде хуҗалык оешып калды. Мөсәвир дә шул исәптә иде. Колхозда калырга теләүчеләргә бу очракта каршы төшмәде Газизҗан. Җиңүе иде бу аның. Өйләдән соң Әлгый Фәсәхетдине җитәкчелегендәге бер төркем халыкны каршы төшеп тә туктата алмады. Газизҗанны колхозның чәчү орлыгына җыелган ашлыгын урлауда гаепләп, тентү белән керделәр. Өч капчык арыш, ике капчык бодай, бер капчык арыш онын һәм ярты капчык чамасы бодай онын — җәмгысы утыз алты пот — алып чыктылар (илле биш ел чамасы вакыт узгач, сабан туе алды көннәрендә район авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы Гаян Сәйфулов белән сөйләшкәндә, Кылыкта колхоз төзүче, хәзер почетлы колхозчы Газизҗан Хәкимҗанов шушы тентүне күздә тотты). Шул ук кичне колхоз рәисенең хатыны Сәхәрия, әле өченче көн генә үзләре хә-

зинәсе белән бәлеш пешереп, ирен каршылаган Сәхәрия, алъяпкыч астына тәлинкә яшереп кенә, күршесеннән кичке ашка умачлык он алып чыкты. Әҗәткә.

Әмма йөдәү-хәвефләр моның белән генә бетмәгән икән әле.

Унышлардан баш әйләнүдә гаепләнеп, Газизҗан Хәкимҗановка унсигез ай төрмә җәзасы бирелде. Шул ук хөкем утырышында Әлгый Фәсәхетдиненең колхозны тарату өчен алып барылган коткысы фаш ителде. Бу хакта утыз шаһит күрсәтү әйтте. Кулаклар башлыгы колхоздан чыгарга ризалык бирүче сигез кешегә яңа суйган сыерының бер алгы санын бүләк итәргә ышандырган булган. Әлгый Фәсәхетдине, җинаять кодексының илле сигезенче статьясы, икенче пункты белән гаепләнеп, шул ук хөкем утырышында кулга алынып, озаграк вакытка төрмәгә утыртылды.

Газизҗан төгәл егерме көннән кайтып төште.

— Татарстанның баш прокуроры чакырып алды үземне,— дип сөйләде ул Сәхәриясенә.— Син азат, диде, без сине кулаклар һөҗүменнән саклау өчен генә кулга алып тордык, яшереп тордык, диде.

— Шулайдыр да,— дип килеште Сәхәрия һәм:— Төрмәгә үк япмаган булсалар да ярый иде дә бит,— дип, ризасызлыгын да белдерде.

— Әй, оныт син аны! Баш прокурор әйтте миңа, колхозыгызны әйбәтләп төзегез, диде. Вәйт әйбәт тә кеше инде, прокурорны әйтәм. Кайчан да булса барып күрәм әле мин аны. Колхозны төзеп бетергәч, имe. Үзен кунакка да чакырырбыз әле, Сәхәрия, яме.

Акыл дигәненне читкәрәк этәргән сөенечтән туган сүзләр иде болар. Шатлык дигәнең акыл утырткан кешене дә гөнаһсыз бала яшенә кайтара шул...

Сентябрьнең соңгы көнендә Әлгый Фәсәхетдине дә Кылыкка исәнсау әйләнеп кайтты. Ябыкмаган да, алҗымаган да иде, киемнәре дә үзенеке иде. Икенче көнне үк өр-яңа киемнәрдән, читек-кәвештән урамга чыкты. Киң читле эшләпәсен маңгаена төшереп киگән иде. Каршына очраучылар белән баш кагып кына исәнләште, берсе белән дә тукталып сөйләшмәде, хәтта сүз дә алышмады. Кулларын артка куеп — төрмәдә гадәтләндергәннәрдер!— олы гәүдәсен алгарак иеп, туры колхоз канцеляриясенә таба атлады.

Иртәнге як иде. Канцеляриядә рәис Газизҗан ялгызы иде.

— Синең тиздән кайтканыңны мин тегендә үк белдем,— диде Әлгый Фәсәхетдине, исәнләшеп тә тормастан, һәм баш бармагы белән артына ишарәләде.

— Кайттым шул. Минем гаебем юк бит.

— Мин дә кайттым.

— Күреп торам.

— Качып түгел.

Әлгый Фәсәхетдине папирос кабызды.

Дөнья дигәнең абзацны тартырга өйрәткән. Ләкин кыйммәтлесен кулга төшергән бу, төрмәдән кайтса да мәгәр.

— Кайттым, дим.

— Күрәм, дим.

— Бер ялгышым булган теге чакта.

— Хатаңны аңлау хәер. Төзәтерлек хата икән — төзәтерсең, бәлки һәм авылда калдыруыбыз да мөмкин.

— Теге чакта, колхоздан чыккан төндә, сине, урам уртасына бастырып, безнең авылда колхоз бетерелде, моннан соң колхозга керергә өндәп, берәүгә дә бер сүз дә әйтмәм, Кылыкта авылдан куарга кулаклар юк, дип кычкыртырга тиеш идем мин.

— Кычкырмас идем. Хәзер бу хатаңны төзәтергә бигрәк тә соң.

— Хәзер соңрактыр. Тиз үзгәрә заман. Теге чакта көч миндә иде. Ант иттергән булыр идем мин сине!

— Юк! Алай уйлавың белән тагын хаталанасың! Син, Фәсәхетдин

абзый, үз алачыгында икәнсен һаман, заман үзгәрешен күрә алмас хәлдә икәнсең.

...Рәсми кәгазьләргә таянып алдарак әйтелгәнчә, бу көздә авылдан өч кулак хуҗалыгы чыгып качты. Аларның берсе йорт-җиренә ут төртеп китте. Ихатада бөтенесе көлгә әйләнде. Үз йортын яндыручы Әлгый Фәсәхетдине иде.

Кара мәче генә булып буендагы йортны тиз оныта алмады. Баштарак ышык куышларда кунып йөрде дә аннары кыргыйланды. Малайлар аны ике җәйдән соң да пуҗум әреме арасында күргәләделәр. Нигезенә тугры бу мәчегә алар Кыр мәчесе дип исем куштылар.

## 7

**Төрле вакыттан — нигездә, сиксәненче еллар башыннан — Җәүһәрия көндәлегенең дәвамы, соңрак — 1970 ел, августның 26—27 көннәре**

*Җәүһәрия көндәлегеннән*

«Безнең өйләребез икәү, кара-каршы өйләр. Урамбаш өебезнең кече ягы — минем бүлмәм. Анда минем стенага терәп ясалган тар сәкем, шуның турысында ук китап-дәфтәрләр куярга озын шүрлегем бар. Сәкене дә, шүрлекне дә эти ясап бирде. Такталарны үзе шомартты, сәкенең йөзлек ырмавын ничек алырга икәнен генә бабай күрсәтте. Бабай ырмау эзен линейка белән сызган кебек итеп башлады, аның балтасы нәкъ кирәкле төшкә генә чабылып торды. Эти дә бабайдан күрмәкче шулай итмәкче иде дә, аның кулында балта читкә чаба шул. Шуңа күрә сәке йөзлегендә балта очының эзләре дага кадагына охшап калды. Эти соңыннан аларны ышкы белән дә шомартып бетерә алмады.

Ырмауны эти өтерге белән алмакчы булган иде дә, бабай рөхсәт итмәде.

— Мондый тирән һәм озын ырмауны өтерге белән чокый китсәң, ярты гомерең шуңа узар,— диде.— Балта белән эшләп булганда, кулыңа өтерге тотма. Балта тотарга малай чактан ук өйрәнергә иде, тыңлаусыз!

Бабай монысын дөрес тә әйтми инде, чөнки эти, мин нәрсә кушсам, шуны үти. Җиһангир сүзенә дә карышмый әле ул. Әй лә, бабай этигә тыңлаусыз дип, әби киребеткән дип яратып әйтәләр ич! Тик менә шуны авыл кешеләре аңлап житкермиләр, этигә төрле кушаматлар такмакчы булалар. Мин инде кайбер абый-апаларны кисәттем дә, эти турында алай димәгез, дидем. Ә алар:

— Без этиеңне яратып әйтәбез бит!— диләр.

Һе, яраткач, матур сүз әйтергә кирәк лә ул. Мин үзем, ратканга күрә, этигә:

— Дөньяда иң-иң әйбәт кеше син, эти!— дим.

Чыны да шулай менә! Шуңа күрә ул миңа:

— Акыллы һәм матур кызым, үземә охшагансың,—ди.

Охшавын мин төскә-биткә әнигә охшаганмын үзе, чәчләрем әниемнеке кебек чем-кара, кашларым да анықыдай кыйгачланып бара. Эти, миңа охшагансың, дигәч, мин моңа да ышанам, эти дөресне гел турыдан ярып әйтә ул. Онытам да икән, әнигә минем иягем дә охшаган, түгәрәк. Бәләкәй чакта синең кебек кинәт көлеп җибәрсәм, минем дә бит урталарындагы чокырларым тирәнәя иде, хәзер генә шул чокырлар җыерчыкларга әйләнеп бара, ди. Әй лә, безнең әни картаймаган ла әле ул, аның йөзендә җыерчыклар бөтенләй юк та, бик беләсегез килсә, әйе. Безнең Сәхәрия әбинең йөзендәге җыерчыкларны ни теләсәң дә бетереп булмыйдыр. Әби картайган шул инде, ул үзе әйтә, карчык кеше, бите җыерчыкланмаса, ямьсез булып күренә, ди. Шулайдыр шул, җыерчыкларны матурайтадыр әбине. Бабай да шуңа күрә матур... Матур дип тә булмый

инде аны, йөзе яңа буразналы бәрәңге бакчасы сыман, кара тутлы.
Әй лә, без барыбыз да акыллылар һәм матурлар.
Ә әтиебез — бигрәк тә әйбәт эти. Әтигә шулай дип әйтергә Җиһангирны да өйрәтәм әле. Йөрсен әле безнең эти гел шатланып кына, кайгы белмичә!
Бүлмәм турында яза идем ич, әллә кая кереп киткәнмен. Бабай әйткәндәй, «бизәнеп» алганмын. Бер эшне бетермичә ташлап, икенчесен башлауны нигәдер «бизәнү» дип атый ул. Аның сүзләренең мәгънәсенә тиз генә төшенеп тә булмый. Сүз дигәннән, беркөнне мине:
— Син, кызым, сүзнең кем икәнен беләсеңме? — дип аптыратты.
— Беләм, — дим, — сүзгә кем дип түгел, нәрсә дип сорау куярга кирәк. Кем дигән сорауга җавап бирсә генә, ул сүз җан иясен белдергән исем була. Ә сүз җансыз, — дип аңлатам бабайга.
— Белмисең икән шул, — диде бабай. — Сүз җанлыларның да җанлысы. Сүзнең тере тәне бар, аның үз тылсымлы дөньясы бар. Шул ук тылсым сүзен күз алдыңа китереп бастырып кара әле менә. Күрәсеңме, төн пәрдәсен күтәреп ачкан таң сыман елмаеп тора ул. Әнә, күр әле, күр, космик корабльне узып, аның алдына төште дә тыпырдап бии-бии, аны үз артыннан әйди. Шул арада, әнә, безнең дәү алмагач төбенә килеп баскан да сандугач сайравын мөкиббән калып тыңлый. Тылсым-галиҗәнаб үзе сандугач сайравын тыңлый! Әйтик, гап-гади... нәрсәне алыйк икән соң... Әйтик, арба сүзе тере түгелмени? Хәтер сүзе... Иген сүзе... Сүзнең җаны бар, кызым, бар, сүз тере ул. Моны син күз алдыңа китереп аңла. Аннары, Җәүһәрия кызым, тагын бер нәрсәне бик тә шәп белергә кирәк. Менә бу тупыл җирдән чыккан да нинди биек һәм юан булып үскән. Минем әти утыртканда, сабый бала бармагыннан да нечкә булган ул. Ничек үскән соң тупыл? Нигә давыл да аудара алмый аны? Агачны тамырлары ничек төз итеп тота? Арыш тамырын күргәнең бармы синең? Бар. Былтыр ук үзем күрсәттем. Аның җеп кебек кенә тамырлары җирдән сабагын да, кылчыгын да, бөртеген дә ничек ала икән соң? Неп-нечкә тамырның бөртек сыйдырырлык авызы юк бит. Менә шуларны бел, Җәүһәрия кызым, ярыймы.
— Син боларны миңа үзең аңлат, бабай.
— Алай, — дип сузып кына әйтте бабай, — бик аңлатыр идем дә, бу хикмәтле тылсымнарны һәркем үзе өйрәнеп белергә тиеш. Югыйсә, тырыш шәкерт булмыйча, остаз була алмыйсың. Аннары, кызым, мин боларны сине өйрәтерлек дәрәҗәдә үзем дә белеп бетермим. Син дә, өнле бала булсаң да, тормыш тылсымын җәйге каникулыңда гына белеп бетерә алмассың, аны гомерең буе өйрәнергә туры килер. Әмма хәзердән ук өйрәнә башлавың — зарурият.
Бабайның үзе генә белә торган шундый сүзләре бар инде аның. Зарурият. Моны безнең Кылыкта бүтән әйтүче кеше дә юктыр. Аның сүз җаны, тамыр белән бөртек арасындагы бәйләнеш турындагы фикерләрен бөтенләй дә аңламадым. Монда үзеннән ишеткәнчә язып куйдым. Үсә төшкәчрәк укырмын, дип.
Әй лә, тагын «бизәнеп» алганмын ич мин. Әби әйткәндәй, ай-й аллам икән!..
Бүлмәдәге дәрес әзерли торган өстәлемне тәрәзә төбенә терәп куйдык. Монысын әни шулай боерды.
— Якты шәп төшсен өстәленә, күзең бозылмас, — диде.
Өстәлне бүлмә тактасына буйлап куйсаң да якты җитәрлек инде анысы. Әни кушуына карышмадым инде, тыңлаулы шул мин. Әни мине гел: «Тыңлаулы кызым», — дип мактап торгач, ни җаным белән карышыйм ди инде, карышмыйм. Аннары бит әле, әти өчен дә тыңлаулы буласым килә минем.
Кичләрен мин бүлмәмдә ут кабызмыйча гына утырырга яратам. Бүлмә тактасына терәлеп, сул терсәгемне өстәлгә куеп, учыма таянам да Урта урамдагы якты тәрәзәләргә озаклап карыйм. Безнең авыл клубы

ул, ике катлы, зур. Аны ак кирпечтән салдылар. Тик түбәсен нигәдер кыеклы итмәделәр. Әтигә шуны әйтергә минем дә башым эшләмәгән. Ул чакта кечкенә идем шул, беренчедә укый гына башлаган идем. Шул клубның икенче катында авылның китапханәсе. Минем әнием Рәсиха шуның мөдире булып эшли.

Китапханәнең тәрәзәләре зур. Тоташ бер пыялалы. Ут алгач та, анда пәрдәләрне тартмыйлар, көчле лампочкаларның яктысы тышка бөркелеп тора. Аның бу өлешен уку залы дип йөртәләр. Бер-бер артлы тезелгән өстәлләрнең буш ы юк. Абыйлар-апалар бик бирелеп китаплар укыйлар, минем кайчаннан бирле бинокльдән карап торуыма исләре дә китми, башларын күтәреп тә карамыйлар, кызыктыр шул китаплары. Нинди китаплар икән алар? Их, шул китапларны мин дә укысам икән! Аннан китаплар алып укыйм мин үзе, балалар бүлегеннән. Олылар ягындагы китапларны карап йөргәнем бар.

Бер тапкыр әнидән:

— Миңа китап алып кайт әле,— дип сораган идем, ул миңа:

— Бүтәннәр хезмәтеннән файдаланып үсмә әле,— диде.— Минем эш урынымнан үз максатларыңда файдаланма. Барып ал, илтеп тапшыр, әчтәлеген сөйләп бир. Иркәләнмә.

Менә минем әни шундый инде. Нәкъ әти холкы аңарда. Бер-берсенә бу кадәр охшасалар да охшарлар икән. Моннан соң мин дә Җиһангирны үзеннән эшләттерәм әле. Ату беркөнне пычракка батып кергән дә туфлиен миңа суза:

— Апа, жу-жу ит,— ди.

Юдым инде, нишлисең, бәләкәй бит әле ул. Үссен генә, эшләтә белермен мин аны. Китапларны ул да үзе алып кайтып укыр.

Утны кабызам да мин дә укый башлыйм. Пәрдәләрне тартмыйм. Минем дә тырышып укуымны күрсеннәр китапханәдәге абыйлар-апалар! Бинокльдән карамыйча да күрсеннәр! Ярышып укыйм, барыбер ярышам! Әй лә, алар болайга карамыйлар, мин генә аларны күрәм. Әнә, бер кочак китабын илтергә кузгалганы Фәрах абый, минем туганнан туган абыем. Моннан да күреп таныйм мин аны. Җил-җил йөрсә, Фәрах абый булыр инде ул. Читтән торып институтта укый, инженерлыкка. Комбайн җене кагылган аңа. Әле бүген дә, чаңгы шуарга чыккач, комбайны янында матавыклануын — бабайдан оттым бу сүзне — күрдем, йөри шунда кар ерып.

Булмә ишегеннан шакыйлар. Җиһангир икәнен белеп торам инде. Шакыган булуы, әни әйткәндәй, рәвешен китерүе генә, минем янга барыбер кермичә калмый ул. Миннән сөйдермәсә, аның күңеле булмый. Керсен инде, әйдә, язуымнан бүленеп торырмын...

Җиһангир яныма килеп сырпалана, колагымны иркәләргә тотына. Аның шундый гадәте бар — яратуын колактан сыйпап белдерә. Кечкенә-кечкенә чакта әнинең колагын тотмыйча йоклап та китә алмый иде ул.

Аннары минем алдагы китапның тышын укымакчы булып карады. Әле барлык хәрефләрне дә өйрәтмәгән идем шул, китапның исемендә ул белмәгән хәрефләр дә бар.

— Җәүһәрия апа, кызык китапмы?

— Кызык,— дим, аның сораштырмыйча барыбер чыгып китмәсен беләм бит.

— Ә кемнәр турында?

— Пионерлар турында.

— Ә алар нишләгән?

— Тырышып укыганнар.

— Җәүһәрия апа, ә син бүген ничәле алдың?

— «Дүрт»ле.

— Ә син тырышмадыңмыни?

— Менә бүген тырышыбрак укыйм да иртәгә «биш»ле алам.

Җиһангир теге өйгә йөгерде. Ишекләрне ябарга да онытты. Әнә, кечке утырышка җыелган бабай, әби, әти, әнигә яңа хәбәрен әйтә.

— Җәүһәрия апа бүген «дүрт»ле алган!
— «Өч»ле түгелмени?
Әни шулай дип сорый инде. Ул үзе мәктәптә дә, институтта да бер тапкыр да «өч»ле алмаган. Безнең әтидә инде билгеләр калейдоскопы — монысы аның үз сүзе. «Биш»легә җавап бирсә дә, «өч»ле куйдырткалаган ул. Бу фәнне шуннан артык белмим, дип. Анысы, бар инде безнең әтинең үзе сүзенә катканлыгы, авыл кешеләре белеп тә әйтәләрдер аңа кайчак, Киребеткән, дип. Ә үзләре әтине барыбер яраталар. Әтине бүтән эшкә куймакчы булгач, җибәрмәделәр. Җыелышта Фәрах абый әтине бигрәк тә мактап чыккан.

Тагын читкә кереп киткәнмен икән ич.
Җиһангир җавап бирмичә торгач, әни кабатлап сорый:
— «Өч»ле алмаганмыни әле апаң һаман?
— «Дүрт»ле алган!
— Апаң мәктәптән кайтуга ук сорарга иде.
— Сораган идем.
— Әле генә тагын сорадыңмы?
— Бу юлы сезгә әйтергә сорадым ла. Апа бүген бик-бик тырышып әзерләнә. Минем белән дә сөйләшмәгән була. Иртәгә «биш»ле алам, ди.
— И-и, әйбәт тә соң минем Җиһангир улым!

Әби әйтә инде моны. Әнә, белеп торам инде, Җиһангирны сөя. Бер Җиһангир булмады инде, аны барысы да сөеп кенә торалар. Әле өстәвенә мин дә иркәлим. Ә мине бер Сәхәрия әбием аркамнан сөя. Әни, күзләре белән миңа бик-бик яратып караса да, хәзер кочагына бик-бик сирәк ала. Мин зур бала булганга шулай итәдер инде, кечкенә Җиһангирга яратуым күбрәк кирәк, диядер. Мин үзем, әби әйткәндәй, боерган булса, барлык балаларымны да гел-гел бик-бик яратачакмын. Әни кебек кырыс булмам. Әллә әбинең:
— Балалар, үсә төшкән саен, кулдан китә баралар,— дигән сүзләренең хаклыгы шушымы икән?
Җиһангир тагын минем янга атылып керде. Тагын тәкелдәргә тотынды.

Безнең өйдә Җиһангирдан да күп сөйләшүче юк. Ничек теле армыйдыр. Әтине дә, әнине дә эштән кайткач аптыратып бетерә. Бабай белән әби дә, кая да булса барып кайтсалар, Җиһангирга бәйнә-бәйнә сөйләп бирмичә котыла алмыйлар. Күп белергә теләведер инде Җиһангирның. Минем энем шул ул, миңа охшаган! Нәкъ мин инде менә!
...Китапханәдән таралыша башладылар. Ике өстәлдә утны сүндерделәр инде. Әле Фәрах абый кузгалмый. Беләм инде, ул озакка чаклы утырачак.
Миңа да йокларга кирәк. Язудан аерыласы килми дә, житәр, вакытында ятмасаң, әни әрли.

Карагызчы, нигә минем турыда да китап язмыйлар икән? Минем турыда язмасалар да ярый ла, Җиһангир турында, бабай һәм әби, әти һәм әни турында бик калын бер китап язсыннар иде. Алар турында шәп китап чыгарсалар, аны укымаган кеше калмас иде. Әгәр безнең класс турында китап язсалар?! Безнең класста тарихка керерлек хәлләр күптән дә күп инде ичмасам! Укытучыларыбыз беравыздан:
— Сезнең класс һәр яктан данлыклы!— дип торалар бит.
Әллә үзем язып карыйммы икән? Булдыра алмам шул. Кызыклы итеп яза белмәм...»

Августның соңгы чәршәмбе иртәсе аяз иде. Төн буе матур җемелдәшкән йолдызлар, лампага өргән кебек, сүнеп бардылар.
Әмир, урманны чыгып, үрне төшкәч, болын кырында туктап торды. Яктырып җиткән, күктә болытның әсәре дә юк, кояш Арыслан тавы башыннан түгәрәк утлы таш сыман булып карый иде.

Кичен радиодан, иртәгә аязучан болыт, төнлә Татарстанда сигезүн, көндез унөч-унсигез градус җылылык, уртача тизлектә җил, вакыты белән көчле җил, яшенле яңгыр, дигәннәр иде. Гаҗәп бу табигать дигәнең, август ахырында яшен яшьнәячәк. Югыйсә, моннан дүрт көн элек түбән урыннарда беренче көзге йомшак кырау да төшкән иде бит. Үр итәге, болын чите — түбән төш ягъни, ә барыбер кырау юк. Бәлки, болын уртасында кыраулы төшләр бардыр? Булмаганны! Күңелең рәхәт уйларга бирелгәндә, башка тузга язмаган нәрсәләр керә, әй!

Әмир авылга болын әчләтеп кайтасы итте. Чык мул. Кырауның әсәре дә юк. Әмирнең күн туфлие үтәли юешләнде, озын курпыда чалбар балаклары су ергандай булды.

— Ат җибәрдем курпыга,— дип җыр сүзләрен көйләмичә генә әйтеп куйды ул.— Ат җибәрергә түгел, моны чабып алырга кирәк. Кыш корсагы озын, терлек күп. Бәлки, колхозчыларга бүлеп бирергәдер. Юк, машина белән чабарга да, киптереп чүмәләгә салгач, шобага уйнап бүлергә. Кызык булсын әле, әй, өлеш бүлүнең борынгы ысулын искә төшерик. Үпкәләшсезен. Аннары болынга ат җибәрәсе булыр...

Әтисе Газизҗан башында торып төзелгән «Революция» колхозында Әмир Хәкимовның председатель булып эшли башлаган елы иде бу. Ул, институтның механика факультетын тәмамлагач, ел ярым чамасы авыл хуҗалыгы идарәсендә инженер булды. Быел язгы чәчүгә төшәр алдыннан авылдашлары председатель итеп чакырып кайтардылар. Газизҗан пенсиягә чыкты, яше узгач та биш елдан артык эшләгән иде инде. Ул үз урынына улы кайтуына башта каршы иде — Хәкимҗаннар нәселенә генә димәгән лә колхоз арбасының төбенә җигелү! Утызынчы елда төрмәдә уздырган егерме көнне һәм сугышта булуын исәпләмәгәндә, колхозга Газизҗан житәкчелек итте ләбаса! Житәр Хәкимҗаннар нәселенә. Тик ахырда нәкъ менә нәсел мәсьәләсе җиңде. Малаен кайтаруга каршы төшеп, Кылыкта аның нәселен тотучыларны нигә азайтырга ди? Әмирҗан гомере буе идарәдә утырмас, бүтән хуҗалыкка җибәрүләре ихтимал. Улының әйбәт житәкче булачагына ышана иде ул. Димәк, чит җиргә җибәргәнче, үз авылыңа, үз колхозыңа кайтару хәер Әмирҗанны. Малаен председательлеккә Газизҗан үзе үк тәкъдим итте аннары. Һәм Әмир Хәкимов председатель итеп бертавыштан сайланды.

Әмир, үз ихаталары буендагы тыкрык турына җиткәч, әнисенең чишмәдән су алып менүен күрде. Каршысына ашыгып барды да чиләк-көянтәләрен үз җилкәсенә алды.

— Әни, мин өйләнәм,— диде ул алга төшеп.

Сәхәрия колагы ишеткәнгә башта ышанып җитмәде, сискәнеп, хәтта тукталып torгандай булды. Аннары, малае янәшәсенә чыгып, чирәмнән атлады. Әмирнең карарын шаяртып бәяләргә дә, чынга алырга да белмәде.

— Нигә өйләнәсең,— дип, беренче уйлауда мәгънәсезрәк сорады ул.

— Сиңа су ташытып булмый ич инде шушылай.

— Шуның өчен генә булса, өйләнмә. Минем әле су ташырлык кына җегәрем бар. Чишмәгә йөрүләре миңа гомерем буена рәхәт кенә булды, мине шуннан мәхрүм итмә. Әй-й, аннары, хәзерге киленнәрнең чишмә сукмагын тарсынганнары да була. Өйләнмә!

— Өйләнәм, дидем.

Кабатлап әйткәч, шаяртуы түгел икән бу киресенә беткән Әмирҗанның.

— Кайчан?— диде дә Сәхәрия көлеп үк җибәрде.

— Бүген.

— Синнән бүтәнчәсен көтмәдем дә инде мин.— Сәхәрия чәчәкле алъяпкычының җилкә элмәкләрен төзәтте.— Тик язылышу якларыгыз ничек булыр икән соң? Язылышмыйча, килен булачак кешене өйгә аяк та бастырачак түгелмен.

— Аның безнең өйгә инде аяк басканы булса? Һәм без бүген язылышачакбыз.

— Кем яза ди сезне? Рәис булып алгач, әллә сиңа закон бозарга ярый дип беләсеңме?

— Гариза күптән бирелгән. Язылышу көне бүген. Район үзәгендә. Паспортта шундагы адрес икән бит әле минем.

— Соң, аны алданрак белгертергә ярамый идемени?!— дип ачынып әйтте Сәхәрия, малаена борылып, ачуын күпертергә теләгәндәй, иелеп куйды.

— Нәрсәгә алдан әйтергә ди?! Бәлки, бер айда без гаризаны кире алган булыр идек. Киленең дә кодаларыңа бүген генә әйтә.— Әмир сәгатенә карады.— Нәкъ хәзерге мәлдә әйтәдер менә. Һе,— дип тукталды ул,— чыннан да, нигә алдан сөрән салырга тиеш ди мин?! Гомереңә диярлек председатель хатыны булып яшәп, әллә синең туй уздырырлык байлыгың юкмы? Кайчан да булса өйләнәсем мәгълүм, мәҗлес хәстәрен син күрергә тиеш.

— Ай-й аллам икән!— дип сузды Сәхәрия.— Син минем байлыгыма кул сузасың түгелме соң?

— Сузмыйм. Ләкин мин сиңа миллион туйлык кына акча алып кайтып бирдем ич инде,— дип, әнисенең күзләренә туры карап елмайды Әмир.

— Менә син ә, кире беткән җан!— дип, тыкрык башында туктады Сәхәрия һәм ике кулын да аска селтәде. Аннары тәкәббер кыяфәт белән малаена карады.— Туй мәҗлесенә акчаң булу гына аз. Туй уздыру өчен, күңелнең энҗедәй хәзинәгә чөмәләкәй тулып торуы кирәк ләбаса, күңел байлыгы кирәк! Улым, улым! Бай без, Әмирҗан, бай! Ләкин шуны бел: әтиең белән әниең бусагасыннан бер тәгам да хәрәм ризык кермәде!

— Ачуланма инде, әни, мин шаярып кына бит...

— Шаярма бу төштә! Келәтеңнең икмәккә тулып торуы гына байлык түгел әле. Байлыкка шатлык өстәлергә тиеш, ди тормыш-аксакал. Казанда биш ел укып кайттың, шуны да белмисең. Ай-й аллам икән...

— Әни, дим, өйләнәм мин бүген. Төп-төгәле шул.

— Ай-й аллам икән инде!— Сәхәрия тыкрык башыннан үз капкаларына таба кырт борылды.— Чишмәдән бакча ызанының гына менәсем калган аны, мине күрмичә дә калган булыр идең. Син кире беткән җан белән өйдә кычкырышкан булыр идек, урам уртасында түгел.

— Әни, минем хәбәргә әллә сөенмәдең инде?

— Шатланмаган кая! Өйлән!— дип, каты кычкырып ук әйтте Сәхәрия, чиләкләрдән су чайпалдырып артыннан кызуланучы малаена.

— Шулай диген, шатланам, диген. Югыйсә, миндәй юаш кешене куркуга төшерүең бар.

— Куркытырсың сине, бүредән толыбын яндырткан Газизҗан малаен!

Болай төрткеле сөйләшсәләр дә, ананың малаен яратуы, улының әнисен дөньяда иң изге кеше итеп санавы бөркелеп тора иде.

— Мин — синең дә малаең!

— Белми идем!— дип ачуын басмаган булды Сәхәрия.

— Бик төгәлләп әйткәнем бар ич инде сезгә, минем әти белән әнидән дә яхшы кешеләр юк дөньяда, дидем, алардан әйбәт бер мин генә, дидем. Чыннан да шулай инде.

— Моны син әйтмичә дә беләм мин.

Сәхәрия, урта өйнең аш-су бүлмәсенә кергәч, Әмирдән чиләкләрен алып, суны мич кырыендагы кисмәккә бушатты.

— Аш суы чишмәсенә барган идем,— дип, эш арасына кыстырып кына куйды Сәхәрия. Шуннан соң, бая ук әйткән сүзләрен кабатлап болай диде:— Соң, балакаем, синең адәм рәтле өйләнүеңне күрмәдем дә мин. Әтиең дә миңа юньләп өйләнә белмәде. Кияү Газизҗан! Үзенчә хәйлә корган, имеш!

Әмир эндәшмәде. Бу дөньяда әнидән дә әйбәт кеше була алмыйдыр, дип, күңеленә меңенче кат салды ул. Горький да, безнең түли алмас

бурычыбыз — бары тик әнигә, дигән. Горький сүзләрен төгәл үк әйтмимдер, әмма мәгънәсе шул.

Сүзне Сәхәрия дәвам итте:

— Әйтәм ич, нәкъ әтиеңчә өйләнерсең дип көттем. Бер Кәшшафетдин улым бөтенесен алдан көйләп өйләнде. Оныгым Фәрахетдиннең дә өйләнүе адәм рәтле булыр, боерган булса. Ә менә синең тумаган малаең үзеңә охшар. Монысына иман китерәм.

— Нәкъ үзем булачак! Киленеңә тамчы да охшамаячак!

— Килен... Килен...— дип, яулыгын артка бәйләде Сәхәрия.— Киленем Рәсиха буладыр бит? Килен сайлауда әкәмәт чыгарып куйма тагын.

— Менә бу соравың өчен мин ачуланам инде сиңа, әни! Килене кем була, имеш! Белеп торасың ич инде! Рәсиха!

— Һе, куркытты! Рәсихадан бүтән кешене, әйтәм ич, бусагамнан да атлатмаячакмын! Тик менә син кире җанны Рәсиха да акылга утырта алырмы икән? Әтиең сыңарын!

— Бүген үк өйләнүемне әтигә үзем әйтимме соң?

— Кияү Газизҗан белән аның Киребеткән малае Әмирҗанның кыланмышларын Кылык халкы бик көтеп тора, ди! Әйттерермен мин сиңа! Бар, әнә, урамбаш өйдә өстәл-урындыкларны тезә тор, ичмасам. Ялт итсен бөтен җир, килен төшә бүген!

Килен төшүне тиз оештырдылар. «Газик» машинасының руле артына, киленне алып кайтырга, Әмир үзе утырды. Арткы утыргычта әтисе белән әнисе иде. Арттан үз «Москвич»ында абыйсы Кәшшафетдин хатыны белән барды. Борынгы Кылыкка Рәсиха килен Әмир янәшәсенә туй күлмәгеннән утырып, артта ике кода, Кәшшафетдин машинасында кодагыйлар, озата килүчеләр машиналарында киленнең туган-тумачалары кайтты.

Туй табыны мул булды. Сәхәрия карчык килен төшәсенә алдан ук җиткелекле хәстәрен күргән булган, димәк. Ә табын әзерләшергә син инде Кылык кешеләренә әйт кенә! Күрше-тирә апайлары туй табынын борчактан да тиз куырганнар иде.

Августның егерме җидесе көнене, атна кичкә, синоптиклар Татарстан радиосыннан һава торышын болай дип хәбәр иттеләр: төнлә дә, көндез дә болытлы, төнлә алты-сигез, көндез унике-унбиш градус җылы, уртача тизлектә җил, вакыты белән көчәюе мөмкин, явымсыз. Хак булып чыкты сүзләре, әкәмәт! Хәер, монысын кич җиткәч кенә бәяләп булды.

Әмма, чыннан да, иртәдән үк күк йөзен болытлар каплаган иде. Күк тымызык күлне хәтерләтә, сыек болганчык булса да, хәрәкәтсез иде ул. Җилнең уртачасы да, көчлесе дә әлегә исми, көн басынкы, тыныч иде. Яшь килен, иртә уянып ишегалдына чыгуга ук, табигатьнең шул тыныч басынкылыгын тойды. Ир хатыны булуының беренче таңы аңа тыныч та, басынкылыгы белән шактый авыр да тормыш вәгъдә итә кебек иде. Ул үзен өйдә беренче уянучы дип уйлаган иде. Алай түгел икән. Сәхәрия лапастан ак чиләк белән яңа сауган сөт күтәреп чыгып килә иде. Каенана чәчәкле яулыгы өстеннән, маңгаен кысып, тагын бер яулык бәйләгән иде, башы авыртып киткән чакларда шулай итә ул.

— Тордың дамыни, килен, йоклыйсы идең. Иртә бит әле.

Рәсиха ничек җавап кайтарырга да белмәде, нәрсә әйтсә дә, каенанасы гаепкә алыр кебек тоелды. Алай дисәң, әнкәсе аңа үз итеп эндәште. Ир хатыны булу, килен булу тормышы ничек башланып китәргә тиеш икән соң бу? Кичәге туй мәҗлесе тормышның бер ярында калды да, бүгенге иртә аның каршысыннан башланып китә кебек. Мәҗлестә каенатасы белән каенанасын, яңа туганнарын үзләренә сиздермәскә тырышып күзәтте. Алар да Рәсиханы сынап караганнардыр, моңа гаҗәпләнәсе юк. Әмма яшь килен үзенә мөнәсәбәттә ясалмалык сизмәде, аны олы нәселгә чын күңелдән кабул иттеләр. Рәсиха шундый

фикергә килде. Шулай да шик бар бит әле күңелдә: бу фидаилек гомер буена дәвам итәрме икән? Гел ихласлыкка боерган булса, җир йөзендә Рәсиха иң бәхетле кеше булачак!

— Әнкәй, мин сыер сава белмим...

Йа, хикмәт, крестьян хуҗалыгы алып барган гаиләдә мондый булдыксызлык гафу ителмәячәген уйлап җиткермәде Рәсиха. Каенанасы моңа каршы сәеррәк сүз әйтте, ачуланмады да, хупламады да бугай ул. Югыйсә, Сәхәрия битараф калмый, өздереп сөйли иде.

— Сыерыгызны кибетчедән саудыргач, ничек белмәк кирәк инде аны.— Һәм Сәхәрия әмер бирә башлады.— Бар, юын да килешлерәк күлмәгеңне ки. Самавыр кайнаган, чәй эчеп ал. Мин сөтне сөзеп урнаштырыйм. Ә-ә, карале, Рәсиха, менә җылы сөт эчәрсең, яме. Эткән көтүне куар. Теге ялкавыңны уят, эшенә бармаска әйтәме әллә ул. Барсын, сөйрәп торгыз. Туйның аның иртәнге мәшәкате авыр, кодалар төшеп җитәр, башка туган-тумача җыелыр. Мин учакка ут элдерәм. Ашны эткәң әйбәтләп карап кайнатыр. Син бәрәңге алып кер, казып кына ал, кирәкне бакча капкасына сөяп куйган. Аннары, синең белән икәүләп, чишмә сулары алып кайтырбыз. Кодалар төшеп җиткәләгәнче, эшне җиңеләйтеп куйыйк. Бүген эш бетмәс инде аңысы. Ай-й аллам икән... Бүгенге мәҗлес кичәгесеннән зуррак та булыр, шәт. Киленне күрергә бөтен авылы сылтау табар. Син бер үк сыната күрмә, Рәсиха. Кем килене дигәндә, Сәхәрия килене, дигән сүзе дә бар бит әле аның.

Ике йортны да, борынгы гадәт буенча, беренче төнгә яшь кияү белән яшь киленгә калдырганнар иде. Газизҗан белән Сәхәрия бер төнгә күршеләренә өйдәш булдылар. Кодалар Кәшшафетдиннәрдә, ә Рәсиха ягыннан килгән бүтән туганнар да шулай ук күрше-тирәдә кундылар. Кунаклар кияү йортына җыелыша башлаганчы, каенана Сәхәрия белән килен Рәсиха чишмә суына киттеләр.

Кылыкта зур чишмәләр бишәү, өчесе Сул Инештә, икесе Уң Инештә. Һәр чишмәнең суы үзгә икән. Сәхәрия су юлында Рәсихага шуны аңлата барды. Бер чишмәнең суы ашны тәмләтә, икенчесе чәйне чыгышлы итә, өченчесенең суын тирлек-туар яратып эчә, дүртенчесенең суы керне бик агарта икән. Алар кайта-китә йөргән арада, табын хәстәрен дә күрделәр. Кәшшафетдин беренче булып килде. Сәхәрия аңа коедан мунчага су ташырга кушты. Коеның суы, Сәхәрия әйтүенчә, нәкъ мунча өчен икән ләбаса, тәнгә рәхәтлек бирә икән! Бишенче чишмәгә каенана иң соңыннан алып барды. Ул Сул Инештә, авылның өске уңаенда ук, аңа тыкрыктан төшеп, елга эчләтеп кенә дә менәргә була. Әмма Сәхәрия Рәсиханы Урта урамнан алып менде. Бу юлы үзе дә чиләк-көянтәләрен күтәргән иде. Ярата иде Сәхәрия урамның уртасыннан йөрергә, бер гадәте иде бу аның. Яшьлегендә бигрәк тә ярата иде. Хәзер урам уртасыннан сирәгрәк йөри башлады. Уза гомер, кырык бишенче елда, Җиңү көнендә туган кече малае Әмирҗан да өйләнде. Урта урамның уртасыннан менсеннәр алар. Кылык кешеләре Сәхәриянең киленен күрсеннәр! Ә Рәсиха әйбәт килен булырга охшаган.

— Әнкәй, бу чишмәнең суы нәрсә белән данлыклы?— дип сорады Рәсиха, тыкрыктан күтәрелеп, Сул Инеш урамына борылгач.

— Моңысының...

Кинәт Сәхәрия сүзеннән генә түгел, баруыннан да тукталды. Көянтәсен икенче җилкәсенә күчерде. Аннары, урам читенә чыгып, чиләкләрен янәшә, ә көянтәсен чиләкләр өстенә куйды.

— Әнкәй, кирәкмәс сорау бирдемме әллә?

— Юк ла, соравың бик урынлы. Үзем ничек башлап, ничек аңлатырга белмим. Син дә куй чиләкләреңне.

— И-и, әнкәй, уңайсыз бит. Сәхәриянең килене уңмаган икән, тукталып ял итмичә, чишмәдән су да алып кайта алмый, диярләр,— дип елмайды Рәсиха һәм каенанасына шушыннан башлап күңеле якынаюын сизде ул.

— Курче, салпы якка салам кыстырырга үзебезгә охшагансың икән ич! Ә монда туктаган өчен яманлап сүз әйтмәсләр. Безнең Кылыкта хаксыз сүз сөйләмиләр, сөйләмәсләр. Монда тукталмыйча үзсак, гаепләсәләр дә урынлы.

Сәхәрия карашын Арыслан тавы башына күчерде. Аннары сулы чиләкләре яныннан ук башланучы бушлыкка текәлде. Ул киленe соравына җавапны читтән башлады.

— Рәсиха, мин сине бер күрүдә үк киленем итеп яраттым бит. Әмирҗан, колхозга рәис булып кайтканчы ук, сезне чәй эчәргә алып кергән иде. Семинар, дисезме әле, китап җене кагылган кешеләр әнә шул семинарыгызга безнең авылга җыелган идегез. Хәйләкәр дә соң! Әмирҗанны әйтәм. Нәкъ этисе, нәкъ Кияү Газизҗан инде. Сезне чәйгә чакыруның сере килен күрсәтүе булган икән. Булачак киленен әнисе арадан үзе танып алырга тиеш явызның. Таныдым бит! Әле кичә сораган идем, киленебез Рәсиха буладыр бит, дигән идем. Кем булсын тагын, ди, тавышын күтәреп әйтә бит. Ай-й аллам икән... Әнисе булачак киленнең бер сөйләшүдә исемен ничек хәтерләп калуына илтифат та итми бит ичмасам.

Рәсиха, каенанасын ярата ук башлавын сиздереп, аңа сыенды һәм аны беләгеннән ике куллап сыпырып сөйде.

— Бу пуҗум,— диде Сәхәрия, каршысындагы бушлыкка күрсәтеп,— минем туган нигезем. Инде ничәмә ел шундый мескен хәлдә мена. Кәшшафетдинемнең Фәрахетдине үсеп җиткәч, шушында башка чыгарырбыз дип исәп корабыз да бит. Әле аңарга егет булырга шактый шул. Кәшшафетдинем башка чыкканда, энеләремнең кайсы да булса исәндер, дигән өметебез яши иде. Инде сугыш беткәнгә егерме биш ел узды, һәлак булганнардыр шул, үлү хәбәрләрен китергән кәгазьләргә хак язганнардыр... Урыныбыз буш. Синең малаең кайчан туып үсеп җитәр, малай табарсыңмы әле тагын. Аннары Газизҗан нигезе өчен дә малай кирәк бит. Фәрахетдинне шушында башка чыгару дөрес булыр. Ул инде күзгә күренгән бала. Тизрәк үсеп кенә җитсен.— Сәхәрия чиләк-көянтәсен күтәрергә әзерләнде.— Ә минем туган нигеземенең бакча башындагы чишмәнең суы, Рәсиха киленем, аш өчен дә, чәй өчен дә, мал эчерергә дә, кер уарга да әйбәт. Бәби коендырырга безнең чишмә суына җитәрдәе юк, дияр иде әни мәрхүмәкәем... Ай-й аллам икән! Кодалар төшеп тә җиткәндер, ә без икәүләп гүләйттә, ике ялкау! Килендәшең хөрмәт күрсәткәндер анысы. Рәт белә ул, мин генә гомер итеп эш рәтенә өйрәнә алмадым, хәерсез. Ә син, Рәсиха, өйрәнерсең, боерган булса, сыер саварга гына түгел, Газизҗанның сөйкемле сөяге Әмирҗан хатыны булырга да өйрәнерсең. Дөнья бу, Рәсиха киленкәем! Дөнья...

*Ахыры бар*

# Әхмәт Рәшитов

## Кем җырлады?

Кайдан соң бу болай ишетелә
Кечкенәдән таныш милли моңнар?
Җырла, җырчы, туган илен уйлап,
Синең җырны кемдер йотылып тыңлар...

Кайдан соң бу җырлар ишетелә,
Агач башларына куна-куна?
Кайсы хыялые килеп чыккан
Салкын тайгаларга, туңа-туңа?

Кем җырлады икән, һай, өздереп?
Бу кырыс җир җырга лаекмыни?
Сандугачлар сайрамаган җиргә
Ямьнәр өстәрме соң татар моңы?

Керә дә җыр сазлы урманнарга,
Адашып ла йөри юлчы сыман;
Ашкынып ла гына чабар иде —
Юлларында аның аксыл томан.

Кем җырлый дип башлар ватасы юк —
Бораулаучы егет, безнең якташ,
Гармунына сагышын сөйли-сөйли
Җырлап утыра кайчак, беткәч вахта...

Кечкенәдән таныш милли моңнар,
Кагылды да йөрәк кылларына,
Бер рәхәтлек бирде юлчыларның
Себер аша үткән юлларына.

## Лангепас

Ерак юллар үтеп килдек монда
Һәм торабыз менә хәйран калып;
Йокымсырап яткан тарафларны
Уятырга килә күпме халык.

Йолдызлар да шул ук, шул ук ай да,
Үзгә бары заман, үзгә — тайга.
Яңгырап тора туган яктан килгән
Таныш моңнар һәрбер буровойда.

---

ӘХМӘТ РӘШИТОВ *(1936) — шагыйрь, «Хатирә», «Сәяхәтнамә», «Киек каз юлы» һ. б. шигырь китаплары авторы. Татарстанның атказанган культура работнигы. Казанда яши.*

Нижневартовск һәм Сургутка
Ныклы терәк кирәк аркасында
Шәһре Лангепас күк япь-яшь кала
Пәйда булды Себер картасында.
Салды аны безнең якташлар да,
Йөрәк җылыларын кушып салды.
Шуңадыр да яңа кала безне
Якты чырай белән каршы алды.

Ят җир түгел Себер безнең өчен —
Киләчәге якты, нурлы аның.
Бу якка да инде килеп җиткән
Саф җилләре яңа заманның.

Көрәш мәйданнары һаман киңрәк,
Мөмкинлекләр башка, көчләр башка.
Алып сыман татар егетләре
Мәйдан тота бүген Лангепаста.

## Балачак хатирәсе

Кышкы тәрәзәдә — кара урман.
Чыкмый һаман кояш.
Шушы тәрәзәнең аязганын
Күрер микән бу баш!

Өрә-өрә сулулары каба
Эретим, дип, читен,
Кояшсыз да, әтисез дә аңа
Яшәү бигрәк читен.

Абагалы сихри чытырманны
Булса иде үтеп!
Урман кырыенда ул әтисен
Торыр иде көтеп.

Кышкы тәрәзәдә — кара урман...
Җирдә сугыш бара.
Атаң җиңәр, кояш чыгар бер көн —
Өзгәләнмә, бала!

## Васыять

*(Ветераннар сүзе)*

Кояшы да сезгә калыр.
Җире дә, җилләре дә —
Без инде китеп барабыз
Мәңгелек илләренә.

Ә сезгә әле яшисе —
Җир сөреп, ашлык чәчеп
Һәм үзсүзле дөнья белән
Көн саен бәхәсләшеп.

Тарихлар язган сабакны
Әллә инде җуйганнар —
Үлем уены уйныйлар
Яшәргә дип туганнар.

Тумаулары мөмкин иде —
Очраклылык сәбәпче;
Ник соң шөкер итми адәм,
Ник сүгенә, ник чәпчи?!

Җир йөзендә бертуктаусыз
Канлы сугыш, үч, җәбер.
Атом дигән күсәк белән
Кизәнмәкче кемнәрдер.

Яхшымы дөнья, яманмы —
Ул кирәк, зарур, тиеш.
Шуңа сезгә калдырабыз
Без аны исән килеш.

Без китәбез. Ә заманның
Яхшыга барышлары.
Тик исәннәр — бу дөньяның
Бердәнбер варислары.

«Без китәбез»... Чират җиткәч,
Сез дә шулай диярсез,
Мәңге яшәргә тиешле
Җиргә башлар иярсез.

Имин илдә батырларга
Бишек җыры ял булсын,
Җирдә һаман гөлләр үссен,
Таңнар һаман ал булсын.

## Аэропорт

Җирдә бураннар котыра,
Күктә дә бураннардыр.
Җиргә кайтасы кешеләр
Ни уйлый торганнардыр?!

Каршылаучылар шикләнеп
Борчыла торганнардыр.
Шуңа күрә дә бер керә,
Бер чыга торганнардыр.

Бураннар һаман басылмый,
Ә күңел түзем әле:
Йомгакка урый бураннар
Күрешү мизгелләрен.

Хәерле хәбәр көтептер —
Сөйләшләр тоньк, сирәк...
Ә миңа монда ни калган?
Ә миңа нәрсә кирәк?

Беркемне дә каршыламыйм,
Беркемне дә озатмыйм.
Бары биген ачам бугай
Күңелдәге йозакның.

Очсын аннан әсир кошлар
Бураннар арасына,
Дәва эзләп йөрәгемнең
Күптәнге ярасына.

Очсыннар ерак-еракка,
Очсыннар хыялгача.
Язмышны көртка батырган
Буранлы еллар аша.

## Апокалипсисмы?..

Карашлар ерак төбәлгән,
Төбәлгән чиксезлеккә —
Ни эзли адәм баласы
Күзләрен төбәп күккә?

Анда тик космик «кабер»дән
Атылып торган ташлар,
Анда яңа кабынган һәм
Инде сүнгән кояшлар.

Анда кызыл гигантлар һәм
Ак кәрләләр өере
Үлем нурлары тарата
Галәмнең салкын җиле.

Карамыйча дәһшәтләргә
Хыялый адәм сыман,
Кая соң без ашкынабыз
Киек каз юлларыннан?!

Эзлибезме җан иясе
Йолдызлар арасыннан?!
Радиокүзләр төбәлгән
Центавр альфасына.

Җирдәге бар җан иясе —
Бер-берсен ашаучылар —
Галәмнән безгә кунаклар
Килмидер бәлки шуңар?!

Ә бәлки без бердәнбердер
Иксез-чиксез җиһанда,
Күктәге хәрабәләрне
Алмыйктыр бәлки санга?!

Чөнки Җирнең үз хәле хәл,
Борчуы, үе башка.
Чөнки мөмкин әверелүе
Аның да җансыз ташка.

Нишләрсең, әгәр булмаса
Сандугач... чәчәк... кеше...
Яман атадан туганнар
Юк итсә яшәешне!

Җанын атом алган җанның
Таштагы шәүләсенә
Галәми җанның ул чакта
Дәшүеннән ни мәгънә?!

Онытмыйк ла — хыялланып,
Йолдызлар күзли-күзли —
Бу илаһи һәм гөнаһлы
Җир атлы җиребезне!

## Биеккә!

*Кешеләр барыбер кошлар нәселеннән.*

С. Сөләйманова.

Гел биеккә алар, гел биеккә! —
Мин көнләшеп карыйм кошларга;
Их, миңа да шушы кошлар кебек,
Зәңгәр киңлекләрдә очарга!

Ярышмакчы булып алар белән
Уйлар кабат канат кагына
Аэроклублы яшьлек көннәремә,
Хыялымның алсу чагына.

Һаваларга әле менмәс борын
Күгемнән соң кемнәр аерды?
Язмышыммы, кошлар каргышымы
Канатымны шулай каерды?

Үкенсәм дә, хәзер соң шул инде —
Туздырылган күпме оялар!
Кыргый «эшләремне» уйлыймын да
Хыялымнан хәтта оялам.

Ә нигә соң җанда сихри аваз?
Ә ниләр соң борчый күңелне?
Борынгыдан канда калган геннар
Шулай күккә өнди түгелме?

Ыгы-зыгы тулы бу дөньядан
Гарык булып туйган чагымда
Әллә ниләр тели күңелем кошы —
Ал хыяллы чагын сагына.

Гел биеккә дәшә, гел биеккә!
Юк, бу хисне тыймыйм... тыялмыйм!..
Артларыннан ләкин җитәлмим шул —
Канаты юк ерак хыялның!

Гел биеккә кошлар...
Гел биеккә!..

*1986—1987.*

# ДӘРТЛЕ, ДӘРМАНЛЫ ӘДИП

МӘХМҮТ ХӘСӘНОВКА 60 ЯШЬ

Мәхмүт Максуд улы Хәсәнов 1927 елның 21 декабрендә Татарстанның хәзерге Саба районы Югары Кибәхуҗа авылында игенче гаиләсендә дөньяга килә. Монда аның балалык еллары уза. 1937 елда Зеленодольск шәһәренә күчеп килгәч, бишенче татар урта мәктәбенә укырга керә. Сугыш вакытында, һөнәр училищесын тәмамлаганнан соң, слесарь булып эшли. Яшьли әдәбият, сәнгать белән мавыгып киткән үсмер 1944 елда Мәскәүнең А. В. Луначарский исемендәге Дәүләт театр сәнгате институтына юнәлә. Аны бетереп кайтканнан соң, башта Яшь тамашачылар, аннары Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында уйный. Озакламый ул әдәби иҗат эшенә бирелә — «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә, Татарстан радиосында әдәби хезмәткәр, хәбәрче вазифаларын үти, укучыларга һәм тыңлаучыларга беренче очеркларын һәм хикәяләрен тәкъдим итә. Әмма сәхнә белән дә бәйләнешен өзми — илленче, алтмышынчы елларда «Нурихан», «Рамай», «Кәя күбәләге», «Хикмәтле Хикмәтулла» пьесаларын яза, алар республикабыз театрларында куела.

1957 елда Мәскәүдә икееллык Югары әдәби курсларда махсус белем алганнан соң, Мәхмүт Хәсәновның иҗаты тагын да киңәеп, куәтләнеп китә. Татарстан нефть үзәкләренең берсе булган Азнакай эшчеләр поселогына күчеп бару һәм егерме бер ел буе шушы якның алдынгы нефтьчеләре, төзүчеләре, игенчеләре һәм терлекчеләре, культура һәм фән эшлеклеләре белән даими аралашып яшәү аның тормыш тәҗрибәсен баета, әсәрләрендә яңа темалар, яңа каһарманнарны гәүдәләндерергә мөмкинлек бирә. Татарстанның беренче нефть разведчикларын сурәтләгән «Яңа горизонт», эшчеләр тормышын чагылдырган «Урман шаулый» повестьлары татар прозасына өметле каләм иясе килүен хәбәр итә.

Балаларга атап язган хикәяләре, «Динозаврлар өнендә», «Шайтан малае», «Зимагур», яшьләргә адресланган «Очар кошлар», «Җирән кашка» повестьлары һәм бүтән әсәрләре башта вакытлы матбугатта, аннары китап рәвешендә кат-кат басылып, укучылар тарафыннан җылы каршы алына. Әмма Мәхмүт Хәсәновны җәмәгатьчелеккә аеруча үз иттергән әсәрләр — аның романнары. Каләменең шомара, сәнгатьчә сурәтләү осталыгының үсә баруын күрсәткән «Юллар, юллар»ы юл төзүчеләрнең эчке дөньяларын ачуга багышлана. «Саф җилләр» дилогиясендә исә авылда барган үзгәрешләр, Мәдинә, Хәдичәләрнең ышандыручан образлары гәүдәләндерелә. Бу әсәрдә колхоз эшләрен, аның кешеләрен яхшы белгән язучының әдәби телгә, әсәрнең сюжетын коруга да игътибары арту күзгә ташлана. Татар эшчеләренең революциягә килүен чагылдырган «Саумы, кояш» романы бу яктан авторга тагын да зуррак сөенеч китерә — әсәр әдәбиятыбызга кушылган күркәм өлеш төсендә бәяләнә.

Мәхмүт Хәсәнов татар әдипләре арасында җитезлеге, кыюлыгы, әсәрдән-әсәргә үсеп баруы белән аерылып тора. Бу фикерне аның КамАЗ төзелешенә багышланган «Кама таңнары», нефтьчеләр тормышын сурәтләгән «Шәҗәрәләр» романнары һәм, барыннан да бигрәк, яңа дөнья күргән «Язгы аҗаган» әсәре раслый ала. Гәүдәләндергән тормыш материалының катлаулылыгы, вакыйгаларның күп тармаклылыгы, язмышларының тирәнлеге, колачлаган вакытының озынлыгы, образларының күплеге һәм кабатланмаслыгы белән дә, әсәрнең сәнгатьчә эшләнеш югарылыгы белән дә бу роман М. Хәсәнов иҗатының гына түгел, туган әдәбиятыбызның да җитди казанышы. Иргали, Гази Гөлүсә — бу әсәрнең байтак каһарманнары укучылар күңеленә иңеп, гыйбрәт бирә-бирә, алар белән бергә яшәвен дәвам итә. «Язгы аҗаган» романы әдәбиятыбыз мәйданында утыз елдан артык җиң сызганып эшләп килгән авторны иң күренекле каләм ияләребез сафына бастырды.

СССР Язучылар союзы әгъзасы, Татарстанның атказанган культура эшлеклесе Мәхмүт Хәсәнов алтмыш яшь тулган көнен иҗади җитлегеп, тагын да матуррак әсәрләр язу үе белән янып, кызу эш өстендә каршылый. Без киләчәктә дә аның илһам чишмәсе озак-озак тибеп торуын, талантының яңа кырлары ачылуын, җәмәгатьчелекне яңа әсәрләре белән куандыруын, укучыларының кайнар мәхәббәтен тоеп, һаман шулай шат күңелле, дәртле-дәрманлы яшәвен, рухы белән гомере буе яшь булып калуын телибез.

Тәүфикъ ӘЙДИ.

**Мәхмүт Хәсәнов**

# СЫЙМАС САДРИ

хикәя



Садри тагын эшсез калды. Өй эче яңадан хатынының яшелле-күкле чәрелдек тавышы белән тулды, колагың гына түзсен.

— Ниш-лим? Җир тишекләренә кереп китәсеңмени бу хурлыклардан?! Ояты ни тора! Кемне эшеннән чыгарып атканнар дисәң, тагын аны. «Ничек котылырга белмиләр үзеннән»,— дип ишеттергәннәр иде, хак булган икән...

Садри: «Мине беркем дә чыгарып атмады, үзем киттем»,— дип сүз кыстырмакчы иде дә, кая ул! Бар, тыеп кара син узынган хатынны.

— Ниш-лим?! «Кемнеке?— Аныкы...»— дигәндә, үлепләр китәсеңмени? Ничекләр итеп җаннарың күтәрә шул мыскыл итүләрне? Адәм мәсхәрәсенә калдың бит инде. Әнә, «Сыймас» дигән кушамат тактылар бит инде үзеңә. «Сыймас Садри» хәзер исемнәрең. Хәзер инде: вак җанлы, бәлачел мыжгы кеше дип кенә дә чикләнмиләр. «Әллә аның бераз җитмиме?»— дип көләләр бит үзеңнән. Үч иткәндәй, «инженер» дигән исем күтәреп йөргән буласың ич, адәм мәсхәрәсе!

Тешен кысып булса да дәшмәскә тырышкан Садриның да чыдамы бетте.

— Җиттеме сиңа, юкмы, ниһаять? Америкада түгел, эшсезлектән интекмәм...

Хатыны тәтелдәвен белде:

— Яшь чагың булса, бер хәл иде. Юк бит! Әнә күр, чалардың бит инде. Яшең кырыкка җитеп килә. Кияүгә бирерлек кызың, үсеп беткән улың бар. Кулыңнан эш килмәсә, бер хәл иде. Юк бит! Нинди генә эшкә алынсаң да, коеп куясың, кайда гына эшләсәң дә, йөзең ак була торган иде. Ниһаять, урыныңн тапты, хәзер инде күңеле ятып тыныч кына эшләр, бәлки, адәм рәтле квартирага күчәрбезме, дигән идем. Күчәрсең, бар, бу «Сыймас» сантый белән! Әлеге дә баягы бер сүз: «Тынышa алмаган, тагын начәлствасы белән телгә килгән!» Йә, әйтче зинһар, кемгә нәрсә исбат иттең соң? Кемгә кирәк булды ул сукыр бер тиенгә тормаган дөреслегең! Монда минем балаларымны үз вакытында ашатасым, җүнле фатирда яшәтәсем килә. Таптың дөреслекне... Әнә, каш ясыйм дип, күз чыгаргансың, шул булган. Һа-ай, шушы кешеләр белән уртак тел табып эшли алмауларың! Үтерә лә!..

— Янә ялгыштың! Кешеләр белән эшли алам мин. Ә менә кешелекләрен җуйган, җыен вак җанлы бюрократ, күз буяучылар белән боткам пешми. Моннан соң да пешмәячәк!..

— Ташлачы, зинһар! Күктән иңгән фәрештә диярсең үзеңне. Кайда юк соң ул кимчелекләр белән житешсезлекләр! Күрим дисәң, атлаган саен бит алар. Аннары, тормышның бөтен кыегын сиңа гына турайтырга, сиңа гына төзәтергә димәгәндер ич?! Моңа кадәр дә шулай булган, моннан соң да дәвам итәчәк. Күзеңне ач, дөнья бу! Гомерең буе «Сыймас Садри» булып яши алмассың бит инде...

Садриның бу юлы да сабырлыгы сынды.

— Әле дә ярый, бөтен кеше дә синең кебек уйламый...— диде төк-

се генә. Ул инде: «Синеңчә: берни дә күрмә, ишетмә, җыен башбаштаклыкка күз йом, үзеңә дә, башкаларга да тыныч булсын, шулаймы?..» — дип өстәмәкче дә иде, тик өлгерә алмый калды. Хатынының яшелле-күкле тавышы яңадан һаваны ярды:

— Соң, җаным, әйтче, зинһар, кайчан әле нәчәлстваны тәнкыйтьләү кешегә бәхет, сәламәтлек белән җан тынычлыгы китергәне бар?! Аның ише эшләр белән шөгыльләнүче махсус оешмалар бар лабаса! Шул ук партия, профсоюз, хуҗаларның җитәкчелегенә контрольлек итүче комиссияләр дә бар ди ич...

Хатынның ярсуы чак кына басылган сыман булды. Шулай да, борынын тартып дәвам итте.

— Әйт, тагын нинди мөгез чыгардың инде?.. Нәрсә булды? Зариф белән һәйбәт кенә эшләп ята идегез ич әле? Нәрсә бүлешә алмадыгыз тагын? Соң, җаным! Чак кына телләреңне тыеп булмый идемени соң? Туры әйткән туганына ярамаганын беләсең ич. Чак кына синеңчә булмадымы, бетте, шундук: «Начар, яман кеше» имеш. Э-эх, кайнар баш, кайнар баш! Ул да хаклык эзли, янәсе. Менә җөре инде яңадан, җилкуар кебек, атна-ун көн буена эш эзләп.

Бу юлы Садриның җавабы әзер.

— Йөремәм! Эшне белешеп куйдым. Гариза белән Хезмәт кенәгәмне дә илтеп тапшырдым. Әнә, кая карама, эшкә чакырып торган игъланнар: «чакырабыз, кабул итәбез!..»

— Кая урнашасы иттең соң?.. — Бу юлы хатынының тавышы кешенекечә яңгырады.

— Бораулау эшләре базасына.

Хатын кеше янә элеккеге кыяфәтенә кайтты да куйды.

— Нәрсә? Базага диденме? Ишкәнсең икән а̃лайса ишәк чумарын. Инженер башың белән берәр складка төнге каравылчы булып яллынмыйсыңмы тагын!..

Садриның йөзе тагын караңгыланды.

— Берни дә белмәгән башың белән хет сөйләнеп торган булма ичмаса! Һәркайсы үзе кечерәк заводка тиң булырлык биш-алты цехы гына бар ул базаның.

Шулчак алтынчы класста укый торган улы кайтып керде. «Бала алдында гына тавышланмаса ярар иде», — дигән уй чагылып китте Садриның башында. Хатыны исә, малае кайтканны гына көтеп торган диярсең — күкерт кебек кабынды да китте.

— Әнә, күр, яңадан мәктәпкә чакырткannар. Тагын укытучысы белән әрепләшкән...

Малай да авызын йомып кала торганнардан түгел.

— Кем әрепләшкән? Беркем дә әрепләшмәгән аның белән...

— Дәшмә, ичмасам! Ачуымны китермә! Тиктомалга ата-ананы мәктәпкә чакыртмыйлар.

— Мин бары тик үз фикеремне генә әйттем...

— Дәшмә диләр бит сиңа! Ул да сөйләнеп торган була бит әле, әтисе сыңары. Каян килсен ди сиңа фикер? Ул бит укытучы. Аңлыйсыңмы шуны: у-кы-ту-чы! Аның сүзе — закон!

Садриның үз уйлары: «Менә шулай тәрбияләнә ул принципсыз мәми авызлар... Бүген аңа: бары тик укытучы гына хаклы дип тәкрарлыйлар. Иртәгә инде ул: бары тик начальник кына хаклы дип уйлаячак. Шулай итеп теләсә нинди кабахәтлеккә күз йомучыга әвереләчәк. Күршесен яки якынын берниди гөнаһсызга акыртып суйганда да, тел тибрәтеп яклау сүзе әйтмәячәк...»

Ул арада чыгып китәргә әзерләнгән хатынының теле янә авызына сыймады.

— Мәктәпкә, эти кеше буларак, сине җибәрәсе иде дә бит, юк! Анда да синең кем икәнлегеңне белеп өлгерделәр... Әйдә инде, җан көеге! Алма агачыннан ерак төшми дип, шуны әйтә торганнардыр инде.

Ниһаять, ана кеше, үзенең җүнсез улын эткәли-төрткәли, өйдән алып чыгып китте.

Бер вакыйгадан соң, чыннан да, эти кешене мәктәпкә чакыртмый башладылар. Сәбәбе түбәндәгедән гыйбарәт иде. Садриның улы Кави белән бер партада утырган малайга, дәресен бөтенләй белмәсә дә, класс житәкчесе өчле билгесен куйган. Шунда Кави: «Дәрес эшләмәдегез...»— дип, үзенең ризасызлыгын белдергән. Садрины мәктәпкә чакырту өчен шул җитә калган. Әмма эти кеше, малаен гаеплисе урында: «Протест белдереп дөрес иткән...»— дип җыелган ата-аналарны шаккатырган. Алай гына да түгел: «Дәреслекне ачып та карамыйча, көч куймыйча өчле билгесе алган балбес, үсеп җиткәч, бармагын-бармакка какмыйча, хезмәт хакы алырга да тартынмаячак»,— дип өстәп куйган.

Икенче көнне улын дүрт-биш малай җыелып тукмап кайтарды. Ә көндәлегендә, ат башы кадәрле, өчле билгесе...

Хатыны Нәгыймәгә, гауга чыгару өчен, шул җитә калды:

— Менә, күпне күрсәң, башкаларга караганда күбрәк белсәң, шулай да була ул: кара көйгәнче тукмыйлар да өчлесен куярга да онытмыйлар.

Садриның җавабы әзер:

— Зарар юк! Чын кеше булу — һәрчак бишледән башланмый.

...Эш табуның берниндн дә кыенлыгы булмады. Садри районда чыга торган «Хезмәткә дан» дигән газетаның дүртенче битенә күз салды да сызгырып җибәрә язды. Иң гаҗәпләндергәне шул иде: барлык белдерүләрдә дә «производство командирлары»— урта звено җитәкчеләре кирәк. Әнә, никадәрле вакансияле урын! Нефть һәм газ чыгару идарәсенә бүлек мөдирләре, участок башлыклары кирәк. Төзү-монтаж идарәләре прорабларга, мастерларга мохтаҗ. Бүтәннәре диспетчер белән бюро җитәкчеләрен чакыра. Хезмәт хакы да ярыйсы гына, премия дә вәгъдә итәләр. Ә бораулау эшләре идарәсенең Үзәк базасына бүгеннән цех башлыгы кирәк. Садри әлеге «Цех башлыгы» дигән белдерүгә тукталасы итте.

«Нәрсә бу?»— дип уйланды Садри. Бер караганда, андый урыннарга дәгъвачылар атлыгып торырга тиешләр иде кебек. Югары уку йортларыннан күпме яшь белгеч чыга. Инженерлар турында әйткән дә юк, алар хәзер буа буарлык. Аларның дәрәҗәсе бик нык кимеде соңгы елларда. Хезмәт хакы түбән. Ә җаваплылык баштан ашкан. Кайбер яшь инженерлар, дипломнарының карасы кибәргә дә өлгермәс борын, «карьера» диптер инде, берәр җаваплы эшкә алына да соңыннан ничек котылырга белмичә иза чигә. Чөнки бөтен җаваплылык әлеге яшь түрәгә йөкләнә: эшчеләрне көндәлек эш белән үз вакытында тәэмин ит, кирәкле материаллар һәм җиһаз-җайланмалар булдыр, хезмәтне оештыр, тәртипне яхшырт, план үтәлеше һәм сыйфат, яңа техника һәм технология, социалистик ярыш һәм идарә итү психологиясе, тагын шундый мең төрле нәрсәләр өчен җавап бир. Гаять катлаулы, күп тармаклы эштән тыш, әледән-әле килеп чыга торган бәхәсле-гаугалы хәлләр дә көтеп тора. Бер якны да рәнжетми-кимсетмичә, беркемнең дә мин-минлегенә тимичә, хәл итәргә тиешсең. Менә шунда инде яшь йөрәк: ялгыз башым, тыныч колагым дип, гади станокчы булып эшләүне мең тапкыр өстенрәк күрә башлый. «Дипломлы станокчы» дигән сүз нәкъ менә шуннан килә дә инде.

Садриның Үзәк базада торба-турбина цехы башлыгы вазифасына туктавының тагын бер сәбәбе бар. Моннан унбиш еллар чамасы элек ул инде бу базаның электр җиһазлары цехында күпмедер вакыт слесарьлыкчы булып эшләгән иде. Әле дә хәтерендә Садриның: Губкин исемендәге нефть институтының Лениногорск филиалында читтән торып укый башлаган еллары гына иде. Уйлана торгач, ул чакта ни өчен эштән китәргә мәҗбүр булуы да исенә төште. Смена механигы белән уртак тел таба алмаган иде. Һаман да шул «җайсыз», «артык дөрес»

кеше булуы аяк чалган иде аңа. Әле дә хәтерендә: тарткалашу бөтенләй юктан башланды. Көннәрнең берендә механик килде дә: «Иптәш Бәдриев, барыгыз әле, теге күз көегенең узелын җыешып бирегез әле, смена беткәнче, конструкция тапшырылырга тиеш»,— диде. Садри исә: «Боерык сездән, йөгермәк бездән»,— дип очынып торучылардан түгел. Башлаган эшеннән бүленмичә генә сорап куйды: «Ничәнче разряд белән эшли соң ул, сез әйткән «күз көеге»? «Дүртенче», диде механик. Садри да җавабын алдан ук әзерләп куйган диярсең: «Минем дә дүртенче разряд кына бит, ничек кенә ярдәм итәрмен икән соң мин аңа?» «Үз разрядына туры килми, гомумән, кулы эшкә ябышмый ул булдыксызның...» «Алайса нигә дип аңа андый югары квалификация бирдегез соң? Акчаны разрядка карап түли торгансыздыр бит?..» Кыскасы, өметен өзгән смена механигы киребеткән слесарь ягына кулын селтәде дә китеп барды. Шуннан соң Садрины юк-бар белән борчымый башлаганнар иде. Соңрак тагын бер вакыйгага булды: планыбыз яна дип, ял көнне эшкә чыгарга куштылар. Бу юлы да Садри, ике сөйләшергә урын калдырмаслык итеп, катгый рәвештә әйтә салды: «Миңа өметләнмәгез, чыкмаячакмын». Имтиханнарга әзерләнү өчен көтеп алган якшәмбесе иде ул Садриның. Эшкә чыннан да чыкмады. Дүшәмбе көнне килде дә, берни булмагандай, эшкә кереште. Аның каравы смена механигы стеналарга менәрдәй булып котырынды, прогул язам дип янады. Янап кына да калмады, докладной да язып биргән иде. Садрины шундук җилтерәтеп цехкомга чакыртып алдылар. Кабинетта цехком председателеннән тыш өлкән инженер белән цехның партгрупоргы да бар иде. «Бу нинди башбаштаклык? Нигә эшкә чыкмадыгыз? Прогул ясагансыз ич?»— дип, мәсьәләне кабыргасы белән куеп каршылаганнар иде Садрины. Аның да җавабы әзер. «Минем прогул ясау түгел, эшкә биш кенә минут соңарып килгәнем дә юк. Ә инде кичәге көнгә килсәк, якшәмбе — минем законлы ял көнем». «Башкалар эшләделәр бит?» «Димәк, хезмәт законнарын бозгансыз». Бүлмәдәгеләр бер-берсенә карашып алырга мәҗбүрләр. Авыз йомып калырга да ярамый. Сүзне өлкән инженер дәвам иткән иде. «Без ул якшәмбене, план тутыру өчен, эш көне дип игълан итәргә мәҗбүр булдык. Вакыты белән мәсьәләгә реаль чынбарлыктан чыгып та карарга кирәк...» Күңелдән ятлап куйган диярсең — Садриның моңа да җавабы әзер: «План тутыру, кешене конституция белән гарантияләнгән ял көненнән мәхрүм итү бәрабәренә түгел, ритмлы эшләү исәбенә үтәлергә тиеш иде, минемчә». Кабинетта хасил булган тынлыкны цехком председателе бозды. Ул, сүз югында сүз булсын дигән кебек, килеп туган әлеге четерекле мәсьәләгә икенче яктанрак суктырып карады. «Ни бит... якшәмбе көнне эшләгән өчен матди кызыксындыру чаралары да каралган иде, хезмәт хакы икеләтә тариф белән түләнде...» Бу юлы да җавапсыз калмады Садри. «Кем исәбеннән түләнде соң?.. Җаваплылыкны тоймыйча, эшне оештыра белмәүче кеше кесәсеннәнме? Аның исәбеннән түләнсә, эшкә чыгу-чыкмау турында бәлки уйлап караган булыр идем».

Шул вакыйгадан соң «дөреслек эзләүче» дигән яманаты чыккан Садрига, ничектер, кул селтәбрәк карый башладылар. Әмма тормыш булгач, төрле хәлләр чыккалый. Көннәрнең берендә, уйламаганда-көтмәгәндә, цехның айлык планын үтәмәү куркынычы туды: баладан чыгу өчен, эштән туктаган бер буровойның предохранитель щитын көнендә-сәгатендә тапшырырга кирәк булды. Шунда Садри, әйтүләрен дә көтеп тормады, бу четерекле эшкә үзе алынды. Карап-күзәтеп торучылар тел шартлатырга мәҗбүр. Дүрт сәгать эчендә щитны машинага төяп тә җибәрделәр. «Алтын куллы егет икәнсең!»— дип, күкләргә чөеп мактадылар үзен. Ни әйтсәң дә, бөтен коллективны зур баладан коткарып калды бит.

Атна-ун көн үттеме икән, цехта яңадан ЧП. Завод кадәрле цехны электр энергиясе белән тәэмин итү системасының фланецы янып чыкты.

Йөзләрчә станоклар, мең төрле механизмнар эшләвеннән яңарак кына шау-гөр килеп торган олы урам чаклы цех шомлы тынлыкка чумды. Бу көтелмәгән хәлдән каушап-югалып калган цех хуҗалары яңадан Садри янына йөгерешеп килде: «Харап!.. Янабыз!.. Зинһар, коткара күр!..» Эш коралларын тәртипкә китереп маташкан Садри бу юлы да: «Баш өсте!..» дип, ярдәм кулы сузарга атлыкмады. Иң элек бу өзеклек өчен җаваплы кешенең фамилиясе белән кызыксынды, аның ни өчен килмәгәнлеген сорады. Әлеге эт йөзнең «бәйрәм итүе» турында ишеткәч, катгый рәвештә: «Юк!» дип, кабат үзенең «җайсыз» кеше икәнлеген исбат итте. Бик тинтерәтә, кысрыклый-яный башлауларын күреп: «Авыру булса, бер хәл иде. Әмма күрәләтә торып, исерек башларны яшереп йолып калу кебек җинаять юлына баса алмыйм. Бигайбә!»— диде.

Бик кыйммәткә төшкән иде коллективка әлеге ЧП. Аның шаукымы Үзәк база белән генә калмыйча, идарәгә кадәр барып җитте. Исерек башны икенче көнне үк эштән сөрделәр. Дүрт-биш сәгать буе цехны эшсез тотканнары өчен, мастерга да, инженерга да, цех башлыгына да шелтә чәпәделәр! Ә берничә йөз кешедән торган цех коллективы квартал премиясеннән колак какты. Шул вакыйгадан соң Садрига да көн бетте, бөтен коллектив кырын карый башлады. Шунда ул, үз гомерендә беренче тапкыр, яхшы, үрнәк эшче булып кына администрациягә ярап булмауны бөтен нечкәлекләре белән төшенгән иде. Нишләмәк кирәк, кинәт кенә вак җанлы ялагайга да, кешелек дәрәҗәсен аяк астына салып таптатырга сәләтле тәлинкә тотучыга да әверелә алмады. Моның өчен икенче Садрига әверелергә кирәк иде.

Шундый уйларга бирелеп, кичә гариза белән Хезмәт кенәгәсен калдырган Үзәк базаның Чупай ташыннан салынган ике катлы административ бинасына килеп җиткәнен сизми дә калды Садри.

Юк, җиңел булмады аңа төрле плакатлар, лозунглар белән чуарланган контора бусагасы аша атлап керүләре. Чын дөресе — сыйрат күпере кичүләргә тиң иде. Нишләмәк кирәк, «кыңгыраулы кеше» булуыңны, синең турында җыен тузга язмаган мәгълүматлар җыелганын белә торып, йөзеңне ертып булса да керәсең. Башкайларыңны ташка орасыңмыни! Эшсез яшәп булмый бит.

— Әйдәгез, әйдә, рәхим итегез, иптәш Бәдриев,— дип күтәреп диярлек каршы алдылар аны кадрлар бүлегендә. Урын тәкъдим иттеләр. Күңеле белән нидер буласын сизенгән Садри утырып торудан баш тартты, калдырган гаризасының язмышы белән кызыксынды.

— Гафу итә күрегез инде, иптәш Бәдриев,— диде бүлек мөдире түбәнчелек белән баш иеп.— Хәзергә өзеп бер сүз дә әйтә алмыйбыз. Чөнки сезнең документлар Үзәк база башлыгы иптәш Дьяконовта. Әмма ул, кызганыч ки, сезне кабул итә алмый. Бүген аның цех җитәкчеләре белән киңәшмә үткәрә торган көне.

Садри, каяндыр бик тирәннән ачуы күтәрелә башлавын тоеп:

— Сездә эшкә урнашу яки эштән китү мәсьәләсен кадрлар бүлеге хәл итмимени?— дип сорарга мәҗбүр булды.

Пеләш башлы, түп-түгәрәк йөзле бүлек мөдире: сезнең ише аферистларны без күп күргән, дигән сыман, астыртын көлемсерәп әйтте:

— Рядовой эшче булганда, әлбәттә, без хәл итәбез. Сүз җитәкче кадр турында бара. Андый вакытта эшкә кабул итү-итмәү мәсьәләсен хөрмәтле Максим Евграфович үзе хәл итә. Документларыгыз аңарда. Иртәгә рәхим итегез!

Икенче көнне дә билгеләнгән очрашу булмыйча калды. Хуҗа кеше бораулау эшләре идарәсенә планеркага киткән. Көтеп торуның да файдасы тияр төсле түгел, аннары уннарча километрларга чәчелеп утырган буровойларга барачак икән. Өченче көнне ул Әлмәткә, «Татнефть» берләшмәсенә киткән иде. Аннан соң шимбә белән якшәмбе. Шулай итеп бары тик алтынчы көнне генә Садри кабул итүгә эләгә алды.

Садри Үзәк база хуҗасын күптәннән күреп белә. Аның төрле җые-

лышларда жете кызыл сүзләр белән чуарланган пафослы чыгышларын да тыңлаганы бар. Кабинетка кергәч, очрашулары да шактый сәер, исәнләшүләре дә бик килеш-килбәтсез чыкты. Атнага якын көттергәне өчен гафу үтенерме дип уйлаган иде Садри, кая ул. «Утырыгыз!»— дип тә әйтә алмады хәтта, бары тик урындык ягына ым кагып ишарәләде генә. Гомумән, Садри рәтле-җүнле сөйләшү булмаячагын ничектер сизенгән дә иде. Документларны алырга да башка берәр урынга сугылып карарга кирәк булыр, дип, күңеленә беркетеп тә куйган иде инде.

Йомшак креслосына терәлеп утырган начальник кулында Садриның Хезмәт кенәгәсе.

— Так, так!..— дип сузды Максим Евграфович аның битләрен актаргалап.— Нефть-газ чыгару идарәсенең фәнни-тикшеренү һәм производство цехында да эшләгәнсез... Анысы яраган.— Хуҗа кеше күзләрен документтан Садрига күчерде.— Аннан китүегезнең төп сәбәбе нәрсәдә?

Садри уены-чынын бергә кушып җавап кайтарды:

— Үземне башка урында сынап карамакчы идем.

— Алай, алай... Янә дә килеп, нефтьне комплекслы хәзерләү һәм кудыру цехы. Аннан ни өчен киттегез? Янә дә көчегезне сынап карау өченме?

— Әйе.

— Ничек соң, максатыгызга ирештегезме? Көч сынашуда дип соравым...

— Ирештем кебек.

— Шулайдыр, шулайдыр...

Дьяконовның күзе яңадан Хезмәт кенәгәсендә.

— Менә монда күп төрле бүләкләр, рәхмәтләр хакында язылган икән. Рацтәкъдимнәр, уйлап табулар өчен...

Ниһаять, Дьяконов Хезмәт кенәгәсен башка документлар янына куйды.— Ярар соң. Әйдәгез, конкретрак сүзгә күчик...

— Мин дә нәкъ шуның өчен килдем,— диде Садри. Сүзгә урынсызрак кушылуын үзе үк абайлап алды. Ләкин төзәтенергә соң иде инде.

— Алайса, анык бер сорау...

— Рәхим итегез!

— Безгә дә: «көч сынашып карау» өчен генә килмисездер бит?

— Юк кебек.

— Бездә дә андый-мондый мөгез чыгарып мәтәшмәссезме соң?

Шушы бер сүз әллә нишләтеп җибәрде Садрины. «Аһ-һ, кабахәт!— дип уйлап куйды ул. Атна буе көттерүең әнә ни өчен кирәк булган икән...»

— Нәрсә, миңа һәркайда да мөгез чыгарырга димәгәндер ич?— диде Садри, сабырлыгын җуймаска тырышып.

Үзәк база башлыгының моңа әллә ни исе китмәде. Ничектер, теләктәшлек белдерергә теләгәндәй, болай диде:

— Әгәр дә мәгәр, уртак тел табып, бездә эшләргә ниятләсәгез, алдан ук кисәтеп куям: бары тик үзегезгә йөкләнгән эшләрне башкару белән генә шөгыльләнергә туры килер. Минем соңгы сүзем шул...

Үҗәтлеге кузгала башлавын тойган Садри: «Барыбер эш чыкмаячак, һич югы, эчемне бушатыйм»,— дигән нәтиҗәгә килде.

— Нәрсә бу? Бездә инициатива җәзалана дип әйтергә телисезме?

Хуҗа кешенең башында: «Моның белән саграк булуың хәерлерәк»,— дигән уй туды ахрысы, тизрәк төзәтенәсе итте:

— Алай димәдем ич.

— Соңгы сүзегез, ничектер, гади сүз булудан бигрәк, катгый резолюция салуга охшабрак яңгырады...—«Беткән баш беткән,»— дип уйлады Садри, теле яңадан авызына сыймады.— Алайса, берьюлы мин дә үз шартымны әйтим: мин гади башкаручы гына була алмам...

Әнә, сәламенә күрә җавабы.

— Алайса, мәсьәләгә алдан ук ачыклык кертик: бездә хәзергә бернинди дә зур үзгәрешләр, реконструкцияләр күздә тотылмый.

Садри да телен аркылы тешләп калучылардан түгел:

— Димәк, минем, производствода булган кимчелекләрне күргәндә дә, искәртү ясарга, яки төзәтү юлларын ачыкларга хокукым булмаячак? Шулаймы?

— Ник алай булсын ди. Андый хокукны сездән беркем дә алмаячак. Әмма ышанып тапшырылган хокуклардан файдалана белергә дә кирәк.

Түземлеге төкәнә башлаган Садри, торган саен үҗәтләнә баруын тойды.

— Эштәге кимчелекләр белән килешә алмау хәзер инде минем каныма сеңгән, гадәтемә кергән.

— Бездә, иҗади атмосфера хакимлек иткән коллективта, кайбер гадәтләрегезне онытып торырга туры килер.

Кабинетта киеренке тынлык урнашты. Үзәк база хуҗасы, эш югында эш булсын дигән кебек итеп, яңадан Хезмәт кенәгәсен кулына алды. Караштырды.

— Н-да-а! Шактый ук эш урыны алыштырырга өлгергәнсез инде.

Садри саруы кайный башлавын тойды. «Әй-йә,— дип уйлады ул Дьяконов турында,— Син әле перестраховщик кына түгел, шактый ук эчпошыргыч вак җан да икәнсең. Чыннан да, уртак тел табып, бергәбергә эшләве авыр булыр».

— Мин кабат сорау бирергә мәҗбүрмен: әлеге сүзләрнең нигә кирәге бар? Мин үземнең кайчан һәм кайларда эшләгәнемне сезгә караганда яхшырак беләм бит,— диде Садри.

Дьяконов каршында утыручыдан бу кадәресен үк көтмәгән булса кирәк:

— Әлеге сүзләр нигә кирәкме?..— дип, кабат сорап куйды ул Садриның сүзләрен рәтләп ишетмәгән кеше сыман.— Алайса, белегез. Соңыннан үзара аңлашылмаучылык килеп чыкмасын дип, кисәтеп әйтүем. Башта игълан ителгән торба-турбина цехы башлыгы урыны хәзергә бушамый. Аның башлыгы Шәйхиевичне, пенсия яшенә керсә дә, киткәләгәнче дип, беразга эшләп торырга күндердек.— Дьяконов мәгънәле итеп тамак кырып, егет ягына күз төшереп алды.

— Димәк, сез мине эшкә кабул итүдән баш тартасыз.

— Алай ук димәдем ич...

— Әгәр дә дөрес ишеткән булсам, тел төбегез шуны аңлата.

Максим Евграфович шундый да күндәм, кеше хәлен уртаклашырга атлыгып торган бер кыяфәткә кереп өстәде:

— Әгәр дә риза булсагыз, мин сезгә шул ук торба-турбина цехында смена мастеры урыны тәкъдим итә алам...

База башлыгы шушы тәкъдиме белән әлеге мәгънәсез сөйләшүгә чик куясы итте. Эшкә урнашмас борын аяк терәп сүз көрәштереп торган «дөнья болгатучы»дан котылачагына шиге юк иде аның. Чыннан да, әллә нинди җаваплы участокларда эшләгән, югары урыннар билгән кеше смена мастеры булырга ризалашамы соң?! Башына ат типмәгән ич аның. Әлеге тәкъдимнән баш тартыр да саубуллашып чыгып та китәр дип көткән иде Максим Евграфович. Әмма, шундый сүз ишетеп тә, егетнең йөзендә бер генә мускулы да селкенмәвен күргәч, алай гына да түгел, бик кулай тәкъдим ишеткәндәй: «Мин риза»,— дигән сүзләрен ишеткәч, тәмам аптырашта калды. Һәм ул, шактый ук килешсез кыяфәт белән, чигенү юлларын эзли башлады. Аның бу мәтәштерүләрен Садри бик ачык күреп тора иде. «Әйдә, үртәшергә икән, үртәшергә»,— дип уйлады ул, һәм каршысында утырган җаваплы түрәне бераз кытыклап аласы итте.

— Бер китәргә ниятләнгән кеше барыбер китәр инде ул. Пенсиягә җыенучы иптәш турында әйтүем. Хәзергә смена мастеры булып эшләп торыйм да урын бушау белән цехны кабул итеп алырмын.

— Планнарыгыз өметле болай,— диде Дьяконов, шактый ук төрттерм*ә*ле итеп.— Хәер, һәрбер уылдык балык булырга тели, диләрме әле?

Ямьсез тынлык хасил булды. Тик озакка түгел, сүзне Дьяконов дәвам итте.

— Сез мастер вазифаларын бик үк ачык күзалламыйсыздыр ахры,— дигән булды ул. Бу сүзләрне, ирен кырыйларына гына поскан мәкерле елмаю белән әйтте.

— Нишләп күзалламыйм ди. Мастер вазифаларын беләмендер, дип уйлыйм. Хәтта, эшләп караганым да бар...

— Белсәгез дә, янә дә килеп кабат исегезгә төшереп кую зыян итмәс. Әйе! Бүгенге көндә мастер — производствода төп фигура. Бигрәк тә безнең шартларда шулай. Базада токарьлар, фрезерчылар, слесарьлар, тагын бик күп төрле һөнәр ияләре эшли. Мастер шул һөнәрләрнең барысын да бөтен нечкәлекләренә кадәр белергә тиеш. Ул коллективны туплый, житәкли, эшләр өчен тиешле шартлар тудыра. Вакытның һәр минутын нәтиҗәле файдалануны, эшчеләрнең һөнәр осталыкларын туктаусыз күтәрүне кайгырта, техника яңалыкларын өйрәтә. Эшнең яхшы оештырылуы һәр эшченең югары житештерүчән эшләве, беренче чиратта, мастерның житәкчелек итү дәрәҗәсенә бәйләнгән. Белгәнегезчә, бигрәк тә бүгенгедәй яңа шартларда, мастер билгеле дәрәҗәдә экономист та, педагог та, психолог та. Мастер — оста дигән сүз. Кайда мастер — шунда иҗади атмосфера. Андый җирдә заданиеләр дә, йөкләмәләр дә уңышлы үтәлә. Тикмәгә генә мастерны производство командиры дип атамый торганнардыр.

— Мастерны әле тагын, уңышка ирешү конструкторы дип тә атыйлар...

Садриның искәрмәстән генә сүзне бүлүенә әллә ни исе китмәде хуҗа кешенең.

— Менә, менә! Дөрес әйттегез,— дип дәвам итте ул.— Бик дөрес! Менә шул, иптәш Бәдриев. Шундыйрак таләпләр куела бездә мастерга. Әлеге сыйфатлары житенкерәми икән, андый мастерның безгә кирәге юк.

— Сез куйган таләпләрнең барысы да эш урынында, эш барышында сыналыр,— диде Садри.

Шулай итеп Үзәк база башлыгына бүтән чигенер урын калмады. Һәм ул: «Әйдә, миннән булсын бер изгелек», дигән кыяфәт белән:

— Ярар! Әйдә, эшләп карагыз...— дип, Садриның гаризасына: «Смена мастеры итеп рәсмиләштерергә»,— дигән әмер язарга мәҗбүр булды.

Коллективта та кочак җәеп каршыламадылар Садрины. Чөнки җыен тузга язмаган шыксыз гайбәтләр аның үзеннән алда килеп житкән иде инде.

— «Дөреслек эзләүче» дип даны чыккан бер авантюрист эшкә кергән ди.

— Миңа да житкерделәр. Бер баш катыручы диләр үзен.

— Керсен! Бездә дә әллә ни озак тора алмас!..

Хәер, эш урынын алыштырып кына кара гайбәтләрдән котыла алмаячагын Садри үзе дә яхшы белә иде. Һәрчак игътибар үзәгендә, ныклы күзәтү астында буласын да тоя иде. Эш булсын дип чак кына тырышты исә: «Тиресеннән чыгардай булып кылана, берәр карьеристтыр әле»,— диләр. Ә инде чак кына эленке-салынкы йөрүеңне чамалый калсалар, тагын бетте: «Әллә ни шаккатарлыгы юк, адәм рәтле белгеч булса, элеккеге эш урыныннан артмас иде», дип теш агарталар.

Садри алыштырыга тиешле цех башлыгы Зәйни агай Шәйхневич та шактый ук сагаеп каршы алды яңа мастерны. Тикмәгә генә кеше сүзе кеше үтерер димиләрдер шул. Әмма эшкә кагылышлы бер вакыйга аларны искәрмәстән генә якынайтты да куйды.

Көннәрнең берендә, Зәйни картка ияргән Садри, төзелеш материал-

лары, гамәлдән чыккан иске турбиналар, башка төрле буровой җиһазлары тутырылган биналар белән танышып йөрде. Шунда ук аэропорт ангары кадәрле бер складта, һәркайсы кимендә кара мунча кадәрле зурлыктагы бары тик бер төрле генә нәрсәләр белән шыплап тутырылганын абайлап алды. Садри әлеге килбәтсез нәмәстәләрнең буровой җиһазы икәнлеген таныса да, ничек аталуын белми иде.

— Бу ни?— дип сорады ул карттан.

— Вертлюг.

— Нишләп шул кадәр җыелды соң алар?

— Аптыраш та йөдәш алар белән, кем, Садретдин туган. Бернәрсә кыла алмыйбыз. Әнә, бүгенге көндә унлаган буровойдан вертлюг сораган заявка ята. Ә вертлюглар, шабаш, юк! Яңасын кайтартып булмый, буровой белән бергә комплектта гына бирелә. Эшне туктатмас өчен башка идарәләрдән бурычка алып торабыз. Бүгенге көндә Әлмәт бораулау эшләре идарәсенә өч, Баулыга ике вертлюг бирәсебез бар. Хәзер инде алыр урын да калмады. Җитмәсә тагын, техника иминлеге инженеры әнә, ике буровойны эштән туктатам дип янап акт төзегән. Барысы да шул каһәр төшкән вертлюг аркасында. Бу бәладән чыгып булмасмы дип, кыланмаган калмады инде. Базаның иң гаярь, Алып батырдай иң достоин ир-егетләрен ярдәмгә чакырып, кувалдалар белән втулкаларын да кыйнатып карагандай иткән идек. Юк, шабаш! Җәнчеп, әнә, тәмам эштән чыгарып ташладык, шул булды.

— Кай җирен төзәтергә соң аның?

— Менә шушы бөҗраларын алыштырырга кирәк. Әнә күрдеңме, ничек ашалганнар. Хәер, гаҗәп тә түгел, җир астына ике километр сузылган корыч торбалар тезмәсен күтәреп торырга һәм дә җан-фәрманга әйләндерергә туры килә шул аларга. Әгәр дә «прихват»-фәлән була-нитә калса, шабаш, бөтенләй харап!

Садри янә сорау бирде:

— Төзәтер өчен нәрсә эшләргә кирәк соң?

Зәйни карт, һәй-й, шуны да аңламыйсыңмыни, дигәндәй, сабыр гына сөйләвендә булды.

— Менә шушы втулкаларны бәрдереп чыгарасы да бөҗраларын гына алыштырасы. Аннары — шабаш!

— Запас бөҗралар бармы соң?

— Келәт тулы. Кирәк кадәр втулкалары да бар...

Садри чак кына «миен селкетеп» карыйсы итте. Бот юанлыгы втулкаларны күсәк белән дә бәреп чыгарырлык түгел иде. Бераз уйлана торгач: «Бәлки пневматик пресс белән кирәктер?» дигән фикергә килде. Һава прессының моңа гына көче җитәчәк. Әмма моның өчен вертлюгларны кыстырып-нығытып кую җайланмасы һәм втулкаларны оялрыннан эшереп-тәрттереп чыгару өчен, югары маркалы корычтан махсус кендек кырдырып алырга кирәк булачак.

Садри иң әлек исәп-хисап ясады, нығыту станының сызымнарын сызгалады, бары тик шуннан соң гына җайланмаларны әзерләү эшенә керешт. Атна-ун көн үттеме икән, авыр автокран, вертлюгларны берәм-берәм күтәреп, пневматик пресс астына ташый башлаган иде инде.

«Каһәр төшкән» втулкаларыннан арынган вертлюгларны күргәч, Зәйни карт, үз күзләренә үзе ышанмаган сыман, тар кысалы түгәрәк пыялалы күзлеген маңгаена ук күтәреп куярга мәҗбүр булды.

— Ну-у, энем, чын егет икәнсең! Җилкәләрдән таулар төште бит әй!

Икенче көнне Шәйхиевич эшкә иртәрәк килде. Кәефе шәп, күңеле күтәренке иде аның. Һәйбәтләп кырынган яңак-иякләрен сыйпаштырып, тәмәке тартудан кызгылт-җирән төскә кергән мыегын бөтергәләде дә, бик гайрәтләнеп, базаның административ бинасына таба китеп барды.

Хуҗа кешенең дә күңеле күтәренке чакка туры килде. Максим Евграфович аны урыныннан торып каршы алды.

— Әйдә-әйдә, хөрмәтле Шәйхиевич, түргә уз! Менә, бу тирәгәрәк рәхим ит!

Зәйни карт кыюсыз гына хуҗа кеше күрсәткән урынга килеп чумды. Ул арада үзәк база башлыгы эшләр белән кызыксына башлады. Сүз уңаенда гына әйткән сыман итеп, яңа мастер турында да сорап куйды.

— Мин дә нәкъ шуның турында сөйләшергә дип кергән идем,— диде Шәйхиевич, үзенә кирәк темага сүз кузгалганга куанган кебек.— Шабаш аның белән...

Дьяконов сагаеп кына калмады, картның каршысына ук килеп басты.

— Нәрсә, берәр мөгез чыгардыңмы әллә?— диде ул, күз-башларын җимерә башлап.— Аңардан теләсә ни көтәргә мөмкин.

— Килешмәскә рөхсәт итегез, Максим Евграфович. Хәер, мөгез чыгаруы хак. Сүзем шул: менә дигән алмаш тапкансыз. Хәзер инде пенсиягә тыныч җан белән китсәм дә була. Егет отличный! Белем дисәң — белем, сәләт дисәң — сәләт үзендә. Яшь булса да, тәҗрибәсе дә бар. Кыскасы, эш дип, янып-көеп йөрүче, менә дигән инженер.

Хуҗа кеше цех башлыгының сүзен бүлде:

— Яндырыр әле ул сезне! Шундый итеп яндырыр, кызган табага баскандай булырсыз!

Максим Евграфович бу сүзләрне, тел төбенә ниндидер кинаяле мәгънә салган сыман итеп, үтә дә җитди әйтте. Карт сагая-икеләнә калды. Ә бит ул бу кабинетка бик изге ният белән, егеткә вертлюглар бәласеннән коткарганы өчен, акчалата премия-фәлән бирдереп булмасмы диебрәк кергән иде. Шулай да тәвәккәлләде карт, булган барлык кыюлыгын бер учка туплап, күңелендәгесен чыгарып салды.

Бу юлы да Максим Евграфовичның сүзе кыска, чабып өзгәндәй, катгый, кырыс иде.

— Әше шул! Шуңа күрә мастер ул. Әнә, рационализаторлар бюросы аша рәсмиләштерегез дә бетте-китте. Тәкъдименең елына күпме файда бирүен исәпләп чыгарырлар да тиешен язарлар...

Хуҗа кешенең әлеге төксе-коры сүзләренә караганда, бер дә көйгә килергә охшамаган иде. Бәлки шуңадыр, Зәйни картның җавабы да, ничектер, бик зәгыйфь чыкты.

— Ни бит, Максим Евграфович...— диде ул гаепле-басынкы тавыш белән.— Алай рәсми килгәндә, әҗере бик бәләкәй чыгар аның.

— Булганы җиткән!

Бүтән сүз озайтып торуның файдасыз икәнлеген шундук төшенде Зәйни карт. Һәм ул, гаебе булмаса да, уңайсызланып, бер үк вакытта хуҗасына өч-дүрт елга бер үтенеч белән кереп тә, сүзен сангa сукмаганга чак кына җәберсенеп, кабинеттан чыгып китте. Әлмәт белән Баулыга, бурычка алган вертлюгларны илтеп бирү өчен, зур йөк машиналары сорарга да онытты хәтта.

Көннәр үтә торды. Садри да моеннан эшкә чумды. Күбрәк вакытын яшьләр арасында уздырырга тырышты ул. Кискечләрне кайрау серләрен өйрәтте. Моның өчен ул тиешле режимга көйләнгән махсус кайрак булдырды. Яшьләр канәгать: станокны алыштырдылармыни!

Әмма Үзәк база хуҗасы белән цехның бер төркем кешеләренең Садрига әле һаман да сырт йоннарын кабартуларына тәмам аптырашта калган Шәйхиевич, ахыр чиктә түзмәде, кайбер нәрсәләрне үзе ачыклыйсы итте. Алтын куллы, нигә генә алынса да коеп куючы, белемле, гадел, риясыз, эчендә тамчы кадәр дә ялганы булмаган Садриның бер урында гына басылып эшли алмавы аның өчен баш җитмәслек табышмак иде. Мастерның үзеннән турыдан-туры сорарга, ничектер, яхшысынмады. Шулай да көннәрнең берендә тәвәккәлләде.

— Бер кабахәтнең йөзен күрәсем килми башлады...— диде тегесе, күзен дә йоммыйча.

— Ниндирәк бәндә иде соң ул? Бәлки мин дә беләмендер?

— Юк, Зәйни агай, белми торгансыздыр. Яшь кеше әле ул.

Шәйхиевич шундый зур низаг чыгуның төп сәбәбе турында да кызыксынып куйды.

— Бер рационализаторлык тәкъдиме аркасында,— диде Садри.— Әлеге тәкъдимне икебез исеменнән бируебезне теләгән булса кирәк. Ризалашмадым.

— Бик әһәмиятле тәкъдим идемени соң?

— Чит илдән валютага сатып алына торган «диссолван» дип атала торган химреагентны янга калдыруга нигезләнгән иде. Нефтьне судан, тоздан, башка төрле кушылмалардан аеру өчен кулланыла ул.

— Соң шуннан?

— Шуннан башланды хикмәтләр. Кулында власть булудан файдаланып, миңа аяк чалу белән генә чикләнмәде, тәҗрибә уткәрә торган резервуарларыма кадәр каядыр озатты. Ә бит ул кабахәтне түрә итеп күтәрүдә минем дә ярдәмем тигән иде. Чукындырасыңмыни аны, урынга менеп утыру белән, алыштырып куйдылар диярсең үзен. Тирәюнен җыен җилкуар, ялагай, тәлинкә тотучылар чолгап алды. Коллективта эшлекле атмосфера бетте...

Бу мәсьәләгә карата Шәйхиевичның да фикере булган икән:

— Шул инде,— диде ул,— бөркет кыясына очраклы рәвештә берәр калай этәч менеп кунакласа, күк капусының да тавык кетәгенә әверелүен көт тә тор.

— Бу күңелсез сөйләшүгә чик куярга теләгәндәй, Садри болайрак дәвам итте:

— Ваклансалар да вакланырлар икән җирәнгеч җаннар. Бөтенләйгә кешелекләрен югалталар. Зариф та: «Бу яңалык түгел, мондый рационализаторлык тәкъдименең безгә кергәненә җиде былтыр инде, авторы фәлән-фәсмәтән»,— дип, бер куштанының фамилиясен атады хәтта. Тегене мөртәтен очратып, стенага терәдем дә кысрыклый башладым: «Шундый рацтәкъдим керттеңме? Кайчан биргән идең?..»— дим. Күзен дә йоммады, җирбит: «Начальник әйткәч, керткәнмендер инде»,— дип тик тора. Сугып ексаң, башыңа бәла аласың.

— Әй-йе! Әтлек эшләүгә тәһарәт кирәкми шул. Теләсәң нәрсә диген, энем Садретдин, синең урында булсам, ут чәчеп көрәшер идем. Җиңелгән кеше сыман, үз теләгем белән китеп бармас идем. Хаклы икәнсең, канга бат, әмма сугыш! Инде алай да булмый икән, югары оешмалар бар. Суд бар, ниһаять!

— Вакланасы килми, Зәйни агай. Кабахәтнең газаплануына да үземне генә гаепле сыман хис итә башлыйм. Мең төрле түбәнсенүләргә, газаплануларга чик кую нияте белән, тотам да гариза бирәм. Андый киеренкелектә иза чигеп яшәгәнче, ике якның да азат булуы хәерлерәк, минемчә.

Шәйхиевич бүтән сүз озайтып тормады, авыр сулап кую белән чикләнде.

Юк, бу коллективта да тыныч кына, басылып эшли алмады Садри. Бөтенләй уйламаганда-нитмәгәндә яңадан гауга, яңадан җәнҗал чыгарды, цех тузгытылган умарта күченә охшап калды. Барысына да дөреслек, гаделлек эзләүче «Сыймас Садри» гаепле иде.

Мондагы беренче көннәрендә ук ике кеше саруын кайната башлады аның. Үзләрен чамадан тыш эре тотуларын, башкалардан күп өстен куюларын өнәп бетермәде Садри. Әүвәле тешләрен кысып булса да түзде. Капылт кына килеп бәрелергә — кешеләре ул түгел. Икесе дә пенсия яшендә. Икесе дә сугыш һәм хезмәт ветераны. Беренчесе — иң югары разрядлы токарь Дергунов, икенчесе — классклы эшче Каюмов. Икесенең дә җыелыш саен урыннары президиумда, икесе дә макталып телдән төшми, икесенең дә зурайтылган фотопортретлары Бораулау эшләре идарәсенең Мактау тактасында.

Садрига бу ике кешенең үзләренә карата булган хөрмәт-ихтирамны

ертлач файдаланулары ошамады. Нинди генә эш турында гәп чыкмасын, сүз барыбер, иртәме-соңмы, акчага кайтып кала иде. Бу ике алдынгының ай саен гына түгел, хәтта атна саен акчалата премияләр алуы беркем өчен дә сер түгел иде.

Садри бер сынады, ике сынады, ахыр чиктә сабыры сынды. Иң элек һәр эшне башлап йөрүче Даниил Петрович белән сөйләшеп карарга булды.

Сөйләшмәслек тә түгел иде шул. Буровойлардан бер-бер артлы төзәтелгән турбина сорап торалар, ә бу эшмәкәрләр төзәтүне юри сузу, аны ай яки декада азагына калдыру ягын карыйлар. Сүз дә юк, турбинаны сүтеп, муфталарын яңабаштан кырып, секцияләрне тоташтыру катлаулы эш санала. Әмма бу ике юньсез картның әлеге кыенлыктан файда күрергә тырышулары Садриның җен ачуларын чыгара иде.

Ниһаять, Садри Дергуновның зур габаритлы станогы янына килеп басты. Останың турбина муфтасын кырып маташкан чагы иде.

— Саумы, Даниил Петрович!

— Сәлам!..

— Эшләр барамы?

— Бара. Әмма авырлык белән. Эше бик катлаулы.

Әлеге сөйләшүгә кадәр Садри, бу ике оста гына башкара ала торган эшнең, ягъни турбина секцияләрен тоташтыру барышын бөтен нечкәлекләренә кадәр җентекләп өйрәнеп өлгергән иде инде. Бу четерекле эшне икеләтә-өчләтә җиңеләйтә торган махсус өлге дә әзерләп куйды. Бернинди ялгышу булмасын, бернинди хата китмәсен өчен, микронлап үлчәп эшләде ул үзенең җайланмасын. Ләкин, вакыты җиткәнче, сынап карамыйча, өлге-шаблоны турында әйтми торырга булды.

Гәп дәвам итте.

— Даниил Петрович, эшегез белән канәгатьсездер бит?

Дергунов смена мастерына күзенең агы белән генә карады. Бу караш: «Сиңа нәрсә кирәк булды әле?» дигәнне аңлата иде.

— Ә нәрсә? Зарланганым юктыр ич? Хәзергә ходайга шөкер, бик канәгатьмен. Хезмәт хакым да сезнекеннән икеләтә диярлек артык. Нәрсә күреп канәгать булмыйм ди мин?

— Димәк, бар яктан да канәгать?

— Канәгать! Нәрсә, әллә берәр дәгъвагыз бармы?

— Юк. Әмма сезнең «тиен»гә генә табынуыгыз гына ошап бетми.

— Аңламадым.

— Һәрбер эшегезне «тиен»гә кайтарып калдыруыгыз турында әйтәм.

— Гафу! Минем акчага баш игәнем юк.

— Ай-һай, шулай микән?

— Шулай.

— Алайса, нигә соң әле хезмәт хакыгыз башка эшчеләрнекенә караганда икеләтә диярлек артык?

Дергуновның да сер бирергә нияте юк.

— Димәк, мин башкаларга караганда яхшырак та, күбрәк тә эшлим. Нәрсә, сезгә ошамыймыни?

— Ошамый димәдем ич. Бүтәннәргә үрнәк булырлык итеп эшләгән кеше һәрчак мактауга лаек.

— Соң шулай булгач? Сезгә тагын ни кирәк?— Даниил Петрович бу сүзләрне, ничектер, үпкәләгән-үртәлгән бер кыяфәттә әйтте.

Садри да кешенең хәтере калыр дип тормады, турыдан ярды:

— Һәрхәлдә мин,— диде ул,— хезмәт хакын намуслы хезмәт куеп алу ягында.

Дергунов кискен хәрәкәт белән кнопкага басты. Станокның гүләве тынды. Токарь бөтен гәүдәсе белән берьюлы Садри ягына борылды.

— Янә аңламадым.

Торган саен кискенләшә, тирәнәя барган әлеге күңелсез сүз көраш-

терүне Садри азагына кадәр дәвам итәргә булды.

— Әллә сез, ике-өч сәгать эшләгән өчен, йөз-йөз илле сумны кесәгезгә салуны нормаль хәл дип саныйсызмы? Житмәсә тагын аңлы рәвештә цехта аврал, штурмовщина оештырасыз.

Даниил Петрович калтыранган кулы белән күзлеген йолкып алды. Күтәрә алмаслык яла ягу, гаделсез сүз ишеткән кеше сыман, күзләрен чекрәйтеп, Садриның йөзенә текәлде.

— Төгәлрәк мөмкин булмасмы? Сез монда бик зур гаепләү сүзләре әйттегез.

— Рәхим итегез! Төгәлрәк тә мөмкин. Сүз турбина секцияләренә подгонка ясау турында бара.

— Ә-ә, сез әнә нәрсә турында икән...— Картның бөтен ихтыярын туплавы, сабырлыгын җыймаска тырышуы йөзенә чыккан иде. Ул, хәттә елмаерга тырышып карады.— Ләкин бит ул һәркемнең дә кулыннан килә торган эш түгел. Аны бөтен базада бары тик ике кеше башкара ала: Сафуан карт һәм мин. Ул эшне башкарган өчен акчаны без... исраф ителгән вакыт исәбеннән түгел, ә башкарган эшебез өчен алабыз. Бу очракта инде сыйфат, класслылыкише факторлар үз көченә керә.

Садри да үҗәтләнүен белде:

— Сүз дә юк, катлаулы эш башкарасыз.

Даниил Петрович аны тупас рәвештә бүлде:

— Соң шулай булгач, сезгә тагын ни кирәк?

— Мин шуны гына әйтмәкче идем: теләгән тәкъдирдә, ул эшне бүтәннәр дә башкара алыр иде.

— Башкарып карасыннар, алайса.

— Бәхәскә калса, әнә яңарак кына училище тәмамлап килгән токарь кыз Фирая да... башкара алачак ул эшне.

Дергунов бу кадәресен көтмәгән булса кирәк, аның йөзенә каткан ясалма елмаюын җил тузгыттымыни, шундук юк булды. Ул, авыр сулап, калтырана ук башлады. Аннары ярсып-каударланып, төкерекләрен чәчеп, бары тик берничә сүз әйтә алды:

— Бүтән мин сезнең белән... бергә эшләү түгел... бер һава да сулый алмаячакмын. Ишеттегезме? Баш катыручы дип әйткәннәр иде сезне, хак икән. Болайга киткәч, икебезнең берсе: я сез, я мин!

Ай-һай яман иде Дергуновның бу минуттагы кыяфәте. Ул бүтән сүз ката алмады, җәһәт кенә борылды да цех башлыгы кабинетына таба китеп тә барды.

Шунда да Садриның теле авызына сыймады.

— Мин барыбер үз фикеремдә калам: хезмәт хакын хезмәт куеп алырга кирәк!

Иртәгәсен, смена башланыр алдыннан, Садрины, ут капкандай, Дьяконов кабинетына чакыртып алдылар.

Бу хәбәрне Шәйхиевич китерде. Теше сызлаган кешенеке кебек, йөзе чытык иде картның.

— Аһ-һ сине! Башсызлыгыңа шаклар катам. Шабаш!— Хәсрәтле тавышы иңрәп, иңәлеп чыкты картның.— Соң алай артык дөрес кеше булам диеп булмыйдыр бит инде!?

— Нәрсә, Зәйни агай, дөреслекнең артыгы да буламыни соң?

— Туры юлым таш ярыр дип кенә яшәп булмый. Аннары, һәрбер туры юлның дөрес юл булмавы да бар.

— Юк, Зәйни агай, күреп торам ич, сез дә алай уйламыйсыз. Әйтәсез генә. Нәрсә бу? Кая барабыз соң без? Нишләп әле: «Мин — сиңа, син — миңа!» дигән яман чир тормышыбызның төп асылына, төп мәгънәсенә әверелеп бара? Дөрес яшәмибез бит, Зәйни агай! Юк ич! Нишләп әле без күрәләтә торып кешелек дәрәҗәбезне, горурлыгыбызны ниндидер аферистлар, кап-йотлар аяк астына салып таптатабыз? Кая барабыз без?!

— Ишкәнсең инде!— диде Шәйхиевич, тәмам өметен өзгән кеше

сыман кулын селтәп. Тавышы тагын да төшенкеләнгән иде аның.— Өстеннән язып биргәннәр әнә. Әйтә килдем мин сиңа, бәйләнмә шул Дергунов белән Каюмов картка дидем. Юк, шабаш! Алар шулай, тегермән ташы яларга ияләшкән этләр кебек, башкалардан күбрәк умырмасалар, эчләре күбә. Хужа да аларны яклый. Коллективта инде берничә тапкыр: «Безгә дә бригада подряды кертеп, яңача эшләп карарга иде»,— дип әйтүчеләр булды. Бар, җиңәрсең Дьяконовны.

Зәйни агай, гаепле кеше сыман, йөзен читкә бора төшеп әйтте:

— Кемгә ничектер, әмма миңа синең белән эшләве рәхәт иде.

Шушы «иде» дигән бер сыңар сүздән барысын да төшенде Садри. Димәк, Дьяконов аңардан котылу чарасын күргән.

— Нәрсә, Зәйни агай, эшләр шуңа ук барып житкәнмени?

— Шулайрак бугай,— диде Зәйни карт зарлы, бер үк вакытта тирән борчылган, арыган тавыш белән.— Кешене батырырга дигәндә булдырабыз ла аны. Әнә Дергунов белән Каюмов нәрсә дип язып биргәннәр. Укысаң, һуштан язып ук егылмасаң да, аягыңда торып калуларың икеле булыр. Эх-х, энем Садретдин! Әйтә килдем мин сиңа, юкбарны күрмә, кирәкмәгән жиргә кысылма дидем.

— Тымызык күлне корт баса ди.

— Бу холкың белән ерак китәрсең, бар! Гомереӊ буе бәрелепсугылып йөрерсең, шул булыр. Хужаларны тәнкыйтьләү — йоклаган арысланны кытыклауга тиң икәнлекне Мәнди анасы да белә.

— Аның каравы, намусым чиста, Зәйни агай!

— Шабаш, синең белән! Башың эшли, кулың алтын, зиһенең бар, әмма...— Шунда Зәйни карт, китәргә җыенган Садриның жиңеннән элэктереп алды да, як-ягына караганнан соң, болай дип өстәде:— Син, энем Садретдин, авызыңны күтәреп, «Китәм»,— дип атлыгып торма анда. Аяк терәп тартыш! Бил алышкансың икән инде, канга батканчы көрәш!

— Ярар, Зәйни агай, шулай итәрмен.

Садри, администрация бинасына житәрәк, Дергуновны очратты. Исәнләште. Әмма тегесе аның сәламен алмады, кара болыттай йөзен тагын да жимерә төшеп, узып китте.

Үзәк база башлыгы Максим Евграфович сүзен Бәдриевның эштән китүе күптән хәл ителгән кебегрәк итеп башлады. Аның да йөзе житди, кашлары жимерек иде.

— Ну-с-с, хөрмәтле Бәдриев! Ни өчен чакыртканымны шәт төшенгәнсездер, дип уйлыйм.

— Юк, төшенеп бетә алмадым.

Үзәк база хужасы мастер ягына кырын караш ташлап дәвам итте:

— Уртак тел табып, бергә эшли алмаячагыбызны башта ук сизенгән идем, күңелем алдамаган икән. Шулай итеп сезгә китәргә туры килер.

Садри беркатлыланып сорап куйган булды:

— Кая китү? Ничек?

— Безгә сезнең белән саубуллашырга туры килер дип әйтүем.

— Янә берни дә аңламадым,— дигән булды Садри, һаман да әле сүзнең асылына төшенмәгән бер кыяфәт белән.— Эштән азат итүегезне сорап гариза язмадым бугай бит?

— Аның каравы менә башкалар язган...— Дьяконов өстәленең уң ягында яткан папкадан берничә бит кәгазь чыгарды һәм тагын да шәрехләбрәк сүзен дәвамлады:— Кемнәр диген әле? Фидакарь хезмәтләре белән коллективның ихтирамын казанган сугыш һәм хезмәт ветераннары. Бөтен базаның карап торган горурлыгы Даниил Петрович белән ике орден кавалеры Сафуан карттан гариза бар. «Я Бәдриев, я без... Бер цехта түгел, хәтта бер базада да эшли алмаячакбыз,»— дип ультиматум куйганнар.— Тагын да үткәзебрәк әйтергә теләгәндәй, тавышын кырыслата төшеп өстәде:— Безне фашист та үтерә алмады. Монда инде без маньяктан инфаркт алып үләсебез килми»,— дип өстәп куярга да онытмаганнар.

Садри янә дә Дьяконовны бүлде:

— Ләкин бит гаризаны мин түгел, ә алар язган.

Смена мастерының шулай үз-үзен берни булмагандай тотуы тәмам аптырашта калдырды хуҗа кешене. Нәрсә бу? Бөтенләй үк дивана түгелдер ләбаса!

— Монда ике төрле фикернең булуы мөмкин түгел. Алар безнең бердәм коллективның терәге, таянычы. Төшенәсезме? Коллективның нигез ташлары. Без аларның абруен күз карасы кебек саклыйбыз һәм саклаячакбыз.

Садри хуҗа кешенең тагын бер йомшак ягын чамалап алды. Максим Евграфович артыграк дулкынланды исә, каушый, тотлыга, шуның нәтиҗәсе булар актыр инде, тоташтан җете-кызыл китап сүзләре куллана башлый.

— Кадровый эшчеләр,— дип ялгап китте база башлыгы, тавышына кырыслык, хәтта чак кына кисәтү өстәп,— коммунистик төзелешнең иң алгы сафында атлаучылар, Туган илебезнең тагын да чәчәк атуы, күгебезнең һаман аяз, һаман тыныч булуы өчен вакытын да, көчен дә кызганмаучылар... Ике сүз белән әйткәндә, җәмгыятебезнең хуҗалары! Даниил Петрович белән Сафуан Ногманович кебек эшчеләребезгә югары коммунистик аңлылык, җәмгыять мәнфәгатьләре белән янып яшәү хас. Алар хезмәт фидакарьлегенең генә түгел, әхлакый тотанаклык һәм башка бик күп күркәм сыйфатларның лаеклы үрнәге булып торалар. Яшь алмашны тәрбияләүче остазлар булуы турында әйтеп торасы да юк. Торба-турбина һәм буровой җиһазларын төзәтү цехындагы станочникларның яртысыннан артыгы — аларның шәкертләре. Ә сез... эшкә кереп өлгермәс борын, шундый эшчеләребезне төрлечә мыскыл итеп, дәрәҗәләрен төшерергә керешкәнсез...

— Аларны мыскыл итәргә җыенган кеше юк. Мин бары тик: хезмәт хакын эшләп алырга кирәк, дип кенә әйттем. Бер тиенлек эшләп ун тиенлек гауга чыгармауны таләп иттем. Белгәнегезчә, акчага мөнәсәбәт — эшче намусына зур имтихан ул. Андый очракта эшченең политик аңы да, мораль йөзе дә сынала.

Дьяконов аны бөтенләй ишетмәгәндәй сүзен дәвам итте.

— Уйлап карыйм да янә да килеп шаклар катам! Ничек итеп сез, ниндидер училищедан килеп, биздә эшли башлавына өч-дүрт ай да узмаган, танау асты да кипмәгән бер кызчыкның эшен әлеге оста кулларның сокланырлык хезмәте белән тиңләп сүз алып бара алдыгыз? «Сез эшләгәнне әлеге кыз да эшли ала»,— дип әйтергә ничек телегез әйләнде? Юк, мондый хикмәтләрне башыма да сыйдыра алмыйм мин. Юк!.. Шәйхиевич әйтмешли: шабаш!

— Хикмәт алмашка килә торган яшь эшчеләрне белеп бетермәвегездә, Максим Евграфович,— диде Садри, кирәгеннән артык үҗәтләнә башлавын үзе үк сизенеп.— Хәзер безгә яңа типтагы алмаш килә. Киң карашлы, хәзерге житештерүнең политехник нигезләрен тирәнтен белүче, өр-яңа машиналарны һәм технология процессларын тиз үзләштерергә сәләтле яшьләр.

Үзәк база башлыгы, бу мәгънәсез сүз көрәштерүгә чик куярга җыенган сыман, як-якка җәеп җибәргән кулларына таянып, өстәле артыннан күтәрелде.

— Менә шул,— диде ул, ике сөйләшергә исәбе юклыкны сиздерергә теләп.— Сынамадык түгел, сынадык. Безгә сезнең белән саубуллашырга туры киләчәк.

— Кемгә ул «безгә»?

— Ягъни мәсәлән, миңа. База өчен хәзергә мин җавап бирәм бит әле.

— Сәбәбен дә әйтә алмассызмы? Бәлки мин эчеп-исереп прогул ясаганмындыр?

— Хикмәт анда гына булса бер хәл иде. Исерек бер айный ул.
— Бу ни? Янаумы?
— Теләсә ничек аңлагыз.
— Һәрхәлдә мин мондый тонда сөйләшүгә күнекмәгән.
— Хезмәт кенәгәгезгә караганда, күнегергә бик вакыт.
— Бәлки мин... мастер буларак, үз вазифаларымны җиренә житкереп башкара алмаганмындыр?
— Бәлки! Мин мастерны беренче чиратта эшне оештыручы, эшчеләрнең квалификациясен күтәрүче һәм, ниһаять, кешеләрне коммунистик рухта тәрбияләүче, дип белә идем. Ә сез, киресенчә, коллективны бозасыз — таркатасыз.
Хуҗа кеше, гәпне туктатыр өчен чара күрергә җыенгандай, алдындагы селекторның бер клавишына басты. Каты итеп, ачу белән басты. Яшел ут кабынды, динамикка җан керде. Шундук: «диспетчер тыңлый»,— дигән хатын-кыз тавышы ишетелде.
— Хәерле иртә, хөрмәтлем! Мине 936 нчы буровой белән тоташтыра алмассызмы икән? Рәхмәт! Алло! Әйе! Гыймазов, синме? Культбудкада туры китерүем һәйбәт булды әле. Кара әле, сезнекеләр бүген төнлә белән турбина алып киткәннәр икән?
— Әйе, Максим Евграфович. Заявкабыз бар иде ич. Үзем дә шалтыраткан идем. Ә нәрсә?
— Ничегрәк эшли дип сорамакчы идем. Турбинаны әйтәм.
— Шәп! Үкерә генә, Максим Евграфович. Рәхмәт! Һич тә иске, төзәтелгән генә димәссең, яңа турбинаң бер читтә торсын. Күз генә тимәсен! Забойга якынлашып киләбез.
— Ярар, Гыймазов. Шуны гына белешмәкче идем. Хуш! Хуш дим! Эшләрең уң булсын!
База башлыгы, зур эш кырган сыман, урындык аркасына ук терәлеп утырды.
— Менә шулай ул! Чын оста башкарган эш ике гомер яши, димәсләр иде аны.
Максим Евграфович башланган эшен азагына кадәр җиткерәсе итте ахры — яңадан төймәләрнең берсенә төртеп алды.
— Степанович! Теге, алдынгыларны бүләкләргә дигән кәгазьләрне алып кер әле.
Базаның өлкән бухгалтеры, олы яшьтә булуына да карамастан, божыр кебек житез-өлгер кеше. Ишек артында гына торган диярсең, ялт итеп килеп тә керде.
— Күпмешәр яздыгыз?
— Гадәттәгечә, Максим Евграфович. Эштән соң калып — өч турбина. Икесенә дә төп-төгәл йөзәр сум!..
— Яраган.
— Барысы да нәкъ сез әйткәнчә, Максим Евграфович.
— Кая, кул куйыйм да, боерык чыгарыгыз...
Садри тагын сүзгә кушылды:
— Боерык чыгаргалаганчы, чак кына сабыр итсәгез иде. Югыйсә барыбер төзәтергә туры киләчәк...
Бу кадәресен Максим Евграфович, әлбәттә, көтмәгән иде. Ул аптырашның ахыр чигенә җиткәндәй: Әй-йе! дип, башын чайкап куярга мәҗбүр булды. Аннары усал-мәкерле көлемсерәп, алдында яткан кәгазьләрне караштырган арада, «булмыш» мастерга төрттереп болай диде:
— Кемгә күпме түләргә, нәрсә өчен түләргә, шулай ук нинди фонддан түләргә һәм, ниһаять, кайчан әмер бирүләр моңарчы сезнең ихтыярда түгел иде шикелле.
Садриның да түземлеге төкәнде. Узынган хуҗасын исенә китерергә теләгәндәй әйтте:
— Чөнки турбиналарның өчесен дә «танау асты да кипмәгән» ком-

сомолка Фирая Сөнгатуллина төзәтте. Сменадан соң калып эшләде.

Дьяконовның резолюция салырга дип күтәргән каләмле кулы һавада асылынып калды. Бухгалтерның да авызы ачылып, баш тирәли бау белән бәйләп куелган күзлеге кас өстенә сикереп менеп кунаклады.

— Ничек?!— Бу сорауны тәмам аптырашта калган Максим Евграфович бирде.

— Шулай,— диде Садри, бик гадәти нәрсә турында сүз алып барган кебек итеп.— Турбина сорап язган заявкалар ята бирә. Осталарга — сезнең сөйкемле сөякләргә бер әйттем, ике әйттем, тыңламадылар. Гадәттәгечә, ай яки декада азагын көтеп, юри суза килделәр. Ахыр чиктә яшь токарь Сөнгатуллинага мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булдым. Һәм, әнә, рәхим итегез, ялт иттерде дә куйды.

Ничек «ялт» иттергәнен Садри үзе генә белә. Башта Фирая: «Сез нәрсә!»— дип, бу турыда ишетергә дә теләмәде. Өне алынды. Бары тик турбинаны асылма кран ярдәмендә күтәртеп, олы станга сузып салып, секцияләргә бүлгәч кенә, бераз җан керде үзенә. Ә инде станокның кашына кискеч белән янәшә нигытылган өлгене күргәч, эшнең нәрсәдә икәнлеген бик тиз төшенеп алды кыз.

Ул арада Садри, хуҗа кеше белән ике арада берни дә булмаган бер кыяфәттә:

— Ярар, Максим Евграфович, мин чыгыйм әле, цехта эш көтә,— дигән булды. Шундук кабат Дьяконов ягына борылды һәм киңәшмиңәш иткәндәй болай диде: — Ә, әй-йе, әйтергә онытып торам икән. Сүзем шул: яшь станочникның — комсомолка Сөнгатуллинаның сменадан соң калып эшләвен ничектер билгеләп үтәсе иде.

Юк, Садриның әйтергә теләгәне бу гына булмаган икән. Менә ул, хуҗасының күзенә карерга теләгәндәй, өстәл каршысына ук килеп басты да тезә башлады:

— Тагын шуны әйтмәкче идем,— урынлы-урынсызга: «Эштән куам, фәлән итәм, төгән итәм»,— дигән сүзләрне чама белебрәк кулланырга киңәш итәр идем. Сез бит җитәкче. Шуның өстенә әле коммунист. Ничек итеп сез минем белән шулай бик җиңел генә «саубуллашмакчы» идегез соң? Аңламадым. Мин бит бабаларыгызның бабаларыннан мирас булып калган шәхси кибетенә ялланмадым. Сез һаман да әле гап-гади бер нәрсәне төшенә алмыйсыз кебек: үзәк база — шәхси биләмә түгел, Дьяконов — купец түгел, без — «баш өсте!» дип, юргалап йөрүче приказчик түгел. Мин үземне, мәсәлән, тулы хокуклы совет гражданины буларак, совет предприятиесенә эшләргә килдем дип уйлыйм. Бу хокуктан файдаланырга хакым бардыр ич минем?

Бер генә мизгел сузылган паузадан соң Садри дәвам итте:

— Гомумән, безгә, Максим Евграфович, кирәксә-кирәкмәсә дә, тырнак астыннан кер эзләп, үзара гаепләшүләрдән үзара ярдәмләшеп эшләүгә күчәргә кирәктер. Шулай иткәндә, барыбыз да отачак. Ә хәл итәсе мәсьәләләр, тормышка ашырасы проблемалар, цехта да, бөтен база буенча да җитәрлек. Алдынгы предприятиеләр үрнәгендә бүгенге көннән үк бердәм нарядка күчеп эшләү чараларын күрә башларга кирәктер.

Тәмам аптырап, шашып калган Дьяконовның да сүзсез каласы килмәде ахрысы.

— Сезгә дә атлаган саен үзегезнең башкалардан акыллырак икәнлегегезне искә төшереп торуның кирәге юктыр, минемчә...— диде ул, ниндидер, шелтәле-үпкәчел тавыш белән. Бу инде баягы хокуклары чикләнмәгән дорфа хуҗа кеше сүзләре түгел иде.

Ул көнне алар эш кешеләречә, тигез хокуклы җитәкчеләр кебек аерылыштылар.

Икенче көнне эшкә килгәч тагын бер нәрсәгә игътибар итте Садри: моңарчы санга сукмаган яки күрмәмешкә салынып узган кешеләр аны, әллә кайдан күреп, кул изәп яки: «Хәерле иртә, иптәш мастер!»—

дип, ихлас күңелдән исәнләшеп каршыладылар. Бу үзгәрешләрне нәрсәгә юрарга да белмәде ул.

Моның сәбәбе, цех башлыгы Шәйхиевич бүлмәсенә кергәч кенә ачыкланды. Өлкән хезмәттәше дә аны сөенеченнән балкып-нурланып каршы алды.

— Ну-у, энем Садретдин!..— диде ул ишек ягына күз төшереп алганнан соң.— Кичә эштән соң партия җыелышы булды. Мондый җыелышны күргәнем дә, ишеткәнем дә юк иде. Пыран-заран китереп аттылар Дьяконов үзен. Шундый теттеләр, кая керер тишек тапмадылар үзләре дә. Иң аптыраш белән йөдәштә калган кеше Дьяконов булгандыр. Берсен дә калдырмадылар. Хәтта, бөтен коллективка дип каралган премия фондын уңга да сулга таратып бетерүе турында да әйттеләр. Дергунов белән Каюмов кордаш та өлешсез калмады: күрәләтә торып аврал, штурмовщина ясап, шуннан шәхси файда чыгарулары турында күзләренә бәреп әйттеләр. Декада, ай һәм квартал саен диярлек уч тутырып «премия» алулары уен эшмени!

Зәйни агай, мыек астыннан гына елмаеп, әйтә салды:

— Яа-а, ходай! Халыкның усалллануын әйтәм әле, кемнең кем булуы белән санашып торды юк, бәбәкләре атылып чыгардай итеп әйттеләр. Түзсәң түзәсең, түзмисең икән, ник чәнчелеп китмисең шунда. Үзгәрә заманалар! Үзгәрә!.. Очкылык тотмадымы соң үзеңне? Синең турында да сүз күп булды. Бигрәк тә яшьләр!.. Аның кебек «җайсыз» кешеләр күбрәк булсын иде әле коллективта дип чыктылар.

Зәйни агайның елмаюдан җыерчыклар баскан йөзе чак кына языла төште.

— Эштән азат итүләрен сорап, кабат сүз кузгаткан идем дә, тагын шабаш! Һаман да шул база башлыгы Дьяконов тыпырчына, сине цех начальнигы итеп куюга каршы. «Партиядә түгел, фәлән-төгән», дип маташкан була. Авызын бик тиз томаладылар тагын үзенен. «Хәзер үзгәртеп кору чоры, коммунист булмаган кешеләрне дә производство командирлары итеп сайлап куярга хакыбыз бар», янәсе. Ә мина җыелыш исеменнән бер шарт куйдылар: синең белән берлектә бөтен цехны бердәм наряд дип атала торган яңа ысулга күчергәч тә, дүрт ягың кыйбла, имештер. Шулай икән, энем Садретдин, ул кадәр нечкәлекләргә минем башым җитмәячәк, сиңа җиңеңне ныграк сызганырга туры килер. Шулай ук цехны да, әллә кем түгел, син кабул итеп алырсың, ходай кушса!— дип, Садрины ярым кочаклап, үз итеп аркасыннан сөеп-кагып куйды.

*1986*

**Илдар Низамов**

# БЕР КАРАДЫМ...

ПАРЧАЛАР

## Гамь нуры

Бу елларда шагыйрьләр гамь не еш телгә ала. Бер-береңә игътибар, гуманлык, кече күңеллелек мәгънәсендә.

Миңа калса, гамь ул иң башта кешенең карашында чагыла.

Әнә, иртәнге урамнан болайга таба җиңел-җиңел атлап, бер яшь ханым килә. Иптәш хатыны белән сөйләшә-сөйләшә атласа да, ул каршысына килүчегә дә игътибар итте. Күтәрелеп карады.

Аның күзләре зәңгәр иде. Март иртәсе кебек чиста, якты иде. Ул бары бер карады. Юк, батырып та карамады, әлеге якты карашын сирпеп кенә алды. Ниндидер мәгънә салып та димәс идем. Гамь белән карады!

Гамь ул кешенең эчке дөньясыннан — җаныннан чагылган бер нур. Күңелең, җаның тормышка, кешеләргә битараф булмаса, үз-үзең өчен генә яшәмәсәң, синдә гамь булыр, һәм иң әүвәл ул синең карашыңда чагылыр.

Рәхәт бит кемнеңдер сиңа бераз гына кызыксынып, кечкенә генә шуклык та кыстырып, аз гына серле дә итеп — кыскасы, игътибар белән, гамь белән карап китүе, шулай итеп сине янәшәдәге телеграф баганасыннан аерып, үзенә тиң санавы. Рәхәт!

Ә үзең соң бирәсеңме кешеләргә шундый рәхәтне? Бармы икән карашыңда гамь?

Бардыр. Булмый калмас. Кешенең тәне гел күзәнәкләрдән тукылган кебек, күңеле дә гамь нурларыннан тора булыр.

Бер карау — бер нур.

Һәркайсыбызның гомере шундый нурлардан торсын иде, һәм без аларны бер-беребездән кызганмасак иде.

## Корама

Торып-торып, әнинең корама юрганнарын искә төшерәм, көрпә, япмаларын.

Бер-берсенә кысып-кысып тегелгән кечкенә-кечкенә өч-дүрт почмаклы ситсы кисәкләренә берәм-берәм карый китсәң, сурәтле китаптагы рәсемнәр кебек, безнең гаилә турында, әти-әни, туганнар, йорт

---

ИЛДАР НИЗАМОВ *(1936) — прозаик, публицист, «Өмет», «Иделем», «Мәхәббәт хакы» һәм башка китаплар авторы. Х. Ямашев исемендәге республика премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган культура работнигы. Казанда яши.*

хәлләре турында, хәтта безнең авыл, аның кешеләре турында әллә нихәтле истәлек хәтергә төшәр иде.

Сәламәтлеге тәмам какшап, инде текми, типчеми башлагач та, әни әле шул юрган, көрпәләргә карап-карап утырыр иде, тик кенә торганда корама кисәкләренең әле берсен, әле икенчесен сыйпап-сыйпап куяр иде. Теге я бу ситсыны ни хөрмәткә, кайчан, ничек алу-кайтартуларын, кемгә нәрсә тегүен, кайсы баласының шул киемгә ничек-ничек сөенүен — ниләр генә сөйләмәгәндер аңа гомеренең шул гап-гади бер ядкарь кисәкчекләре.

Хәтерлим, кораманы типчегәндә, әни һәр кисәкне җентекләп карап, бер-берсенә куеп үлчәп, чагыштырып, сыйпап-тигезләп сайлар иде, төсен-төскә, сызыгын-сызыкка тәфсилләп яраштырыр, төн йокыларын, күз нурын җәлләмичә тегәр иде. Сабырлык, түземлек, уңганлык билгесе ул корама юрган, япмалар. Корама тегү кызларны әйбер кадерен белергә, аны сак тотарга, зәвыклы, тәртипле булырга да өйрәтә.

Бервакыт шулай Сергей Есенинның туган авылы Константиновкада булганда, шагыйрьнең туган йортында аның әнисенең караватына ябылган корама юрганны күреп, сәер бер дулкынлану кичергән идем. Шул йорт, шагыйрь үзе, әнисе миңа тагын да якын, тагын да кадерле булып киткән иде. Нишләптер ул шагыйрьнең бик үзенчәлекле, бик талантлы иҗатына турыдан-туры бәйледер кебек тоелды. Уйлый калсаң, нәкъ әнә шул корама сурәтләрен дә без аның шигырьләре итеп укыйбыздыр әле.

## Куен дәфтәре

Яңа елга аяк басканда кешеләр теге елда ниләр булганын күз алдыннан кичерми калмыйлардыр, башкарган эшләре хакында үз-үзләренә исәп-хисап бирәләрдер. Мин исә бер ел буе тутырылган куен дәфтәремне алып, почмагына «... ел» дип язып архивка салып куйганчы, аны битләп-битләп карап чыгам.

Кайвакыт тоташ-тоташ та карарга туры килә. Ике һөнәрем дә, елгачылыгым да, журналистлыгым да юл белән, сәфәр-сәяхәт белән бәйле һөнәрләр булганга, куен дәфтәрем төп эш коралым санала. Шуңа күрә алар гомер буе тутырылган. Куен дәфтәре — юлъязма да, көндәлек, хәтта кечкенә генә музей да ул.

Менә бу дәфтәрчек нишләп авыр икән дисәм, кечкенә генә бер шайба кисәге дә каптырып куелган икән — КамАЗда штампланган беренче деталь!

Ә менә бу битләрдән әчкелтем-төчкелтем ис әле дә очып бетмәгән. Каучук бөртеге дә саклана икән. Түбән Камада булган тантананы хәтерләтте.

Бу блокнотка сап-сары бер «бит»тә өстәлгән — өрәңге яфрагы. Горкида, Владимир Ильичны соңгы юлга озаткан аллеяда. Җир шарының төрле почмакларыннан бөек юлбашчыбызны искә алырга килгән күп кешеләр арасында басып торганда, өстебезгә иелгән карт өрәңгедән туптуры куен дәфтәремә очып төшеп, шунда истәлеккә калган яфрак.

Янә дә бер ис борынга тиде — таныш, тәмле ис. Гап-гади арыш башагы икән ләбаса. Туган яклардан — Казан арты басуларыннан ияреп килгәндер инде. Ә тагын бер генә бит аша үзебезнең ишегалдыннан өзеп алган исле үләннең сары эшләпәсе...

Куен дәфтәрендә күбрәге, әлбәттә, язу-сызулар. Ни генә сөйләми алар! Бүтән кешегә берни аңлатмый торган тамга-сүзләр синдә әллә нихәтле хәтирә уятып җибәрә. Шулай да нинди генә төртке, нинди генә билге булмасын, аларның күпчелеге кешеләр турында, кешеләр язмышы турында.

## Безгә канат кайда чыккан?

Зур иделләр, диңгезләр күреп кайткач, безнең инеш бик кечкенә күренә шул. Чыннан да, кай төшен бәпкә атлап кына чыгарлык бит.

Ә нигә соң шул диңгезләрдә йөзгәндә без аңа тыелгысыз тартылабыз, нигә без аңа хыял канатларында гел-гел талпынабыз? Кечкенә, ә онытылмый!

Уйлый китсәң, безгә хыял канатларын шул инеш үзе бирмәгәнмени, зур диңгезләргә шул инеш безне үзе чыгарып җибәрмәгәнмени! Беренче корабларны бит шунда агыздык. Әй язгы ташу вакытында кинәт тулышып, ташып киткән инеш бозындагы салам өеменә ут төртүебез, шул «кораб»ның әле ераклашкач та серле җилкәне белән күңелләрне очындыруы, шуларны озата-озата якты хыялларга бирелүләр!

Ә инеш буеның серле әрәмәләре, сандугачлары, ә чыклы болынчыклары, төз камышлары, беләүдән шома сукмаклары...

Менә кайда чыккан безгә ерак сәфәрләргә алып йөрерлек хыял канатлары!

## Кайта алмаганнар өчен

Көтүче Әкрәм абый белән сөйләшеп торабыз. Читтә йөреп, озак кына шахталарда эшләп кайткан кеше. Кайту сәбәпләрен сорашкач, карашын еракка-еракка төбәп, әллә кайларны әйләнеп чыкты да:

— Сагындыра анда,— диде.— Баштагы елларда уйлап та карамаган идек. Зариф абыйга аптырый идем. Бергә күмер чабабыз. Чаба-чаба да бу, кинәт туктап: «Их туган, утыз биш ел авылда, туган илдә булган юк, кайтып, бер суык бәрәңге генә ашар идем»,— дия иде. Кайта алмады. Сугыш башланды. Алар забойда чакта немец җәлладлары шахтаны шартлаткан.

## Хат уку

Хат килсә, кычкырып укырлар иде. Иң башта өйдә кем булса, барысына да берәм-берәм сәлам укыйлар. Хатта язылмаганнарга да әйтәләр.

Бала чакта безгә атап сәлам язсалар, бик тә күңелле була иде.

## Кич утыру

Авылда кышкы кич. Тышта җил улый, яфрак-яфрак кар бөртекләрен тәрәзәгә китереп бәрә. Караңгы пыяла агара бара, агара бара.

Ә өйдә җылы. Кич утырабыз. Әниләр йон яза, бәйләм бәйли. Яшь рәк кызлар җырлап та утыралар. Вакыт-вакыт миннән китап укыталар. Прәннекле чәй дә әзергә.

Әни бүген оекбашны миңа бәйли. Киертеп карый. Шундый йомшак, шундый җылы, саласы килми тора. Салып биргәч тә әле, яртылаш кына бәйләнгән булса да, оекбашның җылысы кала, тәме, рәхәте озак кына тәннән китми тора.

## Сүзсез аңлашу

Вакыт-вакыт без — бертуганнар, җыелышканда, авыр сугыш елларын да искә төшерәбез. Хәтер — хәйләкәр, иң азаплы көннәрне дә ничектер күңелле, кызыклы итеп саклый.

Башкалар өлгергәнче, дип, ат кузгалагына да бик иртә торып болынга чаба, яңа гына кардан арчылган басуда тездән балчык ярып өшегән бәрәңге җыеп йөри, әни бәрәңге төйгән тукмакны яларга чират булдыра торган идек... Барысын да, барысын да елмаеп, җанланып искә төшерәбез.

Чөнки ул хәлләрнең ничек-ничек булганы болай да, сүзсез дә аңлашыла.

Шулай да ара-тирә туктап калам: барыбызга да аңлашыламы соң, арабызда инде безнең белән булмаган яңа туганнар — хатыннарыбыз, ирләребез, килен, кияүләребез бар бит хәзер. Алар бу «елмаюларны» аңлыймы соң?

— Әни өстәлгә һәркайсыбыз алдына бер бал кашыгы шикәр комы сибәр иде. Әйе, әйе, хәтерлисез микән, ул аны чыннан да сибәр иде, шуңа ипине тидереп-тидереп алганда тоташ эләкмәсен, бөртекләп кенә эләксен дип шулай эшләгән ул аны. Вәт шулай итеп ашарга хәзер, ә, шуннан да тәмле ашамлык бар микән дөньяда!— дим мин һәм, барыгыз да беләсезме соң шундый тәмле нәрсәне, дигәндәй күтәрелеп карыйм.

— Әгәр дә ипи яңа гына пешеп чыккан булса, бигрәк тә тәмле була торган иде,— дип өсти киленнәребезнең берсе.

Карале син аны! Чыннан да шулай иде бит!

Димәк, башка туганнар да белә без белгәнне, алар да кичергән ул елларны. Бу — безнең гаиләне тагын да ныгыта.

Шулай шул, сугыш елы балалары бер-берсен, солдатлар кебек үк, сүзсез дә аңлый.

## Сыйпагыз!

Мин үземнең тәбәнәк булуым сәбәбен эзлим дә, кечкенә вакытта эти баштан сыйпамагандыр, дим. Нәкъ ай үсәсен көн үсә торган чагымда эти сугышта иде.

Мин белгән карсак малайларның этиләре я юк, я алар — бала яратмый торган, аларны шешәгә алыштырган төксе кешеләр.

Сыйпагыз, этиләр, малайларыгызның башыннан. Яратып, өметләнеп, өметләндереп сыйпагыз. Үссен малайларыгыз!

## Әни карашы

Юлда салкын җил бәргән ахрысы, тамак авырта башлады. Әни мәтрүшкәле сөт хәстәрләп йөри. Менә әз генә әчкелтем, әз генә төчкелтем мәтрүшкә исе борынга бәрелде. Җылы касәне ике куллап тотып, әкрен генә чөмерәм дә чөмерәм. Карлыга башлаган тамак төбем йомшарып та китте шикелле.

Шулай тәмләп эчүемне карап, әни дә канәгать. Утызга җиткән, инде үзе бала атасы булган «сакаллы сабыена» да шулай иркәләп, шулай яратып әниләр генә карый аладыр.

Әни карашы белән өртеп бирелгәнгә күрә дә шулай тәмле, шундый ләззәтле, шундый шифалыдыр ул мәтрүшкәле сөт.

## Әти сөйли — безгә гыйбрәт

Председатель итеп сайлаганның өченче көнендә түбән оч Хәким мәҗлескә дәште. Моңарчы мәҗлескә йөрешү түгел, сәламне дә елга бер алышкан кешеләр үзебез, гомер буе мари ягында эшләп йөрде.

— Кызык бит әле бу, Хәким,— дим,— кемне мәҗлескә чакырырга синдәң әле син: минеме, председательнеме?

Аптырап калды.

— Кемне дип... Кемне булсын, сине инде.

— Мине бит моңарчы беркайчан да дәшкәнең булмады. Анда нәрсә турында гына сөйләшербез икән соң без? Ә председатель булганым өчен генә мәҗлескә йөрисем килми, гафу ит,— дидем.

## Табигать — әниебез

Үзебезнең инеш буйларына, басу-болыннарга, әрәмә-урманнарга сокланган, баш игән чаклар булды.

Чит җирләрдәге елга, күлләргә, сопка, урманнарга сокланып, телсез торган чаклар да булды.

Ниһаять, алдыбызда диңгез. Табигатьнең тагын бер могҗизасы. Беренче күргә ук күңел тибрәнде, тирән итеп сулыш алынды. Тәннең һәр күзәнәге табигатьнең бу яңа бөеклегенә сокланып, аның көчен, мәгърурлыгын тоеп сулкылдый кебек иде. Бу минутта анда табигатькә хөрмәт, аңа баш ию һәм шул ук вакытта аның белән мәнә шушылай бергә булу, бергә сулау шатлыгы хисе дә бар.

Табигать бөек! Кешедә, минемчә, беркайчан да аны җиңәргә, аннан бөегрәк булырга ихластан теләү хисе тумагандыр. Табигатьтән өстен булырга өндәү үзе (андый хәлләр дә булгалады)— гайре табигый хәлдер. Һәм кешеләр мондый өндәүне беркайчан да кабул итмәгәннәр, аны үтәргә беркайчан да омтылмаганнар.

Чөнки кеше — үзе табигать баласы бит. Кем инде үз анасы белән көрәшә, аны җиңәргә омтыла?! Дивана гына омтылса омтылыр. Адәм баласы үзен тудырган бөек могҗизага соклана, әлбәттә, аңардан бераз шүрли, шикләнә, иң мөһиме, аңарга иярергә, аңардан өйрәнергә, аның серләрен белергә тырыша.

Әлбәттә, вакыт-вакыт кешенең әнисенә караганда матуррак, белдеклерәк, көчлерәк, абруйлырак буласы килә. Табигый хис. Үскәндә була торган хис.

Тик бу бит җиңәргә омтылу хисе түгел.

## Соңламадым

Табигатьнең күз ачып йомганчы үтеп китә торган мизгелләре була.

Язгы чикләвек чукларының шундый нәфис, саф икәнен беренче тапкыр күрәм. Кайда йөргәнмен моңарчы! Җиңел сары чуклар. Кайберләре гәрәбә кебек куе-сары. Әмма кояшта барысы да тере кебек яналар. Эчтән җылы бөркиләрдер кебек. Кояштан алган җылыны шулай нур итеп сибәрләр, сибәрләр дә үзләре ереп, бал тамчысы булып төшәрләр шикелле.

Чыннан да, бал исе килә ахрысы, әнә бал корты килеп җиткән. Быел чыккан беренче корттыр әле ул, чынласаң.

Бал корты кунганда да, ул күтәрелеп очып киткәндә дә чук өстенә бик сизгер караш кына тоярлык алтын тузан күтәрелде һәм сизелер-сизелмәс болыт башка чуклар өстенә очып китте.

Быел чикләвек күп булыр, шөкер!

Икенче көнне, алтын чуклар искә төшеп, магнит кебек, аларга тартылдым. Килсәм, күзләремә ышанмый тордым — нурсыз соргылт алкалар гына асылынып тора.

Ярый әле табигатьнең серле бер мизгелен үз күзем белән күреп калганмын, дигән сөенеч кенә юатты.

# Кемгә иярәсең бит

Бер урманчы сөйләде. Зәңгәр чыршыны гади чыршылар арасына утырткannar. Ун еллап та вакыт үтмәгән, чыршы әкренләп үз төсен югалта барган һәм ул, кешеләр еллар буе тәрбияләп аңарда барлыкка китергән яңа, нәфис сыйфатларын югалтып, гап-гади чыршы булып калган.

Кем арасында яшәп кемгә иярәсең бит.



# Мизгел

Әллә ни гомерләр үтсә дә, күңелдә һич уңмый, тутыкмый торган мизгелләр кала.

Командировкадан кайтып төштем. Нишләп бу юлы сәер бер тынгысыз сагыну белән сагынып кайттым әле?! Ишекне дә үз ачкычым белән бик сак кына ачтым. Башка вакытта төн булса да кнопкага басып, сине уята-уята, шаярып, көлдереп кайтып керә идем.

Өйдә тып-тын. Син юк?! Өйдә булырга тиешсең бит — ике айлык озын ялдасың.

Аяк очларына гына басып, түр бүлмәгә үтәм. Ә-ә-ә менә кайда икәнсең! Диванда ятасың. Бала кебек кулыңа битеңне куеп яткансың. Йөзеңә, гәүдәңә тәрәздән якты төшкән. Җиңел ситсы күлмәгеңнең вак-вак зәңгәр чәчәкләре дә тередер, җемел-җемел киләләрдер төсле. Иреннәрең, нидер тәмләгән кебек, селкенеп-кысылып куя. Йокламыйсыңдыр, әлерәк кенә башыңнан үткән ләззәтле бер хәлне искә төшереп, уйланып кына ятасыңдыр кебек.

Сагынудан, соклanudан телсез калып, алдыңа тезләнәм. Әкрен генә, бик әкрен генә иелеп, тере кебек җемелдәгән зәңгәр чәчәкләргә битемне тидерәм. Син әкрен генә, бик әкрен генә мине җылы чәчәкләргә кысасың, кайнар пышылдыйсың:

— Рәхмәт кайтуыңа. Безгә тегендә барырга да вакыт житә инде,— дисең.

# Хис — мәңгелек

Хиссез кеше булмый. Яралганда ук ул хис белән өретелгән була. Монысын табигать кайгырта. Шуннан соң инде аның хистән аерылмавы кешеләргә бәйле.

Туачак кешенең беренче хәрәкәте күңелнең иң төптәге кылларын да тибрәтеп җибәрә. Кара син аны, селкенә диген, ә! Тизрәк якты дөньяга чыгарга, безнең белән яши башларга тели.

Әле әнисе, әле мин, аннары икебез бергә, бер-беребезнең кулын кулга тидереп, аны сыйпыйбыз, дулкынлана-дулкынлана, тын алмыйча, аның хәрәкәтен тыңлыйбыз. Кызык! Рәхәт! Өстәвенә җанны серлелек тә кытыклый. Шикләнү, курку да юк түгел — исән-сау, хәвеф-хәтәрсез туармы? Шул ук вакытта әле бер-беребездән, туасы баладан сәер бер оялу, тарсыну кичерәбез. Әни буласы кешенең кичерешләре безнекеише генәдерме! Кыскасы, без хис дөньясында. Изге теләкле, куаныч белән өртелгән, өметле, сәламәт хис дөньясында. Бу хис әле карында яткан адәм затына да, һичшиксез, рухи азык булып күчәчәк.

Без аны шундый ук хисләр белән кабул итәрбез, дөнья буйлап хисле кеше атлап китәр.

Шөкер, бөтен гомере буе ул хистән аерылмас.

## Суга баралар

Яшь ана кызчыгы белән суга бара. Кызының да кулында чиләк. Чиләге чәчәкле, матур уенчык чиләк. Үзенә дә күп булса яшь ярымдыр. Атлавы да әле алпан-тилпән, тип-тигез җирдә дә сөрлегеп-сөрлегеп куя.

Әмма тырышып атлый. Ул бит суга бара! Әнигә ияргә кушылганы өчен түгел, ә суга барырга кирәк булганы өчен дип шулай тырышып бара.

Әлбәттә, баланың кулына печенье я берәр шалтыравык тоттырып та суга барып була. Ләкин ул вакытта инде бала үзен ияреп йөрүче дип хис итәр иде, суга баручы дип түгел.

Ә боларның аермасы адәм баласы өчен бик зур, һай бик зур!

## Төен

Кызым курчагының керләрен юган да бау бәйләргә маташа. Әмма бауны төенли белми.

Төенне ул үз гомерендә беренче тапкыр күрә. Менә ул беренче тапкыр төен бәйләргә өйрәнә.

Булды бит! Гап-гади төен үзе, шулай да аның килеп чыгуына, үзенең шуны булдыра алуына бала бик тә сөенеп, көлеп җибәрә.

Ә бу тормышта сине нинди төеннәр көтә, балакай. Күпмесендер, төрледән-төрлеләрен, үзең бәйләрсең, ә кеше төенләгәннәрен күпме чишәргә туры килер!

Бар теләгем шул, бәйләгәч тә, чишкәч тә, гел шулай көлеп җибәрсәң иде!

## Аңлады

Ниһаять, бүген ул баланың һәр таләбен канәгатьләндерә килүнең нәрсәгә китереп терәгәнен аңлады.

Бала башта компот сорады. Бирде. Бала эчмәде, кесәл таләп итте. Бирде. Бала кабып кына карады да чәйгә үрелде. Анысын да бирде.

— Нишләп сөтсез, сөт сал!— дип акырды бала. Ясап бирде. Шунда бала аяк тибеп:

— Сөтен ал!— дип кычкырып җибәрде.

Яшь ана аңа текәлеп шаккатты да калды.

## Фикер офыгы турында

Бакча өенең өске катына менә торган баскыч ясыйм.

Басма араларын күпме калдырырга соң? Алай үлчим, болай күзлим — үз адымыма көйлим, хатыннныкын, балаларныкын да чамалыйм. Гаиләдә кем бар, барысының да менәсен-төшәсен күз алдына китерергә тырышам. Уйламадым түгел, кыскасы.

Күрше дә килгән икән. Кыш буе күргән юк иде, хәлен белергә булдым. Ул инде өенең өске катын өлгерткән дә икән. Баскычына игътибар иттем. Аралары бигрәк якын тезеп-тезеп куйган.

— Нигә алай куе?— дим.

— Шулайрак булды бугай шул,— ди.— Үзебез өчен бәлки бик үк кулай да түгелдер, бала-чага менеп йөри башласа инде...

Менә ничек! Аның да малае бар. Өйләнмәгән әле өйләнүен. Әмма ул аның өйләнәсен, оныклары буласын, шушы баскыч буйлап мүкәләп-мүкәләп менеп китәселәрен күз алдына китергән.

Минем дә малай, кызлар бар лабаса...



## Өйдә кем баш?

Дәрәҗәле генә җитәкчегә яшьләр җыелышында сорау бирделәр. «Гаиләдә ирме, хатынмы баш булырга тиеш?» Бер генә сүз белән җавап бирмәде. Грек галимнәре алай диган дә рим галимнәре болай диган дип, ир дә, хатын да баш була ала дигәнрәк нәтиҗә чыгарды. Әмма мондый икеле-микелелек үзенә дә ошамады бугай, азактан сүзен:

— Ире тиле булса, әлбәттә, хатыны баш була инде,— дип бетерде.

## Вакыты җитсә...

Кара-каршы ике күрше. Икесе дә картайды. Капка төбендә генә утырып, дөньяны карашлары белән генә алып барырга калды.

Элек еш ызгышалар, үпкәләшеп, айлар, хәтта еллар буе сөйләшмичә, аралашмыйча яшәгән чаклары да була иде.

Хәзер тәмам килештеләр, бер генә көн дә аерылып яши алмыйлар.

Сәбәбе дә бик җитди икән шул — иртән берсенең капка төбендә утыралар, төштән соң — икенчесенекендә. Шунсыз мөмкин түгел — сөякләре кояш җылысы сорый, тәннәре кояш артыннан йөри.

## Килен нигә әйбәт

Киленнәр турында сүз чыккач, бер апа:

— Минем килен әйбәт, анысы,— диде. Шуннан келт кенә нидер исенә төшеп.— Улым әйбәт минем, киленем шуңа күрә әйбәттер,— диде.

Ике апа, бер-берсен аңлап, кет-кет көлешеп алдылар.

## Бабай дәресе

Сәгать телен күчерә башлаган идем, кечкенә Гөлназ килеп җитте.

— Кирегә таба бора күрмә,— ди.

— Нишләп?

— Бабай кушмый: «Менә син урамнан атлап барганда, аягыңнан кирегә тартсалар, нишләрсең, егылып, гарип булырсың. Сәгать тә ватыла»,— ди.

## Басуда июль төне

Авылның июль төнен хәтерлим. Мичтән чыккан һава кебек көндезге бөркүлек инде кими төшкән, тик таң җиле исәргә иртәрәк, бит-

кә әлегесен җылы дулкын бәреләә. Бернинди хәрәкәт юк, дөньяда тымызык тынлык, күңелне сабыр сере белән кымырҗытып, каядыр өметле дәшеп торган җанлы тынлык бу.

Инеш буендагы таллар, йокымсыраган кебек, уйга чумган, чукчук ботаклар су өстенә асылынган. Аларда да нидер көтү.

Сандугачны көтәбезме әллә? Ә ул үзе, мөгаен, үги ана яфракларына, камыш кыякларына чык бөртекләре кунып, энҗе бөртекләре кебек җемелди башлап, куаклар арасыннан төссез ефәк кебек кенә сыек томан күтәрелә башлаганны көтәдер.

Әллә басулар башка халәттә микән? Ындырны үтеп, шунда чыгам. Юк, икән, тук башакларын иеп, арыш та тынып калган. Ник бер кымшану булсын. Бөтен басу нидер көтә.

Ниһаять, аңладым, арыш басуының дулкынланып тирән-тирән сулаганын тойгандай булгач кына, аңладым: басу урак көтә. Бөтен авыл, бөтен дөнья бу июль төнендә дулкынланып урак өстен көтә ләбаса.

## Табигать кочагында

Монда, ахрысы, сазлык булган. Аяк асты юеш, йомшак мүк. Түмгәк артыннан түмгәк тезелеп киткән. Текәлебрәк карасам, алар җете кызыл төрткеләр белән чуарланган икән. Мүк җиләге икән! Бик күптән күргән юк иде. Иелеп карагач, алар да ягымлы күзләр кебек, җанланып киттеләр. Үзләре белән шулай кызыксынганга сөенешкән кебек ёлмаялар ахрысы. Ә инде алырга дип үрелеп, түмгәк өстен каплаган чәнечкеле үләнгә бармакны чәнчеткәч, наян гына көлештеләр дә шикелле.

Мамык түшәк кебек йомшак, ямь-яшел мүк өстенә яттым. Баш өстемдә биш-алты нарат очы. Алар бер түгәрәк хасил иткәннәр — җитәкләшеп, яшь кызлар түгәрәк әйләнәмени. Ап-ак яулык та бөркәнгәннәр әле. Җилферди. Ап-ак болыт икән. Бирелеп тыңласаң, бу түгәрәкнең җыры да ишетелә сыман — наратлар биектә-биектә, яшел ябалдашларын чайкый-чайкый, талгын гына гүлиләр дә иде.

Портта бетон яр. Өч рәт бетон плитәләр еракка-еракка сузылган. Рәт аралары яшел сызык. Шушындый гадәти булмаган шартларда — таш астыннан да үсеп утырган, үзенә күрә батырлык күрсәткән нинди тереклек иялəре икән алар? Каяле, күрик әле.

И-и-и, менә сиңа могҗиза: үзебезнең гап-гади әрем, акбаш, куз-галагыбыз икән. Менә кемнәр икән кырыс цивилизация белән бергә атлаучы, кыенлыкларга бирешмәүче кыюлар.

Без яшь чакта кура җиләге җыйганда, арада ап-агы очрап куяр иде. «Айда пешкән җиләк», ди торганнар иде. Серле, тылсымлы нәрсә иде ул.

Хәзер кайвакыт тик кенә торганда шул җиләк искә төшә дә, фән моны ничек аңлата икән дип, белешмә китапларга үреләм. Әмма... кире куям. Бик гади генә аңлатырлар да балачакның тылсымлы бер истәлеге төшәр дә ватылыр кебек тоела.

## Халык кем яклы?

Мәйданда халыкның тапкырлыгы, зиһене, еллар буе туплаган тәҗрибәсе тантана итә. Сабан туе уеннары ул — халыкның фикерләү рәвеше, яшәү рәвеше, акылы, зирәклеге.

Тамаша җыр-бию белән башланып китә. Җырлар ил кадере, сагынып кайтулар, дус, туганнар кадере, аларны хөрмәт итү, дәртләнеп эшләү һәм шуның нәтиҗәсе — матур яшәү, кайнар мәхәббәт турында. Монда халык күңеленә хуш килгән җырлар гына җырлана.

Ә биюләр! Салмак бию, очынып бию, кыланып-шукланып бию, башка халыкларның хәрәкәт-кыланышларына ишарәләп, хезмәт, тормыш күренешләренә ымлап бию. Хәрәкәтләрдә дә халыкның уе, осталыгы, тапкырлыгы чагыла.

Уеннар ни тора! Һәркайсы тапкырлык сорый, көч-гайрәт, җитезлек, җорлык, түземлек сорый. Алай гына түгел, олы җанлылык, кече күңеллелек, шуклык-наянлык сорый.

Әнә капчык киеп йөгерергә җыеналар. Сабан туена да эш киеменнән генә килгән шамакаерак яшьләр дә очрый бит әле. Шундый берәү капчык даулый. Комиссия членнары күз кысышып алалар да командага аны да кертәләр. Менә йөгерү башлана. Теге егеткә оннан чистартылмаган капчык биргәннәр икән, мәйданга тузан күтәрелә. Халык рәхәтләнеп көлешә.

Күз бәйләп, төенчек эзлиләр. Ике кешене җибәрделәр. Кладовщик Әхтәс. Юан. Кабаланмый, капшап кына, халык гөжләвенә колагын торгызып, астыртын гына төенчеккә якыная. Ә икенчесе яшь егет. Җиңелчә генә, тиз-тиз шуыша. Үзенең елгырлыгына, тырышуына ышана, хәйләләми. Кемнең кем икәнен, ничек кылануын халык тиз абайлап ала, ул — яшь егет ягында. Эчкерсезне, хәйләсезне, җитезне ярата халык. Астыртынны ул өнәми. Түзә алмыйлар, «тегеләйрәк, болайрак!» дип егеткә ярдәмгә ашыгалар. Комиссия тыярга маташа, әмма шул кадәр халыкның авызын ябып буламы? Тик егет тә чит тавышларга колак салмаска тырыша, шулай да менә, ниһаять, аның кулы төенчеккә беренче булып тия. Мәйдан җиңел сулап куя.

Ә уеннар дәвам итә...

## Хөсетсезләр

Сеңлемнең малае да җиткән егет булган. Мәйданга шакмак җыярга чыкты. Сөлек кебек буй-сын. Караш үткен, игътибарлы, шук.

Пары — Казан кызы. Шулай ук яшь, сылу. Ул биләр! Аның да йөзендә шаян елмаю — ярышу хикмәте.

Икесе дә канатланып, җиңел йөгерәләр. Шулай да егетнең адымнары озынрак шул, кызның ике-өч вак атлавын бер генә сикерә. Аның шакмак күче күзгә күренеп тизрәк кими. Ә халык бик игътибар белән күзәтә. Сыный халык...

Менә егетебез, бер сулыш тын алып, кыз күченә дә күз салды һәм тизлеген... баса төште. Мин җиңел сулап куйдым. Егетебезнең әнисенә карадым. Әле генә аның карашы артык киеренке иде, бит алмасы агара башлаган иде. Улының кызны күрә торып артта калдырырга теләмәвен төшенеп, ул елмайды, бит алмасы алсулана башлады.

Шөкер, нәселебездә хөсетлек юк; ярышу бар, көнләшү дә бар, теш кысып узышу бар, әмма хөсетлек юк!

## Көтәләр

Сабан туе көнне өйдә аш-сый пешереп куймаган кеше бик сирәк буладыр. Кунак көтмәгәннәр дә әзерләнә.

Шул гадәт искә төшеп, Әтнәдә автобус килергә ярты гына сәгать калса да, әнинең яраткан хатыны — чыбык очы туганыбыз Җәмилә апага сугылдык.

Әй, сөенде инде, әй сөенде, бик күптәннән кайтып күренмәгән сукбай улы кайтты диярсең. «Быел беркем дә кайтам дип язмады, кичтән дә бер кеше күренмәде. Ә бит кем дә булса кайтып керер кебек. Бик озак кайтмаганнар да сабан туенда кайтып күренә. Шуңа күрә бүген күршеләр кунакка чакырса да, беркая да бармадым. И-и-и рәхмәт яугырлары, менә бит, ярый әле чыгып китмәгәнмен, сезгә язган ризыклар пешергәнмен икән», дип ул җәһәт-җәһәт кенә мич-тән күпереп пешкән кабартмалар чыгарды, безне табынга утыртып, кайнап торган самавырыннан сөтләп чәй да ясый башлады.

## Бөеклек — гадилек

Күз тимәсен, бигрәк сөйкемле! Гомеремдә беренче мәртәбә күрәм инде әллә шундый чибәр хатын-кызны.

Ягымлы, әмма бераз серле зур кара күзләр. Бу мәгънәле, вәгъдәле караш белән тагын очрашасы килеп тора.

Иреннәр дә мәгънәле. Чия ирен дигәнне моңарчы ишетеп кенә йөргәнбез, асылын белмәгәнбез икән. Бар икән ул чия иреннәр! Пешеп килгән чияне күз алдыңа китер: салкынча да түгелдер, кайнар да түгелдер. Чын чиядә кояш җылысы, ә чия ирендә җан җылысыдыр.

Ирен ачылганда тип-тигез, ап-ак тешләр җемелдәп китә, алардан башка иреннәр, мөгаен, болай күңелгә тартым булмас иде.

Чәч юлы да ап-ак. Кап-кара чәчкә ап-ак юл бик килешә икән. Тигез үрелгән ике толым. Текә маңгайны, озынча алсу йөзне үтә сөйкемле, мөлаем итә икән.

Нигә сылу соң ул шул чаклы!? Сере нәрсәдә? Бер нәрсәсе дә артык түгел бит инде югыйсә.

Чү, тукта, артык түгел, дидекме? Әйе, әйе, артык түгел, бар да үз урынында, бар да табигый, самими. Бар да гап-гади.

Гадилек! Кайда да — кеше йөзе, холкында да, табигатьнең үзендә дә, сәнгатьтә дә сокландыргычның, бөеклекнең асылы һичшиксез гадилеккә кайтып кала. Гади, табигый нәрсә генә бөек була ала.

Әлеге керфекләр каралтылган дип, иреннәргә буяу, биткә пудра сөртелгән дип күз алдына китерүем булды, ханымның серле ягымлылыгы, сөйкемлелеге бетте дә китте.

## Мөлаем булу кирәкме?

Университетта мөлаем генә бер укытучы ханым бар. Яшь укытучы. Башка вакытта үзе башлап исәнләшә, сүз дә башлап җибәрә иде.

Гомумән шундый киң күңелле, самими мөлаем холыклыдыр дип, кәеф бик шәптән булмаса да, бу юлы аның белән үзем башлап, елмаеп күрештем.

Коры гына, хәтта төксе итеп җавап бирде. Лифтта икәү генә менә идек. Бәлки сүзне үзе башлар дип көттем. Юк, башламады. Телсез күтәрелү уңайсыз иде, үзем кәеф-хәлен сораштым. Күп булса бер-ике сүз әйтте дә тынды.

Бактың исә, ул инде кафедрага күтәрелгән булган, ишекләр бикле, ачкычка дип, вахтерлар янына кире төшкән булган да анда да табылмаган. Мин аның нәкъ менә «кайнап чыккан» мәленә туры килгәнмен икән.

И-и-и дөнья! Минем дә бәлки шундый халәткә юлыккан минутларым буладыр, аерма берүк мине сабырлыктан, тап миңа бер генә чеметем түземлек!

# Ярый әле тыңламады

Безнең алдан бик матур бер кошчык сикерә-сикерә йөгерә. Яңа гына кардан арчылган тау сукмагында җим чүпләнә. Түше алсу, канатларында яшелле-кызыллы туры сызыклар. Матур!

Миннән башка аны тагын ике егет күзәтә икән. Алдагысы, фотоаппаратын юнәлтеп, кача-поса аңа якынаерга тырыша. «Тавышланма!» дип, икенче кулы белән арттагы иптәшенә ишарәли. Ә кош, ул якынаям дигәндә генә, очып китә дә ерак та түгел тагын төшеп, йөгерә башлый. Егет — янә аның артыннан.

И-и-и кошчык, чибәркәй, нигә үз кадереңне үзең белмисең, төшерттер егеттән карточкага, даның еракларга китсен, шөһрәт кызыктырмыймыни соң сине!? Тыңла сүземне, тукта бер генә секундка. Курыкма кешеләрдән!

Кош шунда туктаган кебек була. Нәкъ шул вакыт кулына таш тоткан икенче егет алдагысын тотып туктата: «Җитте сиңа, юк белән булашасың, кая әле мин аны!» Һәм...

Ай, кошчык, нишләдек без...

Ярый әле кош мине тыңламаган, туктамаган икән. Очты да китте.

Ә мин уйга калдым: бу дөньяда әле һәр киңәшне тыңларга да ярамый, күрәсең.

# Үз-үзен газаплау

Авылдашым Камил абый кергәләп чыга. Яңалыклар, яңа китаплар белән кызыксына. Артистлар турында сөйләшеп алабыз. Авылның беренче гармунчысы иде. Һәм... иң ата эчкечесе иде. Авыл тарихында аның кебек мәгънәсез, әшәке эчкеченең булганы булмагандыр.

Хәзер эчми. Төзелештә эшли. Чит илләрдә дә эшләп кайтты. Яхшы исәптә. Кызлар үстерде. Элекке хәлләрне искә дә алмыйбыз. Шулай да беркөнне сорадым:

— Камил абый, салганың юкмы?

— И-и-и энем,— ди бу,— кемгә саныйсың син мине, нинди гөнаһларым өчен әле үземне-үзем шул чаклы җәзаларга, газапларга тиеш?

# Әхмәт Гадел

## Сөю

Давылларга ялвардым мин:
шаулап миңа килегез!
Әмма диңгездә ял итә —
ялкау ахры җилебез.
Яшеннәргә ялвардым мин:
күктән биек буегыз,
хисләрем сыймый эчемә,
күкрәгемне уегыз!
Ләкин яшен биек күктә,
болытлар кочагында...
Хыялымнан тудың, сылу,
Ярсып йөргән чагымда.
Тудың да җылы китердең,
наз да бүләк итәрсең.
Тик... тукта, яшьлек өметем,
ташлап кая китәсең?!
Давылларны күрмәдең ич,
Күрмәдең яшеннәрне...
Давыллардай кубып минем
күрмәдең яшенләүне!
Еракларга, шатлыкларга
ничек барып җитәрсең?
Яшьлегеңә матурлыкны
ничек юлдаш итәрсең?!

❁

Ялкын белән көл арасы —
Ут — кызган күмер.
Яшәү һәм үлем арасы —
Көрәшле гомер.

❁

Туйра үссә — иман булыр.
Малай үссә — иләмән булыр!

❁

Кер, бәхетем, арага,
Бер дәва бул ярага!
Ике бәхет бер булганда,
Урын калмас ялага!

---

ӘХМӘТ ГАДЕЛ *(1942) — шагыйрь, «Яшьлек урамы», «Көмеш кылган җырлары» һ. б. шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

Тел, тешләсәң, авырттырыр,
Бәгыреңне өздерер.
Сер, сакласаң, ябыктырыр,
үз-үзеңнән биздерер.

Көреп ятсаң да бикләнеп кеше тапмас төшкә,
Үзеңнән качып булмый, белегез, һич тә!
Кара сакал алдан бара, бер нигә карамый,
Тарасаң да, юсаң да, күп чак ул бернигә ярамый!

## Яшьләргә бер киңәш

Корал алсаң, илне саклыйм дип тот,
Каләм алсаң, Җирне аклыйм дип тот.

## Кар монологы

Һәр кешенең батыр чагы була,
Буйсындырыр чагы дөньяны...
Мин дә ишәм диеп йөргән идем,
Күкрәк белән тимер койманы...

Таш — асфальтны тишеп үскән үлән
Минем аша үтә төсле.
Агачлардагы яфраклар
Миндә дә бит үсә төсле...

## Өметем

Сагынам, улым!
Таңнарымда сиңа барам — төшләремдә...
Шулай җир сагынадыр йолдызларга очкан болытларны,
Ә болытлар сагынамы Җир-ананы?!

Сагынам!
Казан янындагы калын урманда
икәү үткәргән төнне сагынам!

Бәхет чәчәге кебек, һаман нурлана —
киләчәкне яктыртамы учак?!.
Синең белән бергә яккан шушы учак
күңелемә күчте: яна, балкый!
Нинди генә учакка баксам да,
күңелемдә җанлана шул төн.
Ике ир-егет аңлашкан изге төн.
Шул төндә сине таптым, улым!
Шул төндә туды өметем.
Шул төндә терәгем барлыгын аңладым...

## Әмирхан Еники

# КАСЫЙМГА СӘЯХӘТ

Күптән инде Касыйм якларын барып күрәсем килә иде. Тарихтан билгеле булганча, моннан 3—4 гасырлар элек Ука елгасы буенда, әнә шул исемдә татар ханлыгы яшәгән бит әле. Тарихи риваятьләргә караганда, аны рус патшалары Казан ханлыгына каршы файдаланыр өчен оештырган булганнар («Касыйм» дип аталуы да Казан ханы Олуг Мөхәммәтнең руслар ягына качкан малае исеме белән бәйләнгән). Шуңа күрә дә ул, баш-аягы белән Мәскәү патшалары кулында булып, аларның Казан ханлыгына каршы барлык походларында да аты-коралы белән катнаша килгән. Әмма Казан ханлыгы җиңелгәч, Касыйм ханлыгының да кирәге беткән. Күпмедер вакыттан соң аны бөтенләй «ябып» та куйганнар.

Ләкин, ханлык бетерелсә дә, халкы калган... «Касыйм татарлары» дип йөртәләр иде аларны. Мине дә әллә кайчан беткән, юкка чыккан ханлыктан бигрәк, шул ханлык җирендә күптәннән яшәп килгән милләттәш халкыбызның язмышы кызыксындыра иде. Бармы алар, һаман шунда яшиләрме, ничегрәк яшиләр, нәрсәләре сакланган яки югалган — менә шуларны күпме-азмы белер өчен, Касыймның үзенә генә булса да барып кайту кирәк иде. Мондый теләк күптән туса да, мин аны төрле сәбәпләр аркасында үти алмыйча йөрдем. Бары 1985 елның август башында гына мин, кинәт кенә кузгалып, Касыймга табан, ниһаять, чыгып китә алдым.

Касыйм шәһәре, әйткәнебезчә — Ука елгасы буенда. Хәзерге вакытта ул Рязань өлкәсенә керә. Аңа Казаннан туры юл юк. Муром аша, яки Горький аша барырга кирәк. Мин Горький аша су юлы белән барырга булдым. Алтынчы августның төнендә Әстерхан — Горький пароходына, ничектер ансат кына аерым каюта алып, әйбәт кенә утырып, киттем. Җәйнең әле хозур чагы, август башында гына коры көннәр дә бик кыздырып җибәрде. Көндезен пароход палубасыннан инде картая башлаган, йокымсырап утырган яшькелт-соры тауларга, кара-кучкыл урманнарга, аксыл кырларга карап баруы да күңелле иде.

Бер тәүлекне тутырып, икенче көннең иртәсендә, сәгать алтыда, пароходыбыз Горькийга җитеп туктады. Ярга чыккач та, мин иң әүвәл Касыймга пароходларның кайдан, кайчан китүен белештем. Сәгать җидедә «Ракета» китә, диделәр. Мин аңа өлгергән дә идем, ләкин кызганычка каршы, билет сатылып беткән, касса инде ябык иде. Ә бу «Ракета» дигән нәрсә тәүлеккә бер генә тапкыр китә имеш, шулай итеп, миңа икенче көннең иртәсенә кадәр Горькийда калырга туры килде. Хәерле булсын, дидем дә, башта елга вокзалының кунакханәсеннән үземә урын алдым. Бусы, көтелмәгәнчә, ничектер уңышлы килеп чыкты. Аннары иртәгә китәр өчен билетны да бүгеннән алып куярга булдым. Ләкин монысы шактый ук мәшәкатьле булды. Иң элек зур залдагы алдан билет сатучы кассаның ачылганын бер-ике сәгать көтеп тордым. Инде бәләкәй тәрәзә ачылып, Касыймга билет сорагач, әчтә утыручы ханым коры гына, урын юк, диде. Һәм билет бирмәде. Аптырап калдым — болай булыр дип һич тә көтмәгән идем. Нишләргә?.. Монда тагын бер тәүлек утырыргамы — юк, булмый болай! Вокзалларда администратор дигән кемсә була иде, шуны эзләп киттем. Аны табып, хәлне аңлаткач, ул кассага записка язып бирде. Әлеге «юк» дигән кассиршага барып, берсүзсез билетны алып, кесәгә әйбәт кенә салып куйдым.

Юл йөргәндә, шуныңише хәлләр очрый инде ул. Әмма кайчагында — һич башка сыймый торганнары да. Икенче көнне, причалга барып, «Ракета»-га утыргач һәм бераздан кузгалып киткәч, мин чын-чынлап хәйран калдым: монда урыннарның яртысы диярлек буш иде. Моны ничек аңларга? Ни өчен кичә миңа: «Урын юк»,— диделәр? Ә кем өчен соң бу урыннар? Бәлки алдагы тукталышларда сатыр өчендер? Ләкин, «Ракета» Горькийдан ераграк киткән саен, төшүчеләр күбәя, утыручылар азая барды. Кыскасы, мин бу хәлне аңлаудан ерак идем. Бары тик моны электән үк сакланып килгән алама бер гадәтнең дәвамыдыр дип кенә уйладым һәм Горькийда кемнәрнеңдер, билет ала алмыйча, торып калуларына ирексездән бераз сыкранып куйдым.

«Ракета» Горькийдан Касыймга 9 сәгать бара. Ә буфеты юк, махсус урыны булса да ябык, эшләми. Хәтта бак белән суы да юк. Моны белмичә утырган кеше көне буе ач барырга тиеш. Мин әнә шундый пассажирларның берсе идем.

Әйтергә кирәк, Ука буйлары бик ямьле икән. Безнең Агыйделдән зурраktыр — менә шуның кара ярларына, киң тугайларына карап бару күңелне хушландырып, ашыйсы-эчәсе килүне дә бераз оныттыргандай булды. Сәгать дүртләрдә, ниһаять, Касыймга килеп җиттек. Көн бик эссе иде.

Су буендагы күп шәһәрләр шикелле үк монда да пристань түбәндә, кала үзе югарыда иде. «Ракета»дан төшкән халык, төеннәрен, яшь балаларын күтәреп, әкрен генә югарыга үрмәлиләр. Кемнәндер: «Шәһәргә менәргә транспорт юкмыни?» — дип сорагач, ул иренеп кенә: «Элек бар иде дә, хәзер юк шул»,— диде. Автобус, түбән төшеп тормыйча югарыдан гына китә икән — рәхмәт яугыры! Чара юк, башкалар артыннан мин дә, әлсерәп, югарыга үрмәләдем.

Касыймның кунакханәсе биш катлы яңа, зур бина иде. Ничектер ансат кына миңа бер кешелек урын бирделәр. Кереп урнашкач та ашау-эчүне кайгырта башладым. Ләкин шушы шәп, зур кунакханәнең дә буфеты юк имеш! Бар иде, эшләүчесе чыгып киткәч, яңа кеше таба алганнары юк әле, диделәр миңа. Нишләмәк кирәк, була андый хәл дә безнең көнкүреш хезмәтендә. Ярый, түбәндә ресторанны бар икән, тизрәк шунда төшеп киттем. Тик монда да күңелне теләгәнчә хушландырып булмады. Чәйләре юк икән, ә бу эсседә куе яхшы чәйне мин бик сагынып килгән идем. Шулай да өстәлләргә графиннар белән морс дигән су куйганнар — чәйгә караганда бу кызгылт суның мәшәкате азрактыр, күрәсең. Анныры монда хәмернең һәр төрлесен китертергә була икән. «Анысы — пожалысты! — диделәр миңа елгыр официанткалар.— Конечно, норма белән генә!...»

Касыймда үткәргән дүрт көнемнең берсе якшәмбегә туры килде. Шул көнне төшке ашка төшсәм, ресторан халык белән шыгрым тулы. Ләкин ашап утыручылар бик сирәк күренә. Нишли соң бу халык монда? дисәм, аларның бик күбесе эчеп чыгарга керүчеләр, имеш! Һәр өстәл артында 3-4 кеше үзләренең 100 граммнарын көтәләр (норма шулай гына). Официантка китереп куйгач, бераз сабыр итә төшеп, үтә күренмәле «суны» ашыкмыйча берьюлы иплән кенә каплыйлар, авызларын сөрткәлиләр, кесәләренә тыгып килгән ипи кисәген яки кыярларын тозлап кабалар да, аннары тәмәке тартып керер өчен тышка чыгып киткән булалар. Ә биш-ун минуттан кире кереп, икенче официантканың өстәленә утыралар да... 100 граммны яңадан кабатлыйлар (кайберләре исә чыгып та тормыйча бер өстәлдән икенче өстәлгә күчеп кенә утыра). Болар барысы да, күрәсең,— даими йөрүчеләр. Официанткаларга да алар Маня, Валя, Галя дип кенә дәшәләр. Дөрес, үзара мөнәсәбәтләрдә беркинди нәзакәтлелек юк, ләкин бер-берләрен яхшы аңлыйлар булса кирәк — «алыш-биреш», гомумән, гаугасыз, тыныч-шома гына бара. Озын сүзнең кыскасы, якшәмбе ялын «отмечать итәр» өчен бирегә килүчеләр әнә шулай, өстәлдән-өстәлгә күчә-күчә, үз нормаларын тотырып, тәмам канәгать хасил булып, ахырда үз аяклары белән «тәртипле» генә чыгып китәләр.

Сорау туарга мөмкин: ни өчен әле мин, төп максаттан читкә китеп, боларны язып торам? Эш шунда ки, болар барысы да — «Ракета»да буш урын була торып та билет сатмау, пассажирларны 9 сәгать буена кайнаган суга да интектереп бару, ә менә мондагы ресторанда аракыны теләгән кадәр эчеп чыга алу — әйе, болар барысы да — апрель Пленумыннан соң һәм эчүчелеккә каршы юнәлтелгән карарлар чыккач, күзгә бәрелеп торган тискәре күренешләр. Аларның тормышта тамыры тирән әле, кешеләрдәге

иске гадәтләр белән нык бәйләнгән — димәк, аларны корытып бетерер өчен дә әле күпме вакыт һәм көч кирәк булачак. Я, шулай булгач, кеше андый тискәре күренешләргә очраган чакта тыныч кала аламы? Менә минем дә дәшмичә тыныч каласым килмәде.

* * *

Инде булмаса төп максатка күчик. Төп максат, әйткәнемчә, Касыйм татарларыннан кемне дә булса күрү, сорашу, бүгенге хәлләре белән бераз танышу иде. Билгеле, минем кулымда беркемнең дә исеме дә, адресы да юк иде. Берәрсен очрату бары тик очраклы гына булырга мөмкин. Килгән көнне үк кунакханәдә юынып, ашап, бераз ял итеп алгач, кич кырын якынтирә урамнардан бер әйләнеп кайттым. Татарлардан берәү дә очрамады, хәер, очраса да, мин аны кайдан таныйм?! Маңгаенда мөһере юк бит аның. Болай каранып йөрү, белмим, нинди генә нәтиҗә бирер икән?

Икенче көнне мин иртә генә торып, шәһәр базарына киттем. Анда инде татар агай-энесе очрамый калмас. Сөйләшеп торуларына колак салып та белеп булачак.

Базарга мин шәһәрнең борынгы үзәк урамы буйлап бардым. Мондагы таштан салынган берничәшәр катлы зур, таза, матур йортларга игътибар иттем. Күренеп тора: бу төз урам кайчандыр Касыймның эш һәм сәүдә үзәге булган булырга тиеш. Хәзерге кибетләрнең дә күбесе шушы урамда иде.

Менә базарына да барып җиттем. Монда да иң элек күзгә ташланган нәрсә — «гостиный рәт» (таштан салынган бер кыек астындагы тоташ кибетләр рәте) белән шактый тузган, төсен югалткан иске чиркәү булды. Ә базар үзе шулардан бер читтә, ачык мәйданда иде. Ләкин ул бик кечкенә дә һәм бик ярлы да икән. Бөтен базарында — бәрәңге дә яшелчә, шуннан башка нәрсә юк та диярлек (мәсәлән, ит, сөт азыклары бөтенләй күренмәде). Хәер, бер нәрсә бик күп иде — ул да булса алма — алмага бай җир икән.

Минем, билгеле, аласым да, сатасым да юк — миңа монда берәр татарны гына очратырга кирәк. Әкрен генә каранып йөрим, ике-өч кеше сөйләшеп торса, шулар янына тукталып колак та салып торам. Аннары тагын кузгалып китәм; базарны бер әйләнәм, ике әйләнәм, өч тә әйләнәм, әмма очрамый гына бит татар! Мин тәмам аптырап калам — базарда татар булмасын имеш!.. Бәлки минем үземә дәшеп карарга кирәктер. Менә базар капкасы төбендә какча, кара тутлы бер кеше җиргә ачып куйган капчыгыннан стаканлап көнбагыш сатып тора. Нәрсәсе беләндер мин бу кешене татарга охшаттым һәм ипләп кенә аңардан, русчалап: «Гафу итегез, сез татар түгелме? — дип сорадым. Ул борылып, гаҗәпләнеп миңа карады да: «Слава богу, я со дня рождения русский!» — диде. Шәп әйтте көнбагыш сатучы, һич бер төрле шик калдырмаслык итеп — шулай әйтү кирәк ул кем икәнеңне сораучыларга! Мин бик мәмнүн булдым аның бу җавабыннан. Тик шуннан соң базарда татар эзләп йөрүем миңа мәгънәсез бер эш булып тоелды һәм артык буталмыйча моннан тизрәк чыгып китәсем килде.

Ул көнне мин ялгызым гына шәһәрне карап йөрдем. Ханлык заманыннан калган кайбер нәрсәләрнең монда сакланганын белә идем — шуларны да барып күрмәкче булдым. Кунакханәдән ерак та түгел икән. Ука елгасына таба сузылган туры гына урам белән китеп, урта зурлыктагы бер мәйданга барып чыктым. Башта кечкенә, куе гына бакча аша үттем. Бакчаның урта бер җирендә — зур гына ак һәйкәл. Үзенә күрә кызыклы гына эшләнгән ул: яшь солдат белән яшь кенә хатын сыны, кулларын бер-берсенә сузган килеш, кара-каршы басып тора. Сузылган куллар өстенә нәни бала сыны утыртып куелган. Ватан сугышы корбаннарына багышланган бу һәйкәл нәрсәне аңлата? Җиңеп кавышуны, яшәүнең дәвам итүен булса кирәк — шулай аңладым мин.

Бакчаны үтүгә, ике катлы һәм аерым манаралы ак бина янына килеп чыгасың. Бу — татар ханнарыннан калган мәчет бинасы. Мәчет үзе бер генә катлы булган, тик соңыннан, совет вакытында, икенче катны өстәгәннәр. Менә шунда инде шәһәр музее урнаштырылган. Мин кергәндә, монда беркем дә юк иде. Музей хадимәсе үз урынында утырып тора, ләкин мин аны борчымаска булдым — нигәдер ялгыз гына карап йөрисем килде.

Түбәнге катта ханнардан калган кайбер нәрсәләр куелган. Пыяла шкаф эчендә, мәсәлән, татарның тутыккан кәкре кылычы, тимер боҗралардан эшләнгән сугыш киеме, ханнармы, бәкләрме кигән чапан, бүрек, кайбер

хатын-кыз зиннәтләре — җыеп кына әйткәндә, татарларга хас әйберләр монда бик аз. Бу калдык-постыклар «Касыйм ханлыгы»ның чынлап та вакытлыча гына оештырылган гомерсез бер сателлит булуын гүя үзләре үк әйтеп торалар иде.

Аннары монда бу якларның табигатен, хайваннар дөньясын күрсәткән кайбер экспонатлар да бар иде. Ләкин алар да күп түгел. Ике-өч бүлмәдән гыйбарәт түбәнге катны ашыкмыйча гына карап үткәч, мин икенче катка күтәрелдем. Монда бүлмәләр күбрәк тә һәм иркенрәк тә иде. Биредә куелган экспонатларның һәммәсе дә революция елларына, совет чорына һәм Ватан сугышына багышланган. Бу алтмыш-җитмеш еллык дәвер эчендә Касыйм шәһәренең тарихы шактый тулы чагылдырылган дип әйтергә була. Шулай ук монда сугыш каһарманнары һәм корбаннарының фоторәсемнәре дә бик күп — берәмләп карап бетererлек тә түгел (соңыннан миңа татардан бер Советлар Союзы Герое булуын да әйттеләр, мәгәр музейда аның фотосы нишләптер минем күземә чалынмады).

Музейдан чыккач, мин борынгы мәчетнең манарасына да менеп төшәргә булдым (теләгән кешегә рөхсәт ителә). Манара эре ак таштан салынган, тышкы күренеше белән Болгар хәрабәләрендәге манарага бик охшаган (бер үк осталар салган диярсең), биеклеге бер 18-20 метр чамасы гына булыр. Менә торган баскычы гаять тар, текә, ике кеше очрашса, үтәрлек түгел. Менә шул баскычтан мин, иңнәрем белән ышкыла-ышкыла, кечкенә түгәрәк мәйданчыкка күтәрелдем. Манара калкулык өстенә салынганга күрә, моннан шәһәрнең үзен дә, бөтен әтрафын да бик тулы күзәтеп булырлык иде. Ука елгасының сул яры буйлап сузылган Касыйм зур гына бер шәһәр икән. Тоташы белән диярлек бер катлы җыйнак аерым йортлардан гыйбарәт, электән калган зур йортлар үзәктә генә күренә, безнең заманның дүртәр-бишәр катлы соры йортлары да күп түгел, ә менә иске чиркәүләр байтак кына икән әле. Уканың аръягы еракларга җәелгән киң, якты тугайлык — шәһәр кешесенә барыр, йөрер урыннар күп монда. Мин үзем дә табигатькә якын шушындый тыныч, аулак шәһәрдә торырга риза булыр идем, әмма ләкин аның ниндидер бик үзенчәлекле авыр шартларына җайлаша алмам дип куркам.

Манарадан төшеп, урамга чыккач, кире кайтыр якка таба атладым. Болай ялгыз гына йөрүнең кызыгы шулай да азрак. Аннары беркемне очрата алмавым да һаман эчемне пошыра да тора. Көнем әрәм бит әле, көнем.

Уйланып бара торгач, башыма кылт итеп бер фикер килде: тукта, мин әйтәм, Касыймның мәчете булгач, зираты да булырга тиеш ләбаса! Бәлки әле караучысы да бардыр. Эзләп тапсам, һич югы, шуның белән сөйләшермен.

Ләкин башта кунакханәгә кайтырга булдым. Көннең эсселегенә түзәрлек түгел. Мондый эсседә әллә кайдагы зиратны эзләп йөрү бер газап кына булачак. Янып-пешеп, бүлмәмә кайтып кердем. Эх, менә хәзер чәй булса иде, куе чәй! Бик заманча итеп салынган зур кунакханәдә чәй юк кына бит.

Көн тәмам сүрелгәч, кичке якта мин татар зиратын эзләп киттем. Ул ерак та түгел икән, шәһәр эчендә диярлек, киң, озын урамның очындарак куе бакча шикелле күренеп үк тора. Сузылып киткән калын койма, таза капка, бер катлы кечерәк йорт — болар барысы да кайчандыр чын кызыл кирпечтән гомерлек итеп салынган. Яңадан йөз ел торса да, үзлегеннән җимерeләчәк түгел.

Капкадан үтеп, кечкенә йортның ишеген ачтым. Эче караңгы, кеше барлыгы сизелми. Башны тыгып кына: «Кем бар икән монда? — дип дәшкән булдым. Түрдәге караватта яткан бер ир заты әкрен генә башын калкытты, аннары тавышы ишетелде:

— Кем кирәк?

Мин, читтән килгән бер кеше булуымны әйтеп, аның, мөмкин булса, торып чыгуын үтендем. Шуннан соң ул кузгала башлады. Капка төбендә агач эскәмия күземә чалынган иде — мин шунда чыгып көтәргә булдым.

Бераздан шактый арык, хәлсез агай бөкрәеп кенә минем яныма килде дә, ике кулына таянып, сакланып кына янәшәмә утырды. Исәнләштек. Танышу өчен мин фамилиямне, кайдан килүемне әйттем. Аның да исемен сорадым. Сафа исемле икән, кайчандыр Нижгардан (Горький өлкәсеннән) килгән, менә шушы зиратны каравыллап ята. Аңа сиксән сигез яшь икән инде. «Эшләве авыр түгелме соң?» — дим. «Нинди эш,— эш юк, мәет бик сирәк килә»,— ди агай. «Касыймда татарлар күпме соң?» — дип сорыйм. «Әллә тагын, кем санаган»,— ди сүлпән генә.

«Шулай да?»...— «Ну, может, бер утыз-кырык семья булыр...» Билгеле, минем агайга ышанасым килмәде, кайдан белсен ул?!. Мәет килүенә карап кына әйтә торгандыр.

Бу кыска гына сөйләшүдән соң, мин аңардан мондагы берәр татар кешесенең адресын әйтүен сорадым. Касыймның төп үз кешесе булсын иде дип тә өстәдем. Агай уйлана калды.

Нәкъ шул чакта безнең янга бик чандыр, тере-җитез генә бер карчык килеп туктады.

— Минем катын,— диде агай иренеп кенә, аннары карчыгына русча дәште.— Менә бу иптәш Казаннан килгән, мондагы берәр татаринның адресын сорый. Син, Катя, яхшырак беләсең, кемнәр бар әле касимскилардан?

— Әнә Ишимбаевка барсын! — диде карчык уйлап та тормыйча.

— Дөрес,— диде агай да.— Әхмәт барсын да белә, сүләргә дә ярата.

— Кем соң ул Ишимбаев?

— Бывший учитель.

Мондый кеше миңа бик ярый иде. «Тетя Катя» адресын да өйрәтте. Мин рәхмәтемне әйтеп, тизрәк шунда ашыктым. Кояш баеган иде инде, ләкин караңгылык иңмәгән иде әле. Федорова исемендәге аулак урамны озак эзләргә туры килмәде. Менә миңа кирәк йорт та: ике катлы, асты таш, өсте агач йорт. Бакчалы ишегалдына кердем. Өске катның тәрәзәләре киңенчә ачык, ут алынган, яп-якты. Мин шул ачык тәрәзәгә: «Әхмәт абзый!» — дип тавыш бирдем. Шунда ук тәрәзәдән зур гына чал баш күренде:

— Кем анда?

— Сезне эзләп килдем! — дидем мин аңа.

— Хәзер, алайса! — диде «баш» һәм, озак та үтми, түбәнге ишектән өлкән яшьләрдәге таза-базык кына бер абзый килеп чыкты. Күрештек. Мин кем икәнемне әйттем. «Әйдәгез, кереп сүләшик!» — диде ул миңа.

Текә генә баскычтан менеп, зур гына өйалдын узып, иркен якты бүлмәгә килеп кердек. Уртада зур өстәл, өстәлдә кайнап торган самавыр — кечкенә чәйгә утырырга гына торалар икән. Бүлмәдә тагын бер яшь ир белән яшь ханым да бар иде — Әхмәт абзыйның кунакка кайткан кияве белән кызы икән. Менә уйламаганда гына күңелле табынга туры килдем бит әле.

— Мактап йөрисез! — диделәр миңа, өстәл янына чакырып. «Мактамаган кая инде ул!» дидем мин эчемнән генә, күтәреп торган матур чынаякларга карап.

Хуҗам Әхмәт абзый яшькә миннән күпмегәдер олырак булыр, сирәк чәчләре тәмам агарган инде, әмма тулы йөзе җыерчыксыз-шома, күзләре дә тере, хәрәкәтләре дә әле иркен-җиңел дип әйтерлек. Ул мине бик гади һәм ачык каршылады. Сөйләшүебез дә күптәнге танышлардай табигый, җиңел башланып китте (күрәсең, минем эше «Касыйм ханлыгы»на килеп чыгучылар белән аңа еш очрашырга туры килгәндер). Сүзгә дә ул юмарт иде. Үзе турында да, бер сорау белән, барысын да сөйләде дә бирде. Касыймда туган, Касыймда үскән, бөтен гомерен шушында (һәм якын-тирә авылларда) укытучы булып уздырган. Иң мөһиме — Касыймның үткәнен дә, хәзергесен дә бик яхшы белә икән абзый! Сөйләшә торгач, кинәт исемә төште: бу мөхтәрәм кеше миңа таныш лабаса! Моннан дүрт-биш ел элек булса кирәк, күренекле журналист В. Песков (телевидениедә «Хайваннар дөньясы» дигән тапшыруны да алып баручы) «Комсомольская правда» газетасында Касыймның карт бер укытучысы турында озын гына очерк бастырган иде. Аның да бит фамилиясе, хәтерем алдамаса, Ишимбаев иде бугай. Әхмәт абзыйның үзеннән сорагач, ул бик гади генә: «Әйе, минем турыда иде шул!» — дип раслады. Кара син, нәкъ кирәк кешегә тап булганмын бит әле, бәхеткә каршы!

Шушы беренче кичтә үк Әхмәт абзый миңа шактый күп нәрсә сөйләде. Дөрес, без ерак тарихка — ханнар заманына кереп тормадык.— күптән беткән, онытылган инде ул. Башта ук әйткәнемчә, мине Касыйм татарларының соңгы замандагы (мәсәлән, XX гасыр дәвамындагы) тормышлары кызыксындыра иде. Ә бу заманны Әхмәт абзый үзе күреп тә һәм ишетеп тә бик яхшы белә икән. Кыскасы, сөйләшү бик кызыклы үтте, чәй дә бик тәмле иде — рәхәтләнеп бер эчтем, ичмасам!

Икенче көнне төштән соң, Әхмәт абзый үзе мин торган кунакханәгә килде. Номерда бераз сөйләшеп утыргач, ул миңа шәһәрнең татарлар яшәгән өлешен күрсәтергә булды. Ашыкмыйча гына узышлый, мине һаман Касыймның үткәне белән таныштыра барды. Ханнар заманыннан ук татар-

лар монда үзләренә аерым бер төбәк булып утырганнар. Урнашкан җире калкулык өстендә булганга күрә, электән үк аны «Татар тавы» дип атаганнар. Ука елгасына таба сузылган хәзерге Татарская белән Нәриман исемендәге иң озын ике урам һәм шуларны аркылы кисеп узган кыскарак урамнар менә шул төбәкне эченә ала икән. Бу урамнардагы йортларның барысы да диярлек кайчандыр татарларныкы булган. Алар Касыйммны да борынрак заманда Ханкирмән дип йөрткәннәр.

Әхмәт абзыйның сөйләвенә караганда, халык монда тулаем таза торган. Күбесе сәүдә яки сәүдәгә бәйле хезмәт белән шөгыльләнгән. Араларында хәтта чит илләр белән алыш-биреш итүче байлары да булган. Аннары Мәскәү, Петербург, Киев кебек мәркәз шәһәрләргә китеп эшләүчеләр, шулай ук зур сәүдә алып баручылар да аз булмаган. Мәсәлән, Мәскәүдәге каракүлче миллионер Ирзиннар яки Петербургтан алып Кырымга чаклы барлык зур вокзаллардагы ресторанчарны тотучы Киевтагы Максудовлар белән Дивеевлар әнә шундыйлардан (шунысы да мәгълүм булсын: менә шул Максудовлар, гимназист улларын һәм кызларын татарча да укытыр өчен, әдип Галимҗан Ибраһимовны 1912 елны Киевка махсус чакыртып алалар).

Касыймлылар — үзара бик нык аралашып, оешып яшәгән халык. Касыймның үзендә бер-берсен белмәгәне, йөрешмәгәне, сәүдә яки хезмәт белән бәйләнмәгәне булды микән?! Берәрсе читкә китеп эш башласа да, тизрәк моннан я якын туганын, я яхшы танышын чакыртып алган. Приказчиклар, официантлар, хезмәтчеләр булып шулар эшләгән. Шулай ук өйләнешү, гаилә кору да күбрәк үз араларында барган.

— Гаиләләр ишле — һәркайсында җидешәр-сигезәр бала була торган иде,— ди Әхмәт абзый.

Бай йортларда балалар өчен гувернанткалар тотканнар, мәгәр аш-суны, гадәттә, бикәләр үзләре карыйлар икән. Тагын бер деталь: бу йортларда дворник һәм кучер булып күбрәк руслар хезмәт иткән. Болар барысы да, билгеле, революциягә чаклы булган хәлләр.

Ул заманда татар дөньясында көчәеп киткән прогрессив тәрәккыяттән касыймлылар да читтә торып калмаган. Хәтта кайбер җәһәттән алгарак та чыкканнар. Мәсәлән, Касыймда беренче югары типтагы мәдрәсә 1833 елда ук ачылган һәм җәдитчә укыту да, башка җирләргә караганда, иң элек шушы мәдрәсәдә башланган. Даны аның шактый еракка таралган. Үз тирәсеннән генә түгел, Идел буеннан, Уралдан, хәтта Себердән дә килеп укыганнар. Безнең язучыбыз Закир Һади дә — шушы мәдрәсәдән чыккан кеше.

Халык саны һаман арта баргач, янә бер мәчет салдырган булганнар. Әхмәт абзый миңа аны да күрсәтте: архитектурасы бик матур, тик манарасы юк — сүтеп ташлаганнар. Шәһәрдә шулай ук бай татар китапханәсе дә булган. Татар телендә басылган барлык китаплар һәм барлык газета-журналлар килеп торган.

Без үзебезнең театр тарихын 1906 елдан башлыйбыз. Ә менә Касыймда халык өчен беренче ачык театр тамашасы 1898 елда ук уйналган. Әхмәт абзыйның әйтүенә караганда, бу хакта Рәшит казый Ибраһимов тарафыннан чыгарылган «Миръат» («Көзге») журналында хәбәр дә басылган булган. Ихтимал, соңрак Касыйм яшьләреннән Петербург һәм Мәскәүдә махсус театраль белем алган Әшраф Синяева, Гомәр Девишев кебек сәхнә осталарының чыгуы да очраклы хәл түгелдер. Әлбәттә, Касыймның рус культурасы үзәкләренә якын торуы, халкының шактый гына өлеше шул үзәкләр белән бәйләнгәнлеге дә аларга уңай йогынты ясаган булырга тиеш. Рус культурасы аша алар Европа культурасына да күпмедер дәрәҗәдә якынайганнар. Франциягә барып, мәшһүр Сорбонна университетын тәмамлап кайткан беренче татар кызы Сара Шакулованың Касыймнан икәнен искә төшерү дә без әйткәнне раслау өчен җитсә кирәк.

Инде Касыймның үткәне белән, өстән генә булса да, танышканнан соң, Әхмәт абзыйдан хәзерге хәлләрне сорашуы ничектер уңайсыз иде. Татар халкы Касыймнан китеп беткән диярлек. Торып калганы да бер 60-70 гаилә булыр.

Әмма халык, таралып бетсә дә, юкка чыкмый бит ул. Язмыш кая гына ташламасын, яңа җирдә тамырланып яши бирә. Кая гына барсаң да аларны очратып була. Еллар узу белән, картлар үлеп бетә, яңа буын үсеп җитә, аның артыннан икенчесе дә өлгерә. Болары инде Касыймны ишетеп кенә белә, бәйләнеш җепләр күптән өзелгән, мәгәр нәсел җепләре өзелмәгән, кайлардадыр, аерым ояларда, нәселләре дәвам итә.

Ашыкмыйча гына киң урам буйлап атлыйбыз. Әхмәт абзый миңа татарлардан калган йортларны күрсәтеп бара:

— Менә бу Девишевлар йорты,— ди.
— Әллә Гомәр Девишиев туган йортмы? — дип сорыйм.
— Ул кадәресен белмим, әйтә алмыйм,— ди Әхмәт абзый. Тагын Акалаевлар, Байрашевлар, Ширинскийлар йортын күрсәтә. Аннары, туктый биреп, каршы яктагы ике катлы йортны күрсәтеп:
— Әнә ул, Әшраф Синяева туган йорт! — диде.
Бу йортлар барысы да бер төслерәк, барысы да ике катлы: асты кып-кызыл кирпечтән, өсте озын-таза бүрәнәләрдән. Кайчандыр гомерлеккә исәпләнеп салынганнар һәм әле дә булса нык торалар. Аларның капка-коймалары да игътибарны җәлеп итмичә калмады. Күп җирдә бит йортлар торса да, капка-койма череп, авып бетә. Монда исә капкалар бер үк стильдәге дүрт кырлы юан баганалар рәвешендә, шул ук борынгы кызыл кирпечтән, гүя йортның үзеннән дә тазарак итеп салынган. Болар инде бервакытта да череп авачак түгел... Әхмәт абзыйның әйтүенә караганда, Мәскәүнең бер өлгер яшь архитекторы килеп, күреп киткәч, «Касыйм татарларының капка-коймалары» дигән темага кандидатлык диссертациясе дә яклаган имеш! (Касыйм татарларының матди культуралары буенча Казан галимнәре тарафыннан да махсус хезмәтләр язылды.— Ред.)
Икенче бер урамнан узышлый, юлдашым яшел түбәле җыйнак кына йортны күрсәтеп: «Закир Һади йорты»,— диде. Моннан күп еллар элек язучы яшәгән йортка мин, билгеле, башкачарак, кызыксыныбрак карадым. Закир Һади — тумышы белән касыймлы түгел, ләкин Касыйм белән нык бәйләнгән кеше. Әле үткән гасырның ахырларында ул Касыймның җәдит мәдрәсәсендә укый, мөгаллим булып, якын авылларда үзе дә балалар укыта, инде бу яклардан китеп торганнан соң да, гомеренең ахырына таба, яңадан Касыймга кайта. Вафат булуы да — шушы туфракта (1933 елны). Болар барысы да аның тәрҗемәи хәленнән билгеле. Ә менә ничек, нәрсәдән үлгәнен ишеткән юк иде. Инде, сүздән сүз чыгып, Әхмәт абзыйдан Закир Һадиның утыз өченче елны Касыйм урамында ачтан егылып үлүен ишеткәч, мин ышанырга да, ышанмаска да белмичә аптырап калдым. Дөресме, чынмы бу? Әмма гомерен шушында уздырган олы кешенең сүзенә ничек ышанмаска мөмкин ди?!.
Урамнар буйлап йөрү һәм Әхмәт абзыйны тыңлау борынгы китап укыган шикеллерәк бер тәэсир калдырды миндә. Гыйбрәтләр бар икән бу калада!..
Ә икенче көнне без янә әлеге тарихи урынга — «Касыйм ханлыгы»ның калдыкларына бардык. Бу юлы монда минем өчен иң әһәмиятлесе Шаһгалидән калган «тәкияне» күрү булды (үзем генә килгәндә мин аңа нишләптер игътибар итмәгән идем). Хуш, нәрсә соң ул тәкия? Махсус эшләнгән бина эчендәге каберлек. Русчасы — «усыпальница» яки «склеп» була шикелле. Үзебезнең телдә моңа туры килгән «төрбә» сүзен беләм, мәгәр «тәкия»не беренче ишетүем. Касыйм татарларына кайдан килеп кергәндер — ачыклап булмады. Ярый, нииндирәк соң ул тәкия? Сарай калдыкларыннан түбәнрәк җирдә эре ак таштан озынча дүрт кырлы итеп салынган тимер ишекле, тәрәзәсез, тәбәнәк бер бина. Ишек башына татарча «Тәкия», русча «Текия» дип язып та куелган. Салынуы — 1555 елда. Ханнар заманыннан хәзергәчә бөтен килеш сакланып килгән тарихи истәлекле нәрсәнең берсе шушы бина да икенчесе — ак манара.
Әхмәт абзый миңа сөйли:
— Бу тәкия эчендә унбер кабер,— ди.— Барысының да ташлары бар, барсына да кем күмелгәне язылган. Тик бер генә кабернең ташы язусыз, шоп-шома, ягъни кемнеке икәне язылмаган. Ләкин мондагы халык телендә борын-борыннан ук, ул кабер — «Сөембикәнеке» дигән сүз йөри. Һәм шуңа халык ышана да иде. Әмма ни өчен аның ташы ялгызы гына язусыз куелган? Моны Шаһгали, бу кабердә кем ятканын беркем дә, беркайчан да белмәсен өчен, юри шулай эшләткән. Чөнки Сөембикә Шаһгалине хан итеп тә, ире итеп тә танымаган, үзенчә үч алмакчы булган инде касимский хан!
Бераз риваятьне дә хәтерләтә бу. Әмма моның, һичшиксез, реаль җирлеге дә бар. Казан тәхетендә утырган ханнарның бик күбесе онытылып бетсә дә, Сөембикә әнә онытылмаган, халык хәтерендә һаман сакланган. Исемен дә шушы көнгә кадәр күп кенә хатын-кызлар йөртә, революциягә чаклы чыгып килгән хатын-кыз журналы да «Сөембикә» дип атала иде. Сәбәбе? Бәлки аның язмышы фаҗигале булганга күрәдер. Тарих ни әйтә соң бу хакта?

1549 елны Сафагәрәй хан үлеп киткәч, Сөембикә ике яшьлек улы Үтәмешгәрәй белән тол кала. Казанның олы голәмәләре бишектәге баланы хан итеп игълан кылалар, ә дәүләт эшләрен башкаруны әнисенә тапшыралар (ягъни, регент итеп билгелиләр). Сөембикә акыллы, нык характерлы, гайрәтле хатын булган дип язалар элекке тарихчылар.

Бу вакыйгалардан соң бер ел да үтәргә өлгерми, Иван Грозный зур гаскәр белән Казанны алмакчы булып килә. Бик каты сугышлар башлана, Казан бирешми, Грозный чигенергә мәҗбүр була (шул чакта Сөембикә үзе, крепость өстенә менеп, гаскәр белән «кумандылык» иткән имеш!) Мәгәр берничә айдан соң Грозный күп гаскәр туплап, яңадан Казан өстенә килә. Көчләр тигез түгел, Казан никадәр каты торса да, хәл мөшкел, сугышны туктатыр өчен, ул солых сорый. Иван патша Казанны сугышып алуның җиңел булмаячагын күреп, солых төзергә риза була, ләкин бик авыр шартлар куя. Шартларның берсе — Сөембикәне улы Үтәмешгәрәй белән бергә, Мәскәү кулына тапшырырга. Казанның олы голәмәләре һәм түрәләре бу шартларны кабул итәләр... Һәм 1551 елның августында Сөембикәне баласы белән бергә зиннәтле кимәгә утыртып, Мәскәүгә алып китәләр. Казан халкы 18 ел Ханбикә булып торган бу гаҗәеп хатынны «аглый, аглый» озатып кала (Сөембикә фаҗигасен Фатих Әмирхан да үзенең «Сөембикә» исемле хикәясендә язган иде).

Ә Казанга хан кирәк. Иван Грозный боерыгы белән тәхеткә Шаһгалине китереп утырталар. (Касыйм ханын Мәскәү патшалары, гүя пешка урынына, әнә шулай күчереп йөртәләр.) Шаһгали Казан тәхетенә инде өченче тапкыр утырып карый, әмма озакка түгел. Бу юлы да ул, үзенең кара эшен эшләгәч, Казан халкының нәфрәтеннән куркып, качып китәргә мәҗбүр була.

Сөембикәне Мәскәүгә китергәч, сабый баласын, аерып алып, чукындыралар, ә үзен бераздан Шаһгалигә хатынлыкка бирәләр. Соңгы гомерен авыр хәсрәт эчендә уздырып, ул 1557 елны шушы Касыйм каласында вафат була.

Әнә шулай язылган иске тарихи китапларда. Билгеле, мин үзем тарихчы булмагач, иске китапларда язылганнарның ни дәрәҗәдә дөреслеген раслап әйтә алмыйм. Ләкин шулай да халык телендә сакланган риваятькә ышанасым килә. Чөнки татар халкы, әйткәнемчә, Казан ханнары арасыннан бердәнбер Сөембикә образын һәм аның ачы язмышын онытмыйча хәтерендә саклап тоткан. Югыйсә кайдан туар иде әлеге риваять? Димәк, «Тәкия» эчендәге язусыз таш астында яткан мәетнең Сөембикә булуы бик тә мөмкин. Әйе, фаҗигале һәм гыйбрәтле язмыш!

Бераздан без борынгы калдыклардан һәм хатирәләрдән аерылып, әкрен генә кузгалып киттек. Сүз күп булмады. Кайтышлый Әхмәт абзый шул ук мәйдандагы моннан 150 ел элек ачылган мәдрәсәнең бинасын күрсәтте. Касыйм «стилендәге» таза капканың ике ягында кызыл кирпечтән салынган берсе зуррак, берсе кечерәк ике гади генә йорт — ничектер шушы көнгә чаклы искермичә-тузмыйча матур гына торалар әле.

Әйтергә кирәк, Әхмәт абзый үзе дә Касыймның үткәне турында материаллар җыя икән. Мәйданнан кайтып, өенә кергәч, ул миңа катыргыдан эшләнгән карталар күрсәтте. Дәфтәр битеннән зуррак бу карталарда Касыйм татарларының көнкүрешләрен (әйтик, йорт-җирләрен, кием-салымнарын, ашсуларын) чагылдырган фотолар һәм шуларга кыска гына аңлатма текстлар урнаштырылган. Кызыклы һәм кирәкле эш. Тик югалмасын гына иде алар!

* * *

...Касыймда дүрт кич кунып, мин бишенче көнне кайтырга чыктым. Әхмәт абзый кияве белән үз машиналарында мине автовокзалга илтеп куйдылар. Юлым Касыймнан — Рязаньга, Рязаньнан — Мәскәүгә, Мәскәүдән Казанга иде. Әнә шулай тәмам булды минем безгә бик аз билгеле Касыймга кыска гына сәяхәтем. Үткәне нинди генә булмасын, Россия үзәгендәге ул кала да — безнең тарихыбызның бер сәхифәсе. Ә тарихның бер генә сәхифәсен дә ертып ташларга ярамый. Һәм мөмкин дә түгел, минемчә!..

*1986 ел.*



**А. В. Яковлев,**
КПССның Лаеш райкомы беренче секретаре

# КҮЛЛӘРДӘН — ИДЕЛГӘ!

Ерак-ераклардан Казанга, самолетка утырып, килеп төшсәгез, сез инде Лаеш җиренә аяк басасыз. Чөнки яңа гына салынган мәһабәт корылмалы аэропорт нәкъ безнең район мәйданыннан урын алды. Өлкән яшьтәгеләрнең кайберләре әле һаман үзалдына бәхәсләшкән кебек сөйләнә:

— Аэропорт безнең җиргә салынгач, аңа «Саламыково» кушарга иде!— диләр. Яңа аэропорт урынында кечкенә генә Саламыково авылы бар иде.— Внуково, Быково, Домодедово кебек яңгырап торыр иде!..

Бу авыл исә атамасын янындагы күлдән күчереп алган. Районыбыз күлләргә бай. Аларның кайберләре, табигатьнең кул тидерергә ярамый торган кадерле һәйкәле итеп, дәүләт тарафыннан саклана. Кара, Чиста, Архирей, Сапуголь, Мүкле, Кавал, Сокуры, Саламыково, Куян күлләре — шундый урыннар. Районыбызның төньягыннан көньягына агып, аны ике өчпочмакка бүлүче Мишә елгасы да шундый ук кадерле һәйкәлдән санала. Ул Макаровка авылы янында Камага коя. Кама исә, Атабай авылы янында, Иделгә тоташа.

Табигатенең бай булуы төбәгебезнең тарихына да эз салган, аңа күренекле шәхесләрнең, катлаулы вакыйгаларның язмышын бәйләгән. Район үзәгебез булган Лаеш поселогына кергәндә: «1557 елда нигез салынган» дигән язу күрерсез. Әмма бу белдерүдә хата бар. Чөнки рәсми тестә Иван Грозный чорында нигезләнгән дип исәпләнсә дә, бу якларда элек-электән шаулы тормыш барган. Хәтта Лаешның үзе урынында да 1481 елда ук авыл булуы билгеле.

1579 елда төбәк аша Ермак атаман узып, үзенең дружинасын тулыландырып, Себер якларын буйсындырырга юл тоткан. 1582 елда Ермакның Лаеш якларына кабат кайтуын, тагын да әлеге явына кирәкле гаскәр туплавын сөйлиләр.

1781 елда Лаеш өяз итеп белдерелә, үзенең гербын булдыра. Ә моннан бераз алдарак төбәккә Екатерина II нең килеп китүе турында да билгеле. «Әби-патша» бу сәяхәтендә Бөек Болгар биләмәләренең калдыклары белән танышып йөргән, Казан ханлыгында яшәүче халыкларның тормыш-омтылышларын аңларга теләгән, имеш. Мишә буйлап, зур көймәдә йөзеп килгән уңаеннан, ул Лаеш җирендәге Рождествено авылына якын гына тукталыш ясаган. Җирле дворяннар аны бик олылап каршылаганнар.

Шул дәверләрдә үк безнең якта Ватаныбыз культурасы күгендә балкырдай йолдызлар күренә башлый. Талантлы шагыйрь Гавриил Романович Державин (1743—1816) соңра яшь Пушкинның шигърияте алдында баш ия. Г. Р. Державин безнең Сокуры авылында туган. Шагыйрьнең әти-әниләре Егорьево авылында күмелгәннәр. Аның бабасының бабасы Иван Васильевич Державинга халык «Тугызынчы» кушаматы таккан булган. Шуңа күрә Иван Васильевич карамагындагы авылларга да Девятово исеме «ябышып» калган. Заманында шагыйрь Державинның үзенә «Әби-патша» тарафыннан бүләк ителгән авыл әле дә шул исемне йөртә: Державино. 1847 елда өяз дворяннары якташлары Гавриил Романович хөрмәтенә Державино авылында бакыр һәйкәл куйдыртталар. 1881 елның 1 мартында һәйкәл Казанга, элекке театр бинасы янына күчерелә. 1937 елда һәйкәл алына. Аның фотосурәте республика музеенда саклана.

Лаеш яклары халыкның азатлыкка якты юл салу өчен алып барган көрәшен дә яхшы хәтерли. 1774 елны, Мансурово авылы янында Каманы кичеп, Пугач яулары Нармонка, Рождествено авылларына якынлашалар, Казанга юл ачалар. Башка авылларның крестьяннары да аларга ярдәм итеп тора. Соңыннан, Екатерина II боерыгы буенча, бу кешеләр каты җәзага тартылган, авыллар «кара исемлек»кә теркәлгән...

Бу тарихи хәлләрдән соң 60 еллап вакыт узгач, 1833 елның 8 сентябрендә Лаешка мәшһүр шагыйрь Александр Сергеевич Пушкин килеп төшә. Пугачев эзләре буйлап, тарихны өйрәнеп...

Лаеш халкы декабристлар хәрәкәтенә дә зур өлеш кертә. Декабристларның җидесе — Лаеш өязеннән: В. П. Ивашев, Ф. Г. Вишневский, В. А. Дивов, А. К. Бярстеев, Ф. М. Башмаков, И. П. Жуков, Д. И. Завалишин. Бу каһарманнарның тормышы һәм көрәш юлы әле тулысынча өйрәнелмәгән. Арада Дмитрий Иринархович Завалишинның эшчәнлеге генә азмы-күпме билгеле дияргә була. Себердән әйләнеп кайткач ул Мәскәүдә яшәгән. Берничә китап авторы. Әсәрләреннән «Записки декабриста» исемлесе аерым игътибарга лаек. Бу декабристның Зинаида исемле кызы булуы, Зинаида Дмитриевна Завалишинаның күренекле революционеркага әйләнүе дә мәгълүм. Ул В. И. Ленин белән дә очрашкан. Гомеренең күп өлешен мәгариф өлкәсенә багышлап, Зинаида Дмитриевна меңнәрчә балаларга аң-белем бирә. Аның шәкертләре арасында партиябезнең күренекле эшлеклесе А. А. Андреев та бар. Зинаида Завалишина 1956 елда дөньядан кичә.

Безнең якта Ленин идеяләре өчен көрәшүчеләр байтак. Мәсәлән, Каны авылында туган Александр Догадов 17 яшьлек чагыннан революцион көрәш юлына баса, 1905 елны ук РСДРПның Казандагы оешмасына керә, өяздә Ленин «Искра»сын тарата. Соңыннан ул ВЦСПСның секретаре дәрәҗәсенә кадәр үсә. Без киләсе елда А. И. Догадовның туууына 100 ел тулуны зурлап билгеләргә әзерләнәбез.

100 еллык юбилейның икенчесен — Бакудагы 26 комиссарның берсе булган якташыбыз Иван Яковлевич Габишев туган көнне билгеләргә дә зур әзерлек бара. И. Я. Габишев — Паново авылы егете. Хәзер безнең кошчылык фабрикасы эшчеләре яши торган поселок һәм район үзәгенең бер урамы, 2 нче урта мәктәп аның исемен йөртә.

Лаеш урамнарының берсенә В. И. Ленинның энисе Мария Александровна Ульянова исеме бирелде. Бу — Мария Александровнаның 1888 елның 19—20 августларында Лаешта булуы белән бәйле. Мария Александровна кунып чыккан йорт шушы урамда әле дә исән-сау килеш саклана.

Бөек Октябрь социалистик революциясенең 70 еллыгы уңаеннан районыбызда Совет властен урнаштыру өчен җаннарын аямаган көрәшчеләрне искә алып китәсе килә: аврорачы Петр Кореев, Кышкы сарайны штурмлаучы Иван Суханов, Кронштадтка барып кергән Дмитрий Тагашев, Гражданнар сугышы каһарманнары Григорий Моисеев, бертуган Секретаревлар, Несмелов, Пигалев, Порфирий Вакатов...

1918 елның октябрендә, Ленин тәкъдиме буенча, илдәге ачлыкка һәм хәерчелеккә каршы көрәш максатыннан, 25 тәэмин итү хуҗалыгы оештырыла. Әлекке алпавыт утары булган Среднее Девятово хуҗалыгы бәрәңге һәм яшелчә үстерә башлый. Соңыннан ул — Октябрьнең 25 еллыгы исемендәге совхоз булды. Совхозның беренче директоры — Мәскәүдән килгән эшче, ВКП(б) члены Иван Журавлев. Ул шактый гайрәтле җитәкче булып чыга. Хуҗалыкны ныгыта, дуңгыз симертүне дә юлга сала.

1919 елның 16—17 июльләрендә Лаеш пристанендә «Красная звезда» агитпароходы тукталыш ясый. Аңа утырып килгән Надежда Константиновна Крупская күпсанлы лаешлылар белән очраша, әңгәмәләр кора. Бу тарихи урыннарга хәзер мемориаль такталар эленгән. Өязнең ул чактагы җитәкчеләре, партиянең өяз комитеты председателе Степан Тарабрин, Башкарма комитет председателе Николай Суханов Ленин эшенә тугрылыклы коммунистлар булган.

1925 елда Лаеш яшьләре Татарстанда беренче комсомоллар колхозы төзиләр. Исеме — «Ильич васыятьләре». Коммунаның алты кешедән торган партия ячейкасын — Сидор Шлыков, унике кешелек комсомол ячейкасын Егор Шлыков җитәкли. Соңра бу коммуна «Ленин юлы» колхозына кушыла (хәзер — совхоз). Шул рәвешле, төбәктә хуҗалыкларны күмәкләштерү башланып китә.

Утызынчы елларда крестьяннарның рухын биләп алган күтәренкелек акиятләргә тиң. 1935 елда безнең Столбище МТСы республикада беренче урынны яулап ала. Мондагы һәр трактор иң зур күрсәткечне бирә — сөрүгә күчереп исәпләгәндә, 1560 гектар җир эшкәртә. Шул елның 14 декабрендә тракторчылардан П. Гусев, Г. Чурунин һәм В. Гусев бертеклеләрдән зур уңыш алучыларның Бөтенсоюз киңәшмәсенә катнашалар. Петр Гусев хәтта чыгыш та ясый. Аңа шунда ук Ленин ордены тапшыралар. Соңра ул МТСның директоры, аннары «Столбищенский» совхозы директоры була, ТАССР Верховный Советына депутат итеп сайлана. Петр Павлович әле дә сау-сәламәт, Столбищеда яши. Хәзер безнең район механизаторлары «Гусев кубогы өчен» ярыш оештыралар. Мондый бүләк тракторны яхшы һәм ни бар мөмкинлегенә эшләтә алган батырга бирелә.

1937 елның 12 декабрендә уздырылган беренче Сайлаулар уңаеннан Лаешка СССР Верховный Советы депутатлыгына кандидат итеп күрсәтелгән Отто Юльевич Шмидт килә. Күренекле галим, сайлаучылар белән очрашканда, мәшһүр «Челюскин» бозваткычы

һәм аның каһарманнары турында сөйли, совет фәненең үсеш юлларын тасвирлап күрсәтә.

Шулай итеп, күңелле генә яшәгәндә, киләчәккә матур-матур планнар корганда дәһшәтле 41 нче ел килеп җитә. Лаешлыларның йөзләрчә-меңнәрчә уллары һәм кызлары Ватанны дошманнан саклап калуга күтәрелә. Сугышка киткәннәрнең байтагы яу кырында ятып кала. Ике якташыбыз — Иван Матвеев һәм Александр Сергеев Советлар Союзы Герое булдылар. Кабан авылында яшәүче Петр Наумов — Дан орденының тулы кавалеры. Берлинны алуда катнашкан егетебез Александр Пылаев Ленин ордены белән бүләкләнгән.

Сугыш елларында Лаеш районы крестьяннары да солдатларча тугры хезмәт итте. Председателе Евдокия Чапчина булган «Красное знамя» колхозы членнары «Татарстан колхозчысы» исемле танк колоннасы оештыру өчен акча җыя башлыйлар. Евдокия үзе саклык кассасындагы бөтен акчасын Дәүләт банкына тапшыра. Лаешлылар колхозның бу фидакарьлеген бердәм күтәреп алалар.

«Красный земледелец» колхозы тракторчысы, колхозчыларның 1936 елгы II съездында катнашкан, Татарстандагы игенче кызлардан беренче буларак, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән Надежда Кореева «Кызлар, тракторга утырыгыз!» дигән өндәмә күтәреп чыга. Аңа дистәләгән кызлар кушыла.

Менә кырык елдан артык инде без тынычлыкта яшибез. Шушы аз гына вакыт арасында Лаеш яклары тагын да ныгып, матураеп өлгерде. Хәзерге мәйданыбыз 2173 квадрат километр тәшкил итә, 74 авыл һәм поселокта утыз сигез меңгә якын кеше яши. Милли яктан, халкыбызның 70 проценты — руслар, калганы — татарлар.

Районда балык, крахмал, сөт заводлары, урман хуҗалыгы, юл төзү идарәсе, ипи салу комбинаты, тегү фабрикасы, техника төзәтү предприятиесе, агропромхимия кебек күпсанлы оешмалар бар.

Лаеш — авыл хуҗалыгы районы. 21 хуҗалыкның күбрәгендә яшелчә, сөт, кош ите җитештерелә. Терлекләр саны да, алардан продукт алу да, гектардан җыела торган бөртекледәрнең күләме дә арта бара. Бөек Октябрь социалистик революциясенең 70 еллыгы хөрмәтенә уңышларыбызны тагын да тәгәлләндерергә ниятлибез. Әйтик, «Юбилейная» исемле кошчылык фабрикасы олы бәйрәм көненә бишьеллыкның ике еллык йөкләмәсен тутырырга тырышып эшли. Нәкъ менә шушы фидакарь коллективның уңганлыгы нәтиҗәсендә Казан каласы кешеләре диетик йомырка белән тулысынча тәэмин ителәләр.

Казан дигәннән, безнең район, башлыча, Казан хезмәт ияләренең табыны мул булсын өчен тырыша. Нармонкадан, мәсәлән, башкалага ел саен 20 мең тонна кишер, кәбестә, чөгендер, кызыл шалкан кебек яшелчәләр озатыла. Тиздән монда яшел борчак әзерләү дә җайга салыначак. Бу совхозыбызны инде ун елдан артык экономика фәннәре кандидаты коммунист Гыйлфан Вафин җитәкли. Совхоз дәүләткә, яшелчәдән тыш, сөт, сыер һәм сарык ите дә сата. Хуҗалыкны ныклы нигезгә бастырганы өчен, Гыйлфан Гатинович Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.

Столбищедагы тәҗрибә производство хуҗалыгы белән җитәкчелек итүче, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты, Ленин ордены кавалеры Усман Вәлиуллин КПССның XXVI съездына делегат булып барды. Бу хуҗалык, районда гына түгел, бөтен республика күләмендә оештырыла торган күркәм яңалыкларны башлап җибәрә. Терлекчелектә тоташ агым белән эшләү, бозауларны салкында тотып симертү кебек алымнар монда ачылды. Хуҗалыкның төп вазифасы исә — югары сыйфатлы, элита орлыклар җитештерү.

Районның кошчылары турында сөйли китсәң, сүз тагын да куерачак. «Атабай» һәм «Комсомольский» совхозындагы үрдәк, күркә үрчетү осталары дәүләткә ел саен 500 тонна кош ите саталар.

Матюшинода исә затлы тире җитештерүчеләребез бар. Аларның даны дөнья базарын шаулата. Әүвәл кеш тиресе генә җитештерелә иде, хәзер, мода таләбенә буйсынып, көмешсыман төстәге төлке дә үрчетә башладылар. Яңа ферма өр-яңа интенсив технологиягә көйләнгән.

Югарыда телгә алынган осталарга кушып савымчы коммунистыбыз Валерий Шаламовның уңганлыгын да әйтергә мөмкин. Ул узган ел һәр сыердан 4700 литр сөт сауды. Валентина Гурьянова, Нина Маркелова да аннан әллә ни калышмыйлар.

Яхшы эшләребезнең башында коммунистлар бара. Аларның кайберләре — Бөек Октябрь өчен кан койган беренче буын коммунистларның оныклары яки балалары. Күбесенең әтиләре Бөек Ватан сугышында батырларча сугышкан. Илебез үткән авыр юл, катлаулы тарих бүгенге көннең матурлыгын тоярга, тыныч хезмәтнең, мул тормышның кадерен белергә өйрәтә. Районыбыз кешеләренең тормышын-көнкүрешен, хезмәтен күздән кичерсәң, шушы хакыйкатьне аеруча тирәннән аңларга була.

# ЯШЬЛӘР БӘХӘСЛӘШӘ

## ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР — Р. ӘХМӘТҖАНОВНЫҢ «БИШТАШ» ПОЭМАСЫ ТУРЫНДА

*Журналыбызның быелгы 4 нче санында шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның «Бишташ» исемле поэмасы басылган иде. Поэма киң җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итте, аерым алганда, редакциягә әсәр хакында күп санлы хатлар килде. Шулай ук поэма республика газеталары битләрендә дә уңай бәя алды. Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Марс Шабаев — «Социалистик Татарстан» газетасында, яшь шагыйрь Ркаил Зәйдуллин «Татарстан яшьләре» газетасында үз фикерләрен язып чыктылар.*

*«Бишташ» поэмасы «Казан утлары» журналы каршында эшләп килүче яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәгендә дә тикшерелде. Түбәндә яшьләргә хас кайнарлык белән үткән шул сөйләшүдә катнашучыларга сүз бирәбез.*

### Фәрит Бәширов:

«Бишташ» поэмасы хакында сөйләшүләр, бәхәсләшүләр күп булыр әле. Әсәр турында төрлечә фикер йөртүчеләр дә булыр. Әмма бер нәрсә бәхәссез: поэма укыла! Әсәрнең «Поэмага чакыру» өлеше үк җитди сөйләшүгә хәзерли һәм «Балачакка барып киләм, сүндереп мин утларымны...» дигән юллар белән укучыны үзенә алып кереп китә.

Менә «Беренче таш»... Кешелекнең балачагы... Тарих һәм хәтер. Бер-беренә аерылгысыз береккән әнә шул төшенчәләргә мөнәсәбәте белән ачыла кеше. Таш белән кардәшенә орган борынгы адәмнән йолдыз биеклегеннән ут яудыручы бүгенге көн варварларына кадәрге юл — бу да хәтердә, вәхшиләр кабызган утның киләчәк өстенә төшкән канлы күләгәсе — бу да чынбарлык. Алар халык йөрәгенә керәчәк киләчәккә дәгъва кылган бер вакытта кешелеккә эндәшеп, гамьсезлектән котылырга, «үлемнәрне үтерергә» чакырган юлларны тыныч кына укып булмый. Гамьсезлек — җинаять. Бүгенге битарафлык иртәгә төзәтеп булмаслык авыр хата булып әверелергә мөмкин. Ул чагында инде соң булачак. Ул чагында инде «барыбыз да Галәм бәгыреннән мордар китәчәкбез ләбаса!» Шагыйрь хәвефләнә, шагыйрь уйлана, шагыйрь кисәтә. Поэманың көче дә шунда, әсәрдәге аерым детальләр, элементлар гомумиләштерелгән мәгънәгә ия. Гомумкешелек борчулары, уйланулары үткәнне һәм хәзергене бергә бәйләүче чара булып, тарих һәм бүгенге көнне бер максатка, бер идеягә юнәлдерүче адым булып хезмәт итә.

*Ни булса да,*
*Җирне минем хәлгә*
*Калдырмагыз,— дидер таш агач,—*
*Дар агачы кебек торам, менә,*
*Сандугачлар килеп кунмагач...*

Җансыз үткәннең бүгенгегә эндәшүе, киләчәкне искәртүе — кешелекне аң булырга, ваемсызлыгыннан йолкып алып уйланырга чакырган шигъри ораннар әсәрнең кыйммәтен билгелиләр дә инде.

Кабатлап әйтәм — поэма укыла. Аерым «ташларда» фикерне кирәксезгә куплетларга сузу күренешләренә күңел тырналса да, матур, оста итеп үрелгән шигъри тезмаләрне күреп сөенәсең дә. Уйлана-уйлана, шагыйрь белән бәхәсләшә-бәхәсләшә, ташлар полифониясен тыңлыйсың.

«Бишташ» — темасы ягыннан да, формасы буенча да соңгы елларда дөнья күргән поэмалардан нык аерыла. Егет белән кызның аһ-ваһына корылган баллы «поэмалар» туйдырганнар иде инде. Уйланулы, кешелек, яшәеш хакында борчылу белән сугарылган

поэмалар, килешик, соңгы вакытта аз, бик аз иҗат ителделәр. Аның каравы, арзанлы мәхәббәт фәлсәфәсе гөмбә кебек үрчеде, су буе сузылган шигырь юллары аша укучыны «кинәндерде».

Рәшит Әхмәтҗановның бу поэмасын тынчу һавада исеп куйган саф җил белән чагыштырып булыр иде. Һәрхәлдә шулай булырына ышанасы килә.

Поэма белән сокланырга да, бәхәсләшергә дә, ахыр чиктә килешмәскә дә мөмкиндер. Әмма битарафлар гына булмаска тиеш. Ә фикерне үстерерлек, уйланырлык, яклап та, инкяр итеп тә дәлилләр китерерлек моментлар поэмада бар. Бәхәсләшик!

## Фәүзия Бәйрәмова:

Рәшит Әхмәтҗанов иҗатына мин, гомумән, аерым бер хөрмәт, ярату белән карыйм. Көтелмәгән табышлары, хис, фикер байлыгы, хикмәтле сүзе белән миңа көчле тәэсир итә аның шигырьләре. Ул — шигырь остасы, кыска сүз остасы. Ә менә «Бишташ» поэмасын укып чыккач, мин каршылыклы фикердә калдым. Шигырьләрендә яшен ташы кебек яндырып, балкытып ала белгән Рәшит Әхмәтҗанов поэмасында шактый таркалып, эзлеклелеген югалткан. Дөрес, поэмада ялтырап-ялтырап киткән урыннар бар, хәтта күп тә. Ләкин алар аерым-аерым гына ялтырыйлар, зур бер фикер, образ тудыруда ярдәм итмиләр, киресенчә, фикерне читкә тарталар — шул «хикмәтле табышлар» белән мавыгуга этәрәләр.

Иң беренче — бу поэмада Таш нәрсә символы? Яхшылыкмы, явызлыкмы? Бу — ташның нәрсәгә яравы турындагы мәгълүматлы бер язмамы яки Ташны образ дәрәҗәсенә күтәрә алырлык зур фәлсәфи әсәрме? Кызганычка каршы, поэма күбрәк беренчесенә тарта. Символ буларак ташның зур мәгънәсе автор алдында билгеле, ачык түгел. Шуңа күрә поэмадагы таш — мәгълүмат иясе генә, ул мәгънә иясе була алмаган.

Поэманың исеме — «Бишташ», ләкин әсәрнең эчендә — Биш таш. Монда Әлмәт ташы да бар, кабер ташы да, ашта пешкән таш та, башка төшкән таш та. «Бишташ», ягъни, тормышның, язмышның мәгълүм уенында катнашучы Биш Таш кына юк. Мин, нигәдер «Бишташ» дигән, кырыс тарих чөеп, атып җибәргән Биш таш булырлык биш шагыйрьбез язмышын күргән идем — Кол Гали, Тукай, Такташ, Җәлил, Туфан. Уен — «Бишташ» уены, тик таш урынына — шагыйрь язмышы, шагыйрь башы... Ул вакытта поэмага куйган эпиграф та акланыр иде: «Таш, батмыйча, су өстендә йөзеп йөрде». Аттылар, башларын кистеләр, төрмәләргә яптылар — таш итеп тарих дәрьясы төбенә атмакчы булдылар — ә алар, барыбер әнә, өскә күтәреләләр, яшиләр, мәңге яшәячәкләр...

Тагы ни? Шагыйрьнең җан тетрәнүе ике юллык хикмәтле табышларына гына җитә, поэманың (һәм тормышның) буеннан-буена барырлык зур, үзәк өзәрлек борчылуы, хәвефе юк. Шуңа күрә — поза күп, сүздә кан-яшь күп, вак үпкә-рәнҗеш сизелә. Халык хакында поэма белән зур сүз әйтергә җыенганда, Тукай, Туфаннарныкы кебек язмыш та кирәктер шул. Кеше сыкранганын карап торып сыкрану — бер нәрсә, үзең шул утларның уртасында булып җыр калдыра алу — икенче нәрсә.

Соңгы сүзем шул — минем яраткан шагыйрем Рәшит Әхмәтҗанов, ни әйтсәң дә, шигырь шагыйре ахры. Ә поэма? Поэма да язарга була, әгәр язмыйча калырга ярамый торган зур сүзең, шул зур сүзне күтәрә алырлык фәлсәфәң булганда. Таш артында торган кешеләр язмышы булганда. Хәзергә әле бары тик — таш, таш, таш кына...

## Әхмәт Сәхапов:

...Кешенең иҗаты аның шәхесеннән аерылмый диләр. Белмим, ни дәрәҗәдә хактыр бу сүз, әмма аны шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов хакында әйтсәләр, ике дә уйлап тормыйча, шулай дияр идем. Чөнки ул — тормышта һәм иҗатында гаҗәеп үзенчәлекле кеше. Бүген без тикшерә торган поэмасында ул үзе турында болай ди:

*Җимереп тә бармыйм,*
*җиңелеп тә,*
*Җиңел узмыйм чорны җәй табып.*
*Туры атлыйм. Җирләр тетрәгәндә,*
*Китсәм — китәм бераз чайкалып.*

Шагыйрь үз сүзләре белән әйткәндә, «Җирләр тетрәгәндә, бераз чайкалып китсә дә», шигъри кыйбласының ныклыгын яңа поэмасында калку итеп күрсәтә алды.

Талантлы шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов поэмасының кимчелекле якларын табу минем максат түгел. Драматург Бернард Шоуның: «Әгәр сез кешене нәрсәгә булса да өйрәтергә маташсагыз, ул беркайчан да аңа өйрәнмәячәк» дигән сүзләрен күңелдә нык бикләп куйганга һәм «Бишташ» әсәрен камилләштерергә тәкъдим итүчеләр минннән башка да булыр дип ышанганга күрә, шигърият сөюче меңнәрчә укучының гади бер вәкиле буларак кына, поэманы укудан туган кайбер соклануларым белән уртаклашып китмәкче булам.

Иң башта шуны әйтергә кирәк: поэма җыйнак, камил композициягә корылган. Калыбы бөтен һәм ул эпик киңлеккә, фәлсәфи тирәнлеккә омтылган әсәрнең «аягына» тышау салмый. Шагыйрьнең фикерләү рәвеше шигъри бизәкләр белән нәфис үрелеп бара. Төгәл ритмик буыннар, поэмада сурәтләнгән чорның йөрәк тибешен тоярга булышучы пульс сыман, күңелгә һәрдаим тәэсир итеп тора: тормышны, табигатьне, тереклекне сау-сәламәт килеш киләчәк буыннарга илтеп җиткерик! Адәм балаларын йомшак юрган урынына таш ябынып йокларга мәҗбүр итмик! Поэма тукымасыннан саркылып чыккан әлеге өн-аваз «үзләрен тарих кисәге итеп тойган явыз Кисекбашлар»ның әле дә тереклек тамырына ялганырга омтылуларын кисәтеп кенә калмый, безне шуларның кайбер билгеләре чагылган усал гамәлләр кылудан да тыелып калырга чакыра... Җанын үз халкы өчен фида кылган Кол Галине рухи ориентир өлгесе дип тәкъдим итә шагыйрь.

Нигездә традицион шигъри калыпта иҗат иткән һәм кайчак аерым битәрләүләргә дә дучар булган шагыйрь «Бишташ» поэмасы белән эчке мөмкинлекләренең зурлыгын күрсәтте, «дары мичкәсендә дарының шактый булуын» бик матур итеп дәлилләде. Тирән ышануымча, фәлсәфи гомумиләштерүләргә омтылуы, фикри-хисле җегәре һәм гражданлык накалының зурлыгы белән поэма шигъриятебезнең зур казанышы булып саналырлык югарылыкта тора.

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов хәзер инде яуланган шушы иҗади биеклектән бер адым да артка чигенә алмый. Ул яңадан-яңа иҗат үрләре яуларга тиеш. Күп санлы укучылары аңардан киң колачлы, зур күләмле шигъри әсәрләр көтә!

## Газинур Моратов:

Рәшит Әхмәтҗанов — шигъри сүзнең тәмен, аһәңен үтә дә нечкә тоемлап иҗат итүче шагыйрьләрнең берсе. Сурәт-образлары халыкчан, күп шигырьләрендәге строфадүртьюллыклары тәмамланган аерым әсәр буларак кабул ителә. Нәкъ халык җырларындагыча! Хәтта строфаларның урыннарын алыштырган тәкъдирдә дә мәгънәгә әллә ни зур хилафлык килмәс шикелле. Ләкин шагыйрьне әлеге дә баягы логикасызлыкта гаепләргә ашыкмыйк. Шигырьнең үз мантыйгы. Шигырьдә ике икең биш була... Юкса «Бишташ» поэмасының иң беренче юлына ук («Бер елмайдым, биш моңайдым») мантыйгы юк дип мөһер сугарга мөмкин. Ягъни мәсәлән, ни өчен әле шагыйрь бер генә елмайган да биш моңайган соң? Әллә соң ничә мәртәбә елмайганын санап барганмы? Кызганычка каршы, поэзия әсәрләренә шушы рәвешле бәя бирү очраклары да булгалый әле.

Рәшит Әхмәтҗановның шигъри фикерләү үзенчәлеген исәпкә алмаганда, әдәбият гыйлемендәге әзер кагыйдә-кануннарга гына таянып эш йөрткәндә, «Бишташ» поэмасына да таш атып була торгандыр, билгеле. Ләкин онытмыйк:

*Тик шагыйрьләр яклаганга гына*
*Җирдә исән калдык, күрәсең.*

Бу юллар — «Бишташ»тан. Мәкальгә, әйтемгә тартым юллар. Андый юлларны поэмадан күпләп китерергә мөмкин. «Бишташ» канатлы сүз-гыйбарәләргә ифрат бай. Менә аларның кайберләре: «Бәхетләр җиңә килгәнгә, Тәхетләр җимерелгән», «Әйдә, таш, безнең кулга күч: Үлемгә бәрсәң генә — Сөрмә була алачаксың Шагыйрьләр каләменә», «Җилләргә булсаң тамыр, Алар да илдә калыр», «...«Туган тел»гә кемнәр ташлана,— Алар өчен Җирдә мәсхәрәле Җиңелүләр шуннан башлана»...

Миңа иң әүвәле әнә шул канатлы юллар кадерле. Аларсыз шагыйрь дә, поэзия дә була алмый. Ә канатлы сүзләр, мәгълүм булганча, парадокска нигезләнә. Иҗат — парадокс дигән тәгъбир Рәшит Әхмәтҗанов әсәрләренә аерата туры килеп тора. Шул җәһәттән «Бишташ» поэмасына да. Әйе, «Бишташ»— парадоксаль поэма. Әсәр сюжетлы вакыйгага түгел, ә бәлки хикмәтле сүз әйтүгә корылган. Ә хикмәтле сүзне бары тик чын шагыйрьләр генә әйтә ала.

## Лэбиб Лерон:

«Таш белән бәргәнгә — аш белән бәр».— дип өйрәттеләр безгә. Шулай эшләдек тә: таш белән бәрделәр, ә без аш белән бәрдек. Һәм җан авыртуын сиздермәскә тырышып елмайдык. Ә бактың исә, гел алай гына булмый икән. Дөнья бу. Үзгәреп тора. Түземлекнең дә чиге була икән...

*...Таш белән бәр — әгәр тисәләр.*
*Аш белән күп бәрдек,*
*Ә барыбер*
*Тамырыңнан сине кисәләр...*

Никадәр тирәнлек, никадәр мәгънә ята бу юлларның нигезендә!..

*Андыйларга мин тау белән бәрдем...*

Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның «Бишташ»ын укыган чакта иң элек менә әнә шул юллар үзенә бөтереп алды. Уйга бирелдерөп, укуны дәвам иттермичә, «тотып» торды: поэманы яңабаштан укый башладым...

Һәм аңладым: имәндә икән — чикләвек!
Тәэсирләр. Тәэсирләр...

Соңгы вакытларда матбугатта дөнья күргән тыгыз, җегәрле, һәр сүзе күңелне кузгата торган искиткеч дүртьюллыклары (әйтер идем, кайбер поэмалар белән тиңләшерлек дүртьюллыклары) белән үз шигъриятенә карата чиксез мәхәббәт уяткан Рәшит Әхмәтҗановның иртәме-соңмы тирән эчтәлекле, уйландырырлык, әдәби җәмәгатьчелекне кузгатырлык поэма язасына ышанган идем.

Юраганым юш килде. Менә, ниһаять, яңа поэма — «Бишташ» безнең алда.

Шагыйрь поэманы бүген уйлап, бүген генә язмаган, ә бәлки күптәннән әзерләнгән. «Бишташ» эскизларын мин шагыйрьнең «Гомер чишмәсе» (1976) һәм «Җан яктысы» (1980) китапларында урын алган кайбер кызыклы шигырьләрендә очраттым.

Искә төшереп үтик:

*Уалып беткәнче ташларны*
*Учымда кысамын... ташлар күп.*
«Төн».
*Ташны каты димим,*
*Әллә инде*
*Башка катылыклар күп күргәнгә...*
«Сине уйлыймын да».
*Таш белән бәрдем мин, таш белән,*
*Баш белән бәрдем мин үлемгә!*
«Китапны актарсаң».

«Бишташ»ны мин һич икеләнүсез автобиографик поэма-уйлану дип атар идем. Бу шулай да.

*Бу таш... болгар бабам торган йортның*
*Нигезеннән купкан, күрәсең.*
*Мин абындым аңа.*
*Телсез кинәт*
*Телгә килде:*
*— Нигә тибәсең?!*

Бу — борынгы бабаларыбыз, тарихыбыз турында уйлану. «Мин абындым аңа». Йөрәкләрне тетрәтеп алган шушы юл безне дә үткәннәргә алып китә. Ә бит юкса еш кына без дә а б ы н а б ы з, тик н ә р с ә г ә абынуыбызны гына искәрмичәрәк калабыз. Ә шагыйрь менә искәргән...

*Күзе бар күк явыз Кисекбашның —*
*Кол Галине әзли...*

Тагын икенче бер урында:

*Минем үз тарихым: Туфан өч көн*
*Ташчы булып бездә эшләде.*

Болар — шагыйрьләр турында уйлану. Уйлануларга Ак Кала — Әлмәт килеп керә. Әлмәт — шагыйрьнең яшьлек каласы. Бу каланы төзүдә ул үзе катнашкан. Миңа калса, шагыйрь Әлмәттәге яңа йортларга нигез салган чакта әлеге поэмасына да нигез салган... Атаклы төзүче Рәшит Саттаров әйткән сүзләр дә поэмага әйбәт кенә кереп киткән. Аның сүзләрен яхшы аңлаган шагыйрь:

*Андыйларга мин тау белән бәрдем:*
*Йортлар салдым — белдем китәсен!*
*Табан астындагы җирдән кояш*
*Хет бер гөлне күккә күтәрсен.*

Юк, мәкальләр искермиләр икән. Алар яңа яклары белән ачыла гына бара икән. Шагыйрьләр шикелле.

## Фәрит Яхин:

Кайсы гына жанрны алмыйк, алар тотрыклы әдәби формалардан исәпләнәләр. Әмма бу әле формада яңалык, үзгәрешләр булмый дигән сүз түгел. Әдәби форма эчтәлек үзгәреше тәэсирендә әкренләп сыйфат күчешен үтә. Шуңа күрә яңача язылган әсәрне, әйтик поэманы, поэма түгел дип, бу жанр таләбенә туры килми дип билгеләргә ашыкмыйк әле. Форма эзләнүләре — безнең әдәбият өчен, аның үсеше өчен иң кирәкле шартларның берсе. Хикмәт шунда, язучылар тормышны һәрьяклап яктырту өчен хезмәт итүче формаларны табуга таба омтылырга тиешләр. Мин Рәшит Әхмәтҗановның «Бишташ» поэмасын шушындый эзләнүләрнең нәтиҗәсе (нәтиҗәнең дәрәҗәсе хакында сүз бармый!) дип карар идем.

Әсәр аерым шигъри буыннардан торган чылбырны хәтерләтә. Билгеле, аны гади тезмә дип кенә карау ялгыш булыр иде. Һәр шигъри буын идея-эстетик нагрузка йөрткәндә генә моңа ирешергә мөмкин. Ә биредә аларның чагыштырмача мөстәкыйльлеге эчтәлекне тирәнәйтергә һәм төп идеяне киңрәк аңларга ярдәм итә, буыннар буларак үзара бәйләнештә килүләре поэманың бөтенлеген тәэмин итә.

Димәк, иң беренче чиратта «Бишташ» поэмасын авторның озак һәм катлаулы эзләнүләренең нәтиҗәсе буларак кабул итәргә кирәк. Шуңа күрә, әсәрнең структурасын өйрәнми торып, аның эчтәлеген, төп фикер сызыгын тотып алу һәм төшенү кыен булачак.

Әсәр «Поэмага чакыру» белән башланып китә. Шушы өлештә «таш» фәлсәфәсенә оеткы салына һәм аның төп асылы билгеләнә: ул — күңелгә җыелып килгән ташлар. Бу шигъри күчешләр, параллельләр буларак ачыкланып, әсәрнең эчтәлеген һәм тәэсир көчен арттырып җибәрә, дөнья һәм кеше арасындагы гармоник бәйләнешне бирү өчен хезмәт итә. Шагыйрь, туктаусыз күчешләр ясап, таш образына аныклык кертә һәм аның эчтәлеген билгели: таштан оя кору! Тормыш авырлыгын күргән лирик геройның яшәү өчен көрәше һәм шуның белән бәхетле булуы төп шигъри фәлсәфә буларак безнең алга килеп баса:

*Авырлыгын күтәргәнгә*
*Дөнья безне аңлады.*

Әмма болар поэманың кереш өлеше генә. Алга таба әсәрнең төп асылы булган «Бишташ»ның төп эчтәлеге ачыла башлый. Аерым-аерым биш таш. Беренчесе — тарих ташы, тарихи таш.

*Бу таш... болгар бабам торган йортның*
*Нигезеннән купкан, күрәсең.*

Алга таба «тарихи ташның» фәлсәфәсе бөтенләй башка юнәлештә үзгәреп китә. Тарихи таш теге яки бу халыкның киләчәккә таба барган юлын аңлатучы, кешеләрнең әхлагын таләп итүче таш кына түгел, бәлки, киресенчә, үз эченә мәкер җыйган үтерүче таш та булуы мөмкин, юкса. Шушы, бөтенләй башка эчтәлектәге ташның килеп керүе бөтен бер шигъри күзаллауны җимереп ташлый һәм тарихның бөеклеге алдында горурлану белән бергә, аның дәһшәтле яклары өчен оят тойгысын уята. Бу — буыннар алдында җаваплылык тойгысы! Һәм ул — үлемгә каршы күтәрелергә тиешле җаваплылык тойгысы!

*Ә кулдагы ташың... телсез калган*
*Иң борынгы матдә... син — телле!*
*Син — йөрәкле! Үлемнәрне үтер*
*Алып бабаларың шикелле.*

«Икенче таш»— залим кешенең каберенә куелган таш. Бу инде үтерүче таш кына түгел, бәлки үз кулында «үлем ташы» тоткан залимга куелган кара таш.

Поэманың бу бүлегендә бирелгән Кол Гали һәм Залим патша каршылыгы, Кол Галинең утта яндырылуы гипотеза буларак кына кулланылса да тарихи шәхесне тарихи дөреслек принцибына нигезләнеп, образ буларак ачуга бераз комачаулый. Тарихны азмы-күпме күзаллаган кеше моны кабул да итми. Шуңа күрә бу өлештә автор Кол Гали шәхесен күрсәтмичә генә фәлсәфә корган булса уңышлырак булыр иде. Ә бит, юкса шигъри фәлсәфә дә бар бу өлештә. Ул бигрәк тә атом бомбасы өчен коелган шахта — саркофаг — караташ параллелендә ныграк һәм эчтәлеклерәк булып ачылып китә. Лирик герой соңгы чиктә бу кара ташны, залим башы итеп тасвирлаган ташны җимереп ата.

*Җиргә бәрдем: чәчелделәр таштаң*
*Гасырлар һәм еллар...*

«Өченче таш» белән «Дүртенче таш» бер-берсенә бәйләнешле, «Беренче» белән «Икенче» төсле бер-берсенең эчтәлекләрен аңлатучы һәм тулыландыручы ташлар.

«Өченче таш»— төзелеш ташы. Бу бүлек авторның шәхси истәлекләренә нигезләнгән һәм кешеләр арасындагы яхшы мөнәсәбәтне белдерүче җылы таш.

Минә ташчы оста өйрәнчегенә эш тәртибен аңлата. Әмма аның ул өйрәтүләре үгеткә дә, таләп итүгә дә корылмаган. Ул укучысын җылы мөнәсәбәте белән өйрәтә. Останың хәтта хәйләкәр елмаюы да ничектер олы күңелле, һәр җирдә очрый торган татар абзыйларын хәтерләтә: нинди киң күңелле алар!

*Хәйләкәр ул абый,— ташлар аша*
*Минем ятим җанны иркәли.*

Таш аша җанны иркәләү — татар шигъриятенең иң үзенчәлекле образ системасына корылган бу юллар Тукайдан ук килә. Тукай шигырендә ятим бала өчен иң җылы таш — әнисенең кабере ташы булса, Р. Әхмәтҗановта ул башкачарак: аның поэмасындагы лирик геройга сыеныр урын бар — яхшы күңелле осталарның үз итүе! Алар ятим җаннарны иркәли беләләр! Шуңа күрә аларның кулында төзелеш ташы.

«Дүртенче таш»— шагыйрь каләмендәге сөрмә ташы. Бу чагыштыру шагыйрь каләменең нечкә булырга тиешлеген дә, кызларның сөрмә тарткан күз карашларын да укучының күңеленә җиткерә. Мөгаен, бу чагыштыру поэманың иң уңышлы өлешләреннән берседер.

Шушы ук бүлеккә Х. Туфанның да килеп керүе табигый һәм, әйтергә кирәк, Туфан образын туры сөйләм аша, Туфанның «үз» сүзләре аша чагылдыру авторның уңышын һәм осталыгын күрсәтеп тора. Хәтта: «Моны болай итеп Хәсән Туфан гына әйтә ала бит!»— дип куясың.

*Җидегәннәргә менеп җитәрсез бит*
*Таш өстенә болай таш өеп.*

Һәм менә ташчыларның үз хакыйкате, аларның хезмәтенә Туфан дәрт бирә, хезмәт дәрте. Ә автор шушы халәтне сурәтләп тә биргән:

*Минем үз тарихым: Туфан өч көн*
*Ташчы булып бездә эшләде.*

Бу ике бүлектә дә төп сурәт ноктасы — җан җылысы. Ул җылы ташларда да, ул җылы Туфанда да, ул җылы карт ташчы елмаюында да.

«Бишенче таш»— тәрәзәдән очып кергән таш. Әлеге таш мәкер белән керсә дә, алга таба бу эчтәлеген югалта һәм яңа эчтәлеккә әверелә. Ул лирик геройның бүгенгегә һәм киләчәккә мөнәсәбәтен белдерергә ярдәм итә һәм автор өчен поэманың соңгы ноктасын куярга кирәкле образ булып әверелә. Бу бүлектән соң килгән тәмамлау — «Поэма белән саубуллашу» шушы деталь ярдәмендә алгы бүлекләргә ярашып китә, соңгы «нокта» фәлсәфи төс ала.

Поэманың төп схематик сызыклары менә шушылардан гыйбарәт. Әмма әсәрнең барлык нечкәлекләрен берьюлы гына тикшереп бетерү мөмкин түгел. Бу инде авторның кайбер кимчелекләрен күрсәтү, аңлатып бирүне дә авырайта.

Иң беренче күзгә ташланганы шул: кайвакыт поэмадагы чагыштырулар, параллель күчешләр шактый куерып китә һәм күңел барысын да берьюлы кабул итеп бетерә алмый.

Аннан соң: Әлмәт шәһәренең, нефть ягының «ташка-таш бәреп каршы алуы» да бераз сәеррәк яңгырый. Бары тик «таш» фәлсәфәсе өчен генә гафу итеә ала.

Гомумән, шуны әйтергә мөмкин: форма новаторлыгыннан, эчтәлек тирәнлегеннән чыгып фикер йөрткәндә — бу поэманы авторның уңышы дип санарга кирәк.

библиография

# БИШЕНЧЕ ЕЛНЫ УЯНДЫК ТАҢ БЕЛӘН...

Бишенче ел революциясе татар халкының миллəт булып формалашуын тизлəтте, хəтта бу процессны тəмамлады дип əйтсəк тə ялгышмабыз дип уйлыйм. Россиядəге беренче буржуаз-демократик революция һəр сыйныфны сыйныф итеп җитлектерде, аларның бер-берсенə булган мөнəсəбəтен ачыклады. Ул татарда да буржуа һəм пролетарийның капма-каршы позициялəрдə торганлыгын исбат итте. Ул халыкның кайбер катлауларында, бигрəк тə интеллигенция арасында таралган сыйныфара солых иллюзиялəренең тамырына балта чапты. Дөрес, əле аннан соң да, хəтта 1917 елда да аның калдыклары очрамый түгел, ə вакыт-вакыт көчəеп тə киткəн кебек була. Шулай да пролетариат, бигрəк тə аның алдынгы сафлары өчен мəсьəлə 1905 елда ук ачыклана. Ул гына да түгел, бу революция татар эшчелəр сыйныфының гомумроссия пролетариатының аерылгысыз өлеше икəнлеген, аның пролетар интернационализм байрагына тугрылыгын ачык күрсəтте.

Бездə Беренче рус революциясенə багышланган хезмəтлəрнең саны шактый булса да, татарларның бу революциягə катнашуына кагылганнарын бармак белəн санарлык. Г. Ибраһимов, Г. Мансуровларның егерменче елларда дөньяга чыгарган хезмəтлəреннəн без əле дə əллə ни ерак китмəдек. Дөрес, Х. Хəсəнов, М. Абдрахманов, Ш. Хамматов, Ф. Газизуллин һəм кайбер башка тарихчылар бу өлкəдə шактый гына зур эш башкардылар. Лəкин татар телендə дөнья күргəн большевистик листовкалар һəм прокламациялəр махсус тикшерену объекты итеп каралганы юк иде əле.

Менə, ниһаять, Татарстан китап нəшрияты 1905—1907 елларда татарча басылган большевистик прокламациялəрнең И. А. Абдуллин тарафыннан төзелгəн җыентыгын чыгарды[1]. Шуңа өстəмə итеп рус телендə И. А. Абдуллинның əлеге прокламациялəрнең тасвирламасы, һəрберсенең табылу һəм өйрəнү тарихын, əһəмиятен яктырткан махсус хезмəте дə дөнья күрде[2]. Бу ике китапның бергə чыгуы тарих һəм филология фəннəре өлкəсендə зур вакыйга. Бүгенге көннəн башлап Казан комитетының 1903—1907 елларда чыгарылган 58 прокламациясе фəнни хəрəкəткə кереп китте дип санарга мөмкин. Əгəр дə И. Абдуллинның моннан башка тагын дистəлəрчə яңа документлар турында мəгълүматлар биргəнлеген искə алсак, нəшер ителгəн китапларның никадəр кыйммəтле чыганак икəнлеген күз алдына китерергə мөмкин булыр.

Ни турыда сөйлилəр соң бу документлар? Моңа бер сүз белəн генə җавап биреп булмый, əлбəттə. Лəкин алар, революцион көрəш шаһитлары буларак, үзлəренə бик күп фактик байлык туплаган дисəк, ялгышмабыз. Чыннан да, шушы чыганаклар нигезендə Беренче рус революциясе турында күпме мəгълүмат алырга мөмкин. Бу документларның əһəмияте моның белəн генə чиклəнми, əлбəттə. Бу листовка һəм прокламациялəр татар хезмəт иялəренə революция турында дөреслекне, ялкынлы Ленин сүзлəрен китереп җиткергəннəр дисəк, без хакыйкатькə якынрак булыр идек. Алай гына да түгел, алар шул хезмəт иялəренең революциягə катнашуы турында, алар арасында большевистик сугышчан сүзнең никадəр киң таралган булуы хакында да сөйлилəр.

Прокламациялəрнең эчтəлеге генə түгел, аларның кайда табылганлыгы, кем тарафыннан төзелүе, нинди вакыйгаларга караган булуы, нинди вариантлары барлыгы, тел үзенчəлеклəре, аларның стиле дə өйрəнелгəн. Прокламациялəрнең авторлары хакындагы мəгълүматлар, нинди тираж белəн таралулары турындагы фактлар — боларның барысы да əһəмиятле.

Бəхəссез хакыйкать булмаган кебек, шиксез фактлар да булмый. Аларга тикшерүче шулай карарга тиеш тə. Шунсыз фəн фəн була алмый. Шик беткəнчегə кадəр телəсə нинди фикер гипотеза дəрəҗəсеннəн уза алмый. Əгəр дə инде бу сүзлəрне рецензиялəнə торган китапларга кайтарсак, шуны

[1] Большевистик сугышчан сүз. Казан, Татарстан китап нəшрияты, 1987.

[2] Абдуллин И. А. Описание первых произведений большевистской печати на татарском языке периода революции 1905—1907 годов. Казань, Татарское книжное издательство, 1986.

әйтергә кирәк: бу ике басмада әлегә кадәр дөнья күргән фәнни хезмәтләрдә исбат ителмәгән, яки тиешенчә дәлилләнмәгән фактлар һәм фикерләр дә юк түгел. Болар асылда прокламацияләрнең авторларын билгеләүгә кайтып кала. Нигәдер И. А. Абдуллин аларның күбесен Х. Ямашев яки Г. Сәйфетдинов төзегән дип саный. Бу очракта ул шушы ике революционер турында күп язган Х. Х. Хәсәнов һәм Г. А. Гарәфетдиновларның авторитеты тәэсирендә калмыйммы икән? Безнең башка күп революционерларыбызның тормыш юлы һәм эшчәнлеге теге яки бу сәбәпле, әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Димәк, аларның фикерен яшерен революцион агитация эшенә керткән өлешләре дә әлегә кадәр тиешенчә бәяләнмәгән. Бу җөмләдән И. Абдуллин тарафыннан искә алынган Г. Мостафин, Ш. Әмиров, бертуган Гафур һәм Ибраһим Колахметовларны әйтеп үтәргә була. Тагы күпме билгесез революционерлар бардыр?!

Прокламацияләрне большевиклар гына түгел, меньшевик һәм эсерлар да язып тарата. Аларның большевиклар белән бергә төзегән прокламацияләре дә бар. Мәсәлән, Казанда, ә соңрак Уфада меньшевик Ибраһим Әхтәмов, Терегуловлар большевиклар Х. Ямашев, Г. Сәйфетдиновлар белән бергә яшерен революцион эш алып баралар, «Урал» газетасын оештыруга да үзләреннән өлеш кертәләр. Укучының игътибарына тәкъдим ителгән җыентыкларга кергән прокламацияләрдә дә аларның өлеше юк түгелдер. Шул ук сүзләрне Х. Ямашевның хатыны Хәдичә Ямашева турында да әйтергә мөмкин. Ул да бит меньшевик була. Без кайвакыт Беренче рус революциясе елларындагы барлык социалистик партияләрнең бергә эшләү фактларына күз йомабыз. Ә бит бу дөреслеккә хыянәт итү. Дөрес, меньшевик һәм эсерлар шул елларда ук үзләренең чын йөзләрен күрсәтә башлыйлар. Алар хезмәт ияләре арасында революциягә карата төшенкелек, пессимизм хисләре тараталар. Казандагы 17—18 октябрьдәге кораллы вакыйгалар вакытында да аларның бу сыйфатлары сизелә башлый. Ләкин бу икенче мәсьәлә.

Тикшерелә торган китапларда тупланган материаллар һәм алар турындагы фикерләр махсус анализга лаеклы. Прокламацияләр һәм алар турындагы ярдәмче материаллар самодержавиегә каршы җәелдерелгән ачыктан-ачык һәм яшерен көрәшне оештыру механизмын тикшерүгә зур өлеш кертәләр. Бездә кайвакыт шул көрәшкә керткән өлеш турында жандармерия фондларында тупланган документлар буенча гына фикер йөртәләр. Янәсе анда никадәр материал күп булса, эш шул кадәр яхшы барган, әйбәт оештырылган. Әйе, бу материаллар нигезендә революцион элементләр билгеләнә, конспирация тәртипләре өйрәнелә. Ләкин шул вакытта ул материалларның жандармерия идарәләрендә тупланган булуы, шул элементләрнең һәм конспирация тәртипләренең тиешле дәрәҗәдә ышанычлы булмаулары турында сөйли, аларның безгә кадәр үк жандармнарга билгеле булганлыкларын раслый. Мондый фактларны тиешенчә искә алмыйча, архивта документ тапкан саен юкка гына шатланмыйбыз микән. Чын-чынлап карасаң, монда бит офтанырга кирәк. Чөнки бу документлар артында күпме фаҗигале вакыйгалар, ачылган явкалар, кулга алынган, сөрелгән һәм җәзаланган революционерлар.

Прокламацияләр, яшерен көрәш чарасы буларак, күп вакыт жандармнар кулына тентү нәтиҗәсендә эләгә. Шул ук вакытта, алар арасында стенадан йолкынган, янсә урамда табылганнары да юк түгел. Нәкъ менә шулар буенча жандармнарга билгеле булмаган явкалар, типографияләр, кызыклы язмышларның эзенә төшеп була. Әлбәттә, мондый эзләргә чыгу, аның буйлап бару җиңел эш түгел. Шулай да аларны табарга, табу өчен яңа ысуллар эзләргә кирәк. Тик шунда гына жандармнар өчен мәгълүм булмаган каналларны, явкаларны ачыклау мөмкин булыр.

И. Абдуллин Идел һәм Урал буендагы шәһәрләрдәге РСДРП комитетларының Беренче рус революциясе елларына караган татарча прокламацияләрен эзләү һәм өйрәнүне дәвам итә. Шикләнмичә әйтергә мөмкин, бу тәҗрибәле тикшеренүче алар буенча да яңадан-яңа китаплар һәм мәкаләләр чыгарыр. Теләк рәвешендә шуны әйтәсе килә: төрле шәһәрләр арасындагы революцион элементләргә аеруча игътибар бирергә кирәктер. Моның өчен киң мөмкинлекләр ачыла бит. Большевистик «Урал» газетасын РСДРП комитетларының күмәк эше дип карарга кирәк. Алда әйтелгәнчә, прокламацияләр, листовкалар да кайбер очракларда күмәк эш нәтиҗәсе буларак барлыкка килгәннәр. Бу мөһим мәсьәләләрне тикшерү әле башланды гына. Аларны тикшермичә торып, татарлар, башкортлар, казахлар һәм башка төрки халыклар арасында социал-демократик фикернең ни дәрәҗәдә киң таралганлыгын өйрәнеп булмаячак. Бигрәк тә Әстерхан, Баку, Оренбург, Ташкент, Уфа, Троицк, Чиләбе шәһәрләре читтә калмаска тиеш. Әле никадәр кызыклы табышлар, күп кенә традицион карашларны чәлпәрәмә китерердәй ачышлар көтә тикшеренүче-тарихчыларны, филологларны, археографларны.

И. Абдуллин ирешкән уңышларның берсе итеп революцион җырларның татарлар арасында таралу тарихын өйрәнү дип санарга кирәктер. Бу бик әһәмиятле мәсьәлә.

Прокламацияләрне без әле бүгенгәчә тулы бәяли алмыйбыз шикелле. Асылда алар информациянең үз заманы өчен иң

оператив төре. Ул бүген басыла һәм бүген таратыла да. Кайберсе жандармнар кулына эләгә, кайберсе исә халык арасында айлар буе кулдан-кулга күчеп йөри. Әдәбиятта бу турыда мәгълүмат юк түгел. И. Абдуллин да аларны читләтеп үтми. Бу уңайдан бер-ике фактны күрсәтеп китү урынлы булыр. 1903 елның 18 ноябрьгә каршы төнендә Казанның Пләтән һәм Мещан урамнарында татар телендә басылган өч прокламация табыла. Аның каян килеп чыкканын, кем таратканлыгын жандармнар белми кала. Яисә инде, «Искра» газетасының 1904 ел 25 январь санындагы отчетына караганда, эшчеләр, бигрәк тә крестовниковчылар, прокламацияне яз каршылагандай каршылыйлар. Анда ни язылган соң дигән сорауга бер татар эшчесе болай ди: «Аны сезнеңчә әйтеп булмый, тик анда бар да дөрес, тик гадел сүзләр генә; ул кәгазьне мин өйдә дә укыдым, өйдәгеләр дә андагы барлык сүз дә гадел диделәр». Шушы кечкенә генә факт большевистик сүзнең никадәр зур потенциаль көчкә ия икәнлеген күрсәтә. Тагын бер факт. «Искра» тарафыннан чыгарылган «Солдат күңеле» прокламациясенең дә Казанда басылган татарча тәрҗемәсен «укый-укый таушалтып бетерделәр»,— дип яза «Пролетарий» газетасы.

Прокламация, брошюра, газеталарда В. И. Ленин турындагы мәгълүматларны өйрәнү тарихчыларыбызның изге бурычы. Рецензияләнә торган китапларда бу мәсьәләгә караган шактый бай мәгълүмат тупланган. Татар матбугатында юлбашчының исеме беренче мәртәбә «Азат» газетасының 1906 ел 19 май санында атала. Анда В. И. Ленинның Петербургта графиня Панина йортында эшчеләрнең зур митингысында сөйләнгән чыгышының эчтәлеге басыла. «Большевистик сугышчан сүз» китабының беренче бүлеге «В. И. Ленинның 1905—1907 елларда татар теленә тәрҗемә ителгән әсәрләре» дип аталган. Әйтелгән чыгышның эчтәлеге дә шунда бирелгән. Аннан башка тагын ике материал бирелә. Беренчесе — юлбашчының «Өч конституция яки мәмләкәт төзүдә өч төрле юл» исемле әсәре нигезендә эшләнгән прокламация, икенчесе — В. И. Ленинның «Дәүләт Думасына кемнәрне сайларга» исемле мәкаләсенең тәрҗемәсе. Революциягә кадәр Ленин әсәрләренең татарлар арасында таралуы мәсьәләсе киләчәктә дә игътибар үзәгендә торырга тиешле проблема.

Икенче бүлек тулысынча РСДРПның Казан комитеты прокламацияләреннән тора. Аларның һәрберсе Ленин идеяләрен халык массаларына җиткерергә зур өлеш керткән дип әйтә алабыз. Шунысы игътибарга лаек: халык массалары татар телендәге листовка һәм прокламацияләрне көтеп алганнар. Бер агитатор авылда крестьяннар белән эш алып барган җиреннән 1905 елның 16 декабрендә шәһәрдәге иптәшенә болай дип язган: «Зинһар, татар телендә прокламацияләр җибәр әле. Мин станциядә татарлар белән сөйләшеп киттем. Алар миннән нәрсә эшләргә, казна кулындагы җирләрне ничек алырга икәнлеген сораштылар (...), татарча прокламацияләр сорадылар. Берәр кеше артыннан җибәр әле». РСДРПның Казан комитеты каршындагы округ группасы 1906 елның 1 октябреннән 15 декабрьгә кадәр авыл халкы арасында 40 мең листовка тарата, шуның дүрт меңе татар телендә була.

Беренче рус революциясе елларында халык массаларын интернациональ рухта тәрбияләүгә зур урын бирелә. РСДРПның Казан комитеты да бу өлкәдә зур эш алып бара. Шушы кадәр прокламациянең татарча чыгарылуы үзе генә дә моны ачык күрсәтә. Һәрбер прокламацияләр татар буржуазиясенең революциягә карата сатлык позициясен фаш итә. 1905 елның ноябрендә прокламация итеп «Казан татарларына» мөрәҗәгать бастырып таратыла. Ул Казанда 17—18 октябрьдә булып үткән коралды бәрелешкә бәя бирүгә багышланган. Бу вакыйгалар пролетариатның җиңелүе белән тәмамланса да, прокламация зур оптимизм белән сугарылган. Ул төрле милләт хезмәт ияләрен дуслыкка өнди, самодержавиене коралды көч белән юк итәргә чакыра («Большевистик сугышчан сүз». 207 б.).

Тикшерелә торган китапларның әһәмияте киләчәктә тагын да артачак. Чөнки бу документлар моңарчы билгеле булган һәм билгесез материаллар белән чагыштырып өйрәнү өчен киң мөмкинлекләр ачалар. Алар сыйнфый көрәш тарихын тагын да җентеклерәк өйрәнергә, яңа проблемалар куярга киң юл ачалар.

**Индус ТАҺИРОВ,**
тарих фәннәре докторы,
профессор.

**Хуҗи Мәхмүтов,**
филология фәннәре кандидаты

# КӨРӘШКӘ РУХЛАНДЫРГАН ҖЫРЛАР

Россиядә эшчеләр хәрәкәтенең тууы һәм бигрәк тә В. И. Ленинның большевиклар партиясен төзүе белән илдә революцион көрәш тагын да киңрәк колач, аңлы, максатчан һәм оешкан төс алды. Эшчеләрнең һәм крестьяннарның сыйнфый аңын үстерү, аларны революцион теория, социалистик идеяләр белән коралландыру партия эшенең гаять әһәмиятле бурычы булып әверелде.

Халыкка социалистик идеяләрне җиткерүнең отышлы һәм үтемле бер чарасы, әлбәттә, поэтик сүз, революцион җыр иде. Революцион җырның яшәүчән көчен, аның төрле киртәләрне җимереп, миллионнарча кешеләргә барып ирешү, аларны көрәшкә туплау һәм рухландыру мөмкинлеген В. И. Ленин бик югары бәяләде. «Германиядә эшчеләр хорларының үсеше» дигән мәкаләсендә даһи юлбашчы «дөньяның барлык шәһәрләрендә, барлык фабрика поселокларында һәм батраклар яши торган алачыкларда кешелекнең яллы коллыктан котылу көне якынлашу турында пролетариатның бердәм җыры һаман ешрак яңгырый һәм полициянең берничи бәйләнүләре дә моңа комачаулый алмый» дип күрсәтеп үтте[1]. «Интернационал» авторы Евгений Потьены ул «җыр ярдәмендә пропагандалаучы иң бөек пропагандистларның берсе» дип атады[2].

Халыкара һәм рус эшчеләр хәрәкәтенең революцион поэзиясе, аның идея-художество ягыннан иң көчле әсәрләре революцион интеллигенция вәкилләре, профессиональ революционерлар тарафыннан иҗат ителде. Рус революционерлары халыкара эшчеләр гимны «Интернационал»ны, «Марсельеза» кебек атаклы җырларны рус теленә тәрҗемә иттеләр, күп санлы яңа җырлар тудырдылар. XIX йөзнең соңгы елларында һәм XX гасыр башында Л. П. Радинның «Смело, товарищи, в ногу», Г. М. Кржижановскийның «Варшавянка», «Беснуйтесь, тираны», А. Богдановның «Песня пролетариев», «Студенческая марсельеза» кебек җырлары барлыкка килде.

Атаклы революцион җырлар беренче башлап кайсы илдә, нинди телдә тууларына карамастан, тиз арада төрле милләт эшчеләренең йөрәкләренә юл таба алдылар. Алар массаларга аңлаешлы формада марксизм-ленинизм һәм пролетар интернационализм принципларын пропагандаладылар. Бу җәһәттән хезмәт ияләренең күренекле эшче-шагыйре Эжен Потье һәм эшче-композитор Пьер Дегейтер иҗат иткән «Интернационал»ның язмышы аеруча бәхетле булды.

«Бу җыр,— дип язды В. И. Ленин,— Европадагы барлык телләргә һәм алардан тыш башка телләргә дә тәрҗемә ителгән. Аңлы эшче нинди генә илгә эләкмәсен, язмышы аны кая гына илтеп ташламасын, туган иленнән читтә, тел белмичә, таныш-белешләреннән башка ул үзен нинди генә ят кеше итеп сизмәсен,— таныш «Интернационал» көе белән ул үзенә иптәшләр һәм дуслар таба ала.

Барлык илләрнең эшчеләре үзләренең алдынгы көрәшчесе, пролетар шагыйрьнең җырын күтәреп алдылар һәм бу җырны бөтендөнья пролетариаты җыры иттеләр»[3].

Казан большевиклары да В. И. Ленинның «социализмны эшчеләр җыры белән пропагандалау» турындагы күрсәтмәсен гамәлгә ашыруга җитди игътибар бирделәр. Зур ышандыру һәм фаш итү көченә ия булуларын истә тотып, РСДРПның Казан комитеты

---

[1] К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында. Казан, 1976, 199 б.

[2] К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында. Казан, 1976, 198 б.

[3] К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында, 197 б.

революцион җырларны аерым җыентыклар, листовкалар рәвешендә бастырып массаларга җиткерде, алардан өзекләрне прокламация текстларында оста файдаланды. Комитетның 1905 елгы апрель аена отчетында «Марсельеза»ның башта 100 данә, аннан «Варшавянка» җыры белән бергә 340 данә бастырылуы, шуның өстенә партия Үзәк Комитетының Көнчыгыш Бюросыннан алынган 150 данә җыр тексты таратылуы күрсәтелә[4]. Шул ук елда «Похоронный марш», «Смело, товарищи, в ногу», «Марсельеза» җырларын эченә алган «Песни борьбы» җыентыгы, «К солдату» исемле җыр-листовка дөнья күрә[5]. РСДРПның Казан комитеты революцион җырларны татарчага тәрҗемә итүне дә мөһим чара итеп санады. Беренче рус революциясе чорында һәм аннан соңгы елларда «Марсельеза», «Похоронный марш», «Варшавянка», «Смело, товарищи, в ногу» кебек атаклы җырлар һәм гимннар листовкаларда татар телендә дә басылып чыктылар. Татарстан Үзәк Дәүләт архивында шундый җыр-листовкаларның аерым нөсхәләре сакланып калган. «Марсельеза»ның беренче тәрҗемәсе РСДРПның Казан комитеты листовкасы формасында гектографта басылган була. Аның башында, шул чордагы яшерен типография чыгарган материалларда куелганча: «Берләшегез, бөтен дөньяның пролетариясе!», ә соңыннан «РСДРПның Казан комитеты нәшер итте» дип күрсәтелгән[6]. Шул ук текст төрле рәсемнәр белән бизәлеп башка листовкаларда да бастырылган. Мәсәлән, листовкалардан берсенең башында — демонстрациягә чыккан халык рәсеме. Демонстрантлар күтәргән алгы плакатта — татарча «Бетсен самодержавие! Хөррият!» сүзләре. Рәсем астында ярым түгәрәк рәвешендә «Берләшегез, бөтен дөньяның пролетариясе!» дип язылган. Текст янына сул як читтә РСДРПның Казан комитеты печате басылган[7].

Революцион җырлар яки алардан өзекләр татарча газеталарда, шулай ук русчадан тәрҗемә ителгән брошюраларда да очрыйлар. Мәсәлән, Г. Тукай «Фикер» газетасының 1906 елгы 46 санында «Интернационал»ның «Никто не даст нам избавленья» дип башланучы строфасын рус телендә файдалана. Шушы ук строфаны шагыйрь газетаның 47 санында татарчага тәрҗемә итеп урнаштыра[8].

«Фикер»нең 1907 ел 7 санындагы баш мәкалә (ул Тукай тарафыннан язылган дип уйланыла) Уральскидагы карагруһчыларны фаш итә, хезмәт ияләрен актив көрәшкә өзер торырга чакыра. Мәкаләнең азагында «Марсельеза» тәрҗемәсеннән бер куплет (кушымта) китерелә:

Торгыл, күтәрел, эшче кешеләр,  
Каршы тор дошманга, ач кешеләр.  
Яңра дөньяга үч авазы.  
Алга, алга, алга[9].

Х. Ямашев тәрҗемәсендә «Урал» газетасына кушымта итеп чыгарылган «Эшчеләрнең котылуы үзләренең эше булырга тиешле» дигән брошюра да «Интернационал»дан алынган «Безне һичкем коткармас» дип башланучы куплет белән тәмамлана (Оренбург, 1906, 35 б.).

«Урал» газетасы редакциясе большевистик брошюралар белән бергә «кечкенә-кечкенә революцион җырлар» җыентыклары да бастырып тараткан булса кирәк. Мәсәлән, 1907 елда Оренбург губерна жандарм идарәсе Троицк шәһәрендә шундый бер җыентыкны кулга төшереп, аны чыгаручыларны эзләргә керешә. Ул җыентык кечкенә форматта, 8 битле итеп, ал кәгазьдә басылган. Конспиратив максат белән кайда, кем тарафыннан басылуы күрсәтелмәгән. Анда татарчага тәрҗемә итеп «Эшчеләр марсельезасы», «Дружно, товарищи» җыры, «Похоронный марш» һәм бер оригиналь әсәр — «Авыл кешесенең җыры» урнаштырылган[10].

Билгеле, көчле полиция эзәрлекләве, цензура кысуы шартларында революцион поэзия әсәрләрен матбугатта чыгару мөмкинлекләре бик чикле булган. Шуңа күрә алар күп вакытта кулдан күчерү юлы белән таратылганнар. Бу җәһәттән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни архивында саклана торган (Әхнәф бине Әсәдулла Җамалетдин тарафыннан күчереп язылган) бер кулъязма җыентык игътибарга лаек (39 ф., 1 тасв., 3 эш). Ул Г. Тукай, М. Укмаси, Н. Думави һәм башка шагыйрьләрнең әсәрләрен, шулай ук күп кенә җырлар, бәетләр, шәкерт садәләрен эченә ала. Җыентыкның баштагы һәм ахыргы битләре юк, әмма 55—88 битләре номерланган һәм бергә теркәлгән хәлдә бик яхшы сакланганнар. Бу өлештә «Татарча Марселье-

4 Листовки Казанских большевиков. 1903 — 1907 гг. Составитель Айнетдинов А. И. Казань, 1941, 72—73 бб.  
5 Шунда ук, 119—121, 111—112 бб.  
6 Гыйззәт Б. Революцион поэзия. Китапта: Г. Халит, Х. Хисмәтуллин, Б. Гыйзәт. XX йөз башында татар әдәбияты. Казан, 1954, 40—42 бб.  
7 Садретдинов Ш. Сәгыйть Рәмиев иҗаты. Казан, 1973, 65 б.  
8 Нафигов Р. И. Тукай и его окружение. Казань, 1986, 86 б.  
9 Шунда ук, 101 б.  
10 Хөсәенов Х. Революционер-большевик Хөсәен Ямашев. Казан, 1959, 146 б.

за» һәм «Авыл кешесенең бәете»[11] дигән әсәрләр дә бар. Алардан соңрак килгән бер биттә «бәгъзе сәбәпләрдә мөбәййине» (бәян итүче) язылмады» диелгән һәм 1906-1907 еллар датасы куелган. Шушы чордагы күп санлы шәкерт дәфтәрләрендә дә революцион рухтагы җырларга, шигырьләргә шактый урын бирелгән булуы мәгълүм[12].

Политик брошюраларны, листовка һәм прокламацияләрне, революцион җыр текстларын татарчага тәрҗемә итүдә, бастырып чыгаруда һәм массаларга җиткерүдә, бер яктан Хөсәен Ямашев, Галимҗан Сәйфетдинов һ. б. профессиональ революционерлар турыдан-туры үзләре катнашсалар, икенче яктан, бу эшкә Габдулла Тукай, Гафур Коләхметов, Фатих Әмирхан, Сәгыйть Рәмиев, Габдрахман Мостафин кебек күренекле әдипләр, журналистлар, шулай ук укучы яшьләр зур өлеш керттеләр.

Кайбер революцион җыр текстларын татарчалаштыруга Гадрахман Мостафин белән бергә Г. Сәйфетдиновның да каләм көче кергән булырга тиеш. Казанда һәм Оренбургта Х. Ямашев белән бергә актив революцион эш алып барган, «Урал» газетасын чыгаруда турыдан-туры катнашкан бу турылыклы большевик һәм ялкынлы публицист политик әдәбиятны татар эшчеләренә үз ана телләрендә җиткерүгә гаять зур көч куйды.

«Урал»да эшләгән вакытта Галимҗан күптәнге хыялын тормышка ашыра — революцион җырларны татар теленә тәрҗемә итә, аларны аерым җыентыкларга туплап бастырып чыгара»,— дип язалар Г. Сәйфетдинов турындагы очерк авторлары[13]. Сүз инде алдарак телгә алып үтелгән җырлар җыентыгы турында бара. Жандарм идарәсе бу җыентыкның авторын һәм бастырып чыгаручысын эзләү процессында Г. Сәйфетдиновны да допроска тартуы турында архив материалларында мәгълүматлар сакланган[14]. «Марсельеза» җырының 1905—1907 елларда татар телендә төп ике варианты булуы билгеле. Шуларның икенчесен — «Татарча Марсельеза» дип йөртелгәнен — шагыйрь С. Рәмиев тәрҗемә иткән дип санала. Бу хакта соңрак сүз булыр. Ә менә РСДРПның Казан комитеты листовка итеп бастырган «Марсельеза» Г. Сәйфетдинов тәрҗемәсе булырга мөмкин[15]. Тәрҗемә, беренче чиратта, русча текстка сүзгә-сүз диярлек якын торуы, ягъни әсәрнең революцион эчтәлеген тулысынча саклавы һәм саф татарча булуы белән сокландыра. Дөрес, кайбер куплетларда рифмалар бик үк уңышлы түгел, әмма, гомумән алганда, бу яктан да тәрҗемә канәгатьләнерлек эшләнгән. Бигрәк тә җырның кушымтасы матур яңгырый:

Торыгыз, күтәрелегез, эшче кешеләр!
Каршы тор дошманга, ач кешеләр!
Яңра дөньяга, үч авазы!
Алга, алга, алга!

Менә бу юлларның шигъри дәрәҗәсе чыннан да югары булуын күрү өчен, аларны «Марсельеза»ның танылган шигырь остасы Нури Арсланов тарафыннан безнең көннәрдә эшләнгән тәрҗемәсе белән чагыштырып карарга мөмкин. Ике кушымта арасында шактый ук якынлык, охшашлык бар:

Кузгал, күтәрел сугышка, эшчеләр,
Ач халык, каршы тор дошманга.
Яңгыра, халыкның үч авазы:
Алга! Алга! Алга! Алга! Алга!

1905 елгы революцион күтәрелеш чорында партиянең Казан комитеты Г. Сәйфетдиновны Алафузов районындагы татар эшчеләре арасында агитация эше алып баруга җаваплы итеп билгели. Ноябрь-декабрь айларында ул күп санлы митингларда ялкынлы речьләр белән чыга. Татар эшчеләренең бу чордагы настроениеләрен, теләк-омтылышларын ул тирәнтен аңлый. Шуңа күрә, массаларның революцион җырларга ихтыяҗын канәгатьләндерү максатында, аның үз каләмен шигъри әсәрләр тәрҗемә итүдә дә сынап караган булуы — бик табигый хәл. Нәкъ шул көннәрдә — «Казан мөхбире» газетасының 5 декабрь санында «Вы жертвою пали в борьбе роковой» («Похоронный марш») җырының тәрҗемәсе «Бәхилләшү» (хөррият өчен корбан булганнарга) исеме белән дөнья күрә. Текст азагында имза урынына куелган «С» хәрефе игътибарга лаек. Аның «Сәйфетдинов» фамилиясенең баш хәрефен аңлатуы мөмкин.

---

[11] Дәфтәр иясе бу әсәрне «Чүкеч» журналыннан күчерүен искәртә. «Урал» газетасы чыгарган җырлар җыентыгында һәм хәзерге фольклор китапларында «Авыл кешесенең җыры» исеме белән басыла.
[12] Госманов М. Каурый каләм эзеннән. Казан, 1984, 84—85 бб.
[13] Гарәфетдинов Р., Юсупов М. Күрсәтелгән хезмәт. 47, 109 бб.
[14] Шунда ук, 47, 109 б.б.
[15] Әлбәттә, бу тәрҗемәнең Габдрахман Мостафинныкы булуы ихтималын да хәтердән чыгармаска кирәк.

И. Абдуллин китергән мәгълүматлардан күренгәнчә, 1905 елның 12 декабрендә полиция Г. Сәйфетдинов квартирында тентү уздыра. Тентү вакытында «Бәхилләшү» җырлистовкасының татарча караламасы, шулай ук «Казан мөхбире» газетасының җыр тексты басылган алты данәсе табыла. Менә бу фактлар да «Бәхилләшү» җырын татарчага тәрҗемә итүгә, аны гектографта һәм газетада бастыруга Г. Сәйфетдиновның турыдан-туры катнашы булуы ихтималын куәтлиләр[16].

«Похоронный марш»ның 1905 елда Казанда рус телендә чыгарылган «Песни борьбы» җыентыгына кертелгәнлеген алда күрсәтеп үткән идек. Шундагы текст белән чагыштырып карагач, тәрҗемәнең оригиналга шактый якын булуы күзгә ташлана. Инде алар арасындагы аерымлыкларга килсәк, татарча текстта:

А деспот пирует в роскошном дворце.
Тревогу вином заливая.
Но грозные буквы давно на стене
Чертит уж рука роковая.—

дигән турыдан-туры патшага каршы юнәлтелгән юллар төшереп калдырылган. Әмма аларның, Б. Гыйззәт язганча, «Казан мөхбире» газетасы редакциясе тарафыннан сызылган булуы да бик мөмкин. «Тагын шунысы характерлы,— дип күрсәтә Б. Гыйззәт,— татарчага тәрҗемә итүче русча текстта булмаган, ләкин әсәрнең идея эчтәлеге өчен кызыклы, бик кирәкле өстәмәне дә керткән. Ул изге юлда һәлак булганнарның бөек эшен дәвам иттерүчеләр турында җырлый, революцион традицияләрнең, көрәшнең яңа буын тарафыннан дәвам ителәчәгенә ышандырган оптимистик юллар өсти:

Яшь иптәшләр барырлар сезнең юлдан,
Һәр эшкә хәзер һәм гайрәтле,—

дип, алмашчылар килүен, көрәшнең дәвам итәчәген белдерә»[17].

Г. Сәйфетдинов революцион җырларга мәхәббәтен бөтен гомере буенча саклады, аларны матбугат аша яки башка юллар белән массаларга җиткерүгә һәрвакыт җитди игътибар бирде. Аның турында 1917 елны Беренче Май алдыннан «Марсельеза», «Варшавянка» кебек революцион җырларны татарчага тәрҗемә итте дип тә язалар[18]. Әмма мөселман социалистлар комитеты органы «Аваз» газетасының 1917 ел 22 апрель санында басылган «Татарча Марсельеза» һәм «Бәхилләшү» исемле мәкаләсендә Г. Сәйфетдинов үзенең бу җырларны бастырып эшчеләр арасында таратуы хакында гына әйтә. «Марсельеза» тексты 29 апрельдә «Аваз» газетасында да басылып чыга. Ләкин бу — С. Рәмиев тәрҗемәсе булып саналучы «Татарча Марсельеза». Газетада ул шундый исем астында басылган да. Ә менә җырның кушымтасы «Марсельеза»ның беренче (листовка) варианты буенча бирелгән. Дөрес, аның да «Торыгыз, күтәрелегез, эшче кешеләр» дигән юлында «күтәрелегез» сүзе, «Татарча Марсельеза»дагыча, «килегез» дип үзгәртелгән.

Әлбәттә, җырны газетада бастырып чыгару Г. Сәйфетдинов инициативасы буенча эшләнгән. Ул «Аваз» газетасының редколлегия члены була.

Революцион поэзия әсәрләренең татарчага тәрҗемә ителүе һәм татар халкы арасында популярлык табуы шактый дәрәҗәдә шагыйрь Сагыйть Рәмиев исеме белән бәйләнгән. Алдарак революцион җырлардан «Марсельеза»ның бер вариантын татарчага С. Рәмиев тәрҗемә иткәнлеге турында әйтелгән иде инде. Бу хакта шагыйрь иҗатына багышланган мәкаләләрдә һәм истәлекләрдә еш телгә алына. «Ләкин,— дип яза Ш. Садретдинов,— бу күрсәтүләрдә конкрет бер дәлил, чыганак, текст китерелми. «Марсельеза»ның ике тәрҗемәсеннән кайсы С. Рәмиевнеке соң? Беренчесеме, әллә икенче вариантмы? Безнең тикшеренүләр шуны күрсәтте: С. Рәмиев тарафыннан «Марсельеза» тәрҗемәләренең икенче варианты — «Татарча Марсельеза» иҗат ителгән. Аның баштагы строфалары, өзек-өзек булса да, 1906 елда «Таң йолдызы» газетасының 61 санында «Казан», 5 нче ноябрь» дигән баш мәкалә эчендә басылып та чыккан».

«Татарча Марсельеза» текстында ирекле тәрҗемә, иярәп язу сыйфатлары зур урын алып тора. Моның кайбер тышкы билгеләрен күрсәтеп үтәргә мөмкин: әгәр русча текст, кушымтасыннан башка, 40 юл тәшкил итсә, татарча текстның күләме 48 юлга җиткән. Оригинал һәм тәрҗемә арасындагы текстуаль якынлыкны һәм образлар уртаклыгын бары тик өченче-алтынчы һәм тугызынчы-унынчы строфаларда гына күреп була. Ләкин моңа карап калган строфаларда «Марсельеза»ның революцион пафосы сакланмаган яки йомшарган дип әйтә алмыйбыз.

---

[16] Абдуллин И. А. Күрсәтелгән хезмәт, 192 б.

[17] Гыйззәт Б. Күрсәтелгән хезмәт, 44—45 бб.

[18] Көрәштәшләр. (Мулланур Вахитов һәм аның көрәштәшләре турында истәлекләр һәм мәкаләләр). Казан, 1972, 29 б.

С. Рәмиевнең замандашы К. Гыйрфанов шагыйрь турындагы истәлекләрендә: «ул тәрҗемә иткән «Марсельеза», «Бәхилләшү» һ. б. ш. кебек революцион җырлар татар халкының яратып җырлый торган әсәрләре иде»,— дип искә ала[19]. Ягъни бу истәлектә «Похоронный марш» җырының да татарчага С. Рәмиев тарафыннан тәрҗемә ителгән булуы атап күрсәтелә.

«Марсельеза» кебек ук, «Похоронный марш» та революциягә кадәр татарчага ике вариантта тәрҗемә ителә. Беренчесенең — «Бәхилләшү» исемлесенең — Г. Сәйфетдинов тәрҗемәсе булуы ихтималы хакында әйтелгән иде инде. Ә «Матәм маршы» исемендәге икенче тәрҗемә, Ш. Садретдинов раслаганча, С. Рәмиев каләменә карый. Бу текст, беркадәр кыскартылган хәлдә, «Таң йолдызы» газетасының 1906 елгы 1 ноябрь санында «Халык корбаннары» дигән мәкалә эчендә дөнья күргән[20].

Ниһаять, шушы ук чорда С. Рәмиев татарчага тагын бер атаклы революцион җырны — «Смело, товарищи, в ногу»ны тәрҗемә итә һәм аның баштагы ике строфасын үзенең «Һәркемнең бурычы», «Казан, 14 ноябрь» дигән мәкаләләрендә («Таң йолдызы», 1906, 63, 64 саннар) бастырып чыгара. Бу җырның кайбер вариантларында «смело» сүзе «дружно» сүзе белән алыштырып та әйтелгән. Татарча чыганакларда ул «Дружно, товарищи» исеме белән йөри башлый.

Күренә ки, Россиядәге беренче революция елларында дөнья һәм рус революцион поэзиясенең күп кенә атаклы гимннары һәм маршлары татарчага тәрҗемә ителәләр. Бу җырлар хезмәт ияләренең политик аңын, сыйнфый көрәш активлыгын күтәрүдә зур роль уйнадылар. Алай гына да түгел, алар турыдан-туры азатлык өчен көрәш коралы сыйфатында да киң файдаланылдылар. Татар хезмәт ияләренең күп төрле революцион чыгышларында: маевкаларда, демонстрацияләрдә, митингларда, баррикада сугышларында «Марсельеза», «Смело, товарищи, в ногу» кебек җырлар тулы куәт белән яңгырадылар. Бу хакта күп санлы документлар, истәлекләр бик ачык сөйли.

«...1905 ел 17 нче октябрь манифестының чыгуы турында хәбәр алынгач та, шәһәр управасы, университет кебек җирләрдә җыелышлар, митинглар башланды... Социалистларның аңа исләре бер дә китмәде. Алар һәрбер җыелышта ул манифестның алдавычкына икәнен халыкка аңлата бардылар. Бер көнне халык шундый җыелыштан соң университеттан чыгып бик зур демонстрация ясады... Халык, «ура» кычкырып, русча һәм татарча «Марсельеза» җырлап, Пләтәнгә таба китте. Пләтән урамы чатына җиткәч, халыкның бер өлеше 5 нче полиция часына, андагы приставны, ярдәмчеләрен, надзирательләрне һәм полицейскийларны коралсызландырырга, бер өлеше Крестовников заводына — андагы эшчеләрне алып чыгарга китте. Заводка килеп җитү белән, андагы эшчеләргә зур митинг ясалды... Хөсәен Ямашев, тротуар баганасына менеп, ...эшчеләрнең кызыл флаг астына җыелырга тиешлекләре турында бик кызу рәвештә бер нотык сөйләп алды. Аның сүзе бетеп җитмәс борын «ура» кычкырып, «Марсельеза» җырлый башладылар. Русча җырлау тукталуга, татарча җырлап җибәрәләр...»[21].

Революцион җырлар татар халкының барлык катлауларына, шул исәптән укучы яшьләр арасына да, киң үтеп керде. Г. Ибраһимов язганча, «исляхчы татар шәкертенең алгы сафы... мәдрәсәне ташлап чыгып, үзе теләгәнчә митингларга, демонстрацияләргә, түгәрәкләргә йөреп, революция рухын тагын да киңрәк ала башлагач, татар шәкертенең йөрәгендәге үзгәреш тагы ныграк тирәнәйде... Башта тик «Уян, шәкерт!» җырласалар, хәзер инде «Марсельеза»ны — «Ташлыйк, туганнар, иске тормышны, ул тормыштан илгә файда юк, булса байлар илән тик түрәләр аркамызда рәхәт күрәләр»,— дип көйли башлады». (Әсәрләр. Сигез томда, 7 т., 337—338 бб.)

Нәкъ шушы фикерне раслаган шикелле, 1906—1907 елларда Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә укыган Фәтхел Корбангалиев үзенең бер истәлегендә болай дип яза:

«Марсельеза»ны, «Сада»ларны яхшы белә идек без. Мәдрәсәдә, кичләрен бергә җыелып, сәгатьләр буе кычкырып җырлый идек. Ул безгә тел белән әйтеп бетерә алмаслык рухи ләззәт, көч бирә һәм безне каядыр алга, көрәшкә, безгә әле билгеле булмаган, әмма ничектер нурлы булып тоелган тормышка чакыра иде»[22].

«Галия» шәкертләре, Галимҗан Ибраһимов инициативасы буенча, 1907 елның февралендә Уфа вокзалына икенче Дәүләт думасы членнарын Петербургка озатырга, шунда аларга үзләренең наказларын тапшырырга җыелалар. Менә шушы вакыйга вакытында татар шәкертләре «Марсельеза»ның нинди көчле көрәш коралы булуын үз тәҗрибәләрендә таныйлар. «Галимҗан наказның баштагы пунктларын укырга өлгермәде,— дип искә ала Ф. Корбангалиев,— каяндыр ике жандарм килеп чыгып, безне залдан куа башлады, берсе Галимҗанның беләгеннән тотып алды, аның кулыннан наказны тартып алырга теләде...

[19] Садретдинов Ш. Күрсәтелгән хезмәт, 66—67 бб.
[20] Шунда ук, 72—75 бб.
[21] Корбангалиев Мөхетдин. Хөсәен Ямашев турында исемдә калганнар. «Безнең юл», 1927, № 1, 30—31 бб.
[22] Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр. Төзүчесе А. Шамов. Казан, 1966, 37 б.

Башка жандармнар да, городовойлар да ярдәмгә килеп җитеп, безне шактый тупас төрткәләп куарга тотындылар. Без, никадәр карышсак та, вокзалдан чыгарга мәҗбүр булдык. Шулай да таралмадык, барыбыз бергә җыелып, перронга килеп кердек. Анда халык шактый иде. Кайсыбыздыр «Марсельеза»ны кычкырып җырлый башлады... Беренче строфаны бердәм күтәреп алдык:

Ташлыйк, туганнар, иске дөньяны,
Китсен аяктан аның тузаны!
Бетсен дөньяның алтын санәме,
Көйсен патшаның алтын сарае.

Бездән йөзләрен чөергән Дума членнарына да, жандармнарга да, городовойларга да бик каныбыз кызган иде. Аларның барысына үч итеп, көчебездән килгән кадәр кычкырып җырлавыбызда дәвам иттек:

Без барыйк мескен иптәшләребезгә,
Барыйк ач калган кардәшләргә,
Аларны без чакырыйк сугышка,
Эшчеләрнең дошманнарына.

Перрон халык белән тулды. Каяндыр бер төркем эшчеләр килеп чыкты. Алар да кушылдылар. Көебез бер булганга, җырыбызда бер төрле дә аерымлык тумады...»

«Марсельеза» җыры, бигрәк тә «Татарча Марсельеза» Россиядәге беренче революция елларында да, Бөек Октябрь көннәрендә дә татар хезмәт ияләре арасында иң киң таралган, иң яратып җырлана торган әсәр булган. Теләсә кайсы маевканың, демонстрациянең ничек узуын тасвирлаган материалларга мөрәҗәгать итсәң дә, аларда һәрвакыт «Марсельеза»ның телгә алынуын күрәсең. Биредә тагын «Аваз» газетасының 1917 елгы 4 санында басылган «Казанда Беренче Май бәйрәме» дигән мәкаләдән өзекләр китереп үтү дә кызыклы булыр: «...Сәгать 9 да кара болыт кебек халык мәйданнан кузгалды. Балык базары, Проломный урамы белән Управа янындагы Ивановский мәйданына киттеләр. Барган вакытта, дөньяны яңгыратып, түбәндәге[23] «Марсельеза»ны әйтеп бардылар... Ивановский мәйданында Алафузов, Пороховой һәм башка завод-фабрика эшчеләре бергә килеп кушылдылар. Бу җирдә крепость эченә кереп киткән делегатларны көтеп, туктап «Марсельеза» әйтеп тордылар. Татар эшчеләре бергә булды. Алар гаять күп булса да, тәртип фәүкылгадә (гадәттән тыш) яхшы булды... Делегатлар чыккач, татарлар үзләренә зур армия булып, Воскресенский, Грузинский урамнары буенча җырлап йөрделәр.

Шушы ук маевка мөселман социалистлар комитетының актив эшлеклесе Каюм Саттаров истәлекләрендә дә тасвирлана. Баштагы чорда комитетның күпчелек членнары һәм татар эшчеләре революцион җырларны белмиләр, бигрәк тә күмәк җырларга күнекмәгәннәр иде,— дип искә ала ул.— Галимҗан Сәйфи «Марсельеза» һәм «Варшавянка»ны татарчага тәрҗемә итте. Көен өйрәтүне Кәрим Тинчурин үз өстенә алды. Беренче Майда коллектив белән җырлап бардык, демонстрациядә ул бик шәп чыкты. «Бик әйбәт чыга, булдырасыз, егетләр»,— диделәр рус иптәшләр»[24].

Тәрҗемә юлы белән таралган революцион поэзия әсәрләре, әнә шул рәвешчә, татар эшчеләре фольклорының органик бер өлеше булып әверелделәр, алар безнең халык иҗатында революцион көрәш темасының ныклап урнашып китүе өчен әйбәт нигез булдылар.

---

[23] Газетада шушы мәкалә астында «Татарча Марсельеза» тексты басылган.

[24] Көрәштәшләр. Казан, 1972, 29 б.

Зиннур Шакиров

# РЕВОЛЮЦИЯ СОЛДАТЫ, ЖУРНАЛИСТ ҺӘМ ГАЛИМ

Мең тугыз йөз унсигезенче ел. Февраль аеның чатнама суык бер көнендә урамнан ашыга-ашыга яшь кызыл гвардияче атлый. Юка, иске шинель аны җылытмый күрәсең: ул кышкы дала җиленә буйсынгандай бөрешеп калган. Менә ул Мөселман хәрби-революцион комитеты урнашкан Кәрван-Сарай янында тукталды, шинель якасын төшереп, тураебрак басты һәм ишеккә таба юнәлде.

Монда аны Мөселман хәрби-революцион комитеты председателе Бәһау Нуриманов көтеп тора иде инде.

— Ә, иптәш Йосыпов, исәнмесез, әйдәгез үтегез, утырыгыз... Сезнең хакта күп ишетергә туры килде. Мәкаләләрегезне дә укыдым. Ялгышмасам, сезнең «Шәркый» дигән псевдонимыгыз да бар бугай. Әйдәгез, якыннанрак танышыйк, үзегез турында сөйләгезче.

— Нәрсәсен сөйлисең инде, биографиям бик кечкенә, ике сүз белән әйткәндә...

Бу вакытта Зәһидка 17 генә яшь була әле. Ә тормыш юлы шактый кызыклы һәм бай.

Зәһид Йосыпов 1901 елның 9 январенда Оренбургта дөньяга килә. Аның әтисе Гайфулла Йосыпов кара эшче була, ә әнисе Сәхипҗамал апа кер юып көн күрә. Йосыповлар гаиләсе ике катлы йортның юеш һәм суык подвалында көн итә. Гаилә ярлы яши, көчкә очны-очка ялгап бара. Зәһидка 9 яшь тулгач, ата-анасы аны «Фокерот» пекарнясына эшкә урнаштыралар. Җәйләрен ул шунда эшли, ә кышларын атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем ала. Мәдрәсәдә уку шома гына бармый. Листовкалар таратканы һәм шәкертләр чуалышында катнашканы өчен ул мәдрәсәдән чыгарыла.

1913 елда Зәһид Оренбургта Кәримовлар типографиясенә өйрәнчек булып эшкә керә, соңрак «Вакыт» газетасы басмаханәсенә күчә. Нечкә күңелле, күп белергә омтылучы яшь эшче кайнап торган шәһәр тормышыннан читтә кала алмаган, әлбәттә. Тиз арада ул алдынгы фикерле эшчеләр һәм яшьләр белән аралаша башлый: шәһәр күләмендә үткәрелә торган җыелышларда катнаша, большевикларның аерым йомышларын үти башлый. Февраль революциясеннән соң большевикларның Оренбург оешмасы Зәһидны политик эшкә тагын да ныграк җәлеп итә. Типографиядә эшләп, азмы-күпме тәҗрибә алган Зәһид яшерен рәвештә рус һәм татар телләрендә большевистик листовкалар бастырып, эшчеләр арасында тарата һәм башка җаваплы эшләр башкара.

Эре сәүдә үзәге, Россиянең Урта Азия белән элемтәләрендә мөһим роль уйнаган Оренбург Октябрь революциясе алдыннан Вакытлы хөкүмәтнең терәк пунктларының берсе була. Монда атаман Дутов җитәкчелегендәге казаклар хуҗа була. Шушында ук башкорт милләтчеләре башлыгы Зәки Вәлиди дә үзенә оя кора. Шуңа күрә С. М. Цвиллинг җитәкчелегендәге Оренбург большевикларына Октябрь революциясеннән соң да губернада совет властен урнаштыру өчен ике айдан артык авыр көрәш алып барырга туры килә.

1918 елның январенда Оренбургны дутовчылардан азат итү өчен барган сугышларда, кызыл гвардиячеләр белән иңгә-иң торып, Зәһид та актив катнаша. Кызыл гвардиячеләр отрядында Зәһид большевиклар партиясе сафларына баса. Һәм шуннан соң яшь большевик баш-аяктан политик һәм әдәби эшкә чума, тулысынча халыкка, партия эшенә бирелә...

Мөселман хәрби-революцион комитеты председателе кабинетында утырганда да ул чираттагы партия йөкләмәсен көтә иде. Әйе, ул ялгышмады. Хәрби революцион комитет аңа большевистик «Мөхбир» газетасы оештыру һәм аны җитәкләүне тәкъдим итте. Шулай итеп Зәһид Йосыпов (Шәркый) Оренбургта татар телендә чыккан беренче

совет большевистик «Мөхбир» газетасының редакторы итеп билгеләнә. Бу аның язмышында борылыш чоры була. Әдәбиятны яратучы, редакторлык эшен сөеп башкаручы З. Шәркыйның соңгы язмышы тулысынча диярлек газета эшенә, журналистикага багышлана. Бу җаваплы һәм мәшәкатьле эшкә алынып, ул бервакытта да, язмыш кая гына ташласа да, журналист һәм әдәбиятчы исеменә тап төшерми.

Заһид Шәркыйга «Мөхбир» газетасында озак эшләргә туры килми. 1918 елның июлендә яшь редакторга, башка коммунистлар белән бергә, яңадан кулына корал алырга туры килә. Шәһәргә дутовчыларның һәм вәлидовчы милләтчеләрнең берләштерелгән көчләре якынлаша. Кызыл гаскәрләр Оренбургны вакытлыча калдырырга һәм Актүбәгә чигенергә мәҗбүр булалар. Әмма бу хәл озакка бармый: шул ук елның кышында кызыл гаскәрләрнең Оренбургка зур һөҗүме башлана. Ак казаклар белән булган авыр бәрелешләрнең берсендә рядовой Заһид Шәркый, яраланып, госпитальгә эләгә. Ләкин ул, аз гына сәламәтләнә башлау белән, яңадан фронтка омтыла. Аны политработник итеп билгелиләр, шулай ук ул «Кызыл маяк» исемендәге армия газетасын чыгарышуда да актив катнаша.

Заһид Шәркый революцион көрәшнең Оренбург чоры турында «Оренбургта революция көннәре» исемле китап яза. Китапта 1905 елдан алып 1919 елга кадәр, крайны дутовчылардан тулысынча азат иткәнче, Оренбургта булган авыр революцион көрәш тарихы тасвирлана. Бу еллардагы революцион хәрәкәтне автор ил күләмендәге социаль-политик вакыйгалар белән тыгыз бәйләнештә күрсәтергә омтыла. Оренбургта озак еллар яшәгән татар әдәбияты классигы Шәриф Камал бу китапны Оренбург төбәге тарихының бер сәхифәсе буларак югары бәяли. «Бөек Октябрь революциясе һәм Гражданнар сугышында катнашучы буларак Заһид Шәркый бу чорны бик тә гыйбрәтле итеп тасвирлаган һәм Бөек Октябрь социалистик революциясендә һәм Гражданнар сугышында катнашучы геройларга тулы характеристика биргән»,— дип яза күренекле әдип. Мәгълүм булганча, 1919 елда В. И. Ленин декреты буенча Башкортстан автономияле республикасы төзелә. Бу уңайдан берничә сугышчан иптәшләре — большевиклар белән Заһид Шәркый Оренбургтан РКП(б)ның Башкортстан өлкә комитеты карамагына, республикада нәшрият-редакция эшләрен җайга салу өчен күчерелә. Бу вакытта республикада вәлидовчыларның йогынтысы шактый көчле була. Алар совет властеның чараларын тормышка ашырырга төрлечә аяк чалырга тырышалар. Вәлидовчыларны 1918 елдан, Оренбургта эшләгән вакыттан ук белсә дә, З. Шәркый бу чорда әле аларның чын йөзен ача алмый. Яшь совет республикасының дошманнарын Гражданнар сугышының башка фронтларында да тар-мар итәргә кирәк була. Һәм ул 1919 елның ноябрендә яңа оештырылган башкорт бригадасы составында Петроград фронтына китә. 1920 елда З. Шәркый яңадан Уфага кайта. Аны «Башкортстан хәбәрләре» исемле республика газетасының редакторы итеп билгелиләр, бераза ул Башкортстан дәүләт нәшрияты мөдире вазифасын да башкара. Ләкин туган төбәк, дала ягы, Оренбург аны гел үзенә тартып тора. Һәм ул яңадан Оренбургта. Балалык, мәктәп еллары, утлы, давыллы көрәш көннәре дә монда узган аның. Монда ул коммунистлар партиясе сафларына керде. Монда, Оренбургта, ул беренче большевистик совет газетасы «Мөхбир»не оештырды һәм редакторы булды. Шуңа күрә Оренбургка ул шатлана-шатлана кайта. Аны, сыналган большевикны, ВКП(б)ның Оренбург губерна комитеты каршындагы азчылык милләтләр бүлеге мөдире итеп билгелиләр. Бер үк вакытта Заһид Шәркый ВКП(б)ның Оренбург губерна комитетының агитация һәм пропаганда бүлеге органы «Юксыллар сүзе» исемле газетаның редакторы булып та эшли. Дәһшәтле 1921 елның авыр көннәрендә язмыш аны татар поэзиясенең булачак классигы Һади Такташ белән очраштыра. Такташ газетаның җаваплы секретаре булып эшли һәм үзенең беренче шигырьләрен дә шунда бастыра.

Соңрак Заһид Шәркый РКП(б)ның Оренбург губерна комитеты һәм Кыргыз өлкә комитеты органы «Юл» газетасының редколлегия председателе була (бу елларда Оренбург Кыргыз (казах) автономияле республикасының башкаласы була).

Классик язучыбыз Шәриф Камал, элеккеге «Вакыт» газетасы редакторы, күренекле әдип Фатих Кәрими белән тыгыз иҗади дуслык берләштергән З. Шәркыйны. Татар классик әдәбиятының шушындый күренекле әһелләре белән бергә эшләү, һәм шулай ук А. Таһиров, Ярлы Кәрим, Д. Юлтый һәм башка язучылар белән аралашу Заһид Шәркыйның әдәби иҗаттагы үсешендә дә эзсез калмый, әлбәттә.

1927 елда ул ВКП(б) Оренбург губерна комитетының «Очкын» исемле газетасы редакторы. Шуның өстенә аңа Оренбургтагы татар педагогия институты директорының урынбасары вазифасы да йөкләнгән була. Бераза ул бу институтның директоры булып та эшли, шунда ук политэкономиядән лекцияләр укый. Заһид Шәркый Оренбург шәһәр советының депутаты итеп сайлана, партиянең губерна комитетында даими член һәм институтның партия ячейкасы секретаре була.

Бу елларда (З. Шәркый Оренбургта 1928 елга кадәр эшли) ул бик күп яза, көндәлек матбугат битләрендә әдәби һәм иҗтимагый-политик темаларга багышланган күпсанлы

мәкаләләр белән чыгыш ясый, татар хезмәт ияләре тормышы турында драма әсәрләре иҗат итә. Аның драмалары шәһәр театры һәм эшчеләр клублары сәхнәләрендә куела. Заһид Шәркыйны еш кына «Орлес», кун заводы, тимер юл мастерскойларында күрергә була. Ул анда төрле актуаль мәсьәләләр буенча докладлар белән чыгыш ясый, РКП(б)ның губерна комитеты кушуы буенча төрле мөһим чаралар (бигрәк тә икмәк хәзерләү буенча) үткәрә. Шулай итеп ташып торган энергияле З. Шәркый Оренбургта һәм өлкәдәге татар, казах һәм башкорт крестьяннары, эшчеләре арасында күпкырлы пропаганда-агитация һәм культура-тәрбия эшләре алып бара.

Заһид Шәркыйның шәхси архивында күп еллар буе аның белән бергә эшләгән якташларының, хезмәттәшләренең истәлекләре сакланып калган. Аларда З. Шәркыйның Оренбург төбәгендә алып барган күпкырлы эшчәнлеге хакында кыйммәтле мәгълүматлар теркәлгән. Тарихчы Ш. Типеев, өч сугышта катнашкан ветеран Ф. Солтанов, тарих фәннәре кандидаты, доцент А. Алиев, БАССР Вакытлы революцион комитетының беренче председателе Г. Дәүләтшин һәм башкалар барысы да З. Шәркыйның туган иленә, коммунистлар партиясе эшенә җаны-тәне белән бирелгән ялкынлы һәм какшамас революционер, принципиаль коммунист булуы турында җылы, эчкерсез истәлекләр калдырганнар.

Бу уңайдан З. Шәркый турында Ф. С. Солтановның истәлекләре аеруча игътибарга лаек. Озак еллар буе ул З. Шәркый белән бергә Оренбургта эшләгән. Бергә эшләү торабара күп эшләрдә чыныгу алган ике коммунист арасында зур, эчкерсез дуслыкка әверелә. Үзенең дусты хакында менә ничек искә төшергән Ф. С. Солтанов:

«1926 ел башында РСФСР Бөтенроссия үзәк башкарма комитетының милләтләр бүлеге мине Оренбург губерна башкарма комитеты президиумына азчылык милләтләр эше буенча вәкил итеп билгеләде.

Мәскәүдән Оренбургка килеп төшкәч, мин партиянең губерна комитетына юнәлдем. Губерна комитетының секретаре мине азчылык милләтләр бүлеге мөдире белән таныштырды. Ул Заһид Йосыпов-Шәркый булып чыкты. 1920 елдан ук таныш булган бу кеше белән бергә эшләргә туры киләчәген белгәч, шатлыгымның иге-чиге булмады. Ул миңа һәрвакытта ошый иде. Үзенең искиткеч гадилеге һәм тыйнаклыгы белән ул тирә-юньдәгеләрне таңга калдыра иде. Ул һәрвакыт гади киенә, акрын гына сөйли. Акыллы карашы, төпле сөйләве аның белән җиңел һәм күңелгә ятышлы әңгәмәгә җәлеп итә иде. Үз кул астында эшләүчеләргә ул бервакытта да тавышын күтәрми иде. Бу очрашуда ул миннән рус булмаган халыклар һәм яшьләр арасында бергәләп эшләүне үтенде. Яшьләр арасында эшләүгә З. Шәркый зур игътибар бирә иде. Казах авылларына чыкканда, еш кына миңа комсомолның губерна комитеты хезмәткәрләрен дә үзем белән алырга киңәш итә иде. Шулай бервакыт З. Шәркый мине кабинетына чакырды. Мин кердем. Кабинетта аңа каршы бер яшь егет утыра иде. Мине күргә, З. Шәркый өстәл артыннан торды һәм таныш булмаган егетне минем белән таныштырды.

— Иптәш Солтанов, таныш булыгыз, комсомолның өяз комитеты инструкторы Җәлилов Муса... Шагыйрь. Казанда укыды, туган якларына эшкә кайтты.

Без таныштык. Шуннан соң ул, Җәлилгә мөрәҗәгать итеп:

— Тиздән Солтанов Буртинск волостендагы (хәзерге Беляевск районы) казах авылларына китәчәк, аның белән син дә бар. Казах телен Солтанов әйбәт белә.

Соңыннан без Муса белән берничә тапкыр төрле волостьларда булдык. Муса казахча бик тиз аңлый башлады. Мин хәзергә кадәр Муса Җәлил белән таныштырганы өчен Заһид Шәркыйга рәхмәтлемен. Яшь дустым Заһид Йосыпов белән миңа Мәскәүдә тагын берничә тапкыр очрашу бәхетенә ирешергә туры килде. Бөек Ватан сугышына кадәр Заһид Шәркый Мәскәүдә эшләде, Садово-Самотечный кольцода яшәде. Һәр очрашуда да без төннәр буе Оренбургта бергә эшләгән көннәрне һәм иптәшләрне искә төшереп сөйләшеп утыра идек, ул Оренбург хәлләрен, андагы иптәшләр хакында җентекләп сораштыра иде. Ул бик ярдәмчел, игътибарлы кеше иде. Бөтен гомере буе аек кеше булды, бервакытта да спиртлы эчемлекләр эчмәде.

Соңгы тапкыр без Оренбургта аның сеңлесендә 1956 елда очраштык. Бу вакытта ул Башкортстанда эшли иде».

1928 елда партиянең Үзәк Комитеты путевкасы буенча Заһид Шәркый Самара (хәзерге Куйбышев) шәһәренә җибәрелә. Партиянең Самара өлкә комитеты катнашы һәм булышлыгы белән З. Шәркый өлкәдәге татар хезмәт ияләре өчен «Урта Идел» исемле газета чыгаруны оештыра һәм аның беренче редакторы була.

Самарада эшләгәндә, газета эшенә чумган булуына карамастан, ул партиянең өлкә комитеты кушуы буенча өлкәдә беренче колхозлар оештыруда да актив катнаша.

1929 ел ахырында З. Шәркый Мәскәүгә китә. СССР Үзәк Башкарма комитеты каршындагы марксизм-ленинизм курсларының редакцион бүлегендә укый. Уку 1932 елга кадәр дәвам итә. Курсларда уку белән бергә ул Мәскәүдә татар телендә чыга торган «Эшче» газетасы редакциясендә эшли. Соңыннан «Коммунист» исемендә чыккан бу газета сәхифәләрендә З. Шәркыйның күп кенә мәкаләләре дөнья күрә.

Курсларны уңышлы тәмамлаганнан соң партиянең Үзәк Комитеты З. Шәркыйны Донецк шәһәренә эшкә җибәрә. Ул Донецкида партиянең өлкә комитеты, өлкә башкарма комитеты һәм профсоюзларның Бөтенукраина Советы органы булган «Пролетар» газетасының җаваплы редакторы булып эшли. Ул тиз арада редакциядә эшне һәм тәртипне җайга сала, шахтерлар арасында оештыру эшләре алып бара, Донбасста эшче көчләрнең алмашынып торуына каршы көрәшә.


1933 елда З. Шәркый яңадан Мәскәүдә. Аны СССР Үзәк башкарма комитетының Милләтләр Советы органы булган «Коммунист» газетасы редакторының урынбасары итеп билгелиләр. Озакламый аны партия Үзәк Комитетының матбугат бүлеге Кызыл профессура институтына укырга җибәрә. 1937 елда укуын тәмамлагач, ул партия Үзәк Комитетының политик нәшриятында редактор-инструктор итеп билгеләнә. Күп тә үтми, «Литературная газета» редакциясе үтенүе буенча З. Шәркый шушы редакциягә, СССР халыклары иҗаты бүлегенә мөдир итеп күчерелә. Бу күчерү очраклы гына булмый, әлбәттә. Эрудицияле, редакторлык эшендә зур тәҗрибә туплаган булуы өстенә ул күп телләр дә белгән. З. Шәркый казах, кыргыз, таҗик, азербайҗан телләрен яхшы үзләштергән. «Литературная газета»да эшләгән чорда аңа еш кына төрле республикаларда булырга туры килгән. Төрле телләрне белү урыннарда тәнкыйтьчеләрнең, әдипләрнең әсәрләре белән танышуны, газетага яңа корреспондентлар табуны җиңеләйткән. Мәскәүдә яшәгәндә, ул җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша: партиянең Мәскәү шәһәр комитетының штаттан тыш инструкторы булып эшли, еш кына эшчеләр алдында лекция һәм докладлар белән чыгыш ясый. Әмма Оренбург далаларында Дутов бандаларына каршы көрәштә алган яралары аны яңадан борчый башлыйлар. Ул, авырып, урынга ята.

Дәһшәтле 1941 ел. Бөек Ватан сугышы башлана. Күз һәм үпкә авыруы аңа көрәшчеләр сафына басарга ирек бирми. Әмма ул фашистларга каршы бөтенхалык көрәшеннән читтә калмый. Башкаланы саклау эшләрендә катнаша. Ләкин, күп тә үтми, аның сәламәтлеге кискен начарлана. Партия җитәкчеләре киңәше белән З. Шәркый Башкортстан АССРга эвакуацияләнә. Дәвалану курсын үткәч, ул яңадан сафка баса. БАССРның Кигинский райкомында эшли башлый. 1944 елда Уфадагы Тарих, тел һәм әдәбият институты соравы буенча З. Шәркый шул институтка фәнни эшкә күчерелә. Монда З. Шәркый 1956 елга кадәр — пенсиягә киткәнче эшли. Фәнни-тикшеренү институтында З. Шәркый XIX гасырда крайдагы культура торышын өйрәнү белән шөгыльләнә. Мәктәп дәреслекләре төзүдә катнаша. Ул аңа кадәр гомуман дип әйтерлек тикшерелмәгән мәсьәләне — башкорт совет әдәбияты үсеше мәсьәләләрен тикшерә, әдәби тәнкыйть мәсьәләләре белән вакытлы матбугатта чыгышлар ясый. 1959 елда З. Шәркыйның «Сайланма әсәрләр»е дөнья күрә. Китапның кушымтасында аның фәнни хезмәтләре һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләренең тулы исемлеген эченә алган күрсәткеч тә бирелгән. Бу елларда ул, авыруына карамастан, диссертация яклап, филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсен ала.

З. Шәркый искиткеч эш сөючән була. Пенсиягә чыккач та (ул — РСФСРның персональ пенсионеры була) ул республика газета-журналлары белән актив иҗади элемтәдә тора, мәкалә-рецензияләр бастыра. Өлкә газетасының 40 еллыгы уңаеннан З. Шәркый БАССР Верховный Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

1961 елның 13 апрелендә Заһид Шәркыйның йөрәге тибүдән туктый. Бөтен гомерен партиягә; илебездә социализм төзү эшенә багышлаган коммунистны соңгы юлга меңнәрчә кешеләр — аның дуслары, туганнары, хезмәттәшләре озата бара. Аның каберенә куелган гранит ташка түбәндәге сүзләр уелган: «Монда 1918 елдан КПСС члены, Октябрь социалистик революциясендә һәм Гражданнар сугышында актив катнашучы, кызылгвардияче, журналист, әдәбият белгече, филология фәннәре кандидаты Йосыпов (Шәркый) Заһид Гайфуллович күмелгән. 1901—1961». Бу көнне Мәскәүдән, Казаннан, Оренбургтан һәм башка шәһәрләрдән телеграммалар ява. Аларның авторлары ялкынлы революционерның, ленинчы большевикның, Бөек Октябрь социалистик революциясе һәм Гражданнар сугышында актив катнашучы Заһид Шәркыйның үлеме уңаеннан тирән кайгыларын белдерәләр.

Оренбург җире какшамас коммунист, революция солдаты, журналист, яңа җәмгыять нигезләрен төзүдә актив катнашучы Заһид Йосыпов-Шәркый кебек шәхесне бирүе белән хаклы рәвештә горурлана.



**«Урал» газетасы басылган йорт.**
Соленый тыкрыгы һәм 9 Январь урамы чаты.

# «УРАЛ» ҺӘМ УРАЛЧЫЛАР

Әдәбият, театр сәнгате, вакытлы матбугат, китап басу — кыскасы, культурабыз тарихының кайсы гына өлкәсенә күз салсак та без Оренбург белән очрашабыз. Татар телендә большевистик көндәлек матбугатның тууы да Оренбург белән тыгыз бәйләнгән. Соленый тыкрыгындагы 14 нче йорт — менә шул күренекле вакыйгага шаһит булган тарихи бина.

1905 елның декабре. Җандармнар РСДРПның Казан комитетын канга батыралар. Кулга алулар, эзәрлекләүләр... Ләкин оешманың берничә актив хезмәткәре, шул исәптән күренекле революционер-большевик Хөсәен Ямашев, кулга алынудан котылып кала һәм Чистай аша Уфага китә. Уфада ул татар телендә большевистик газета чыгару җаен эзли. Әмма бу ниятен тормышка ашыру мөмкин булмый.

1906 елның ноябрендә Х. Ямашев татарча китап басу, газета-журналлар нәшер итү үзәкләренең берсе булган Оренбургка килә. Иң элек ул татар телендә социал-демократик эчтәлектәге брошюралар бастыру һәм таратуны җайга сала.

Озакламый татар телендә беренче большевистик газета дөнья күрә. Аңа «Урал» дип исем бирәләр. Ул Х. Ямашев җитәкчелегендә 1907 елның 4 январеннан 27 апреленә кадәр чыга. Газета ике телдә — рус һәм татар телләрендә чыгарга тиеш булса да, күп сәбәпләр аркасында татар телендә генә дөнья күрә. Газетаны чыгару өчен акчаны партиянең Үзәк Комитеты члены И. А. Саммер тапшыра. РСДРПның Урал өлкә комитеты ярдәмендә чыккан «Урал» газетасы татар, казах һәм башкорт хезмәт ияләре арасында марксизм-ленинизм тәгълиматы идеяләрен пропагандалап, аларны пролетар интернационализм рухында тәрбияләүдә, большевиклар партиясе тирәсенә туплауда зур роль уйнады.

«Урал» атнага 2—3 тапкыр дүртәр битле булып чыга. Аның тирәсендә социал-демократлардан, алдынгы эшчеләрдән һәм хөр фикерле яшьләрдән торган хәбәрчеләр даирәсе туплана.

Х. Ямашевның Оренбургтагы революцион эшчәнлеге «Урал» газетасын чыгару белән генә чикләнми. Аның җитәкчелегендә редакция хезмәткәрләре марксистик әдәбиятны татарчага тәрҗемә итеп дөньяга чыгаруда да мәгълүм эш башкаралар. «Урал»-чылар татар телендә биш брошюра бастырып чыгаралар. Анда РСДРПның максатлары, эшчеләр сыйныфының тарихи роле, социализм һәм халыклар дуслыгы идеяләре пропагандалана. «Урал» газетасы һәм аңа кушымта итеп чыгарылган брошюралар партиянең җирле комитетлары тарафыннан киң илебезнең төрки халыклары яши торган төбәкләргә үзәкләштерелгән рәвештә таратыла. Әлбәттә, «Урал»ны чыгару шома гына бармый, чөнки ул Россиядә Беренче рус революциясе чигенгән, сүрелгән, ә реакция, киресенчә, һөҗүмгә күчкән вакытта нәшер ителә. Шуңа күрә газетаны тарату аеруча кыен шартларда бара. Полиция газета укучыларын даими күзәтү астында тота, аларны эзәрлекли, өйләрендә тентү ясый һәм кулга ала. Полиция эзәрлекләвеннән качып газетаны укучыларга төнләрен таратырга туры килә. Властьлар «Урал» редакциясе нәшер иткән политик брошюралар сатуны да тыялар. Мәсәлән, 1907 елның гыйнварендә Фатих Кәриминең Оренбургтагы китап кибетеннән политик брошюралар конфискацияләнә, ә кибет хуҗасына 300 сум штраф салына. Редакциянең үзендә дә тентүләр, конфискацияләүләр булып тора.

«Урал», чыга башлавыннан соң өч ай вакыт үткәч, 1907 елның 27 апрелендә ябыла. Кыска гомерле булуына карамастан, ул революцион көрәш тарихында тирән эз калдырды, гомерләрен бөек Ленин идеяләрен тормышка ашыруга, социалистик җәмгыять өчен көрәшкә биргән профессиональ революционерлар тәрбияләүдә, хезмәт ияләрен самодержавиегә һәм буржуазиягә каршы көрәшкә әзерләүдә искиткеч зур роль уйнады.

*Җ. Миңнуллин тексты.*

*4—11 нче саннардагы «Оренбургта культурабыз истәлекләре» рәсемнәрен М. Шакирҗанов фотолары буенча З. Мөхәммәтҗанова ясады.*

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Татарстан Язучылар союзының 17 сентябрьдә узган ачык партия җыелышында язучыларның республикабыз авылларына шефлык ярдәме күрсәтү буенча эшләгән эшләре һәм бу өлкәдә алда торган бурычлар турында сүз барды. Әлеге мәсьәлә буенча җыелышта язучы Р. Кәрами чыгыш ясады. Фикер алышуларда әдипләр М. Садри, С. Баттал, Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, Р. Мостафин, Б. Гыйззәт, Н. Дәүли, Г. Ахунов, Р. Харис, И. Юзеев, Мәхмүт Хәсәнов, Ә. Галиев, Г. Шәрәфи, К. Тимбикова, Р. Батулла, Ә. Рәшитов, Л. Шакирҗанова, С. Ибраһимова һ. б. катнашты.

### БӨЕК ШАГЫЙРЬ ИСТӘЛЕГЕНӘ

18 сентябрьдә Профсоюз урамындагы 23 нче йорт янында 1833 елның сентябрендә Александр Сергеевич Пушкинның Казанда булуы истәлегенә мемориаль такта ачылуга багышланган митинг булды. Митингны Бөтенроссия китап сөючеләр иркле җәмгыятенең Татарстан бүлеге идарәсе председателе, ТАССР культура министры урынбасары М. Низамиев ачты.

Мемориаль тактаны ачу хокукы китап сөючеләр җәмгыятенең иң актив членнарыннан берсе булган Казан химия-технология институтының өлкән укытучысы В. Лобовка бирелде.

Мемориаль тактада: «Бу йортта 1833 елның сентябрендә шагыйрь Э. П. Перцов янында Александр Сергеевич Пушкин булды», дигән сүзләр язылган.

Митингта шулай ук КДУның Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлеге мөдире В. Аристов, шагыйрь Р. Фәйзуллин чыгыш ясады. Пушкинның үлемсез шигъри юллары Ленин комсомолы исемендәге Казан яшь тамашачы театры артистлары башкаруында яңгырады.

### ДУСЛЫК СӘХИФӘЛӘРЕ

21—24 сентябрьдә Татарстан Язучылар союзы идарәсенең җаваплы секретаре Мөсәгыйт Хәбибуллин белән «Казан утлары» журналының баш редакторы урынбасары Ринат Мөхәммәдиев тугандаш Башкортстанда булып кайттылар. «Кызыл таң» газетасы, «Агыйдел» журналы коллективлары, республиканың радио һәм телевидение хезмәткәрләре белән очрашуларда алар бүгенге татар әдәбияты алдында торган бурычлар һәм «Казан утлары» журналының планнары хакында сөйләделәр, ике тугандаш республика әдипләре арасындагы хезмәттәшлекне тагын да җанландыру хакындагы җитди сөйләшүләрдә катнаштылар.

Башкорт дәүләт университетының филология факультетында һәм Илеш районының «Игенче» колхозында «Казан утлары» һәм «Агыйдел» журналларын укучылар белән очрашулар булып узды. Әдәбиятлар дуслыгы бәйрәменә әверелгән әлеге кичәләрдә Башкортстан әдипләре: «Агыйдел» журналының баш редакторы Әмир Гәрәев, Роберт Баимов, Суфиян Поварисов, Таңсылу Карамышева, Риф Мифтахов һәм башкалар катнашты.

Татарстаннан килгән кунакларны партиянең Башкортстан өлкә комитеты пропаганда бүлеге мөдире У. Н. Бакиров һәм Илеш райкомының беренче секретаре И. Т. Шәяхмәтовлар кабул итте. Бу очрашуларда «Агыйдел» һәм «Казан утлары» журналларының дуслык багланышларын тагын да тирәнәйтү һәм традициягә кертү ихтыяҗы билгеләп үтелде.

### МУСА ҖӘЛИЛ ӨЛЕШЕ

Әлмәттәге СССРның 50 еллыгы исемендәге «Җәлилнефть» идарәсе мастеры Р. Хәбибуллин җитәкчелегендәге комсомолйяшьләр бригадасы тугыз кешедән тора, ә эшләп алган хезмәт хакын унга бүлә. Мондый тәртип бирәдә 1984 елда, ягъни бригада тулы хокуклы член итеп Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилне кабул итеп алганнан соң кертелгән иде. Шуннан бирле Муса Җәлил исәбенә эшләнгән 5600 сум акча Совет тынычлык фондына күчерелде.

### ҖЫР ДУСЛАШТЫРА

Бөек Октябрь социалистик революциясенең 70 еллыгына багышлап, Украинаның республика телевидениесе «Тугандаш республикаларның сәнгать осталары» дигән тапшырулар оештыра. Июнь аендагы тапшыруларның берсендә тамашачылар

РСФСРның һәм Татарстанның халык артисты Ренат Ибраһимов белән очрашты. Тапшыруда Р. Ибраһимов турында ул Киевта гастрольдә булган чакта төшереп алынган язмалар, телевидение киносы күрсәтелде, аның башкаруында җырлар һәм опера әсәрләре яңгырады.

## ГАЛЕРЕЯ ИСЕМЕН ҮЗГӘРТӘ

Әлмәттә культура тормышында истәлекле вакыйга булды. Моннан 12 ел элек шәһәр художество мәктәбендә ачылган һәм шуннан бирле җәмәгать башлангычы тәртибендә уңышлы эшләп килгән Картиналар галереясына «Республика сынлы сәнгать музее филиалы» дигән исем бирелде.

Үзенең эшләү дәверендә Әлмәт Картиналар галереясының экспонатлар фонды бик нык артты. Хәзер анда 800 дән артык картина бар. Узган чорда алар белән 200 меңнән артык кеше танышты.

## ФӘННИ ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР

27 майдан 14 июньгә кадәр СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының комплекслы экспедициясе Уральск, Әстерхан төбәкләрендә, халкыбызның фольклор, музыка үрнәкләре һәм борынгы китапларын, кулъязмаларын барлау, җыйнау юнәлешендә эшләде. Р. Ягъфәров, Г. Макаров, Ф. Яхин халкыбызның культура тарихына караган күп кенә кызыклы материаллар алып кайттылар. Йөзгә якын кулъязма институт архивына тапшырылды (шулар исәбендә болгар-татар язма әдәбиятына нигез салучы мәшһүр шагыйрь Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» дастанының бер кулъязмасы бар).

Мамадыш районында археография экспедициясе вакытында кулъязма 16 китап, басма 14 китап табылды. Кулъязма китапларның күбесе иске татар телендә. Алар арасында 18 нче һәм 19 нчы гасырда популяр булган кыска хикәят китаплары, бер китап эчендә Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгариның «Горбәтнамә» поэмасыннан өзек бар. Шулай ук 16 нчы гасыр әсәре дип фараз ителә торган «Могҗизатнамә» дигән шактый зур күләмле, шигырь белән язылган әсәр табылды.

Игътибарга лаек табылдыклар арасында Баскан авылыннан Беренче бөтендөнья сугышына китеп мәрхүм булган Кәшафетдин Мөбарәкшинның ничек сугышка алынуы һәм Кытайга кадәр килеп җитүе турында шигырь белән язылган хаты бар. Югары Берсут авылында яшәүче 83 яшьлек Фәтхуллин Лотфулла бабай белән Югары Сон авылының Кәримова Бәдәр әбинең кулъязма дәфтәр-китапларында шагыйрь Мифтахетдин Акмулланың «Иң әүвәле кирәк нәрсә...» дип башлана торган популяр шигыренең халыклашкан вариантлары очрады.

Сарман районында эшләгән археографик экспедиция членнары кызыклы фольклор материаллары таптылар. Арада төрле бәетләр, шигырь дәфтәрләре, кулъязма китаплар, революциягә кадәр басылып чыккан китаплар, нәсел шәҗәрәләре һ. б. бар.

## КАЗАН КУНАГЫ

6 августта Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында Ленинград шәһәреннән, СССР Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Әнәс Бакеевич Халидов булып китте. Якташыбыз гарәп телендә язылган кулъязма китаплар буенча илебезнең иң абруйлы белгечләреннән санала. Ә. Б. Халидов Институтның кулъязмалар фонды белән танышты, үзенең киңәшләрен бирде, фәнни китапханәгә хезмәтләрен бүләк итте.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы Латыйпов Кави Таһировичка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 11 август Указы нигезендә, «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет әдәбияты һәм театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы Ишморатова Рәйсә Гыйниятулловнага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 11 август Указы нигезендә, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен түбәндәге иптәшләргә, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 18 август Указы белән, «Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде:

Исәнбәт Йолдыз Нәкыевнага — музыка белгече.

Макаров Марс Андреевичка — Казан шәһәренең 69 нчы урта мәктәбе каршындагы музыка студиясе укытучысы.

Совет культура өлкәсендәге хезмәтләре һәм озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен Татарстан АССР Дәүләт китап палатасы директоры Әнисә Мәгъсумовна Хисамовага, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 12 август Указы белән, «РСФСРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Совет хореография өлкәсендәге хезмәтләре өчен М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисткасы Ирина Шәрифовна Хәкимовага, РСФСР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 24 август Указы белән, «РСФСРның халык артисткасы» дигән мактаулы исем бирелде.

# ШАНЛЫ ТАРИХ ЕЛЪЯЗМАСЫ

Тарихи Бөек Октябрь көннәре... Ул — республикабыз рәсем сәнгатендә иң актуаль һәм даими темалардан берсе. Октябрьнең рәсем сәнгате елъязмасында башкалабыз Казанда революциянең җиңеп чыгуына китергән мөһим вакыйгалар, гүяки кадр артыннан кадр булып, теркәлеп бара.

Мәсәлән, рәссам Л. Фәттахов портреты (1963 ел) безне мәшһүр татар революционеры Мулланур Вахитов образы белән таныштырса, рәссам В. Федоров исә үзенең картинасын (1980 ел) халкыбызның шундый ук кыю улы революционер Камил Якуб батырлыгына багышлый. Г. Медведев картинасында (20 еллар ахыры) кызыл армиячеләрнең Арча кырында юнкерларга каршы аяусыз сугышы тасвирлана. В. Тимофеевның утызынчы елларда иҗат ителгән полотносы 1917 елның 27 октябрендә Театр мәйданында үткәрелгән митинг турында сөйли.

Революциянең гүяки фрагментлар рәвешендә сурәтләнгән бу аерым сюжетларын Л. Фәттахов белән Х. Якуповның зур полотносы (1972 ел) гомумиләштерә кебек: бу картинада Казанда Октябрь көннәренең һәм Совет власте урнаштыруның үзәк вакыйгалары яктыртыла.

Тарихи чынбарлык әсәрнең сюжет нигезе итеп алынган. 1917 елның 25 октябреннән 26 сына каршы төндә, Казанда кораллы пролетариат тарафыннан контрреволюцион көчләр тар-мар ителгәннән соң, элеккеге губернатор сарае бинасында уздырылган утырышта Петроградта Совет властен игълан итү турындагы телеграмма укыла.

Шанлы Октябрь вакыйгаларының бу кульминацион югарылыгы әлеге тарихи җыелышта катнашучыларның чиксез зур шатлыгы, рухи күтәренкелеге аша тасвир ителә. Кораллы восстание җитәкчеләре Николай Ершов, Мулланур Вахитов, Яков Шейнкман, Гирш Олькеницкий образларын, революцион халык вәкилләре — Идел флотилиясе матросларын, Казан заводлары эшчеләрен, шулай ук кызыл яулыклы кыз һәм татар карты образларын җанлы, тулы канлы һәм калку итеп күрсәтү картинаны тарихи чынбарлыкка якынайта һәм аның ышандыру көчен тагын да арттыра.

Әсәрдә төсләр күчешендә аеруча бөтен нечкәлеге, нәфислеге белән кызыл төс өстенлек итә. Бу исә Совет властен игълан итү тантанасына чын-чынлап революцион рух өсти.

Татарстан рәсем сәнгатенең ике зур остасы тарафыннан, шул рәвешчә, бинһая зур күренешне — халык массаларының куәтле чыгышын күрсәткән тарихи-революцион картина иҗат ителде. Картинада һәр аерым образ һәм типның үзгә-үзенчәлекле итеп бирелүе әсәрне бер бөтен итеп берләштерә, аның эмоциональ тәэсирен көчәйтә. Картинаның әлеге вакыйга үзәге булган бина стенасын бизәргә тиешле панно формасында булуы да югарыдагы фикергә тәңгәл килә.

Әйе, хәзерге вакытта ул ТАССР Министрлар Советы бинасында — нәкъ менә 70 ел элек шушы тарихи җыелыш узган йортта урнаштырылган. Бу картинаны караганда аның эмоциональ ялкыны, эпик көч-кодрәте сиңа да күчә һәм син үзеңне шушы онытылмас вакыйгаларның үзәгендә катнашкандай итеп тоясың.

**В. А. ЦОИ,**
ТАССР сынлы сәнгать
музееның фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның беренче битендә:** Л. Фәттахов белән Х. Якуповның «Казанда Совет власте урнаштыруны игълан итү» картинасы. Юрий Филимонов фоторепродукциясе.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казанда С. М. Киров һәйкәле.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотосы.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ
# (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)